
# казан утлары

9. 1992



**КАДЕРЛЕ УКУЧЫЛАР!**

Мөхтәрәм милләттәшләр!

Башка күп кенә газета-журналлар кебек, матди ярдәм алу өчен, без дә **Редакция фонды** оештырдык. Татарстанда, Россиядә, БДБ дәүләтләрендә, чит илләрдә яшәүче милләттәшләребезгә мөрәҗәгать итәбез. Безгә ярдәм итәргә теләүчеләр булса, хәл кадәри акчаларын түбәндәге адрес белән күчерә алалар:

**420066, г. Казань, ул. Декабристов, 1. Волжско-Камский акционерный банк РКЦ ГЦБ. Р/счет № 700161998/2345114 МФО 265005. Для Фонда Редакции.**

# КАЗАН УТЛАРЫ

АЙЛЫК ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

ОЕШТЫРУЧЫЛАРЫ:

ТАТАРСТАН ХӨКҮМӘТЕ, ТАТАРСТАН ЯЗУЧЫЛАР БЕРЛЕГЕ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА

**9**
(839)
**1992**

КАЗАН

## *Бу санда*

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР ҺӘМ ШИГЪРИЯТ

Ж. РӘХИМОВ. Батырша. *Роман.* . . . . . . . 3
РОБЕРТ ӘХМӘТҖАНОВ. Туу. *Шигырьләр.* . . . 49
Ә. ГАЛИЕВ. Авылдашлар. *Роман.* . . . . . . . 54
Р. ЗӘЙДУЛЛА. Кичектергән сәфәр. *Шигырьләр.* 127

НУРИ АРСЛАНОВНЫҢ ТУУЫНА 80 ЕЛ

РӘШИТ ӘХМӘТҖАНОВ. Кешеләрне яклап яшәде. . . . . . . . . . . . . . . . . 132
Н. АРСЛАНОВ. Тотыла. *Шигырьләр.* . . . . . . 133

ДРАМАТУРГИЯ

Т. МИҢНУЛЛИН. Илгизәр + Вера. *Драматик хикәя.* . . . . . . . . . . . . . . . . 138

«КАЗАН УТЛАРЫ»НА 70 ЕЛ

Котлаулар. . . . . . . . . . . . . . . . . 161
Гөрләп үтте безнең бәйрәмнәр (*Тантаналы кичәдән репортаж*). . . . . . . . . . . . . . 162

ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

Заман сулышын тоймасаң... (*Язучы һәм галим Альберт Яхин белән әңгәмә*). . . . . . . . . 177

ТАРИХЫБЫЗ БИТЛӘРЕННӘН

Ә. КӘРИМУЛЛИН. Гаяз Исхакыйның Шиһап Мәрҗани турындагы мәкаләсе уңаеннан. . . . . 182
Г. ИСХАКЫЙ. Шиһабетдин әл-Мәрҗани хәзрәтләре. . . . . . . . . . . . . . . . . . 184

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. . . . . . 189

*Баш мөхәррир*

**Равил Фәйзуллин**

*Редколлегия*

**Гариф Ахунов**

**Гүзәл Вәлиева-Сөләйманова**

**Тәлгат Галиуллин**

**Аяз Гыйләҗев**

**Салих Маннапов**

**Зиннур Мансуров**

**Ростәм Мингалимов**

**Фәрвәз Миңнуллин**

**Минтаһир Минһаҗев**

**Мөхәммәт Мәһдиев**

**Ринат Мөхәммәдиев**

**Рашат Низамиев**

*(баш мөхәррир урынбасары)*

**Индус Таһиров**

**Марс Шабаев**

*(җаваплы сәркатип)*

**Тәүфикъ Әйди**

**Марсель Әхмәтҗанов**

Безнең адрес: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2.

Телефоннар:
баш мөхәррир — 53-07-60,
баш мөхәррир урынбасары — 53-07-09,
җаваплы сәркатип — 53-36-12,

*бүлекләр:*

чәчмә әсәрләр, шигърият, очерк — 53-07-61,
тәнкыйть, фән, сәнгать, хатлар — 53-07-63,
корректорлар — 53-07-65.

## В НАШЕМ НОМЕРЕ

«Проза и поэзия»: окончание романа ДЖ. РАХИМОВА «Батырша», начало романа А. ГАЛИЕВА «Земляки»; стихи РОБЕРТА АХМЕТЗЯНОВА и Р. ЗАЙДУЛЛИНА.

«К 80-летию Нури Арсланова»: статья РАШИТА АХМЕТЗЯНОВА, стихи поэта.

«Драматургия»: драматический рассказ Т. МИННУЛЛИНА «Илгизар + Вера».

«70-летию журнала «Казан утлары»: поздравления, репортаж из торжественного вечера, посвященного юбилею журнала.

«Литературная критика»: интервью М. Валиева с писателем и ученым А. Яхиным о внедрении новой методики в преподавании татарской литературы.

«Из страниц истории»: статья А. КАРИМУЛЛИНА о публицистической деятельности Г. Исхаки; статья Г. ИСХАКИ «Шигабутдин Марджани».

Дневник общественно-политической жизни.

«На наших обложках»: картина художника Ахсана Фатхутдинова «Дух переулка»; лауреат премии Мусы Джалиля, поэт Ркаил Зайдуллин.

*Мөхәррирләр:* Мансур Вәлиев, Рәдиф Гатауллин, Шамил Маннапов, Кояш Тимбикова, Тәүфикъ Әйди, Рәшит Әхмәтҗанов.
*Техник мөхәррир:* Тәслимә Сибгатуллина.
*Корректорлар:* Гөәзада Моратова, Лилия Гатуллина.

Производствога бирелде 04.08.92 ел. Басарга кул куелды 09.09.92 ел. Офсет ысулы белән басылды. Кәгазь форматы 70×108 1/16. Учетн.-изд. табак 14,2. Басма табак 12 (16,8).
Тираж 23995. Заказ В-364. Бәясе 1 сум 80 тиен.

Татарстан газета һәм журналлар нәшрияты басмаханәсе.
Казан, Декабристлар урамы, 2.

© «Казан утлары», 1992 ел.

ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

**Җәмит Рәхимов**

# БАТЫРША

РОМАН

## Икенче кисәк

### Унынчы бүлек

Карышбашка ул Сөмбелә йолдызлыгының урталарында кайтып төште. Кайнарлыгы суынмаган иде. Ул бит, туган туфрагына аяк басуга, шәкертләренен һәм фикердәшләренең бер ишен Гәйнә-Уса якларына, икенчеләрен — Себер юлына, өченчеләрен — Чистай вә Казан тарафларына чыгарып җибәрмәкче, халаекларны дәррәү күтәрелергә чакырып, чаң сукмакчы! Мәгәр ниятен җиренә җиткерергә ашыкмады.

Суынып-сүрелеп, шикләнеп-шөбһәләнеп калуының сәбәбе — бөрҗәннәрнең артыннан куып җитеп тапшырылган хәбәрләре иде. Ие, Бөрҗән иләүе тулысынча купмады. Себер юлыныкылар исә бөтенләй атларга да менмәде, хәтта гомерлек гыйсьянчы саналган Юлай булып Юлай старшина кымшанмады. Өстәвенә, Оренбур ягыннан бихисап урыс пулклары килә икән, дигән сүзләр йөри. Чөй өстенә тукмак, дигәндәй, кичә генә соңгы төнгелегендә аны куып җиткән чапкын болачы башкортларның, йорт-җирләре белән, кыр казаклары ягына качып китүләрен әйтте. Димәк ки, ул ниятләгән, ул уйлаган дәррәү кузгалу барып чыкмады. Нишләргә? Мондый хәлдә Гәйнә татарларын күтәрергәме? Уй-исәпләре шулкадәр дә буталчык, авыр иде ки, Батырша тәмам чиргә сабышты, урынга ятты.

Шул чарасыз көннәренең берсендә капкасы төбенә дүрт сибайлы килеп туктады: «Узарга ярый тыргандыр бит»,— дигәннәре ишетелде.

Бу көннәрдә ялгызы бәргәләнеп, шулкадәр йончыган иде ки, тавышка җиңеләеп киткәндәй булды, миһманнарына каршы чыкты Батырша. Йөрәге сизенгән икән, килүче Гәйнә абызы Исхак мелла иде.

— Сөйләгел, Гәйнәдә ни хәл вә ни хәбәр?

— Хәлләр әүвәлгечә,— дип башлады Исхак, суза төшеп.— Халаеклар көтә-көтә көтек булдылар, мәгәр коралларын ташламадылар. Сән безгә өч-дүрт булса да кешеңне җибәр, хәзрәт, йорттагы мишәрләрнең инанмагы вә куәтләнмәге өчен. Гәйнәләр үзләренең ялгыз түгеллекләрен белсеннәр.

— Хөердер,— дип җаваплады Батырша.

---

Ахыры. Башы 7, 8 нче саннарда.

Шыгырдап ишек ачылды һәм бусагада Зөлхәбирә күренде. Ул әллә ире хафасыннан, әллә янарак кына өченче оланыннан котылганга, төмам суырылып, ябыгып калган иде.

— Сиңайтәм, табын әзер,— диде ул, гадәтенчә сабыр гына.

Табында кабат яу турында сүз чыкмады. Кунаклар самавырда пешкән йомырканы арыш ипие белән ныгытып, чәй эчеп алдылар да кайтыр юлларына кузгалдылар. Батырша исә үзе белән ерак юлдан кайткан Борһанны эзләп китте. Көтмәгәндә урамда Ибраһим атлы шәкертенә юлыкты. Ул егетне мәдрәсәнең тып-тын ихатасына алып керде һәм, як-ягына каранып алганнан соң, йомышын әйтте:

— Хәзер үк ат менеп ал да, Орыш ауылыннан Гәләкәйне, Миргасыйм карьясыннан Максудны вә Уразколны һәм дә Торнадан Йосыф мелланы алып килгел!

Өйләдән соң дәшелгәннәрнең дүртесе дә мәдрәсәдә иделәр инде. Мулла кунакларны һәм үзенең төп ярдәмчесенә әверелеп беткән Борһанны мәдрәсәнең караңгы һәм салкынча бүлмәсенә алып керде, озынозакка сузмый, нотыгын сүзләде:

— Сезне аның өчен өндәдем,— диде ул, Исхак абыз килеп-киткәннән бирле ныгып, көрәеп киткән тавышы белән.— Иң яхшы атларыгызга менеп, Гәйнәгә барыгыз!..

Егетләр аның чакыруын беравыздан кабул иттеләр:

— Динебез хакына җаныбыз фида улсын! — диделәр.

Алай да Йосыф мелланың үз фикере бар икән:

— Вәлинигъмәт, бәне Гәйнәгә җибәрмәгез, бәне Әй буена юллагыз, анда белешләрем күптер,— диде ул.

— Хәердер, бигрәк тә әйбәт!

Егетләрне өйләренә озатты да үзе урамга чыкты Батырша. Ул инде ябай халык белән очрашуны тансыклаган, алар белән сүзләшүне сагынган иде. Йортыннан ерак та түгел ихата киртәсенә таянып торучы ике адәмне күреп алды. Солтан Акбалтыр углы белән агасы Мостафа икән. Мулла килә-килешкә сүз катты:

— Ни сүзләшәсез?

Бераз дәшми торганнан соң, Солтан телгә килде:

— Гәйнә иләүе халкы атларга атланалар, бире таба киләләр дию күптән ишетәбез. Әгәр ул тарафлар килсә, безнең мишәрләребез дә һич икеләнми атларга менәрләр иде.

— Сабыр итегез, өметегезгә җитешерсез,— дип юатты аларны Батырша.

Ирләр шулай сөйләшеп торган арада, авыл башында ниндидер атлылар күренде. Кулларында сөңге, җилкәләрендә ян-садаклар. Кораллы бәндәләр күренүгә, Батырша тетрәнеп китте — халаекларның кузгалуы микәнни?!

Мәгәр аның өмете акланмады. Атлылар Карышбаш аша узучы арттагы авыллар булып, Бөрҗән башкортларына каршы пахут чыкканнар, имеш. Бу хакта аңа әлеге дә баягы Гәләкәй сөйләде. Батыршаны күрүгә, егет орышлылар төркеменнән аерылып чыкты да хәзрәтне бер читкә тартты, ашыга-кабалана тезәргә тотынды:

— Әй, хәзрәт, указ килгән. Нугай юллары кузгалганнар, ыстаршина Яныш камандасы, атларга менеп, анлар өстенә барсыннар! — дип. Әмма, хәзрәт, күңелегезне хуш тотыгыз, бәнем Гәйнәгә бармакымдан пахутка бармакым хубрактыр. Мөселманнар кузгалуга, бән үз кулым астындагы кешеләрне сезнең карамакка алып кайтырмын.

— Хәердер...

Батыршага яңа мәшәкать өстәлде: Гәйнәгә бару өчен янә ике кеше табарга кирәк иде. Ул Борһанны табып, аңа Мөслим старшина камандасыннан Әхмәрне, казанлы Исмәгыйльне алып килергә кушты. Батырша уенда күргән-ишеткәннәре яңарды, шуларның берсе, нарат шырпысы сыман, миенә төртелеп калды. Димәк ки, Яныш ыстаршина Бөрҗән

халаеклары өстенә пахут чыга. Бит ул вирнай ыстаршиналар да мөселманнар ләбаса! Күңелләрендә аз гына иман заты булса да, үз канкардәшләренә кылыч күтәрмәсләр. Тик үгетләргә кирәк үзләрен! Бүген Сөләйман старшина янына барып житешмәс инде анысы. Ә менә Яныш Чуртанлыкүлдә генә. Бүген үк кузгалмаган булса, өлгерә! Ул капкасына житкән жиреннән, кисәк борылып, ике чакрымдагы Чуртанлыкүлгә китеп барды...

Хәерлегә булсын, Яныш бүген яна туган сабыйдай аек, башына кәләпүш киеп, тирләп-пешеп чәй эчеп утыра иде. Мәгәр чырае чытык, хафа-хәсрәте йөзенә чыккан. Алай да мулланы ачык каршылады.

— Ни хәл вә ни хәбәр, Яныш агай?

Старшина указ килүен, анда ниләр язылганын сөйләп бирде.

— Әй, Яныш агай,— диде Батырша дустанә генә,— үзегезгә мәгълүмдер, жаһил урысларнын гайәтдән кичкән золымлыклары вә жәфалары сәбәбендән мөселманнарымыз төрле бәлаләргә тарып торалар. Мөселманнарымыз илә бергәләп, дин вә дөньямыз мәнфәгате хакына, ул хәсис вә гайәтдин кичкән залим вә жаһил каферләргә жавап бирик, аларның золымлыкларына каршы чыгыйк мәллә, дим?!

Яныш авыр сулап куйды, дәшми-тынмый гына чынаягындагы чәен эчеп бетерде һәм кунагы кебек үк — әйтерсең, гомерлек ахирәте — жылы һәм йомшак итеп сөйләп китте:

— Әй, вәлинигъмәт, барча хәлләр мәгълүмдер. Беләбез кем, залимнәрнең жәфалары хәлдән кичкәндер вә көннән-көн артадыр. Әле менә тагы йортларымызда аз бәһагә эшләнә торган дегет куллыкның күн ясау тыелып, халаекларыбызга балык мае сатып алырга боерылды. Бер-ике сум чыгарып жирдә ун-егерме сум тотарга калабыз. Әй, нигә сүләп торырга?! Карап тораек, кем алдыра төшсә, шул якка аварбыз.

Бу кадәр дә сансызлыктан каны кайнап чыкты Батыршаның, үзе дә сизмәстән тавышын күтәрде:

— Хак сүзне әйтмәк тиешледер, Яныш агай. Сәнең хәлең хәйләсе беткән, йоны житкән төлкегә охшаштыр. Артыннан эт басып житкәч, койрыкны гаh унга, гаh сулга салыр. Юк, сабыр гына утырып булмас, ыстаршина!

Ул эчелеп бетмәгән чынаягын этеп куйды, кисәк торып, урыныннан кузгалды, кайнарланып чыгып китте.

Иртәгесен башка старшиналар белән киңәшергә тиеш булса да, өлгерми калды Батырша. Мишәрләрнең байтагы, һәрвакыттагыча, бола кубарган халаеклар өстенә пахутка чыгып киткәннәр иде инде. Мулла, оясына ерткыч янаган ана кош мисалында, йорты белән мәдрәсәсе арасында туктаусыз йөренә-йөренә, Гәйнәдән хәбәр көтте. Әмма хатхәбәр күренмәде. Шик-шөбһә, борчылу-гасабилану эчендә сәгатьләр, көннәр үтте, ашкынулы уйлары ташкынында ялгызы шашынды Батырша.

Ихтилалның илһамчысы жибәргән дүрт кеше һәм аның яуга фатыйхасы Гәйнә тарафларының кәеф-халәтләрен үзгәртте дә куйды. Менә чаклы үзләренең уй-ниятләрен иң якыннарына да белдерергә шөбһәләнеп йөргән кешеләр, баштанаяк коралланган хәлдә, урам-мәйданнарга чыктылар, берсен-берсе тиз үк, менә бүген үк каферләр өстенә кузгалырга ярсыттылар.

Ул арада Гәйнә иләүенә яңа хәбәр таралды. Имеш, ясаклы татарлар урыс авылы Медянкидагы Шәвкун бакыр заводына һөжүм иткәннәр, имеш, Торговиж һәм Сокольск хәрби ныгытмаларын камаганнар, имеш, Быково авылы урыслары Ачит кальгасына качып китеп кенә котылганнар. Халык тәмам кызды, ярсыды, шашты.

Ниһаять, яу дәртеннән алгысыган татарлар түзмәделәр, волость үзәге Кызылъярга таба кузгалдылар. 28 август иртәсендә монда жыелган

жайдаклар, авылга гына сыешмыйча, ындырлар артына ук бүселеп чыкканнар иде. Һәркайсы сөйли, кычкыра, кулларын бутый. Хәер, игътибарлабрак тыңлаучыга аларның ни дәгъвалауларын, нәрсә таләп итүләрен аңлавы мөмкин иде. Әнә берсе — топ кебек тазасы, бөтен битен көрән сакал-мыек басканы шашып-тилереп кычкыра:

— Әй, халаек, бирән зәхмәтенә тарыган ыстаршина Абдул Хужагол углын тотып дөмектерергә кирәк! — ди.

— Ие шул, үзебезне йотканчы, җанын җәһәннәмгә олактырырга!

Йодрыкларын бутый-бутый акырышкан бәндәләр, ләгънәт-каргышларын онытып, базар мәйданындагы ике жайдакка текәлделәр. Ул да түгел, берсеннән икенчесенә күчә-күчә, авыл буйлап сүз китте:

— Акбаш батыр! Акбаш батыр!

— Тегесе — Мостай баһадир!

— Әйа, болар булгач, эш пешә!

Инде алты дистәне тутырып килүенә карамастан, яшьләрчә житез һәм чос Мостай исә бер төркем ирләргә ниндидер эш боерды. Тегеләре базар мәйданы артындагы бура янына ашыктылар. Гыйсьянчы татарлар башлыгы Мостай арбага менеп басты, беләгенә чукмар аскан уң кулын күтәрде — шау-шу тынып калды.

— Гәйнәләр! — дип кычкырды ул, карлыккан тавышы белән базар мәйданын күмеп.— Без бүген ялмавыз ыстаршина Абдук Хужагол углы белән аның ялганчы битекчесен хөкем итәбез. Ошбу ике сасык, бер сүздә булып, халаекларны талады, анларның канын эчте. Инсаннардан указ кушканнан артык ясак жыйды, шул акчага баеды... Житте!

Базар мәйданы өстендә күк күкрәгәндәй булды — йөзләрчә бугаз берьюлы дәһшәтле сүзне кабатлады:

— Үлем! Үлем!! Үлем!!!

Әмма Абдукны асарга иртәрәк иде әле. Халык, аны хөкем итәргә, дип, бердәм кычкырса да, мәйданның бер ягында аерым төркем аксакаллар үз сүзләрен әйтмәгәннәр иде әле. Мостафа арбадан төшеп, алар янына килде:

— Әйа, аксакаллар, сез нә дисез?

— Безнең сүз — ил сүзе булыр,— диде күрер күзгә аксакалларның барыннан да өлкәнрәк чал карт.— Халаекларны алдап, харам мал жыйган, динебезне, шәригать-йолаларыбызны санламаган адәм имгәгенә элмәк фарыз. Ил-жиргә гыйбрәт улсын! Амин.

Ул соңгы сүзен әйтеп бетергәндә, Мостай инде дар агачы янында иде. Ул, килә-килешкә, бая гына үзе басып нотык тоткан арбаны эләктереп алды һәм, аны жиңел генә сөйрәп, элмәк астына китереп куйды.

Хөкемгә гартылган старшинаны шуңа бастырдылар, муенына элмәк кидерделәр. Егетләр төркеме шаулашып, аның аягы астыннан арбаны тартып алуга, Абдулла Хужагол углы һавада асылып калды...

Ничә еллар буе үзен кан елаткан түрәләрдән үч алу ләззәте авылга жыелган халаекны гаярьләндереп, комарландырып жибәрде, яшьрәкләр, баш өсләрендә йодрыкларын, камчыларын болгый-болгый, кычкырышырга тотындылар:

— Акбаш батыр! Алып бар безне кальгалар өстенә!

— Усасын да, Көңгерен дә туздырып ташлаек!

— Дөрләсен бөтен Чулман буе!

Сүзгә бик үк оста булмаса да, Акбашка да арбага менеп басарга туры килде — халык гөжләүдән туктады.

— Ашыкмаек, егетләр,— дип башлады гыйсьянчылар башлыгы, сабыр гына.— Бар кадәр алайларны барлаек, башлыкларны жыеп сүләшәек. Тагы ике көннән, йәгъни ашлык сугу аеның берендә, Уса-Көңгер юнәлешендә кузгалырбыз. Жыелу урыны — Кызылъяр авылы, базар мәйданы.

Сентябрьнең берендә базар мәйданы иртә таңнан гөрләп тора иде

инде. Биш дистә чамасы егет, атларына менеп алганнар. Менә алай башлыгы да күренде, мәгәр ул егетләрне куандырмады.

— Бераз котәек, жыела төшсеннәр,— диде Акбаш һәм каядыр китте.

Яугир егетләр чарасызлыктан тел кашып, ярсыган йөрәкләрен басар өчен, усал сүзләр кычкырышып торган арада, авыл башында нииндидер атлылар күренде. Йөз иллеләп жайдак! Кулларында кылыч-сөнге, иңнәрендә — ян-садаклар. Чырайлары нурсыз вә ачулы иде. Житмәсә, башлыклары — базык гәүдәле ир уртасы кеше, мондагылар янына килеп житүгә, дәһшәтле боерды:

— Коралларыгызны ташлагыз да өйләрегезгә таралыгыз!

Болачылар аның сүзен уенга алдылар. Ник дигәндә, алар инде яна алай башлыгын танып өлгергәннәр иде. Күршедәге Барды иләве старшинасы Туктамыш Ишбулат углы! Ул бит моннан атна элек кенә, болачыларның Тулва тугаендагы жыенында, Гәйнә иләве старшинасы Абдул Хужагол углын үлтерергә кирәк дип, халыкны үзе ук котырткан иде. Нишләп әле бүген үзенең кан дошманы Абдукны аскан егетләргә мондыен көфер сүз сүзли?

Туктамыш старшина, болачы егетләргә өстән генә мыскыллы карап-карап торды да, янә үкереп жибәрде:

— Йә, ни дип каттыгыз?! Марш, марш өйләрегезгә!

Егетләр инде аның уйнап сөйләмәвенә төшенделәр. Мәгәр бу бәндәнең кинәт үзгәрү сәбәбен аңламадылар. Кая ул, әлеге кызу көннәрдә икейөзле һәм мәкерле адәмнең эчендәге этлекләрен аңышу!

Базар мәйданындагы хәлне житкергәннәр күрәсен — атын камчылап Акбаш килеп житте, ярсу айгыры Туктамышныкы өстенә менә язып, тыелып калды.

— Сән нишлисен, ыстаршина?! — дип үкерде ул, уйнаклаган атын бер урында тота алмыйча.— Кит, хәзер үк югал күз алдыннан!

Ул зыңгылдатып кынысыннан кылычын тартып чыгарды, аны башы өстенә күтәрде. Шул мәлдә нидер сызгыргандай булды — Акбашның киң күкрәгенә тал саплы ук килеп кадалды. Алай башы гажәпсенеп, як-ягына каранды, аннан кисәк чайкалды һәм гөрселдәп жиргә барып төште. Аны яклап кылычларын алган тагы биш-алты егетнен дә гомерләре шулай ук уктан киселде. Болачыларның калганнары, кинәт хәрәкәткә килеп, авылдан читкә ташландылар. Мостай аларны Кызылъярдан ике чакрымда гына куып житте.

— Тукта, туктагыз! Кая барасыз?!

Егетләр әле кая баруларын да, ни кылачакларын да белмиләр иде. Мостайны күреп, исләренә килделәр. Мостай исә тыныч кына әйтеп салды:

— Хаклык сездәдер, мөгаен. Туктамышныкылар шактый ишле күренә, булган көч белән генә кыйрата алмабыздыр үзләрен... Ярый, әйдәгез Карышбашка, Батырша хәзрәт катына. Нишләргә кирәклеген ул әйтер!

Гәйнәгә дип юл чыккан егетләр киттеләр дә, суга төшкәндәй, юк булдылар. Бер көн котте аларны Батырша, ике көн көтте, үзе читлектәге жәнлектәй йөренде. Гажизлектән аптырагач, Яхъяга юлга жыенырга, Гәйнә хәлләрен белеп кайтырга кушты. Янә ике көн узды. Ниһаять, капкасы төбендә таныш түгел жәяүле пәйда булды. Әлеге бәндә сәлам бирмәде, телсез кеше сыман шым гына билендәге калтасыннан язу чыгарды.

— Бу мәктүп кемнән вә сән кемсең? — дип сорады мулла, теткәләнеп беткән хатны кулына алып.

Сәер юлчы шунда гына телгә килде һәм серле генә сөйләп китте:

— Әй, хәзрәт, бәнем кем идекүм вә бу язу кемдән идүке сәңа хажәт дәгүл. Бу язу эчендә әгъләм ителгәнне үзеңә хажәт эшкә жәһәтлән. Вә ләкин бу дустлык мәктүбе Борай жәмәгатеннән дәю белгел.

Борай якларыннан, димәк ки, дусты Сөләйман старшинадан. Мулла

язуга бакты, шуннан файдаланып, юлаучы юкка чыкты. Мәгәр Батырша инде аңа игътибар итеп тормады, ул бөтен барлыгы белән хат эченә кереп чумган иде. «Имам-әл-мөселман мөллә Баһадиршаһ хәзрәтләренә әгъләмдер,— дип укыды ул, иреннәрен кыймылдата-кыймылдата.— Сән ислам дине хакында һиммәт итеп, Гәйнәгә дүрт кеше җибәргәнекеңне динебезне дошманнары — монафикълар аңлап, ул дүрт кешенең артыннан тәкърар-тәкърар күп кешеләр җибәргәннәр. Анларны тоту өчен вә халаекларны алдаулар, куркытулар берлә күңелләрене чүктерер өчен. Әмма Гәйнә халаекларының ярымы атларга атланганнар иде. Шул хәлдә ул монафикъларның кешеләре барып, вурлар тотарга килдек, халаекларда андый вурлыкка һич киңәш юктыр дип, кешеләр өстенә кешеләр тәкърар-тәкърар барып, халаекларның күңелләрен чүктереп, бәндәләр ике яры бүленгәннәр һәм кешеләр дә үтерелгән. Тагы ни хәлләр булырын ходай белсен, кашки, халаекларны куәтләндерү өчен күп кешеләр җибәрегезче, дәхи үз хозурыңда кешеләр алып торган булсаңызчы?! Ул динсез монафикълар ошбу төндә үзеңезне һәлак итмәк кәсдендә торалар. Бик тизлек вә һәм саклык берлә башыңызны коткаруга җәһәтләнегез!»

Хат уйланырлык иде. Батырша, кайнап-кайнарланып, Борһанны эзләп китте, Карышбашта булган кадәр бәндәләрне җыярга кушты.

Үзе исә өенә ашыкты. Кайтып керүенә, чоландагы җәясен, садагы белән укларын барлады, яу купканнан бирле беренче мәртәбә остазбикәсе белән ачыктан-ачык сөйләшергә булды. Зөлхәбирәне ак якка чакырып кертте. Анысы ике айлык кызы Зәнваны, имчәгеннән аермый гына, түшен каплый-каплый килеп керде:

— Ни бар, атасы?

Батырша хатыны каршына килде, бер кулы белән йомшак кына сабыйны тотты, икенчесен Зөлхәбирәнең аркасына салды һәм сагышлы сүз башлады:

— Әй, җәмәгатьләрем, күземнең нурлары, күңелем сөрурлары, хәлләребез мөшкелдер, үземне һәм дә сезне саклый алмадым. Бүген төндә йортыбызны монафикълар камап алуы, орыш булуы ихтимал. Бәңа исә качып китәргә туры килмәгәе. Остазбикә, нә кылгайсың? Йортта каласыңмы, әллә бәнем берлә китәсеңме? Яисә берәр шәкертем берлә Урал аръягына, туган төбәгеңә озатыйммы?!

Зөлхәбирә бәләкәчен күкрәгенә кыса төште:

— Ни күрсәк тә, бергә, хәзрәт!..

Батырша соңгы төнен хатыны вә балалары белән үткәрмәкче итте. Аларны юлга әзерләде, ризыклар, кирәк-яраклар төенләште. Тәрәзәләргә сыек яктылык сирпелүгә, урамнан тавышлар ишетелгәндәй булды. Батырша кабаланып урыныннан төште, тәрәзә буена килде. Нәкъ аның йорты каршында кораллы җайдаклар йөренә иде. Ул, тын алырга да шикләнеп, баскан урынында катып калды. Кемнәр вә күпме кеше булыр? Тик болай торып урамдагыларның кемнәр икәнен дә, саннарын да белеп булмый иде. Кем белә, алар бәлки мәдрәсә артлап, Карыш суы буеннан да камаганнардыр. Шунысы хак, бу кадәр атлыларның таң тишегеннән йортын урап алулары тикмәгә түгел.

Батырша алдагы якка чыкты, бала кочаклап яткан Зөлхәбирәгә эндәште:

— Җыен, остазбикә! Балаларны киендер дә, мәдрәсәгә килерсез. Бән анда булам.

Ул ук-җәясен алып, мәдрәсәгә килгәндә, егетләр инде бар да аякта, ни кылырга белми аптырашып торалар иде. Хәзрәтне күрүгә, аңа ташландылар:

— Әйа, хәзрәт, һәр тарафтан камап алганнар. Йөз илле чамасы булырлар. Ни кылаек, нишләек?

— Йә, ярар, бөтенләй үк хәвефкә төшмәгез. Ходайга тәвәккәл итеп, авылдан чыгып карарбыз.

Нәние Зәнваны күкрәгенә кысып, Таҗик белән Зөләйханы җитәкләп,

остазбикә килеп житте. Егетләр дә атларын житәкләп килделәр.

Капкага житәрәк, барысы да коралларын орыш хәленә китерделәр. Ләкин сугышырга туры килмәде — урамдагылар, аларга карап, тын гына кымшанмый торалар иде.

Бу яктагы йортларга сыена төшеп, авыл башына таба киттеләр. Дошман як һаман да шулай тораташ сыман хәрәкәтсез. Борчулы киеренкелек эчендә дүрт-биш йорт арасы үтүгә, алда Янышның давыл яллы аты күренде. Старшина, юлны кисәргә ниятли иде булса кирәк, айгырын урамга аркылы атлата. Батырша төркеме якынлашуга, ул кынысыннан кылычын тартып алды, гайрәтләнеп кычкырды:

— Әй, хәзрәт, кан койма, орышсыз гына бирел!

Батырша садагыннан ук алды, аны жәясенә иплән, керешен тартты. Яныш исә, атын кисәк борып, кораллы егетләре артына кереп посты, шуннан сүгенә-сүгенә жикеренгәне ишетелде:

— Анагызның... карап каттыгызмы?! Атыгыз, ат!

Егетләре исә кымшанмадылар. Шуннан файдаланып, Батырша күн итеге үкчәсе белән атының корсагына тибеп алды — чаптырып китте. Төркеме аңардан калмады. Ике дистә чамасы жайдактан торган алай авылдан алты чакрымдагы урманга таба юртып китте.

Карышбаш тынып калды. Ул төнге вакыйгалардан айнып житмәгән иде әле. Кешеләр исләренә килергә өлгермәделәр, кыр капкада янә атлылар төркеме күренде. Жайдаклар, ак күбеккә баткан атларын чаптырып, урам буйлап үттеләр дә, туп-туры Батырша мулла капкасына килеп туктадылар. Төркем алдында килгәне, ияреннән атылып төште дә, капкадан эчкә узды. Гажәп, ишекләр ачык, өйнең асты-өскә килгән, жан әсәре күренми. Мостай ишегалдында аптырап йөргән арада, гәйнәләр янына Солтан Акбалтыр углы килде. Сәлам бирмәде, авыр көрсенеп әйтеп куйды:

— Соңардыгыз шул, соңардыгыз!

Әйе, соңардылар гәйнәләр. Әгәр Карышбашка һич югы иртә таңнан килеп житсәләр икән, хәлләр бөтенләй башкага әйләнер, Гәйнә илен ялкын урар, ул гына да түгел, бөтен Чулман буен, Чистай, Казан якларын ут алган булыр иде!

## Унберенче бүлек

Ниһаять, батыршаныкылар урман авызына життеләр. Аерым булып алгарак чыгып торган карт каен күләгәсенә кергәч, Батырша кайнарланган атын туктатты, әле генә узган юлларына күз салды. Анысы тыныч һәм аулак иде. Мулла канәгатьлек белән битендәге тирен сөртеп алды, йөзенә елмаю чыкты:

— Шөкер, оланнар, котылдык бит мөртәтләрдән.

Туктаудан файдаланып, карашы белән юлдашларын барлап чыкты. Азайганнар бугай. Әле Карышбаштан чыкканда гына төркемдә ике дистәләп атлы бар дип чамалаган иде, хәзер жәмгысы — дистә ярым. Димәк, башкалары ычкынган. Болары да ташлап китсә?! Батырша, үткер күзләре белән яудашларының һәркайсы йөзенә бага-бага, аларны кабат тикшерде. Юк, качмаслар! Монда — аның иң якын шәкертләре, көрәштәшләре. Менә үзенең якташлары — Себер юлы мишәрләре Максут Аксин һәм Уразгол Исламов, Казан ягы ясаклы татары чая Исмәгыйль Алкин, аның якташы — Мөслим Ибраһимов. Әнә мишәр егетләре Миррәхмәт Акъсәетов белән Ибрай Тимергазин, Көнгер өязе татары Дәүләтбай Кәжәголов. Башкорт егетләре Көчекбай Иманколов, Нури Басканов, Чурагол Миңлебаев. Жәмгысы — ун татар, биш башкорт. Алар берсеннән-берсе таза, берсеннән-берсе гаярь. Аннан да мөһиме — тугрылар. Алай да шатланасы урында көрсенде Батырша — арада аның үз улы булып беткән фикердәше Яхъя юк иде.

Инде борылып, урманга кереп китәргә торганда, дала түрендә ялгыз җайдак пәйда булды. Ул юлсыз-нисез җирдән, кылганнары котырып утырган тау битләвеннән мондагыларга таба томырыла иде. Батырша җәясенә үрелде һәм шул мизгелдә атлыны танып алды. Чаптарын ак күбеккә төшереп, мулла артыннан ашыгучы бу бәндә — Яхъя иде.

Күп тә үтмәделәр, юкә кисендеге лапылдыгына килеп керделәр. Ял итү өчен урынның моннан да кулаен, махсус эзләсәң дә, тапмассың. Батырша туктады, атыннан төште һәм ян-җәясен кара-кучкылланып утырган юкә үрентеләре төбенә ташлады.

— Йөгез, ял итеп алаек, оланнар!

Мәрткә киткәндәй күпме йоклаганнардыр, якында гына ир-атлар сөйләшкән тавышка уянып китте Батырша. Елан чаккандай өтәләнеп аягына басты, яшь юкә ботакларын кулы белән аралап, урман авызындагы ачыклыкка күз салды. Йөздән артыграк булыр җайдак бер тегеләйгә, бер болайга узгалап, нидер эзли, ул да түгел, кабат бер урынга җыелып, нидер киңәшә. Сизелә: урманны тарарга җыеналар болар.

Батырша шулай күзәтеп торган арада, егетләр дә уяндылар. Мулла янына башлап Яхъя белән Казан яклы Исмәгыйль килеп житте:

— Нәрсә бар, хәзрәт?

— Янышныкылар, ахры — безне эзлиләр,— дип җаваплады Батырша.— Вә ләкин ыстаршина үзе күренми, хәсис...

Эзәрлекләүчеләр аларны авылда ук камап алганнар иде бит. Мәгәр өсләренә ташланырга ашыкмадылар. Мәдрәсә капкасыннан чыгып, басу ягына китүләрен карап-күреп тордылар, ләкин ук атмадылар. Хәтта кем сасык җан Яныш әмереннән соң да урыннарыннан кымшанучы булмады. Аңлашыла ки, әлеге кораллы мишәрләрдә Батыршага карата яманлык нияте юк.

Бу хәлдән файдаланырга, кан коймый гына арынырга кирәк. Үзе яннарына барса, мәчеттәгечә вәгазь-нотык сөйләсә, аны аңларлар, хәерхаһлык күрсәтерләр, бәлки. Ие, ие, үгет-нәсихәт ясарга мөселманнарга! Ул инде әнә шул карарына килеп, урынынннан ук кузгалган иде. Кисәк туктап, кире борылды, җирдә яткан янын, садагын алды, егетләргә эндәште:

— Мелла кем Яхъя, һәм дә син Исмагул, бәнем берлә барамсыз?!

Ике егет ияртеп, урман ешлыгыннан чыгып килүче Батыршаны күргәч, җайдаклар тып-тын калдылар. Ян-җәясенә, янсә кылычына үрелүче түгел, кыймылдаучы да юк — бар да тораташ булып каткан. Аптырау вә гаҗизлектә калган атлыларга килә-килешкә кычкырды мулла:

— Әйа, мөэмин-мөселманнар!..

Мәгәр дәвам итә алмады, сүзен кабәхәт җикеренү авазы күмде:

— Ни дип каттыгыз?! Атыгыз, чабыгыз шул уйнаштан туганны!

Тавышына караганда — Хәйбуш сотник. Әнә үзе дә күренде. Кипкән кабыктай чандыр Хәйбуш, төркемдәгеләрне этә-ега, алга чыкты, кулындагы мылтыгын гыйсьянчы муллага төбәде. Тагы бер мизгел генә тоткарлансан да, соң булачак иде. Батырша җәя керешен тартты, төзәминитми атып җибәрде. Сотник кинәт чайкалып куйды, кулындагы мылтыгын төшереп җибәрде һәм шуның артыннан үзе дә җиргә егылды.

Бу хәл төркемдәгеләрне айнытып җибәрде, әмма коралга тотынучы булмады. Арадан кайсыдыр:

— Хәзрәт, безне атма! — дип ялварды.— Сеңа яманлыгыбыз юктыр!

— Хәердер. Өйләрегезгә кайтыгыз, мөселманнар.

Эзәрлекләүчеләр белән очрашу болачылар өчен хәерле тәмамланды. Алай да тагы да монда калу турында сүзнең булуы мөмкин түгел. Лапылык баскан караңгы бер чокырга житкәч, туктадылар, ботак-сатакны кылычлары белән турап, куышлар ясадылар, аларның эченә үлән һәм яфрак түшәделәр.

Тәүге көннәрендә үк атларның берсен суярга туры килде. Тамак тук, урын-җир көйле. Өстәвенә, тирә-юньдә әбиләр чуагы тантана итә. Вафа-

сыз иркенлек һәм хорлек егетләрне алдый, юата иде. Бер Батырша гына, иреннәрен чәйни-чәйни, туктаусыз уйлана, алдагы көннәрен күз алдына китерергә тырыша. Күр, әнә атна да үтмәде, инде ике атны суеп ашарга туры килде. Ризык хәстәрен хәзердән, кар төшкәнче күрергә кирәк!

«Сунарга» әүвәл, шушы төбәк кешеләре азык-төлекне тизрәк табарлар дип, Максут белән Уразголны озаттылар. Ләкин тегеләре шул китүдән, суга төшкәндәй, юк булдылар. Әллә карат әтрәтенә барып каптылар, әллә... Юк, качтылар, дип уйларга берәү дә җөрьәт итмәде. Дошман кулына төшүләре хактыр. Шуна инанган хәлдә икенче парны — башкорт егетләре Сәфәр белән Чураголны юлга әзерләде хәзрәт.

Бер көн көттеләр егетләрне, ике көн көттеләр. Әмма «сунарчылар»ның болары да хәбәрсез югалды. Шул хафага төшеп уздырган төннең таңында качаклар станында хыянәт мәгълүм булды — ясаклы татар Акчура аты, коралы-ние белән качып китте.

Монысы инде һич көтелмәгән вә башка сыймас бер хәл иде. Батырша чираттагы күзәтүеннән әйләнеп кайтканда, үзләренең станнары кырында ук, өч кеше басып торганны күреп алды. Алар, качакларның куышларына төртеп күрсәтә-күрсәтә, үзара нидер сөйләшәләр иде. Әйа, эзәрлекләүчеләргә күптән мәгълүм икәннәр ләбаса! Батырша тегеләрнен кире киткәннәрен көтте, аннан ашыгып торлакка кайтты, егетләрен күтәрде. Юлга, фәкать юлга!

Бер көнлек җир китеп, Чирмеш урманына керделәр. Монысы инде Карышбашның үтәдән-үтә күренә торган вак-төяк агачлыклары түгел, чын мәгънәсендә карурман. Ул Чулман иделе буйлап ерак-еракларга сузыла — бер кереп адашсаң, исән-сау чыгармын димә. Кая карама, анда чирмешләр утын-бүрәнә кисеп яталар.

Аулаграк җир эзләп йөри торгач, сазламак уртасындагы калкулыкка, куе нараттыкка урнаштылар. Инде төннәр сизелеп суытты — аннан-моннан гына корыштырган куышларда тереклек итешле түгел. Тик качак башы тагы кая барсын да, ни эзләсен?! Соңгы өчлары һәм куллары белән чокырлар казып, өсләрен ботак-сатак белән томаладылар.

Мәгәр котелгән иминлек килмәде. Утынчы чирмешләр әллә юри, әллә ялгышып, биш-ун кешелек төркемнәр булып, әле аннан, әле моннан стан янына килеп чыга торалар.

Шулай беркөнне, Батырша нарат төбендә үзләренең язмышлары хакында уйланып утырганда, торлакта чит-ят кешеләр пәйда булды.

Батырша янәшәсендә яткан ян-җәясенә үрелде, чакырылмаган кунакларга каршы күтәрелде.

— Нә йомыш, знакумнар?! — диде ул, сүс сыман сакалы кендегенә җиткән, бераз бөкре картка карап.

Тегесе чал мыегын сыпырып алды, кызарган күзләрен сөрткәләде, дустанә тавыш белән сүз катты:

— Сеснс пик күп кораллы кешеләр эслиләр — ераккарак китегез! — диде ул. — Каптырырлар, тәки катыр җиппәрерләр үсегесне...

Алар үз телләрендә нидер сөйләшә-сөйләшә китеп бардылар. Мулланың фикере яктырып куйды, баядан бирле янында уралган Яхъяга эндәште:

— Җыеныгыз, күчәбез!

Көнярымлык юл китеп, очсыз-кырыйсыз урманның икенче бер төбәгенә төштеләр. Яңа урында да шул ук хафа, шул ук уй. Кешеләргә җылы урын, ризык кирәк.

Күпме баш ватсаң да, егетләрне азык эзләргә җибәрүдән башка чара юк иде. Калган ике атта дүрт егет «сунарга» китеп барды. Батырша дүрт юлдашы, хатыны, өч баласы белән торып калды.

«Сунарчылар» исә иртән дә күренмәделәр. Ачлыкка үзе түзә иде әле Батырша. Ә менә балаларның өзгәләнүләренә чыдар чама юк. Чарасызлыктан гаҗизләнгән мулла җәясен-угын алып, урман арасына кереп китте. Берәр киек атып булмасмы дип, ярты көн йөрде, мәгәр күзгә

урман, киек-җәнлекләре кырылып беткәндәй, тын вә аулак иде — утынчы чирмешләрдән качып бетканнәр бугай.

Башын салып кайтып килгәндә, кечерәк бер аланда поши күреп алды. Җәясенә ук элде, керешен тартты. Инде атам дигәндә, аландагы җанварның тышаулы ат икәнен шәйләп алды, җәясе үзеннән-үзе җиргә төште.

Ул кыйналган-изелгән хәлдә куышына кайтып егылды, күзләрен йомды. Әмма тынгылык тапмады: нәни Зәнва туктаусыз елый, өч яшьлек Зөләйха, әледән-әле шыншып, ашарга сорый, җиденче яшенә чыккан Таҗик та өзлексез анасын йөдәтә.

Бу хәлдә ата йөрәге ничек түзсен?! Батырша ашкынып куышыннан чыкты. Яхъяны иярттеп, теге аланга таба китте. Бәхетләренә, ат һаман да шул урында кырау суккан үлән сабаклары чемченеп тора иде. Тышавын чиштеләр дә, атны җитәкләп станга таба алып киттеләр.

Икенче көнне төш вакытында аларны ике дистәгә якын чирмеш урап алды. Кулларындагы чукмар-күсәк, балта-сөңге булуына караганда, ниятләре изгедән түгел. Башлыклары әлеге дә баягы бөкре чирмеш карты. Тик ул теге көндәгедән нык үзгәргән — кызгылт күзләрендә хәтәр очкыннар.

— Пес сесне,— дип башлады ул, кыю гына,— пер айдан пирле урманыпызда асрыйбыз, сесгә һич яманлык итмәенчә һәм дошманыгыска мәгълүм итмәенчә. Ахыр сес песгә яманлык иттегес, атымысны суйдыгыс. Инде куркамыс, үсемесне үлтерерсес, дип. Кораллларыгысны пирегез, үсегез китегес!

Рәнҗүле булсалар да, бәгырьләре катмаган икән — чирмешләр борылып киттеләр. Әмма инде качакларга да монда калу мөмкин түгел иде. Булган кадәр әйберләрен төенләделәр дә кузгалдылар.

Үлән баскан сизелер-сизелмәс урман юлыннан ике чакрым чамасы үттеләр. Батырша инде кулайрак урынга туктап, төн уздыру хакында уйланып бара иде. Кинәт артта Зөлхәбирәнең җан ачысы белән кычкырганы ишетелде:

— Сиңайтәм!

Борылып карауга, шаккатты мулла. Урман юлында ниндидер җайдаклар айкала, кемнәрдер кычкырыша, балалар чырылдый. Башта ул, ук атмакчы булып, җәясен күтәрде. Әмма бу эшнең мәгънәсезлеген абайлап, янын җиргә атты, үзе гаиләсе ягына ыргылды. Яхъя исә сөңгесен кулыннан ычкындырмады, өстәвенә мулланы иңеннән тотып алды:

— Чү, хәзрәт, кызма! Аларны коткару мөмкин түгелдер. Үзең генә харап булырсың. Күрәсең ич, атлыларның исәбе юк.

Батырша баскан урынында катып калды, ике күзе төбендә дә энже бөртеге булып яшь күренде, калтыранган иреннәре арасыннан йөрәгенең ярасы саркып чыкты:

— Җәмәгатьләрем, күземнең нурлары! Сезне һәм үземне яраткан бер ходаема тапшырдым, бәхил булыгыз!

Яхъя исә, җан талашып, аны агачлар арасына сөйри иде:

— Әйа, хәзрәт, соңарабыз!

Чыннан да, җайдаклар инде аларга борылганнар, атларын камчылап, урман юлыннан киләләр иде. Остаз белән шәкерт урман ешлыгына кереп югалдылар.

Өркетелгән боланнардай, ярсып-шашынып төнката күпме юл үткәннәрдер, яктырып килгәндә, бер чишмәгә тап булдылар. Туктап ял итәитә, озаклап салкын су эчтеләр һәм чишмә башындагы зирекләр төбенә утырдылар. Шунда, ничек туры килсә, шулай йоклап киткәннәр. Ниндидер тавышка сискәнеп, икесе берьюлы уянганда, дөнья ап-ак — тын гына утырып тәүге кар ява иде. Искәрмәстән бер-беренә карадылар, икесе бертавыштан кычкырып җибәрделәр:

— Әйа, нә кылаек!

Нишләргә белми, зар-интизар булып утыра торгач, Батыршаның

чырае яктырып китте, колагына остазы Габделрахманның сүзләре ишетелгәндәй булды: «Башыңа бәла-каза төшсә, үземә килеп егыл!»

— Әй, мелла Яхъя, кузгал, китәбез,— диде ул, аягына калкып.— Казан юлына — Тайсуганга. Остазым Габделрахман ярдәменнән ташламас!

Шулаен шулай да, тик кай тарафта соң ул Тайсуган? Карурманда атна чамасы уралдылар. Ачлыктан хәлсезләнеп, нәүрүз бүресе мисалына җиткән бу ике бәндәгә егылып үлүдән башка чара калмаган иде. Һич көтмәгәндә, шактый киң урман юлына килеп чыктылар. Яңа яуган карны арба тәгәрмәчләре ергалаган. Димәк, моннан кемнәрдер йөри, димәк, якын-тирәдә авыл бар!

Әҗәлләре җитмәгән икән әле — юл аларны бәләкәй генә татар авылына алып төште. Ярлы гына агайның җылы өе, таралып пешкән тары боткасы алар өчен фәрештә канаты булды.

Качаклар юл сораша-сораша, бер унайдан хәер эсти-эсти, Нәдергә килеп чыкканда, дөньяда инде кыш иде. Туңудан тешләре-тешкә тисә дә, Тайсуганга якты күздә керергә базмадылар, кайсысыныңдыр ындырында, саламга чумып, караңгы төшкәнне көттеләр.

Габделрахман аларны ачык каршылады, мәгәр чыраенда һәм үз-үзен тотышында ниндидер шик-өркү сизелеп тора иде. Табынны мулдан әзерләтте, әмма хатын-кызларга урам як тәрәзәләрне томаларга кушты. Аннан инде кунакларны өстәл янына утыртты һәм, алар сүз башлаганны да көтми, әйтеп куйды:

— Бән сәнең хәлләреңне беләмен.— Әй, Баһадиршаһ,— дип өзгәләнде Габделрахман, кашыгын кулына алып,— инде өч-дүрт тапкыр пыр туздырдылар мәдрәсәне. Һәр шәкерттән пашпурт таптыралар, ата-бабасы хакында төпченәләр. Монда сыгынсагыз, үзегез дә кабарсыз, бәне дә хур иткәйсез. Йәгез, аштан үрелегез!.

Сөйләшми генә шулпага ябырылдылар. Батырша, үпкәләгән баладай, дәшми-тынмый ашавында булды. Тик ни дисең инде монда? Бәлки, чыннан да, хәл шулайрактыр. Хак, Тайсуган олы юлдан ерак түгел, узып-китеп йөрүче өзелмидер. Димәк, аулаграк авыллар ягына авышырга кала. Андый тыныч җир исә Шушма суы буенда гына.

Уйларын Габделрахман бүлде:

— Ачуланма, Баһадиршаһ, һич кенә дә сыендыра алмыйм. Мунчада йоклап чыгыгыз да, иртүк кузгалырсыз, боерган булса. Анасы, мосафирларга ипи, җылы киемнәр әзерлә!

Итле токмач тансыклаткан иде. Алай да ашы-аш булмады Батыршаның. Бар дөньяга рәнҗеп, теләр-теләмәс кенә тамагын туйдырды да, Яхъяны ияртеп, мунчага китте.

Алар йокыларыннан торып, Зәй буе әрәмәсенә төшкәндә, көн әле яктырмаган иде. Елгага җитәрәк, Батырша туктады һәм кайчандыр үзе кинәнеп печән чапкан аланнарга карап, уйга калды. Колагына Тутыяның көмеш тавышы ишетелгәндәй булды — дөнья яктырып китте. Әмма рәхәт мизгел күз ачып-йомганчы юкка чыкты, каршына мең сораулы карлы юл килеп басты.

— Йә, мелла Яхъя, нә кылаек?

Тегесе уянып киткәндәй булды, беренче кар күренгәннән бирле уйлап йөргәннәрен сыгып чыгарды:

— Әй, хәзрәт, алланың язмышыдыр имди. Әнә теге таллыкка керәек тә, кар өстенә ятып, ачлыктан вә суыктан туңып үләек!

— Юк,— диде мулла, кискен генә,— үземезне-үземез үлтермәк — шәригатебезгә хәрәмдер. Терек җанда өмид бар, диләр. Хак тәгаләнең рәхмәтенә өмид әзмәек.

Сүзен әйтеп бетерде дә, кисәк борылып, тар сукмактан Зәйгә таба төшеп китте Батырша. Адымнарының ныклы һәм ышанычлы булуына карагандa, ул инде нәрсәдер ният иткән иде.

Ниһаять, Сагышлы суының Шушма елгасына кушылган җирендә

утырган Нәдер старшинаның иске авылына килеп чыктылар. Билгеле, аларны монда да һичкем көтми иде. Шунысы өметле — Иске Нәдер олы юллардан читтә. Батырша туктады һәм ничә көннәрдән соң беренче тапкыр көр итеп әйтеп куйды:

— Шушында тупланәбез, мелла Яхъя!

Шәкерте сагышлы күзләрен аңа төбәде, гаҗизлеге ярылып яткан сүзен авызыннан сыгып чыгарды:

— Өйләре бик бәләкәй күренәләр, хәзрәт, фатир төшермәсләр.

Батырша кулын алга — Шушма ярындагы үрдә ялгызы моңаеп утырган манарасыз мәчеткә таба сузды:

— Безнең фатир анау алла йорты булыр, мелла Яхъя!

Кич булганчы агачлар арасында таптандылар да, күз бәйләнүгә кыю атлап авылга таба киттеләр. Мәгәр урамга кермәделәр, ындыр артлап мәчеткә уздылар. Бәхетләренә, мәчет чоланының ишеге бикле түгел иде. Аны ачып, эчкә үттеләр, караңгыда кармаланып, идәнен ачтылар һәм, аллы-артлы сикерешеп, базга төштеләр. Бүгеннән, менә шушы мизгелдән, аларның йорты да, гаиләләре дә, мәгыйшәт иткән дөньялары да — ошбу караңгы баз иде.

## Уникенче бүлек

Гөнаһына кереп булмый, посып калу дигәнең, Янышның гамәлендә түгел, ниятендә дә юк иде. Барына да шул махмыр шаукымы сәбәп булды. Исәбе — этрәтне Хәйбуш сотник карамагында Карышбаштан чыгарып җибәрергә дә, бер-бер аулак почмакка сугылып, ияре бавындагы күн капчыкта чупылдап, күптән күңелен кытыклап йөргән хәмерне шәпләп авыз итмәк вә егетләрен куып җитмәк иде. Әллә инде төнне йокысыз үткәрү галәмәте, әллә кичен, Карышбашка кузгалыр алдыннан, шул шайтан суын күбрәк җибәргән — Яныш мәлҗеп төште.

Ул уянганда, кояш кыйбла як тәрәзәсенең карындыгын алсуга манган иде инде. Ул үзенең озак йоклавына һәм, шуңа карамастан, башының һаман да рәтләнмәвенә кәефе кырылып, камчысын кулына алды да чыгарга ашыкты.

Алларындагы солыны ашап бетергән атлар иртән калдырган урында, туры түшәм астында аягүрә черем итәләр. Карабаш кына күренми. Эчендәге җене кузгалып, хәсрәт сакчысын караштыра башлады старшина. Бакса, тегесе дөньясын онытып, таралып, нигез буендагы чирәмдә йоклап ята. Яныш ике сикерүдә егет янына килеп җитте һәм сигезәрләп үргән камчысы белән Карабашның арт санына сыдырды:

— Уйнаштан туган, сасык,— дип сүгенде Яныш, аның артыннан җирәнүле карап.— Тиз үк атны китер!

Акулча капкасын чыгуга, айгырын Чуртанлыкүлгә борды Яныш, үчачуын басарга тырышып, камчысы белән атына сыпырып алды һәм җилеп юртып китте. Әмма аның чаптырып кайтуы бушка иде. Авыл тын, егетләр күренми. Аларны эзләүдә мәгънә юк. Сабыр итәргә, үзләре кайтканны көтәргә кала. Ул атын йөгәне-ние белән ишегалдына җибәрде дә ак өйгә узды, йомырыны мөлдерәтеп тагы бер салып эчте, караватка чалкан ятып, хәл алмакчы булды.

Этрәт кичкә таба гына кайтып төште. Яугирләрнең чырайлары сытык, күз карашлары боек. «Үзләренең гаепләрен сизәләр тагы»,— дип уйлап алды Яныш һәм аларга җикерергә дип, сүзләрнең иң усалларын кешене кимсетә торганнарын сайлады. «Маңкалар, җебегәннәр, шул этне дә тота алмадыгыз!» — дип кычкырырга өлгермәде, Хәйбуш сотникның ат сыртына аркылы салынган гәүдәсен күреп алды. «Ярый әле үзем бармаганмын»,— дип сөенде старшина, шатлыклы йөзен егетләрдән яше-

рә төшеп,— югыйсә Хәйбуш сотник урынына үзеннән үлә гәүдәнне сөйрәп кайткан булырлар иде.

Янышта башка да хөкүмәт яклылар кулына төшәр, боерган булса. Кабар, капмый калмас. Әнә ич, тирә-юнь патша гаскәрләре, чиру кешеләре белән мыжлап тора.

— Ярый, өйләрегезгә таралыгыз! Кирәксә, чакыртырмын!

Каргау вә каһәрләү, җикерү вә сүгенү көтеп, башларын иеп торган яугирләр басынкы һәм хәерхаһ тавыш белән әйтелгән бу сүздән соң, җиңел сулап куйдылар.

Яныш исә ял итәргә, йокларга җыенмады. Теге шайтан суыннан тагы бер авыз итеп куйды да болдырга чыгып утырды, әйле-шәйле башы белән булып узган хәлләргә йомгак ясарга, алдагы көннәргә ниятләрен ныгытырга булды. Аллага шөкер, шушы яшенә кадәр патшага тугры хезмәт итте, олуг түрәләр кушканны җиренә җиткереп үтәде. Шуңа да «вирнай» дигән ат алды. Сынату һич тә ярамас. Батыршаны тотмаса-тотмас, мәгәр бик тә тырышып эзләгән булып кыланыр. Болачыларны эзлим дип, әллә кая чабасы юк. Гыйсьянчы мулланың иярченнәре Карышбашның үзендә дә, тирә-як авылларда да җитәрлек. Шуларның берсен генә каптырганда да, «вирнай» дигән атына тап төшмәс, абруе — абруй булып калыр, боерган булса.

Яныш иртәгесен егетләрен таш келәт күләгәсенә җыйды да әйтте:

— Күбегезнең Батырша муллага хәерхаһ икәнегез бәңа мәгълүм,— диде.— Шул явызны әүлия урынына күреп, олуг хата ясадыгыз, башкисәрне кулдан ычкындырдыгыз. Ярый, бән кинә кумыйм, ачу сакламыйм. Гафур рахман, узган эшкә — салават. Янә дә килеп, алда гөнаһыгызны юар, гаебегезне аклар эшләр чыгып тора. Анысы — гыйсьянчы мулланың иярченнәрен, инде ходай кушып, җае чыкса, ата вурның үзен тотып, кул-аякларына богау салмак. Бүгеннән шул изге эшкә тотынабыз, насыйп итсә!

Карат әтрәте имин игенчеләрнең котын алып, авылдан-авылга күчте, вак урман-әрәмәләрне, кола-яланнарны айкады. Аннан-моннан җыелган сүзләргә караганда, болачыларга мөнәсәбәте бар дип фаразланган бәндәләрнең йорт-каралтылары асты-өскә китерелде, әйбер-каралары ватылды, урын-җирләре туздырылды, ындыр-әвеннәр тентелде. Әмма ни Батырша үзе, ни тарафдарлары табылмады.

Шул рәвешле атна чамасы дуамалланып йөргәннән соң, карат әтрәте Миргасыйм авылына килеп чыкты. Ошбу карьядан ике егетнең Батырша әтрафында уралганлыкларын тәгаен белгәнгә, старшина монда озаграк юанды. Гаҗәбе шул — куштаннар куйган балдан авыз итмәде, болачыларны эзләтте. Калмады чорма-түшәм, калмады әвен. Ләкин кара исемлеккә теркәлгән Максут белән Уразголның үзләре түгел, эзләре дә юк иде.

Ходайдан вакыты җиттеме, бүген авызына хәмер капмау галәмәтеме, зиһене ачылып китте, Яныш төпле уй йөртер хәлгә килде. Юк, болай тавышланып, адәми затлар өркетеп йөрүдән эш чыкмас, хәйлә вә мәкер кирәк монда. Иң шәбе — кайда да булса ящеренеп, вурларның кайтуларын саклап яту.

Ул шулай уй-исәбенә чумып торган арада, капка шагырдады һәм артында Әбделман йөзбашының ялагайлануы ишетелде:

— Токмач куера, Яныш агай. Әйдә, өйдән рәхим ит!

Табын янына үзе якын иткән егетләреннән берничәсен юри чакырды старшина һәм, сәкегә утырып алуга, болай җил куып йөрүне ташлап, авылга кайтып китү хакында сүз кузгатты.

Ниятенең ныклыгын раслап, ул аштан соң ук атына менде һәм, егетләрен ияртеп, авылдан чыгып китте. Әмма Миргасыймның кырый йортлары күздән югалу белән, алар уңга — күз җитүгә карамастан, ямьяшел булып утырган таллыкка борылдылар. Әрәмә зурдан булмаса да, бәләкәй отрядны атлары белән бергә сыйдырышлы иде.

Алар әрәмәдән чыгып, тузанлы юлга борылырга өлгермәделәр, үр

сыртыннан каршыларына төшеп килүче ике җайдак күзләренә чалынды. Әлеге мескеннәр, андый-мондый хәвеф сизмичә, җай гына юртып киләләр иде. Каршыларында пәйда булган атлыларны күрүгә, кисәк туктадылар, ул да түгел, борылып кирегә элдерделәр.

Яныш камчысы белән атына сыпырып алды һәм, корбанына ябырылган карчыга сыман, үргә томырылды. Егетләре дә, табыш барын сизгән бүре өере мисалында, старшина артыннан төштеләр.

Офыкта күренеп торган урманга хәтле шактый ара бар иде әле. Җитмәсә, качакларның атлары хәлсез, чабуларының юне юк. Яныш старшина качакларны басып җитте, аларны бер якта калдырып узды да айгырын юлга аркылы куйды, кылычын кынысыннан тартып чыгарды.

— Туктагыз! — дип үкерде ул, инде болай да туктап калган атлыларга.— Сез кем вә кай тарафларга юл тотасыз?! Пашпуртларыгыз бармы?

Шул мизгелдә каратларның берсе хихылдап көлеп җибәрде:

— Хи-хи-хи! Болар бит, Яныш агай, без эзли торган асыл кошлар — Миргасыйм авылыннан Максут белән Уразгол!..

Максут белән Уразголны Уфага, ун гаярь егете белән, Яныш үзе озата барды. Олуг түрәләр күзенә чалынырга шундыен җай чыксын әле! Бер уңайдан ил-җир хәбәрләре дә ишетеп кайтыр, аннан инде иркенләп үзенең йорт эшләренә тотыныр.

Әмма хыялындагы тынгылык килмәде. Ул инде фетнәчеләрне Уфаның атаклы зинданына олактырып, үзен бөек яугир Искәндәрдәй хис иткән хәлдә, Чуртанлыкүлгә кайтып китәргә җыенган иде. Уйланмаганда-көтмәгәндә аны провинция кәнсәсенә чакырып алдылар һәм кулына гарәп хәрефләре белән нәкышләнгән кәгазьләр тоттырдылар. Ышанычлырак булсын, диделәр бугай, аларның урысча нөсхәсен дә күрсәттеләр, татарчага тылмачлап бирделәр. Әлеге кәгазьләр Сенатның Батырша явы уңае белән чыгарылган махсус манифесты һәм Оренбур губернаторы Неплюев җәнапләренең грамотасы, имеш.

Провинция түрәләренең документларны үзенең ана телендә шәрехләүләренә карамастан, Яныш аларны юньләп тыңламады. Старшинага хәзер фәкать бер нәрсә мөһим: тырышлыгын күрсеннәр дә тиешенчә бәһаләсеннәр!

Алай да: «Биш йөз сум»,— дигәннәрен ишетүгә, ул тетрәнеп китте, тотлыга-тотлыга әлеге җөмләне кабатлауларын үтенде. Пәхтә сакаллы, сары чырайлы түрә исә иренмәде, тагы бер кат, Яныш аңларлык итеп шәрехләп бирде:

— Да, старшина, Батырша явызны тотып бирүчегә — биш йөз сум!

— Би-и-иш йөз-з-з! Бу бит... бу бит тулы бер хәзинә! — дип кычкырды ул, тәмам шашып.

Уфадан ничек кайтканын хәтерләми Яныш: әллә очты, әллә әфсен канатында җилде. Юл буенча йөрәген талап кайткан кайнар уйлары, Чуртанлыкүлгә җиткәндә, әмер-канун булып миенә беректе. Барлык Идел-Урал аймакларын актарырга, җирнең өстеннән табылмаса, астыннан табарга ахмак мулланы!

Яныш ашыга иде. Шулай булмыйни, биш йөз сум ярлыкаш акчасына кызыгучы бер ул гына түгел. Ишетүенә караганда, әнә, вирнай ыстаршиналарның барысы да атларга менгән, егетләрен күтәргән. Өстәвенә, губернада урыс пулклары мыжлап тора. Әмма Батырша, төтен булып очкандай, югалган иде.

Күзе алдына ат башыдай алтын булып килгән биш йөз сум хакында уйлана-уйлана, шашынып йөргән көннәрнең берендә, Яныш башына бик шәп бер фикер килде: Батырша ахмак түгел — якын-тирәдә посып ятмас. Оренбурга, яисә Казан ягына барып чыкмый да чыкмый. Ул якларда түрәләргә каршы яу купкан явызларны түгел, хуҗасыннан качкан колларны да бик тиз каптыралар. Ихтималы — мулланың үз фикердәшләре — галим-голәмә, шәкертләр арасында яшеренү. Тукта, ул бит Нәдер иләүенең Габделрахман мулла мәдрәсәсендә гыйлем алган бугай?!

Тайсуганга алар төш аугач килеп життеләр. Ләкин Яныш авылга керергә дә, мәдрәсәне камап алырга да ашыкмады. Якындагы урманда кичне көттеләр. Әмма анда да кузгаласы итмәделәр. Төнге караңгылык тәмам куерып, этләр тынып калгач кына, авылны һәм тау буендагы мәдрәсәне камап алдылар.

Таң яктырып килгәндә Тайсуган инде олы яу узган урынны хәтерләтә иде. Мәдрәсәнең һәм йортларның асты-өскә килгән, төнге кунакларны һай-һаулап каршылаган этләр үтереп ташланган, мал-туар туздырылган, биш йөз сум дәртеннән тәмам кайнарланган старшина егетләре кулы астына туры килгән дистәләгән ир-ат кыйнап-изеп ыргытылган иде.

Яу башы Яныш зур өметләр баглаган Нәдер иләүендә дә табылмады. Шул уңышсызлыктан гарьләнгән һәм ярсыган старшина туган ягына әйләнеч юл белән Минзәлә яклап кайтасы һәм юл уңаеннан Чирмеш урманнарын тараштырасы итте.

Юк, ни генә димә, хак тәгалә бәхеттән мәхрүм итмәгән иде Янышны. Калын урманны тараштырып, акрын гына Гәйнә ягына авышып барган көннәренең берендә, алдан баручы юртавыллар эчкәредәге ташландык юлдан җәяүлеләр төркеме хәрәкәт итүен хәбәр иттеләр. Күзәтчеләр төркемгә якын ук килеп караганнар: качаклар ачлар-ялангачлар, тагы да гаҗәбе — кулларында бала-чага, имеш.

Сүзнең ахырын ишетүгә, Яныш өнсез калды, сабырсызланып калтырана башлады. Хак, бу ул — Батырша! Карышбаштан сабыйлары белән чыгып китүен үзе күреп торды ла.

Старшина алай ук ярсымаса, салкын акыл беләнрәк эш итсә, алар, әлбәттә, Батыршаны бик асат эләктерә алачаклар иде. Бөтен эшне Яныш үзе харап итте: куанычлы хәбәрне ишетүгә, иярендәге сабасын алды, капчыкның авызыннан гына голт-голт итеп, хәмер чөмерде, аннан инде, авызына ризык та кабып тормастан, егетләрен әлеге серле урман юлына ашыктырды.

Юртавыллар зирәк егетләр икән: үткән юллары кырыендагы агачларга кылычлары белән тамга сала кайтканнар. Качакларның эзләренә тиз төштеләр. Мәгәр аларны ничек каптырып алу хакында берәү белән дә киңәшмәде Яныш. Биш йөз сумлык башның якында гына икәнен абайлап алуга, юха еланы сихерләгән куяндай, качаклар артыннан ташланды һәм шул сабырсызлыгы белән эшне бозып куйды да инде.

Тын урманда Зөлхәбирәнең ачыргаланып кычкырып җибәрүе төркемнән алда баручы Батырша белән Яхъяны сискәндерде. Мулла хатынын һәм балаларын якларга талпынды, әмма шәкерте аны тотып калды. Мулланың гаиләсе эләгүгә, Яныш шулкадәр шатланган иде ки, Батыршаны куу мәсьәләсенә кул гына селтәде.

— Хафаланмаң,— диде старшина, тавышын бөереннән чыгарып.— хәзер инде ул үзе бәне эзләп киләчәк. Һәр тарафка сүз житкерегез: Батыршаның хатыны вә балалары Яныш старшина кулында, дип.

Ни аяныч, Янышның өмете бу юлы да, көзге үрмәкүч пәрәвезедәй, әзелде — Батырша гаиләсен эзләп килмәде, киресенчә, күккә ашкандай юкка чыкты. Мәгәр үкенечнең олырагы алда икән әле. Чурганлыкүлгә кайтса, Кузьма писыр аны капкасы төбендә көтеп тора. Старшина югында Уфадан һәм Оренбурдан кәгазьләр килгән — шуларны житкерүе.

— Нә язалар?

— Һаман да бер балык башы,— дип иренеп кенә җавап сүзен башлады Кузьма.— Батыршаны һәм аны иярченнәрен тоту, восстаниенең эзен себерү һәм дә башкалар. Яңасы шул — Батырша башына ярлыкаш акчасы элеккеге биш йөз урынына мең сум итеп билгеләнгән.

Яныш башта авызын ачып катып калды, җәрәхәтләнгән ерткычтай еш-еш сулады, аннан, кулындагы тезгенен ташлап, йодрыклары белән башын кыйнарга тотынды, үзе туктаусыз карганды-сүгенде:

— Дивана, тавык мие әчкән ахмак! Кулга килеп капкач ычкындырдым...

Ак өйгә узып, бугазына аллы-артлы берничә йомры хәмер койгач кына, басыла төште старшина. Алай да сукрануыннан туктамады, үзалдына мыгырдый-мыгырдый ятагына авып төште һәм, тузанлы өс-башын да салмыйча ук, йоклап китте.

Иртәгесен ул инде бөтенләй башка кеше иде. Нигез буендагы такта өстендә бөкшәнеп яткан Карабашка кычкырды:

— Бар, тиз үк егетләрне күтәр!

Әйе, йокы-ял, ашау-эчү кебек иркәләнүләргә вакыты юк иде старшинаның. Азгын мулланың гаилә калдыкларын Уфага илтеп тапшырасы, аннан ерак төбәкләргә юл чыгасы бар. Ул кин, иркен ишегалдында бер тегеләйгә, бер болайга чабулап каударланды, үзе туктаусыз сөйләнде:

— Мең сум бит, мең сум!

## Унөченче бүлек

Яткылрак урыннарда зәңгәрләнеп кар, яисә көзгедәй ялтырап су ятса да, түбә җирләрдә инде аяк асты җилләгән, яшь үлән борынларга өлгергән иде. Беренче эшләре шул булды: хайван мисалында дүрт аякланып күке башы һәм сәрдәгә ябырылдылар. Ашый-ашый корсаклары тулды, әмма тамаклары туймады. Адәм мал түгел шул, аңа ипи яисә ит кирәк.

Бер-бер авылга тап булу нияте белән, урман буйлап атладылар. Күп тә үтмәделәр, алларында мал-туар көтүе күреп, туктап калдылар.

Шик-шөбһәләре көчле иде. Әмма тамак үзенекен итте, көтү турына якынлаштылар. Баксалар, сыер-сарыклар былтырдан калган үләнне чемченеп йөриләр, урманнан аерылып калган ялгыз туйра төбендә учак төтенли, ә көтү хуҗасы шуның янында рәхәтләнеп йоклап ята.

Нишләргә дип уйланып торган арада, Батыршаның күзе туйраның коры ботагына элеп куелган төенчеккә төште. Кижеле ашъяулыкка пөхтә итеп төрелгән бу төендә, әлбәттә, көтүченең көнлек азыгы иде. Мулла шәкертенә төртте, туйрага ишарә ясады. Тегесе исә аны шунда ук аңлап алды. Күз ачып йомганчы төенчекне эләктереп, кире йөгерде.

Урманның эченәрәк үттеләр. Ашъяулыктагы ризык, һәм ул шактый мулдан иде: пешкән ит, ярты ипи, биш йомырка, корт. Бу кадәр нигъмәт ач качаклар өчен чын хәзинә иде — ризыкка ябырылдылар. Алай да комсызлыкларын җиңделәр, йомыркаларны һәм бераз ипи кыерчыгын кара көнгә калдырдылар.

Инде, көтүче уянганчы, ашъяулыкны илтеп, урынына элеп куярга кирәк иде. Эшнең монысына да Яхъя алынды. Әмма китеп озак тормады, атыла-бәрелә кабат килеп җитте. Ул көтүченең уянып, тамак ялгап алырга әзерләнгән вакытына тап булган икән. Тегесе, туйрага эленгән төенчеген тапмагач, ялтын-йолтын як-ягына карап алган һәм, тиз үк урыныннан кубып, көтүен авылга таба куып киткән.

Бирим дигән колына — чыгарып куяр юлына, ди. Көтүченең учагы янып торган килеш калган иде. Урманнан коры-сары ташып, аны дөрләтеп җибәрделәр. Аннан инде анадан тума чишенеп, сәләмә киемнәрен ялкын өстендә кыздырып алдылар.

Инде монда бер генә мизгелгә дә артыгын калу ярамый иде. Гадәттән тыш ябык, пычрак һәм сәләмә, чәч-тырнаклары җитеп ашкан Яхъяның хәер эстәп йөрүләре тирә-юньдәге авыл халкын сискәндерми калмагандыр. Әлеге көтүченең дә өенә кайтып, ниткәндер «биглыйлар»ның үзенә һөҗүм итүләре, ризыгын талап алулары хакында сөйләве бик ихтимал.

Аталы-уллы булып беткән мулла белән шәкерт зур урманга кереп югалдылар. Аларны инде базда үлем көтеп яткан Батырша белән Яхъя димәссең: чырайларына бераз кот кунды, аяк-кулларында егәр артты.

Алай да, хагын әйткәндә, кыяфәтләре әле һаман да ат өркетерлек иде: чәчләре колак-маңгайларын күмгән, хәтта ки калак сөякләренә кадәр төшкән, кап-кара тырнаклары җир сукаларлык. Яхъяны һич кенә дә егет кеше димәссең: сирәк мыегы шыксыз тырпайган, сыек сакалы эт гөнҗәләсе булып киезләнгән. Батыршада сакал-мыек хәсрәте юк-югын, аның бите-ияге хатын-кызныкыдай шоп-шома. Бары тик сирәк-мирәк тырпаешкан бала йоннары гына, кырау суккан басудагы берән-сәрән калган тары үсентеләре сыман, акаешканнар. Кыскасы, килеш-килбәтләре теләсә кемне сагайтырлык иде.

Үзләренең исә бу хәлләреннән хәбәрләре юк. Тирә-юньдәге хозурлыкка сөенә-сөенә, атлыйлар да атлыйлар. Лапылыклар арасында шомлы булып торган тирән чокырлар, хәвефле баткаклар үттеләр, әледән-әле очраган чишмә буйларында туктап ял иттеләр, корырак һәм җайлырак урыннарда куның-куның та калгаладылар. Дүртенче көнне алар ихатасыз кырый йорт янында, таратып ташланган каен бүрәнәләре, усак киртәләре арасында, кулына балта тоткан берәү янында торалар иде инде. Шикләнерлек ул-бу күренмәгәч, әлеге бәндәнең янына килделәр, парлап сәлам бирделәр:

— Әссәламегаләйкем!

Кәләпүшле, кулындагы балтасын бүрәнәгә чапты, күтәрелеп юлаучыларга бакты. Тегеләрнең сәләмә киемнәре, житү чәчләре, әрвахныкыдай көлсу, утә ябык йөзләре — адәм куркытырлык кыяфәтләре шөбһәгә салды, бугай, сәламне кабул итмәде. Төксе генә сорап куйды:

— Сез кемнәр вә кая барыш?

Узган көздә ук күңелгә ятланып беткән җавапны Батырша бирде:

— Тайсуган мәдрәсәсе шәкертләре буламыз, азык-нәфәкә кирәк.

Сүзнең ахыры болай да аңлашылып торса да, авыл агае аның баш өлешенә ышанмады, хәйләле елмаеп, мосафирларга яңа баштанаяк карап чыкты, гаскәри түрә сыман кистереп әйтте:

— Алайса, менә нәрсә, шәкертләр. Анау чокырда бәнем мунча бар: суы кайнар, себеркесе парланган, селтесе чуен белән мичендә. Барыгыз, юынып чыгыгыз!

Юлаучылар күктән иңгән бу бәхеттән шашар хәлгә житеп, хуҗа күрсәткән тарафка ашыктылар. Дүрт-биш адым ясарга өлгермәделәр, артларында агайның яңа әмере яңгырады:

— Тукта, сабыр! — диде дә, үзе ашыгып өенә кереп китте. Бераздан исә кызыл башлы сөлге белән тотып потлы чуен алып чыкты, аны «шәкерт»ләр алдына куйды да алача ыштаны кесәсеннән ике чаган кашык алды:

— Ашагыз!

Шушы гомергә тиклем яшәп, тары боткасының тәмен белмәгәннәр икән. Баксаң, шуннан да тәмле, шуннан да татлы ризык юк икән дөньяда!

Мунча дигәне тау битләвен казып ясалган баз икән. Алай да шактый иркен, читәннән үрелгән алды исә җир өстенә ук чыгып тора.

Чишенеп ташладылар да, бар булган сәләмәләрен мунча ташлары өстенә җәйделәр, мул итеп пар салдылар, үзләре исә мунча алдына чыктылар.

— Утыр, — диде Батырша шәкертенә, имән агачына ымлап.

Тегесе утырып алуга, мулла сарык йоны ала торган кайчы белән Яхъяның киезләнеп беткән пычрак чәчен кыркырга тотынды.

Үзләре өчен чын бәлагә әверелгән «арслан ялларын» җәлләп тормадылар.

Озак каңгырап йөргәннән соң, оҗмахка тиенгәндәй, сөенешә-шатланыша ничә кат чабынганнардыр да, селтеле су белән мунчалалап ничә тапкыр юынганнардыр?!

Берзаман мунча алдында хуҗаның көр тавышы ишетелде:

— Күмер исенә исермәгәнсездер бит, шәкертләр?!

— Юк, берни юк, — диештеләр мунчадагылар. — Рәхмәт инде, агай.

— Ярый-ярый! Менә, чиста күлмәк-ыштаннар калдырам.

Хуҗа үзе: «Иркенләп юыныгыз».— дип торса да, ярты көн буе мунчада пычтырдау оят иде. Ашык-пошык коендылар да хуш ис килеп торган киндер күлмәк-ыштан киделәр.

Тагы чирек сәгатьтән Батырша белән Яхъя чиста һәм җыйнак өйнең сәке йөзлегендә, олы җиз самавыр янында утыралар иде. Киҗеле ашъяулык җәелгән табында таш савыт белән бал, акмай һәм кышозын төшләргә кереп йөдәткән, каерып киселгән арыш ипие телемнәре. Почмак якта чартлап-шартлап мич яна, табада нидер чыжлый.

Юмарт вә кешелекле хуҗа үзе дә сүзчән һәм мәзәкчән — табын гөрләп торды. Ул үзе Хәсән атлы булып, Куак суы буендагы ошбу Куак башы авылына әле узган җәй генә Ык буеннан, мал-туарын куып, күчеп килгән икән, абзар-кура салырга да өлгермәгән. Балалары яшь, булганы да кызлар гына, хатын ярдәме белән генә әллә кая китеп булмый, ди. Җитмәсә, чәчү кулны тота.

Хуҗа «шәкертләр»гә абзар-кура торгызуны, ихата киртәләүне йөкләмәкче. Бу исә мосафирларның ниятләренә туры килә, күңелләрендә яшәү дәрте уяга иде. Эшне тамак хакына килештеләр.

Ике атна буе бөтенләй диярлек бушка маташсалар да, Батырша белән Яхъяның күңелләре тыныч, хөр, йөзләре шатлыклы иде. Хәсән үзе иртә таңнан кара төнгәчә кырда булды, түгәрәк ак битле хатыны Маһруй һәм ике кызы гел өйдәләр. Аш үз вакытында пешкән, мәтрүшкә чәе кайнаган, мунча ягылган була. Мосафирларга күзгә күренеп кот кунды, тәннәрендәге җәрәхәтләре җыелды.

Мәгыйшәтенең чигенә житкәндә, бәндә дигәнең берни уйламас, борчылмас бер мәхлукка әйләнә икән. Иске Нәдернең мәчете базында кышның соңгы көннәрен үткәргәндә Батырша да шул хәлгә төшкән иде. Инде Куакбашка килеп егылгач, монда ашап-эчеп, чистарынып тернәкләнгәннән соң, ул еш кына алдагы көннәре хакында уйлана башлады. Тик күпме генә исәпләмәсен, киләчәге караңгы, алдагы юллары ябык.

Уйлана-уйлана да каршында бер генә яктылык күрә мулла — ул да булса, түрәләр каршына барып, үзе баш ору, ярлыкау сорау. Нигә, элегрәк балаларда катнашып, җиңелгәннән соң татар-башкортлар шулай итмиләр иде мени? Башларын саклап калганнар бит! Инде кыенның иң зурысын алганнары сөргеннәргә сөрелгәннәр, мәгәр анда кол хәлендә булса да тереклек иткәннәр. Ата-баба башыннан үткән аңа да ярамасмыни соң? Коллыкта булса да, тереклек итү, дөнья яктысын, җир өстендәге үлән-чәчәкләрне күреп яшәү... Ие, аның үләсе килми, килми!

Көн дә бер үк уйлар диңгезендә кайный торгач, Батырша ниятен беркетте — Казанга барып, язмышын патша түрәләре кулына тапшырырга карар итте.

Башында өзлексез биешкән сорауларга җавапны дөнья үзе ашыктырды. Килешенгән абзар-кура инде өлгерде, ихата читән һәм киртә белән уратып алынды. Хәсәннең кунакчыл өендә инде тагын да егылып ятуы оят, кая да булса олагырга кирәк. Ярый әле, тамак хакына гына, дип сөйләшсәләр дә, эшне ошаткан күрәсең, хуҗа аз-маз бакыр акча да бирде.

Иртәгә юлга чыгасы төндә Батыршаның миенә бер ачыклык инде — Гәбделрахман мулла мәдрәсәсе буенча шәригы Иштирәк исенә төште. Ие, ие, кайчандыр бергәләп мулла-мөдәрриснең чолыклыгын саклаган Иштирәк. Ул Тайсуганнан унбиш-егерме чакрымдагы Бигәш авылыннан булып, ике кыштан соң мәдрәсәне ташлап, атасы янына кайтып киткән иде.

Хак тәгалә аларны бәхеттән бөтенләй үк мәхрүм итмәгән икән әле — Иштирәкнең мәрхүм атасы йортында бер җайга яшәп яткан көне. Тәмам олыгаеп, ир уртасы булып житешкән, егәрлеге куәтендә. Мәгәр төнге кунакларны салкын каршылады.

Алай да качакларны бөтенләй читкә тибәрмәде Иштирәк. Зәйнең текә ярындагы мунчасына ымлады:

— Анау мунча, шунда урынлашыгыз,— диде ул, битараф кына.— Тик бән сезне, сез бәне белмәйсез. Янә дә килеп, зинһар дип әйтәм, озакка исәп тотмагыз!

— Хәердер,— дип куйды Батырша, гадәтенчә, тыныч кына.— Рәхмәтләр яусын, сәңа зыян-зәбрәт китермәбез.

Шулай сүзләштеләр: Яхъя, тирә-як авылларга йөреп, азык-нәфәкә теләнә, Батырша исә, кешеләр күзенә күренмәенчә, җыелган кадәр ризыкны кояшта киптерә, кош-корттан саклый.

Әлеге шөгыле башта мавыктыргыч кына булып тоелса да, тора-бара мулла ялыкты, аны сагыш басты. Шундый сагышлы көннәрнең берендә, эче пошуга чыдый алмый, яр башына күтәрелде, малайлар комарлыгы белән мунча башына да менеп китте.

Кабыгы мурып-череп беткән кыектагы тишектән башын тышка тыкты Батырша. Артык биек булмаса да, моннан тирә-юнь хәйран яхшы күренә. Әнә купшы өянкеләр төбенә Бигәшнең аз санлы йортлары сыенган. Алар тын, монсу, кызганыч хәлдәләр. Батырша, дөньяның матурлыгына кинәнә-кинәнә, кояш чыгышы тарафына күз салды. Алда, дүрт-биш чакрым чамасы ераклыкта, Бигәшнеке сыман ук бөдрә өянкеләр, башларындагы саламнары каралып беткән өй кыеклары күренә. Күрше авылны танудан битәр, йөрәге белән тойды мулла — Әлмәт!

Кинәт йөрәге какты, башы әйләнде Батыршаның, эчен чәнчеп ниндидер дуамал көч узгандай булды. Әйе, Әлмәт! Гомер бакый аңа тынгы бирми, йөрәген тырнап торган карья. Анда аның Тутыясы, анда аның яшьлеге!

Мунча түбәсеннән кайчан вә ничек төшкәнен хәтерләми Батырша: аягы астында гына, узган гомере булып, аның яшьлек елгасы агып ята, монсу тавышлар чыгарып чупылдашкан дулкыннар исә: «Тутыя, Тутыя»,— дип җырлыйлар. Әйе, Тутыя. Шул, гомерлек йөрәк җәрәхәте — моннан кул сузымы җирдә генә. Шул илаһи затка тагы бер генә күз салса, калган гомерендә ни генә күрсә дә, үкенмәс Батырша! Ә нишләп күрмәскә ди?! Әлмәткә, Әлмәткә!

Иртәгәсен, Яхъяны кәсебенә озаткач, ул болай да сәләмә киемнәрен аба-жаба киеп алды, көн шактый эссе булырга вәгъдә итсә дә, башына мескен бүреген элде, кулына таяк тотты, бар кадәр алам-саламнары арасыннан бер капчык тапты, бераз бөкересен чыгарып атлый-атлый, ындырлар артлап кына Әлмәт юлына төште. Бигәштән бераз китүгә, өс-башын карап алды, үзенең кыяфәтен күз алдына китерде. Хак, ул бөтенләе белән саилчегә охшап калган. Шунысы начар, сакал-мыегы юк. Бу исә — аның гомерлек шәхси тамгасы. Тәвәккәллек зур, тик аңа инде — барыбер. Бар теләге — Тутыясын тагы бер күреп калу.

Кайчандыр Әлмәтнең яшь мулласы дип аты чыккан имамның өен табуы кыен булмады. Ул мәчет каршында ук икән. Батырша бердәнбер урыс капкага якынлашты, йөрәге генә күкрәгеннән сикереп чыгарлык булып тибә.

Менә хыялында йөрткән капкага да житте, бәхетенә ул терәтелмәгән иде. Кече капканы ачып, эчкә күз салды. Җиргә төшкән энә ялтырап ятарлык итеп себерелгән ишегалдында кулына себерке тотып, ак киндер алъяпкычлы бераү, аксаклый-аксаклый, абзар-кура ягына үтеп бара иде. Батырша, күләгә кебек кенә, ишегалдына узды һәм такталары сары гәрәбә итеп юылган болдырга атлады. Әйа, Тутыяның кулы тигән бәхетле такталар! Ул инде шуларга басарга дип, аягын күтәргән иде.

Шул чак әлеге бәндә, кисәк борылып, аны күреп алды һәм чакырылмаган кунакка ташланды:

— Әй, саилче, мулла өйдә юк, җеназада,— диде ялчы.

— Иә-ә, әпә-пә...

Ялчы, хәерченең телсез-чукрак икәненә ышангач, кулын селтәде, кире борылып үз юлына китеп барды. Батырша исә ишек бавына омтылды.

Зур, чиста һәм якты өй эче яңа пешкән ипинең хуш исе белән тулы,

әмма түр якта берәү дә күренми иде. Батырша бусага төбендә туктап калды һәм, йортка чит кеше кергәнен белдереп, тамак кырды. Почмак якта савыт-саба шалтырап алды, ул да түгел, түргә чыга торган аралыкта, өстенә киң итәкле күлмәк кигәнлектән, юантыграк булып күренгән хатын-кыз пәйда булды. Мич почмагында кисәк туктап, өнсез калды, аннан канаты каерылган аккоштай талпынды, кинәт йөзен читкә борды, битен яулык чите белән каплады һәм өйне ярып кайнар пышылдады:

— Апуш абый!

— Тутыя!

Әйе, бу аның гомере буе йөрәгенең түрендә саклап йөрткән Тутыясы иде. Шул ук нурлы ак йөз, янып торган чем-кара күзләр, уймак авыз. Гүя ул әле һаман, теге чактагыча, Тайсуган болынында арба янында басып тора.

Бер-берә кочагына омтылган ике йөрәкниндидер тылсым көче белән кавышмый калды, ниткәндер сихри төш булып үткән мизгел һәр икевенә мәңгелек булып тоелды. Ниһаять, Тутыяның бәгыреннән сыкрап чыккан пышылдавы янә бөтен өйне ярды:

— Кит, Апуш абый, нәмәхрәм кылма!

Инде Батырша да исенә килде, үзенең шашынулы хисләрен җиңеп, ишеккә борылды. Тик аны ачарга өлгермәде, артында Тутыяның көмеш тавышы теге чактагыча кыңгырау булып чыңлады:

— Тукта, юлыңа ни бирим, Апуш абый?!

— Рәхмәт, берни кирәкми, Тутыя. Хуш, бәхил бул!..

Хәзер инде аны монда берни тотмый. Юллык азыгы, кесәсендә азмы-күпме акчасы бар. Бүген үк, менә хәзер үк үзенең соңгы юлына чыгарга әзер.

Алар җыеп-киптерелгән сынык-санныкларны Бигәш әрәмәсендә, тал куышында саклыйлар иде. Иртә таңнан юлга чыгарга ниятләп, кичке буйда әлеге үзләренә генә билгеле тал янына барырга, тупланган ризыкны мунчага алып кайтырга һәм капчыкларга тутырып куярга булдылар. Көн инде тәмам кичкә авышкан булса да, саклану чарасын да онытмады мулла. Чабып алырлык булып үлән үскән тар гына юлдан шәкерте алдан атлый, Батырша үзе исә ук атар чамасы арттан, Яхъяны күрә-күрә бара.

Әрәмә эченә таба йөз сажин чамасы үтмәгәннәрдер, уң кулда, таллар арасында, коры чыбык-чабык чытырдады, шуның артыннан ук Яхъя өстенә дистәгә якын яугир ташланды. Каршында кылыч тоткан әзмәвердәй егетне күргәч, Яхъя эшнең нидә икәнен аңлап алды һәм тын әрәмәне ярып кычкырып җибәрде:

— Әйа, хәзрәт, качың, кач! Алар монда — күбәү,— дип кычкырды.

Батырша, һәр ягын ут чорнаган урмандагы киек-җәнлектәй, атыла-бәрелә, таллар арасына ыргылды.

## Ундүртенче бүлек

Йа хода, бу урманнарның да чиге бар икән! Батырша төн караңгылыгында да яктырып торган сирәк каеннар арасыннан үтте дә дугалы атларны күмешле арыш басуына килеп чыкты һәм иген арасында бормаланып яткан юл буйлап китеп барды. Әйа, урак өсте җитеп килә ләбаса! Ие, чиллә ас керде. Ялгышмаса, сөмбеләнең сигезенче көне башланды. Шулай, һиҗри 1169 ел сөмбеләсенең сигезе. Аның Карышбаштан качып китүеннән соң елга якын вакыт үткән.

Бигәш әрәмәсендә яудашларының соңгысы Яхъяны да югалткач, нияте нык үзгәрде Батыршаның. Күптәнге губерна үзәге Казанга, чит-ят урыс түрәләре каршына барып басканчы, Борай якларындагы Әҗик авылында яшәүче Сөләйман старшина катына килүне кулайрак тапты. Сөләйман — ни әйтсәң дә, үз кеше: үз мишәрең, үз мөселманың. Мәсьә-

ләнен икенче ягы да бар: теге елларны, Карышбашта мәдрәсә гыймарәт итү дәрте белән йөргәндә очрашкач, алар дуслашып та киттеләр.

Сөләйман старшинага бармый, кемгә барсын ди Батырша?! Аның инде башка дус-ишләре, туган-тумачалары, якыннары калмады диярлек. Сөләйман агай исә мулланың абруе, гыйлемлеге алдында баш ия, аны санлый, олылый. Сүз дә юк, старшина дусты кочагын җәеп каршылар, мунчасын яктырыр, бар булганы белән сыйлар. Тугры, гадел һәм кешелекле булып бөтен тирә-юньгә танылган аксакалның хыянәт итү, аны сату ихтималын башка китерергә дә ярамый. Менә бүген таңда ук очрашырлар, чәй янында киңәшерләр-серләшерләр. Шунда инде Батыршага бөтен эчен ачып салыр. Түрәләр Сөләйман белән икәвен яхшы атларда Оренбурга озатырлар, Ниплүй янарал белән күрештерерләр. Шунда инде губернаторның үзенә генә әйтер Батырша: бәнем патша хәзрәтләрен, шәрәфәтле мәликәбезне күргем килә, аның үзенә генә әтә торган сүзләрем бар, дияр.

Әйа, юлындагы бихисап манигъ-киртәләрне үтеп, патшабикә зат катына барып җитсәме?! Сүзен әйтә белер, боерган булса!

— Ул өч хадисән хәбисәнең берсе улдыр,— дияр Батырша илтифатлы мәликәгә,— кайсы мөселманнардыр кем, аларның теләмәке вә ризалыкы улмаенча, ислам диненә тәрәк итеп, урус диненә кермәккә вә һәм теләмәк вә риза улмак кебек чиркәнеч вә күңел кайтаргыч эшләргә кылынганнар ирделәр. Шул мөселманнарны әүвәлгечә ислам динендә торырга ирек куймаучы залимнәрнең үзләрен хөкемгә вә җәзага тарту кирәктер!

Вә дәхи ул хадисән хәбисәләрнең икенчесе улдыр кем, кадими падишаһларымыз чорында вә шартында лазим ителмәгән хезмәтләрне мөселманнарымыз өстенә йөкләмәктер: ислам диненнән яздырылганнарның хәзмәтләрен калган мөселманнарымызның өстенә йөкләмәк тик, чирүле мишәрләр өстенә егерме бишәр тиен ясак салмак тик, ясаклыларның ясагын арттырмак тик, чирүле мөселманнарга чиру хезмәтеннән башка ике баш эшен эшләтмәк тик. Ике баш эше дидекемез улдыр, һәр елда указ киләдер: чиру кешеләре пахутка чыксыннар, билгеле урыннарында каравыл тору өчен, дию. Ул указ кушуынча, чиру кешеләре пахутка барып, каравыл тормак эшен башкаралар вә һәм, указдагы каравылчылык эшләреннән башка, бөтен җәй буенча төрле башка эшләр эшләмәскә ирексезләнәләр.

Вә дәхи ул хадисән хәбисәләрнең өченчесе улдыр кем, хак тәгалә хәзрәтнең тагларда вә күлләрдә яраткан тоз хәзинәләрене, ирекле вә кызганыч бәндәләрне мәхрүм итеп, кальгаларга бикләмәктер. Өч хадисхәбисә, йәгни яңа пәйда булган бозык эшләр, ошбулардыр...

Каршында, сыек томан эчендә авыл шәүләсе төсмерләнде. Ялгышмаган — Әҗик! Алай да турыдан-туры Сөләйман старшина йортына барып керәсе итмәде Батырша. Кем белә, түрә кешеләр кунаклар булуы ихтимал. Иң шәбе — кайчандыр үзендә шәкертлектә торган Ишназарга сугылу.

Шул ниятен ныгытып, авыл уртасына, мәчет ягына борылды — Ишназарлар өе гыйбадәт йортыннан егерме сажин чамасы гына арырак иде. Җил капканы ачып, эчкә үтте, ишегалдындагы тәрәзәгә шакыды:

— Ишназар үдәмү-ү-ү?

Уйламаганда-көтмәгәндә эчтән бер хатын җавап бирде:

— Үдә юк, печән чабалар, кичкә кайтырлардыр,— диде хатын, йомшак кына. Аннан исә тавышын күтәрә төште.— Кем сән, ни хаҗәтең бар?

Батырша кайтарып сүз әйтмәде, дәшми-тынмый гына туп-туры мәчеткә таба атлады. Бәхетенә, анысының ишегендә йозак юк иде. Шикләнерлек нәрсә күренми. Сакланып кына ишекне ачты — тегесе, күгәннәре күптән дегет күрмәгән бугай, иләмсез шыгырдады. Әмма Батырша моңа игътибар итмәде. Җинел атлап эчкә үтте, түбә такталарын ачып, чормага менде, остазы Габделрахман һидиясе — биле бөрмәле

кыска чикмәнен салып, коры яфрак катыш балчык өстенә җәйде, мескен бүреген башы астына салды да чалкан ятты.

Батырша, мәрткә киткәндәй, каты йоклады, берни ишетмәде, авылда ниләр барын белмәде. Ул шулай «хәл алган» арада исә ирен һәм улы Ишназарны печәнгә озатып, ялгызы төн үткәргән Фәризә, таң алдыннан тәрәзә шакудан коты алынып, хафага төшкән иде. Шуннан инде бүтән йокламады, көн яктырып житүгә, курка-өркә тышка чыкты, ашыгып абзарга үтте, малларын, тавык-казларын барлады, бакчага узды. Керсә, эш харап: миләш һәм балан куаклары арасындагы чолыклар, ягъни бүкән умарталар, җирдә аунап ята, бал кортлары пыр туздырылган, сытып-изеп бетерелгән. Бүген-иртәгә бал аерыткырга дип торганда бит! Ах явыз, таң тишегеннән тәрәзә кагучы тиктән йөрмәгән икән!

Фәризә, бөрмәсенә кыстырган күлмәген төшерде, камзулын һәм шәлъяулыгы өстеннән кырпу бүреген киеп алды да, җил-җил атлап, Сөләйман старшина йортына китте. Теге бәндә тәрәзә какканнан соң, күп тә үтмәде, иләмсез итеп мәчет ишеге шыгырдады. Ие, угры шунда — мәчеттә! Үзе посып киткән икән, баллы кәрәзләрне алла йортына яшергән!

Сөләйман исә аны тыңлап бетермәде, ак өенә узды, тәрәзә ачып кемгәдер кычкырды:

— Кереӊ!

Ашыгып елгыр писыр Мөхсин Әбделман углы килеп керде. Старшина аңа авылда булган кадәр халыкны тиз үк мәчет янына җыярга, өйләрендә булмаганнарның кайда вә нишләп йөрүләрен ачыкларга кушты. Тегесе атыла-бәрелә чыгып китте.

Чатта Куштан Исхак, Бастырык Рәсүд һәм кәҗә сакаллы азанчы Куян Исмай басып торалар иде. Сөләйман Куян Исмайга борылып әйтте:

— Азанчы, мәчеткә кергел, карагыл: угры анда посып ятмыймы, бал кәрәзләре күренмиме?

Ул арада мәчет янына кулларына сөңгедер, күсәктер тоткан ирләр әрсез алабай мишәр хатыннары җыелды — ыгы-зыгы башланды.

— Сүз юктыр ки, угры — Әҗик кешесе түгелдер!

— Сүлисеӊ тагы! Әлбит, бу — урыс эше. Угрылыкка алар маһир.

— Мәсҗедне якшылап карарга кирәк!

— Җәмәгать! Угры — манарада! Әй, азанчы, тазарт манарынны!

Болай да коты алынган Куян Исмай бөтенләй үләр чиккә җитте. Алай да монда гавамның зурлыгы, ирләр кулындагы сөңге-күсәкләр аңа дәрт-дәрман бирделәр бугай, ул, камырга әйләнгән аякларын көчкә сөйрәп, мәчеткә таба китте. Ишеген курка-өркә генә ачып, уңга-сулга, аска-өскә бакты, түшәмдәге каерылган такталарны күреп алды, кәҗә тавышы белән шәрран ярып җибәрде:

— Угры — мәсҗеттә!

Батырша халык шаулашканга уянып китте. «Угры — мәсҗеттә!» — дигәннәре ишетелде. Ул, киеменә ут капкандай, сикереп торды, мәчет кыегындагы череп беткән кабыкны аергалап, аска күз салды. «Сөләйман ыстаршина монда булса, төшеп, яннарына барам, ул юк икән — качам», — дип ниятләде, мәйдандагы халыкны күзәтеп. Әмма, әллә каударлануы белән, старшинаны күрмәде. Батырша, җилтерәп, чикмәнен киеп алды, бүреген башына чәпәде дә такталары алынган тишектән аска сикерде. Дуңгыз тәпие булып беткән ялан аяклары белән гөрселдәп идәнгә килеп төште — бусага төбендә иелеп-бөгелеп маташкан кәҗә сакаллы кеше, йөрәк өзгеч чинап, авып китте. Мулла сикереп тәрәзә төбенә менде, аның рамына китереп типте — чылтырап пыяла коелды. Батырша мәчет буендагы кычытканлыкка томырылды.

Башлап Сөләйман старшина исенә килде, аннан Куштан Исхак, Бастырык Рәсүл, башкалар ни булганын аңлап алдылар, мәйдандагы халык, бердәм телгә килеп, кычкырышырга тотынды.

— Тот, тот!
— Урысны ычкындырма!
— Башына, башына — күсәк белән!

Батырша эзәрлекләүчеләрдән нык аерылды, каенлыкка якынлашты. Каракның күрәләтә кулдан ычкынуын сизеп алган Сөләйман туктап, артына борылды, тынына каплана-каплана, кычкырды:

— Ат-лар китер-е-гез, ат-лар!

Аның әмерен көтеп торганнар диярсең, сәлексыман житез, яшь көрән айгырда старшинаның олы улы Давыт килеп житте. Чаптырып килгән унаена жиргә сикерде. Бастырык Рәсүл гүя атланмады, айгырны озын ботлары арасына кыстырды гына кебек. Алай да елдам чаптырып китте, калганнар аның артыннан җәяү теркелдәделәр.

Менә артларыннан икенче ат тоягы тавышлары ишетелде. Рәхмәт төшкере, Сөләйманның кече улы Килмөхәммәт икән. Сөләйман, һич ярдәмсез, атка үзе сикереп менде һәм Бастырык Рәсүл артыннан юыртып китте.

Куштан Исхак, булачак старшина Давыт вакыйга кайнаган урынга Сөләйман белән бер үк вакытта диярлек килеп життеләр. Давыт, йөгереп килү унаена, камчысы белән Батыршаның пәке тоткан кулына сукты. Тегесе нык авыртудан сызланып, бер мизгел генә хәрәкәтсез торган арада, бердәм өстенә ташландылар, жиргә егып салдылар да кулларын артка каердылар.

— Җибәрегез, бән — үзем! — дип карулашты Батырша.
— Нә кеше сән? — дип сорады Бастырык Рәсүл.
— Мөселманмын.
— Атың ничек?
— Сөләйман өендә танышырбыз.

Качакны жирдә әвәләп маташкан арада, яннарына писыр Мөхсин килеп житте һәм, гомергә тыныч кеше, урман буен ярып кычкырып жибәрде:

— Бу бит — Бәһадиршаһ хәзрәт! Яу башлыгы, шөһрәтле ахуныбыз!

Мөхсиннең гажәпләнүле сүзен ишеткәч, барысы да «аһ» итте. Кайсыдыр көйләп диярлек такмакларга тотынды:

— Әй, хәзерәтемез, вәлинигъмәтегез, динемезнең олугы, күңелләребез чырагы, сән идүкеңне белмәдек. Әй, ходайның тәкъдире, гөнаһларымыз шомлыгы,— дип көрсенде.

Өс-башы сәләмә, пычрак һәм үзе мәхбүс хәлендә булса да, мәшһүр мулла горур иде. Ул теге такмаклаган бәндәгә борылды һәм әйтте:

— Бән ходаемның хөкеменә вә казасына разый булып, бу рәвешле тоткын ителгәч, хәсрәтләнмимен. Бәс, сезләргә мең сум ярлыкаш хакланып, морадыгыз хасыйл улгач, ничен хәсрәтләр жыясыз?

Батыршаны старшина өенә алып кайттылар. Сөләйман, гадәтенчә, кунакчыллык күрсәтте — мулланы нигъмәттән сыгылып торган табын янына утырттылар.

— Сән аша, вәлинигъмәт, тамагыңны туйдыр,— диде хуҗа һәм, йомыш тапкан булып, тышка чыкты.

Ишегалдында таптанучы бер төркем халык арасыннан улы Давыт белән писыр Мөхсинне чакырып алды:

— Егетләргә әтегез: йортны уратып алсыннар, берәүне дә кертмәсеннәр вә чыгармасыннар. Үзегез исә, иң якшы атларга атланыгыз да, Уфага чабыгыз! Түрәләрнең иң олысына кереп әтегез: Сөләйман ыстаршина ата вур Батыршаны тотты дип.— Инде өчәүләп ишектән чыгып барганда, ул улы Давытның жиңеннән тартты һәм колагына пышылдады.— Сән анда мең сум хакында исләренә төшерергә онытма!

Ашыгып өенә керде, ит шулпасы белән булышып утырган Батыршаның каршына килде. Гаять тә хәсрәтле кыяфәттә сүз катты:

— Әй, хәзрәт, вә илла, сәне беләмез вә һәм сәңа кәсд итмеш дәгүл ирдек.

Вә ләкин бер кешенең умарталарын ватып, балын угрлаган сәбәбле, ауылымызны тикшереп, тәмам иткәннән соң, кешеләрне мәсҗедкә җибәргән идем...

Старшинаның хәерхаһлыгына күңеле булды Батыршаның:

— Әй, ыстаршина, сәңа мәгълүм итимен ошбуны кем, бәнем олуг падишаһымыз хәзрәтләренең үзенә әйтергә тиешле сүзем вә йомышым бардыр,— диде.— Ул сүземне вә йомышымны падишаһымыз хәзрәтләренә житештерүгә һичбер хәл җай таба алмаканлык өчен, сәңа килгән идем, сән бәне үз ихтыярым вә теләгем илә Уфа кальгасына илтер өчен.

— Сезне тапкан кешегә, хәзрәт, мең сум ярлыкаш тәхсыйс, кылынгандыр,— диде Сөләйман, куанычлы хәбәр әйткәндәй, шатланып.— Бу кадәр сезнең падишаһка кирәклегез барлыгы һәм дә бәңа сезне яшереп калу мөмкин дәгүл. Әлбәттә, сезне Уфага илтермен. Анда үз сүзегезне үзегез мәгълүм итәрсез.

Аулакта күзгә-күз калгач, старшина артыгын сузмаска булды:

— Вәлинигъмәт, күңелегезгә рәнҗү китермәгез,— диде ул, өстәлгә карап,— безнең сезгә яманлык кәсдебез юктыр. Сез үзегез фәһем иясе — аңлыйсыз булыр: «Сән үзе килде»,— дип мәгълүм итмәкемездән, безгә файда юктыр вә һәм сезгә дә булмас. «Үзебез тотып алдык»,— дидек исә, безгә мең сум насыйп булыр, алла бирсә!

Батыршаның яңагына суктылармыни?! Ул сискәнеп китте, тәне кызышып чыкты, йодрыклары кысылды, бөтен вөҗүде үч һәм ачу белән тулды, менә-менә дус старшинасы өстенә ташланып, аны буып ташлар хәлгә житте. Алай да түзде, сабыр итте. Сөләйман уйнап кына әйтәдер, менә хәзер көлеп җибәрер, кызарыр һәм тупас шаяртуы өчен гафу сорар дип көтте. Әмма тегесе пошынусыз һәм тыныч иде:

— Әй, хәзрәт, хафаланмагыз, өметегезне өзмәгез, падишаһымыз рәхмәтледер,— дип сөйләнде ул, әле дә шул хәерхаһ тавышы белән.— Бәнем камандадан Сәлимҗан берлә Гайнулла да катыр киттеләр, һичбер зарлары вә яман хәбәрләре ишетелмидер...

Ак якка әзмәвердәй ике егет килеп керде. Батыршаны элэктереп алдылар да, күз ачып йомганчы, кул-аякларына богау салдылар. Бераздан Батырша суына төште һәм, иреннәрен чәйни-чәйни, үзалдына әйтеп куйды:

— Алтын күргәч, фәрештә дә юлдан яза, диюләре хак икән.

Калганы төштәге сыман бик тиз булып үтте. Шомлы фәйтун моннан йөз илле чакрымдагы Уфага таба кузгалды. Инде төн таңга авышуга карамастан, урамның ике ягын тутырып халаеклар бөялгән, әмма алар көчсез вә чарасыз. Бары сагышлы вә хәсрәтле авазлары гына ишетелгәләде:

— Хуш, хәзрәткәемез!

— Бәхил бул, вәлинигъмәт!

Офыкта 1756 елның тугызынчы август таңы яктырып килә иде.

## Унбишенче бүлек

Юлда бернечә ат яндырып, Уфадан чапкын килеп төште һәм Неплюевка пакет тапшырды. Аның күптән көтелгән хәбәр икәнен сизенде Иван Иванович һәм ялгышмады — Уфа канцеляриясе атаклы коткычы Батыршаның тотылуын житкергән иде.

Мондый сөенечле хәбәрләр губернаторга икеләтә көч-куәт, егәр өсти. Ул тиз үк подполковник Исаковны чакыртты, Уфага чапкын әзерләргә кушты. Үзе исә боерык-инструкция язарга утырды. Батырша эшенә ул шәхси секретареннан башка кешене катнаштыра алмый иде. Мие гаҗәеп тизлек белән уйлый, каурый каләме кәгазь бите өстендә йөгереп кенә торды губернаторның: явыз вор Батыршаны бик көчле сак астында Оренбургка китерсеннәр! Конвой башлыгы Батыршаның кул-аякларын-

дагы богауларны шәхсән карап-күзәтеп торсын, тукталган, яисә кунган урыннарда махсус сакчылар һәм кораллы пикетлар булсын! Әлеге конвой башлыгы итеп билгеләнгән капитан, явызның үз-үзенә ул-бу кылмавын, дүрт күз белән күзәтсен. Ашаганда тамагына сөяк кадалмасын тагын — итнең йомшагын гына бирсеннәр!..

Августның егерме өчендә Батыршаны Оренбурга китереп җиткерделәр. Неплюев, бу гаҗәеп затны күрү өчен, төрмәгә чапты. Анда баргач нибары бер сорау бирде:

— Уфа ягының Себер юлы, старшина Яныш Абдуллин карамагындагы Карышбаш авылыннан мишәр мулласы Абдулла Мәзгытдин, кушаматың белән атасак, Батырша синме?

— Мин! — диде Батырша горур гына.

Неплюев башка сорау бирмәде, кинәт борылып чыгып китте. Яңалыгын Сенатка хәбәр итәргә ашыкты. Бүген Оренбург төрмәсендә явыз вор белән очрашуын, аның чыннан да Абдулла Мәзгытдин, ягъни Батырша икәнен тәфсилләп язды. Бераз уйланып утырды да: «Сездән остәмә таләп килгәнче, башка сорау алмыйм», — дип тә өстәп куйды.

Августның егерме алтысында Сенат Батыршаны Петербургка китерү хакында карар кабул иткән икән. Нәкъ ярты айдан соң шул турыда указ килеп төште. Хәтта аны аулаучыларны да онытмаганнар, иң ахырга: «Аны тотучы старшина Сөләйман Деваевны, өметләр баглатып, идарә итүче Сенатка юллагыз», — диелгән иде.

Бүлмәсенә өркә-шүрли генә килеп кергән капитанны күргәч, Иван Иванович урыныннан калкынып куйды һәм кулы белән өстәле яныннан урын күрсәтте. Кыланышына караганда, ул һич кенә дә ызгышырга җыенмый иде. Әмма Болховский утырмады, өстәлдән ике адым чамасында басып калды.

— Сезгә, князь, — диде Неплюев, — бер тоткынны Мәскәүгә хәтле озатып куярга кирәк. Тоткын ифрат та явыз һәм куркыныч! Менә шуна да әлеге бурычны сезгә йөкләргә булдык.

— Менә монда мин махсус инструкция әзерләп куйдым. — Неплюев, кулына ниндидер кәгазь тоткан хәлдә, аягына басты. — Укырсыз, өйрәнерсез — әле вакыт бар. Хәзерлек эшенә исә бүгеннән тотынырга кирәк. Юл чыгымнарына биш йөз сум акча билгеләнде. Бөркәүле махсус арба ясатырга тиешсез. «Кадерле кунак»ка тун, чикмән, ыштаннар, бүрек, бияләйләр, җылы аяк киеме, күлмәк, уравычлар, астына салырга киез сатып алырсыз. Тоткынны ашату өчен көненә алты тиен каралган. Түйганчы һәм тәмле ашарга житәр дип уйлыйм. Барлык чыгымнарны менә шушы шнурлы кенәгәгә язып барырсыз...

Әнә шул көннән башланды да инде тамаша. Болховский көннәр буе сәүдә рәтләрендә уралды, тимерчеләр, балта осталары янына барып чыкты. Батырша өчен өсте ябулы махсус арба ясатты, драгуннарга, дип егерме биш олау юллады, атлар, җылы киемнәр сатып алды. Кичләрен исә әлеге инструкцияне ятлады — Неплюевның теләсә кайсы минутта шул хакта соравы бар.

Юлга сентябрь азакларында гына кузгалдылар. Алда — атларга атланган казак сотнясы, алардан соң пар ат җигелгән көймәле арбада — Батырша, аның янәшәсендә һәрдаим ике сакчы, офицер һәм капрал. Төп йөккә ятап башлыгының шулай ук пар атлы күн тышлы фәйтуны, аннан инде мылтыклы драгуннар төялгән егерме биш олау тагылган. Ай ярым дигәндә, Самара, Арзамас, Муром, Владимир калалары һәм җирләре артта калды, инде менә Мәскәү губернасы буйлап баралар.

Баштарак, бигрәк тә Оренбург белән Самара арасын үткәндә, губернатор инструкциясенең һәр сүзенә ябышып эш итте Болховский. Батыршаны кулдан ычкына күрмәсен, алай-болай үзенә зыян салмасын, елгаларны кичкәндә, суга ташланмасын!

Бара торгач, хәлләр үзгәрде. Татар һәм башкорт җирләре артта калды. Өстәвенә, көннәр тәмам бозылды, туктаусыз яңгырлар койды.

юллар ат-адәм үтә алмаслык баткакка әверелде. Драгуннарны һәм офицерларны сагыш, битарафлык басты. Капитан инде атка атланмый, гел диярлек фәйтунда, назланып бара. Эч пошуын басар өчен дип, исерткечтә капкалый башлады.

Чүлмәкчедән күрмәкче дигәндәй, драгуннар белән бүтән офицерлар да аракы эзләү, кәеф-сафа кору белән мавыктылар. Поручик Левашовны әйткән дә юк: көнен дә, төнен дә кызмача.

Берзаман күмәкләшеп эчү гадәткә әйләнде. Мөселман динендәге татар казаклары гына әлеге типтерүләрдән читтәләр. Мәгәр аларның барысы да диярлек Батыршага хәерхаһ, тоткын качып китсә, сөенешерләр генә.

Башын мендәренә салып, изрәп барган князь йоклап ук киткән икән. Шыгырдап фәйтун ишеге ачылуга, уянды, билендәге кылычына ябышты. Мүкәләп кереп килүченең Левашов икәнен күргәч кенә эченә җылы йөгерде.

— Биш йөз... ик... чиләкле завод... ик... аракы заводы,— дип сөйләнде поручик, икылдап.— Тулы мичкә... ик... китерергә куштым... ик. Җитәр бит?!

Болховский торып ук утырды:

— Молодец, поручик. Инде шәп кенә алан да табыгыз!..

Тагы чирек сәгатьтән кәрван ялга туктады. Юл буенда ук чабылмаган печәнле иркен генә алан, эчтәрәк тагы бер кечерәк ачыклык шәйләнә.

Каны язылып, тәне кызышып киткән капитан, мәж килеп чатырлар корып, аш әзерләп маташкан кешеләр янында басып торудан җиксенеп, тоткын арбасы янына китте. Күзе ияләшә төшкәч кенә монда алай ук дөм-караңгы түгеллеген, арбаны томалаган күн ярыкларыннан төшкән яктылыкның ярыйсы ук икәнен абайлады, арткы почмакта киез өстендә бөкшәнеп яткан мулланы күреп алды.

— Нихәл соң, Бахадир-шаһ?! Җалуың юкмы? Сакчылар кыерсытмыйлармы үзеңне? — дип сорады.

Батыршаның аягы очындагы карагай кискәсе селкенеп куйды, зынҗыр чыңы ишетелде. Әмма тоткын дәшмәде, икенче ягына борылып ятты. Аның өчен җавапны арба тәгәрмәче белән маташкан сакчыларның берсе бирде:

— Пычагым булсынмыни аңа?!

— Карагыз аны! — дип янады Болховский, урысчага күчеп.— Этлек исәплəп ятмасын ул вор. Андый-мондый хәл була калса, башларыгызның гәүдәләреннән аерылулары бар!

Ул әйләнеп килгәндә, һәр ике алан шактый җанланган иде инде. Офицерлар һәм драгуннар аш пешкәнне дә көтмәгәннәр, аракыдан авызланганнар. Һәр учак, һәр табын янындагы шау-шулы бәхәсләр шул хакта сөйли. Бераздан исә кәрван тукталган мәйданнарда кәеф-сафа тәмам кызды. Батырша арбасы янындагы сакчылар да табын янына китеп барды. Сакчыларның һәр сулышын тоеп, ишетеп яткан Батыршага шул гына кирәк иде дә инде. Ул, урыныннан торып, богау чылбыры җибәргән кадәр, ишек янына килде, аны сыза гына ачып, учаклар ягына бакты: гаскәриләрнең берсендә дә дөнья кайгысы калмаган.

Монысы бигрәк тә ярады. Батырша көймәнең алгы ягына куелган талчыбык чуманнан чүкеч һәм чыра пычак табып алды, ашыгып үзе беркетелгән карагай кискәсе янына килде һәм, богавын, таш кебек каты түмәр өстенә куйды да, аны кисәргә тотынды.

Чакылдаган тавыш аландагыларга ишетелмиме, дип туктый, тынлап-тынлап тора да, янә эшнә керешә Батырша. Манма тиргә табып маташа торгач, богау тимере киселеп чыкты. Аланда һаман да шул мәхшәр икәнен күргәч, аяклары иреккә тиенгән тоткын иплəп кенә, наратлыкка кереп китте.

Ярый әле, пычагы белән чүкечен үзе белән алган иде. Чакрым

чамасы җир киткәч, таза гына иман төбенә тап булды һәм, инде каударланмый гына, кулындагы богауны ватарга тотынды.

Хәзер ул ирекле кош, дүрт ягы кыйбла! Кыйбланың кая икәнен генә белми. Хәер, аңа бер генә юл кирәк — пайтәхеткә илтә торганы. Әйе, ул барыбер Петербурга, патша хәзрәтләре каршына барачак. Ләкин кул-аяклары богаулы мәхбүс булып түгел, үз ихтыяры белән бирелүче яу башлыгы булып!

Ул да түгел, олуг бер елга ярына килеп чыкты. Суның киңлеге байтак, тирәнлеге дә юк түгел бугай — кайнап, бөтерелеп ага. Җаен монда кораблар да йөзә торгандыр, мөгаен. Ата-бабаларның Ука дәрьясы дигәннәре шулмы, әллә башка берәр елгамы?

Батырша шулай уйланып торган арада, ни беләндер җилкәсенә китереп суктылар. Ул чайкалып китте, ләкин егылмады, гәүдәсе белән артына борылды. Үзеннән ике адымда гына, шәрә кылычын тотып озын буйлы, таза драгун басып тора иде.

Урман арасыннан һай-һаулап бер төркем исерек солдат килеп чыкты. Алар, килгән шәпкә, Батыршага ябырылдылар: аны сугып ектылар да, тупас күн итекләре белән аны типкәли, таптый башладылар. «Әҗәлем шушы икән»,— дип уйлап алды мулла, куллары белән башын тотты, иманын әйтеп калырга ашыкты. Шулчак кемнеңдер кискен боерыгы яңгырады:

— Туктагыз! Тоткынга тырнагыгыз белән дә агылмагыз!

Ашыга-кабалана Болховский белән Левашов килеп җитте. Алар ерактан ук капрал әмерен кабатладылар.

Тәмам таптап ташлаудан котылса да, Батырша аягына басарлык түгел иде инде. Драгуннарның кайсыдыр иске япанча сөйрәп килде. Мулланы шунда салдылар да дүртесе дүрт почмагыннан тотып, кәрван тукталган урынга алып киттеләр.

Болховскийның йөзе киндер булып калган, күзләре куркулы. Шүрләрсең дә, Батырша үлгән тәкъдирдә, аның үзен дә дар агачы көтә. Шуңа да ул ашыгырга булды. Хәзер үк кузгалырга да, төн буенча барып, Мәскәүгә җитәргә һәм бәланс төрмә шифаханәсенә урнаштырырга!

Дүрт почмагыннан тартылган япанчада талгын гына чайкалып баручы Батырша исә кул-аяклары, тәне-башы сызланудан, саташулы-уяу хәлдә, ишетелер-ишетелмәс кенә ыңгырашып бара. Ул әледән-әле онытылып китә һәм, йә берсеннән-берсе ямьсез төшләр күрә: әнә аны гомер бакый эзәрлекләүче Каракош килеп чыкты, башына кунды һәм миен чукый башлады...

Ул уянып китте һәм, башы сызлаудан бигрәк, төше өзелүгә гасабиланып, тешләрен шыгырдатты, ыңгырашты.

## Уналтынчы бүлек

Гыйсьянчы мулланың тотылуы уңае белән гомер сөргән урыннарыннан кубарылучылар Батыршаның гаиләсе һәм көрәштәшләреннән башка да байтак иде. Августның егерме алтысында Оренбурга өлкән углы Давыт белән старшина Сөләйман Деваев килеп төште.

Батыршаны ышанычлы кулларга тапшыргач, Сөләйман янә авыраеп китте: һич сәбәпсез туңып-калтырап йөдәде, хәле тәмам бетеп, урынга егылды. Алланың рәхмәте табиблар, им-томчылар, хәтта тирә-юньдәге иң абруйлы муллалар да булдыра алмаганны Уфа кәнсәсеннән килгән бер кәгазь кисәге әйләндерде дә салды — старшина икенче көнне үк аягына басты. Әлеге хикмәтле кәгазьдә старшина Сөләйман Деваевны, мәгълүм ярлыкаш акчасын алу өчен, Оренбурга чакыралар иде.

Ходаның хикмәте диген, шул көннән бөтенләй үзгәреп китте ул. Көймәле арба әзерләтте һәм ерак юлныназланып кына үтәсе итте. Вә

һәм бик дөрес эшләде, ястыкка сөялеп, юрганга төренеп баруына карамастан, юл газабы аның карт тәнен тәмам ваткан иде. Шуңа да ял итәргә ашыкты Деваев.

Ни хикмәттер, губернатор аларны кабул итәргә ашыкмады. Неплюевта өтек мишәрләр хафасы юк иде. Башта ул Батырша явында катнашучыларны ярлыкау хакындагы указны ашыктырды. Аның таләбе буенча, Сенат әлеге указны 1755 елның беренче сентябрендә үк игълан итте. Губернаторның исәбенчә, ярлыкау хакындагы сүзне ишетүгә, башкортлар, өерләре белән, элек яшәгән җирләренә кайтырга тиешләр иде. Ни гаҗәп, тегеләре кайту турында уйламадылар да. Үз тауларына кайтып егылган һәркемгә бирәр чикмән вәгъдә итүнең дә файдасы тимәде хәтта. Бу эштә иң кулае, әлбәттә, морза Тәвкилев иде. Иван Иванович шул хактагы фикерен канцлер Бестужев-Рюминга язып җибәрде, Алексей Ивановичка генерал-майор чинын бирүне ашыктыруларын сорады.

Сенатта үзенең һәр сүзенә ләббәйкә дип торуларын яхшы белгәнгә, Неплюев бу юлы да башкаладан җавап көтеп тормады, морзаны кабинетына чакыртты, һәм гадәтенчә, тәкәллеф белән сүз башлады:

— Сезгә, Алексей Иванович, тагы бер җаваплы эш чыгып тора бит әле, хөрмәтлем...

Морзаны алмаштырып куйганнар диярсең:

— Теләсәгез нишләгез, Иван Иванович, әмерегезне җиренә җиткерә алмаем, арыдым, картайдым, җаным ял сорый,— дип карулашты.

Шул борчулары белән өч-дүрт көн үтте микән, Сенаттан язган хатына җавап килеп төште. Канцлер Бестужев-Рюмин губернатор фикерен хуплавы белән бергә морза Тәвкилевкә генерал-майор чины бирелүен хәбәр иткән.

Пакеттагы кәгазьләр белән танышып чыгуга, Неплюев янә морзаны чакыртты һәм, әлбәттә, сүзне картның күңеленә хуш килердәеннән башлады:

— Менә шулай, Алексей Иванович, көткән сәгатебез сукты — генерал-майор чины белән ихластан котлыйм үзеңне, кадерлем!

Тәвкилев әллә нишләп китте, сырхауларын да, картлыгын да онытты, ризалык сүзенең авызыннан чыкканын тоймый да калды:

— Баш өсте, галиҗәнап. Тик бер шартым бар: крестьяннарым бөтенләй диярлек калмады минем, Иван Иванович. Җирләрем арта тора, ә эшләргә кешем юк.

— Алырсыз, Алексей Иванович, әлбәттә алырсыз. Тик сез аларны башта кайтарыгыз әле.

Тәвкилев миссиясе — урдага гади шымчы, яисә озын колак җибәрү генә түгел. Шулай ук башкортлар хафасы белән генә дә чикләнми. Ул казакъ урдаларының Россия канаты астына керүләрен тәмамлаштырырга тиеш! Морза анда Урта урда ханы Нурали, аның туганнары Эрали һәм Айчувак белән очрашачак. Димәк ки, бу эшкә акча-малны кызганып булмый.

Сөләйман исә бүләк алучы авылдашларының шатлыктан колакларына кадәр ерылган авызларына карый-карый, боегып калган иде дә, Котлымөхәммәт морза телгә килде бит әле:

— Сиңа, Сөләйман ыстаршина, олуг бүләкне мәрхәмәтле падишаһымыз үзенең изге куллары белән тапшырырга булды? — диде.

Бүләкләү мәҗлесенә Яныш старшина да чакырылган икән. Тик нишләп килмәгән? Хәбәрен ишетми калганмы, чирләп-нитеп киткәнме?

Болай уйлап, ялгыша иде Сөләйман. Хикмәт шунда ки, тәүфикълы булып кыланган астыртын мәчегә тиң Сөләйманны соңгы вакытта җене сөймәс булды ул. Зурдан купмады, үзенә иптәшкә олы улы Солтанбәкне генә алды да ерак юлга чыкты. Оренбурда ул, Сөләйман старшина белән очрашмас өчен, кала читендәге бер йортка фатир төште. Кәнсә тирәсендә уралмады, бар эше Сөләйман артыннан шымчылык итү булды. Губернаторның кабул итү көнен-сәгатен дә белмәде түгел Яныш, мәгәр тан-

таналы мәҗлескә махсус бармады, көндәшенең Оренбурдан китеп олагуын көтте.

Сөләйманны пайтәхеткә аны үзенең писары Мөхсин белән татарчаны су кебек эчүче капрал Петр Ашмарин озата барачаклар, имеш. Юлына, дип, кулына, ярлыкаш акчасы исәбеннән, биш йөз сум акча бирделәр, ям станы саен өчәр олау алу өчен юл кәгазьләре тоттырдылар.

Өч юлаучы Яман каладан шау-шусыз гына чыгып китте. Шуны гына көтеп, ирennәрен чәйнәп бетергән Яныш, икенче иртәдә үк губерна кәнсәсенә килде, әмма тагы оттырды. Аны губернатор үзе түгел, ярдәмчесе дә кабул итмәде хәтта. Яныш белән әлеге дә баягы эшлекле-елгыр секретарь сөйләште: кичекмәстән пайтәхеткә барып, олуг бүләкне падишаһ кулыннан алырга кушты, язулар бирде.

Юл азабы — гүр газабы. Кырыкмаса кырык мәшәкать-кыенлыклар күреп, өшеп-күшеп, Сөләйман, юлдашлары белән, октябрь ахырында башкалага барып егылды. Егылды дип, әүвәл Сенат ишеген какты. Монда исә аның белән юньләп сөйләшүче дә булмады.

Аларны Адмиралтейство янындагы Икенче мещан урамында яшәүче тол хатын Миллер йортына китереп керттеләр. Яңа фатирда беренче сүзе «чәй» булса, икенчесе — «урын» иде Сөләйманның. Үзе алып килгән бал белән тирләп-пешеп чәй эчкәч, ялгызы бер бүлмәдә йомшак урынга ауды старшина һәм шуннан инде кузгалмады.

Улын иярткән Яныш аларның үкчәләренә бастырып килде, тик куып җитәргә ашыкмады. Петербурга килгәч тә фатирының Сөләйманныкыннан ераграк булуын үтенде.

Язмыш дигәнең аларны гомердә төшләренә дә кермәгән җирдә — патша сараенда очраштырды — Елизавета Петровна үзе кабул итте.

Хак, башта мондагы зиннәткә вә байлыкка акылдан язар чиккә җиткән Яныш берни хакында да фикер йөртер хәлдә түгел иде. Затлыдан-затлы бүлмәләрнең берсендә, үзенең якташларын күргәч кенә, исенә килде, елмаеп куйды. Нигә дисәң, мең сум ярлыкаш акчасына ия булачак Сөләйман бөтенләй бетешкән, күзләре эчкә баткан, борыныннан кыссаң, җаны чыгар хәлгә җиткән.

Зиннәт-хәзинәдән башлары әйләнеп, егылабыз, дип торганда, каршыларында алтын тәхеттә утыручы патшабикәне күреп алдылар һәм аллы-гөлле келәмнәр түшәлгән идәнгә капландылар — падишаһка баш ордылар. Юк, бу — Рәсәйнең мәликәсе генә түгел, әкиятләрдә генә була торган алиһә. Әнә бит, күтәрелеп тә карамый, йокыга талгандай утыра.

Өстән фәрештә авазы ишетелде:

— Торыгыз, әй, сөекленәр!

Алар аякларына баскан арада, императрица яраннарына баш какты, арадан берсе — адәмнән бигрәк, күркәгә охшаганы кулындагы кәгазь төргәген сүтеп җибәрде һәм нидер укый башлады.

Сөләйман, әлбит, берни аңламый. Хәер, аңа монда сөйләгән нәрсәләрне төшенеп торуның кирәге дә юк. Фатирына кайтып яткач, тылмачы Ашмарин барын бәйнә-бәйнә сөйләп бирәчәк аңа. Яныш исә урысчаны ярыйсы үк сукалый, һәрхәлдә, сүзнең ни хакында барганын аңыша. Әмма ул да башта берни тыңламады, патшабикәне урап баскан кайсы тутый кош, кайсы әтәч сыман яраннарга карап шаккатты — бу кадәр эшсезне ничек итеп туендырмак кирәк?!

Чү, теге күркә Сөләйман старшинаның нинәр белән бүләкләнүе хакында укый түгелме соң? Ие, шулай. Әнә бит ни ди:

«Авырлыгы дүрт кадак та кырык алты мыскал булган, алтын йөгертелгән көмеш чүмеч. Аны Санкт-Петербург цехы остасы Иван Фейрбах сиксән өченче сафлык дәрәҗәсендәге көмештән йөз сиксән сигез сум да унике тиен ярымга төшереп ясаган. Аның рәвеше озынча булып, зур булмаган дүрт аякта тора. Аңа түбәндәге сүзләр язылган: «Императрица галиҗанәпләренә тугры вә ихлас хезмәте өчен мишәр старшинасы Сөләйман Деваевка һәдия ителә».

Сөләйман Деваев өчен кылыч полковник Яков Шубскийдан ике йөз алтмыш сумга сатып алынды һәм дә аны чарлаган-бизәгән өчен патша сараеның алтын эшләре остасы Георг Экартка йөз кырык биш сум түләнде, димәк ки, ул кылыч казнага дүрт йөз дә биш сумга төште. Кылычның кынысы кура җиләге төсендәге бәрхеткә алтын-көмеш кунысы төшереп ясалган, сабы — көмеш. Кынысы да, сабы да фирүзә, яшма һәм башка ташлар белән бизәлгән. Кылычка мондыен юллар язылган: «Алланың рәхмәте белән без, Елизавета, бөтен Россия императрицасы вә хөкемдары һәм башкалар, һәм башкалар ошбу кылыч белән мишәр старшинасы Сөләйман Деваевны тугры вә ихлас хезмәте өчен бүләкләдек».

Чикмән — кура җиләге төсендәге бәрхеттән, зәңгәр ефәк белән эчләнгән, һәр яктан алтын өрфия белән уратып алынган. Кыска чикмән — алтынсу парчадан, эчлеге — алтынсу өрфия белән бизәлгән ак саржа, сәдәфләре көмеш, кысаларда шәрык бәллүрләре. Кеш тиресеннән тегелгән бүреккә ун карыш бәрхет, ике тире тотылды, түбәсе — чикмәннеке төсле үк бәрхеттән. Җәмгысы дүрт йөз сиксән өч сум да илле бер тиенгә төште.

Төрле төсләрдәге ефәктән тукылган көмеш кәмәр Мәскәүдәге ефәк тукымалар фабрикасы һәм завод тотучы беренче гильдия купец мещан Василий Макарович Хостатовтан кырык сумга сатып алынды. Барлык бүләкләрне төргүгә сиксән дүрт тиен тотылды. Димәк ки, Сөләйман Деваев бүләкләре мең дә бер йөз унҗиде сум да кырык җиде тиен ярымга басты».

Яныш күркәдәй кабарганын тойды, тәне кызышып, битләре янып чыкты — шартлар хәлгә җитте. Шул мизгелдә Сөләйман кинәт гөрселдәп егылды — аны күтәреп аулак бүлмәгә алып киттеләр.

Яныш исә, шул ыгы-зыгыдан файдаланып, тышка чыкты.

Атлый торган урамы бик олыдан булып, шау-гөр итеп тора, һәр ике ягында — кибет-хәрчәүнәләр. Ул ямьсез уйларыннан һәм күңел газабыннан арынырга ниятләп, шул хәрчәүнәләрнең берсенә барып керде. Менә бәхет, монда бөтенләй диярлек кеше заты юк. Кереп өлгермәде, янына өрлектәй егет — половой килеп басты.

Аллы-артлы ике чәркәне бушатып, әллә ниләр кыландырып кызлырылган калҗа капканнан соң, кәефе үзгәрде дә куйды Янышның, чыраена мөлаемлык чыкты, иреннәренә елмаю кунды — бая гына патша сараенда үртәлүләре чүп кенә бер нәрсә булып калды.

Ресторан дигән нәрсәләр күңеленә хуш килде Янышның. Аларга икенче көнне дә, өченчесендә дә, аннан соң да барды. Атасының холкынгадәтен яхшы белгән Солтанбәк башта дәшмәде. Ниһаять, сабырлыгы төкәнде. Юк кәгазьләрен рәтләде, кием-әйберләрне, патша сараеннан китерелгән бүләкләрне төенләп куйды. Һәм беркөнне иртән махмырдан интегеп утырган атасына шактый каты итеп әйтеп салды:

— Атай, китәек! — диде.

Әмма тыныч кына китә алмый калдылар.

Төн урталары булды микән, таң алдымы, Солтанбәк ниндидер тавышка уянып китте. Берәү, ач бүре улаган авазлар чыгарып, ишеклетүрле йөренә, нәрсәләргәдер абына ниләрнедер аудара.

— Уты гына да юк бит аның,— дип сукранды ул карангыда һәм янә кунагын көйләргә-чөйләргә тотынды.— Утыр әле, Яныш агай, берәр чокыр эчеп җибәр!

Менә Яныш мич почмагын кочаклап алды да бәрелгәли-сугылгалый башлады.

— Мичне ишә! — дип кычкырып җибәрде хуҗа.

Солтанбәк сәкедән төште:

— Әдә, атай, ятаек! Тана!..

Сүзен әйтеп бетермәде, маңгаена Янышның зур йодрыгы килеп төште, күзеннән утлар чәчелгән егет сәке буена тәгәрәде. Шуннан инде

бөтенләй кулдан ычкынды атасы, ул гөрселдәтеп өстәлне әйләндереп капладь, чалтыратып тәрәзәне коеп төшерде. Солтанбәк белән ямчы ана ташландылар. Акылыннан яза башлаган старшинага җен көчләре кергән диярсең...

Яныш башкача селкенмәде. Ямчы белән Солтанбәк мүкәләп, яшеренгән урыннарыннан чыктылар. Исәпләре йокыга киткән старшинаны күтәреп сәкегә салу иде. Янышка тотынулары булды, икесе беравыздан кычкырып җибәрделәр:

— Әбәү! Боз кебек!

Атасының үле гәүдәсен, ям чанасына салып, калган юлына алып чыкты Солтанбәк.

Февральнең ундүртенче төнендә Сөләйман старшина да җан тәслим кылды. Ярый әле, кесәсендә йөз илле сум акчасы калган икән. Шуның кырык сумын сарыф итеп, Мөхсин аны Выборг ягы зиратына саф мөселманнарча җирләде. Хәерсез хәбәр Сенатка ук барып ирешә. Оберпрокурор Трубецкой атаклы мишәр старшинасының әйберләрен барлап, опись язарга һәм аларны, имзалык яздырып, Мөхсин писарьга тапшырырга кушты.

## Унҗиденче бүлек

Мәскәүдән Петербургка кадәр сузылган озын юлда Батыршаны карау-күзәтү тәртибе элеккечә калса да, аның юлдашлары — офицерлар һәм драгуннар күзгә күренеп үзгәрделәр. Ука суы буендагы вакыйгадан соң, эчү-исерү дигәнне бөтенләй оныттылар. Инде үз-үзләрен тотышлары ук башкача: гамәл-шөгыльләре хәрбиләрчә төгәл, фәрманнар кальгадагыча ачык-кыска, солдатлар исә аларны үтәүдә йөгереп кенә торалар.

Кыскасы, бар да әйбәт, бар да — губернатор инструкциясендә язылганча. Көннәр генә суытты. Ләкин Батырша өчен монысы да хафа түгел, аның туны да, бүреге дә, киез итекләре дә бик җылы, астындагы киезе йомшак. Мәскәүдә чанага күчереп утыртылган көймә дә хәзер инде элеккечә талкымый, йомшак һәм җай. Менә-менә Петербургка житәрләр, мөгаен. Капитан Болховский белән поручик Левашов һәм драгуннарның сүзеннән дә шуны чамаларга була.

Алай да бүген көндәлек тәртипкә әллә ни булды әле. Батырша иплән ятарга өлгермәде, ишегалдында фәрман авазлары ишетелде. Батыршаны җилтерәтеп киендерделәр дә тышка алып чыгып киттеләр. Бакса, атлар җигүле, капка ачык. Аны гадәттәге урынына кертеп, авыр карагай кискәсенә чылбырлап куюга, озак тик торудан ялыккан атлар, урыннан ук юыртып, кузгалып та киттеләр.

Бу серле төнге сәяхәтнең асылына төшенә алмады Батырша. Хәер, бүгенге сәер хәлләр аны һич кенә дә пошындырмый иде. Әйдә, ашау — байдан, үлем — ходайдан, барысы да — зобанилар кулында. Үзен шулай юатып, тынычлап йокламакчы булды тоткын. Тик күзенә йокы эленмәде. Тунының якасын күтәреп, киезе өстенә җайлап ятты да, чана табаннарының, нәрсәгәдер ризасызлык күрсәтеп, ыңгырашуларын тыңлыйтыңлый, уйга батты...

Ие, Мәскәүдә, нишләптер, байтак — бер ай чамасы тоттылар аны. Аңа хәтле исә төрмә шифаханәсенең ятагында аунады мулла, ике атна чамасы шул «оҗмах»та ятканнан соң, аны дапруска чакырдылар.

Сорау алучы гаять тә купшы, алтынланган пагунлы гаскәри түрә иде. Урысчаны аның сүзләрен генә аңларлык сукаласа да Батырша:

— Низнай, нипанимай, — дип тәкърарлады.

Икенче көнне аны шул ук бүлмәдә яп-яшь әфисәр каршылады һәм, мулланы гаять гаҗәпләндереп, саф татарча әйтеп куйды:

— Утыр, мулла, һәм сөйлә: кәефең-исәнлегең ничек?

— Шөкер,— дип әйткәнен сизми дә калды Батырша.

— Мин Сенатның обер-секретаре Хрущов буламын,— диде түрә.

Батырша байтак кына дәшми утырды, аннан исә тегенең күзләренә туры карап, ярып салды:

— Бән рәхмәтле мәликәбездән башка берәүгә дә берни әйтмәймен.

Түрә мондыен җавапны һич кенә дә көтмәгән иде бугай, аптырап йөдәп калды, шактый гына сүзсез утырды, аннан сүрән генә әйтте:

— Ярый, киңәшербез. Барыгыз, ял итегез!

Атна буе аны борчучы булмады. Беркөнне исә төрмә-шифаханә хәдимнәре мулланы янә теге бүлмәгә алып киттеләр. Анда Батыршаны әлеге дә баягы татарча белүче әфисәр көтә иде.

— Менә нәрсә, мулла Батырша, без императрица җәнапләре белән хәбәрләштек. Кызганыч, алар сезне кабул итә алмый. «Безгә житкерәселәрен кәгазьгә язып бирсен» — диделәр.

— Ә ул төркине укыймы?

— Үзләре укымый укуын, тылмач-тәрҗемәчеләре бар.

— Бән серемнең берәүгә дә фаш булуын теләмим.

Мулланың кирелегенә кәефе кырылса да, ачуын йөзенә чыгармады Хрущов, һаман да ягымлы булырга тырышты:

— Алайса, без болай итик, мулла. Язганнарыңны букчага салыйк та сургычлап куйыйк. Янә дә килеп, хатны мин императрица җәнапләренә үз кулларым белән тапшырачакмын. Валлаһи ачмыйм, мулла!

Шул сөйләшүдән соң ул төрмә шифаханәсендә үзенең беренче таныкнамәсен язды. Әмма барын да ачып салмады. Батырша әле һаман да мәрхәмәтле мәликә белән очрашасына өметләнә иде...

Ул олауның убылуыннан уянып китте. Алай да үре бик кыска булды. Ул да түгел, атлар өстәл өсте кебек тигез җирдән, әллә инде боз өстеннән, атладылар. Вакыйган, елга кичтеләр, ахыры, чана текә үргә күтәрелде һәм, озак та үтми, туктап калды.

Батыршаның чылбырын шомарып беткән кискәдән ычкындырдылар, чанадан төшерделәр һәм, кәмит аюы мисалында, житәкләнгән хәлдә каядыр алып кереп киттеләр.

Яңа «фатир»ның бихисап бүлмәләрендә тоткынга урын табылмады. Аны таш баскычтан аска — дымык исе килеп торган караңгылыкка төшерделәр. Хибесханә исе килде.

Туктадылар. Тупас тимер ишекнең йозаклары шалтырады, күгәрә башлаган иләмсез зур күгәннәр шыгырдады. Аны жиңелчә төртеп җибәрделәр дә, шул ук иләмсез тавышларны чыгарып, өстеннән биклəп алдылар.

Ие, кабат хибесханә. Алар провинциядә дә, губернада да, башкалада да бер үк — төрмәнең үзгә сасы исе.

Яптылар да оныттылар. Ник кенә бер исләренә төшереп, янына керсеннәр дә, ник кенә бер чакыртсыннар.

Уйлары шул хәтле шомлы, шул хәтле дә көенечле иде ки, Батырша тәмам хафага калды. Ул әле Уфада чакта ук зиндан каравылчыларын иң олы түрә белән очраштыруларын сорап йөдәтте. Оренбурга килгәч, шул өметенең чыңга ашачагына ышанычы артты. Ниһаять, мәхбүс катына керде Ниплүй янарал, әмма ачыктан-ачык сүзләшүдән качты. Инде монда — падишаһ ишеге төбенә килеп житкәч тә, аңа илтифат итүче, чакыртып сүзләшүче юк.

Ул әнә шундый шөбһәле уйлар диңгезендә кайнаган көннәрнең берендә, хибесханәнең авыр шыксыз ишеге иләмсез шыгырдап ачылды, һәм янына ике бәндә килеп керде.

— Жыен, дапруска! — диде аларның берсе.

Тар, озын аралыктан атлаган уңайга, аз-маз күз төшергәләп кенә алса да, дөресен чамалый иде Батырша. Рәсәй империясенең олы диңгезгә чыгуы хакында бөтен Европага сөрән салып һәм илнең куәтен кычкырып торган бу манараны — Петропавел каланчасын шул 1756 елның

утызынчы апрель төнендә яшен суккан иде. Манараның янган өлешен кирпечтән һәм тимердән ясап төзәтү әле озакка — елдан артыкка. Батырша моннан киткәнчегә тиклем сузылачак иде.

Бүлмәләрнең берсендә иске танышы — обер-секретарь Хрущовны күргәч, күңеле күтәрелеп китте Батыршаның, бу очрашуны хәерлегә юрады. Ник дигәндә, Хрущов аны, әлбәттә, шанлы мәликә белән очраштырачак.

Вә әй хәсрәт, обер-секретарь маңгайга шапылдатып суккандай, кисәк әйтеп куйды:

— Ярый, мулла, шаярмадык түгел, шаярдык. Инде явызлыкларың турында сөйләп бир! Императрица җәнапләре хатынны тыңлап бактылар, мулла, вә һәм канәгатьсезлек белдерделәр. Бик аз язган, диләр.

— Азсынса, катына чакыртсын, барын сүзләрмен!

Хрущов нәзек аскы иренен тешләп, тынып калды. Ни дисен инде бу кире беткән татарга?! Елизавета Петровнаның әледән-әле чире тотып егылуын бәя итмәссең бит аңа?!

Батыршаны шул көнне үк, чын мәгънәсендә, таш ләхет булган казаматларның берсенә күчерделәр. Ялгызлыкта атналар, айлар үтте, аны искә алучы булмады. Төшенде Батырша: явыз түрәләр аның рәхимле падишаһ янына барып житүен өнәмиләр. Шул уеннан йөрәге «жу-у» итеп китте Батыршаның. Юк, аның үләсе килми! Нинди генә михнәтләр, җәбер-золымнар күреп булса да, якты дөньяда яшисе килә әле аның. Тик бу тар, салкын ләхеттән ничек котылырга да, хөр, иркен дөньяга ничек чыгып егылырга?

Инде өмете бөтенләй киселеп, шәм сыман сүнәргә генә калдым дип яткан көннәрнең берендә, миендә ажаган уйнап алгандай булды Батыршаның. Ул тупас һәм пычрак сәкесендә аунаган җиреннән сикереп торды, шашкан кешедәй, ишекле-түрле йөренә башлады, иреннәре пышылдады: «Котылу юлы бар бит, бар! Тәвәкәлләргә генә кирәк».

Миенә ачыклык иңгән шул көнне үк ниятен ныгытып бетерсә дә, ошбу уен атна буе чарлады Батырша, котылуның башка әмәлләрен эзләп карады. Инде башкача чара юклыгына инангач, салкын төрмә ишеген йодрыгы белән дөмбердәтергә тотынды.

Тавышка сакчы килеп житте, ишектәге «күз»дән сорады:

— Нишләп ишек жимерәсең, гололобый?!

— Әфисәрне чакыр, сүзем бар!

— Сүзең ни? — диде ул, мыскыллы елмаеп.

— Сүзем улдыр, бән урыс диненә күчәргә ният иттем.

Әлеге сөйләшүдән соң нәкъ бер атна үтте дигәндә, Батыршаны тагы каядыр алып менеп киттеләр. Беркөнге бүлмәгә түгел, икенчесенә — яктырак, зиннәтлерәк вә зуррагына алып керделәр. Мулланың күзенә иң әүвәл ташланган нәрсә исә затлы өстәл-урындыклар да, идәндәге йомшак келәмнәр дә, патшабикәнең диварга эленгән олы сурәте дә, әллә кайсы мәмләкәтләрдә ясалган хикмәтле биек сәгать тә түгел, каршындагы киң, иркен вә рәшәткәсез тәрәзәдән күренеп торган теге әкияти манара, кояз чиркәү иде.

Рәсәйнең бөеклеге булып алдына баскан шул илаһи күренешкә ымсынып торган арада, әйтерсең лә түшәмнән, ягымлы вә садә аваз килде:

— Узыгыз, утырыгыз, мулла, — диде аваз, саф төрки белән.

Сул як почмакта, өстенә кура җиләге төсендәге постау ябылган өстәл янында бер бәндә утыра.

— Менә биредән рәхим итегез, мулла, — дип кабатлады «фәрештә», янәшәсендәге үзенеке сыман ук кәнәфигә ымлап.

Инде Батырша да мәсьәләне төшенеп алды — бу адәм ул үзе сораган урыс пубы булырга туры килә.

— Мин Петр вә Павел соборының ключаре Стефан Левицкий.

— Ключар ни-нәрсә ул?

Батыршаның кинәт күңеле сүрелде, чырае сытылды:

— Бәнем пуп нше урыс гали-голәмәсе берлә сүзләшәсем килгәние...
— Мине нәкъ үзегезгә кирәкле галим-голәмә дип кабул итә аласыз!
Мулла аңа эчке бер җылылык һәм хөрмәт белән карап алды, ак та, кара да димәде, каршындагы манараның иң очында матапучы осталарга бакты. Левицкий исә:
— Батырша әфәнде, сез христиан диненә күчәргә теләк белдергәнсез. Әгәр шулай икән,— диде.
— Сиңа хагын әйткәннәрдер, кем Ычтапан. Күчәм. Вә ләкин нәсарә диненең исламнан яхшырак вә өстенрәк икәненә инандыр!
— Кайсы да булса диннең, тәгълиматның һәм фикриятнең асылын ачыклау, аның уңай якларын исбатлау өчен айлар димим, еллар кирәк, Батырша әфәнде. Шулай да динебезнең кайбер үзенчәлекләре, сез әйткәндәй, өстенлекләре белән таныштыра алам. Христиан диненең сафлыгын, хаклыгын һәм бөеклеген шул нәрсә ачык күрсәтәдер ки, ул исламнан борынгырак. Сез, әлбәттә, беләсез: Мөхәммәт пәйгамбәр үзенең өйрәтүләрен яңа эраның алтынчы гасыры азакларында башлап җибәрә, безнең дин исә исламнан биш йөз еллар алда туа, мулла.
Левицкийның борынгы хәкимнәргә охшый төшеп, үтә белдекле булып кылануы көлке тоелды. Батырша укыган тәварих китапларында болгар бабаларыбызның исламны, урыслар үз диннәрен тапканчыга кадәр, күп элек кабул итүләре хакында язылган, остазлары Габделрахман белән Габделсәлам да гел шулай сөйләде.
— Сән, Ычтапан, боларны каян алып сүлисендер, белмәем. Мәгәр бар халаекларга мәгълүмдер ки: сезнең урыс бабаларыгыз, аю өннәрендә яшәп, попларга вә карурманнардагы төрле кирәмәтләргә табынып, саташып йөргәндә, безнең болгар бабаларыбыз пакь таш мәсҗедләрдә аллага сәҗдә иткәннәр.
— Хәзерге Россия җирләренә нисбәттә, сез хаклы, Батырша әфәнде.
Болай да сөйләшергә тансыклап беткән Батыршада бәхәсче комарлыгы кузгалды:
— Әйә, башкаларны күз уңында тотасың икән, Ычтапан. Анысы хак, изге китаплар Коръән Кәримгә кадәр дә булганнар. Алла Муса пәйгамбәр аша Тәүратны, Давыт аркылы Зәбурны, Гайсә ярдәмендә Инҗилне җиргә иңдергән. Вә ләкин шунысы аяныч ки, хәтта яһүдләргә дә хакыйкатьнең бер өлеше генә җиткерелгән. Алар үзләренең гафилләкләре берлә алла васыятьләренең байтагын онытканнар, эчкерлекләре дә хөсетлекләре илә кайберләрен гавемнан яшергәннәр, яисә бозганнар-үзгәрткәннәр. Менә шуңа да хак тәгалә Мөхәммәт хәзрәтләрен илче итеп җибәрә. Нәзарә динендәгеләр — әле дә шул томаналыкларында.
Надан татар мулласы бәхәскә бу кадәр дә маһирдыр дип көтмәгән иде Левицкий, мәгәр Батыршаны чәнчеп аласы итте:
— Менә-менә, үзегез үк икърар итәсез, Батырша әфәнде. Тәүрат, Зәбур, Инҗилләр — борынгы китаплар, Коръән исә шактый соң барлыкка килгән. Инҗилнең бер юнәләше, тармагы гына. Мөхәммәт исә — Гайсәнең шәкерте генә!
Коръән Кәрим турында бу кадәр үк көфер сүз ишетү Батыршаны чыгырыннан чыгарды. Ул, кайда һәм нишләп утыруын һич уйламастан, зынҗырын чыңлата-чыңлата, сикереп торды, Стефанның өстенә очып кунардай булып, тезеп китте:
— Хаталанасың, Ычтапан. Коръән Кәримнең Тәүрат белән охшаш урыннары төрле чорларда барлыкка килсәләр дә, бер алла тарафыннан иңдерелгәннәр. Вә ләкин Коръән һич тә кабатлау түгел! Ул — мәһабәт бер бинадыр! Ул бит — Рәсүлулла үзе уйлап чыгарган нәрсә түгел, алла сүзләре. Аның төп нөсхәсе хак тәгаләнең тәхете астында саклана. Коръән — егерме ел дәвамында Мөхәммәт галиәссәламга Җәбраил фәрештә аша өлешләп индерелгән хакыйкатьтер.
— Туктагыз, артыгын кайнарланмагыз, Батырша әфәнде, утырыгыз,— дип туктатты аны Левицкий. Чөнки ул бу дуамал бәндәдән

чын-чынлап курка калган иде. «Богаулары белән башыңа тондыруы да бар»...— Сез дөрес әйтәсез, мулла, дин булмаса, кешеләр әле күп еллар буе кыргыйлыктан чыга алмаслар иде. Бу— хакыйкать. Ләкин ул хакыйкать башка диннәргә дә карый. Чөнки диннәрнең максатлары уртак— халаекларны буйсынуда тоту.

Батырша кәнәфиендә кымырҗып, сикергәләп алды, алай да үзен-үзе тыя төште, тик барыбер урыс пубына каршы дәшми кала алмады:

— Вә әй хәсрәт, сән бөһтан сүз сүзлисең, Ычтапан. Бән, сәнең күк, башка диннәрне үрәнмәдем. Үзебезнең хак динебез исламнан башкасын белмим диярлек. Вә ләкин сүзеннең хак булмавын чамалыйм. Ник дигәндә, безнең динебез берлә урыс дине арасында, кара исәп белән генә дә, аерымлыклар буа буарлык.

— Мәсәлән?

— Һы, әйдә, диннең нигезеннән башлыйк!— Аллаһы тәгаләдән. Мөселманлыкның беренче шарты— аллаһның барлыгын вә берлеген тану ул. Шуңа да без: «Ля илляһы иллалаһы Мөхәммәд рәсүлуллаһ»,— дип иман китерәбез. Сезнең урыс алласы исә— почмакка куелган ябай бер сүрәттер. Аңа табынырга да, аны чүплеккә чыгарып ташларга да мөмкин. Җитмәсә, аллаларыгыз бихисап.

Мулланың үтә наив фикер йөртүе янә көләсен китерде Левицкийның. Ләкин вакыты авыз ерып утыра торган түгел, христиан диненең бөеклеген расларга кирәк:

— Сез төшенеп бетмәгәнсез, Батырша әфәнде. Алла— алла инде ул. Христиан динендә дә үзенең асылы белән берәү генә. Ләкин ул өч шәхес буларак— бер: алла— ата, алла— ул һәм изге рух. Иконаларда Христос, алланың анасы, шулай ук изгеләр сурәтләнә.

Стефан бик тәфсилләп христиан диненең асылы хакында сөйләмәкче иде дә Батырша тагын сабырсызланды:

— Ул кадәресен аңламаем, Ычтапан. Бән белгән хәтлесе шулдыр: урысларның аллалары — ызба саен. Аларның гөнаһысы фани дөньяда ук кичерелә. Кем кичерә дигән әле? Ябай бер пуп. Христиан динендәге кеше гөнаһ кыла да, шунда ук тәүбәгә килә. Янә кыла, тагын тәүбә итә. Хәтерең калмасын, Ычтапан, мена шуңа да сезнең халык эчү-исерү, зина кылу, кыйнашу-җәберләшү, талау-үтерү кебек хәлләрне чүпкә дә санамый— әлхасыйл, урыс дине бәндәләрне әхлаксыз, миһербансыз, кешелексез итеп тәрбияли... Мөселманнарда исә— гөнаһ кичерелми. Әнә шул хәл аларның вөҗданнарын газаплый, бәндәләрне тагы да гөнаһ кылулардан тыеп тора.

Ключарь гади бер татар мулласының эзлекле һәм төпле сүзенә исе китеп тыңлый-тыңлый онытылып киткән икән. Чыннан да, кызык иде аңа Батыршаның фикерләве:

— Сез бик кыю һәм кызык фикер йөртәсез, Батырша әфәнде,— диде ул, тәмам комарланып киткән мулланы бүлдереп.— Шунысы аяныч, безгә саубуллашып торырга туры килә.

— Бәңа барыбер,— дип битарафлык күрсәтмәкче булган иде дә, вакытында тыелып калды Батырша, әлеге бәндә белән ни өчен очрашулары исенә төште һәм хәлне төзәтмәкче булды:

— Бәнем язмыш сәнең кулда инде, Ычтапан!

Салкын таш ләхет белән бергә Батырша башына салкын акыл да килде. «Ялгыштым, бугай,— дип уйланды ул, үзенең тупас ятагына утырып.— Ычтапан белән бәхәсләшмәү кирәк иде. Ис, дәшмәскә, ни сөйләсә, шуңа ышанган булып кыланырга һәм чукыну дигәннәрен тизләтергә!» Булмады. Кабат ялгызлыкта узган ике көнен гел диярлек намазлык өстендә үткәрде мулла.

Өченче көнне исә аны тагы өскә чакырттылар. Шул ук бүлмә, шул ук затлылык, шул ук байларча киенгән Ычтапан. Әмма бу юлы ул Батыршаны йөз ел күрмәгән туганын очраткандай кыланды, каршы килеп, мулланы кулыннан алды, житәкләп, йомшак кәнәфигә китереп утыртты.

Шунда гына күрде Батырша: бүлмәдә тагын бер яңалык бар икән — кәнәфиләр янына бәләкәй генә өстәл куелган, өстендә җиз самавыр, анысы тирәсенә хәлвә, бал ише төм-том куелган. Самавыры моңлы итеп сайрап утыра.

Ошбу күренеш Батыршаны әллә нишләтеп җибәрде, күңелен әллә кайларда калган Карыш буйларына алып китте. Ярый әле, Ычтапан сагышка батарга бирмәде аңа, нурлы бер мөлаемлык белән сүз башлады:

— Без нәрсәдә калган идек әле, Батырша әфәнде? Ә, әйе, диннәрнең аерымлыклары турында. Аларны һаман бар дип саныйсызмы?

— Санап утырсаң, бардыр инде алар, Ычтапан. Вә ләкин... ни бит... Безнең сүзгә кирәкмәсләрдер.

— Юк, юк, аларны белү бик тә кызык. Мин, мәсәлән, син сөйләгәннәр хакында уйлап караганым да булмады. Йәле, йә?

Батырша янә уйланып калды:

— Каратуннар тагы,— дип куйды.

— Алары кемнәр була инде?

— Сез урыслар аларын «монахлар» дип йөртәсез.

— Кызык, монахларга ни булган?

— Анысын сән якшырак беләсең, Ычтапан. Каратуннар гомер бакый һөҗрәләрдә ялгыз башлары яшиләр, гаилә кормыйлар, нәсел калдырмыйлар. Пәйгамбәребез Мостафа галәйһис-сәлам исә нәселсезлекне гаепләгән. Вакыйган аңлы рәвештә җиһанда нәсел калдырмау — зур гөнаһ, Ычтапан. Ә сезнең дин шуны яклый.

— Монысын инде арттырыбрак җибәрәсез, мулла. Монахлар алар шул ук дәрвишләр ләбаса. Ә мөселман дөньясы дәрвишләргә бай.

— Ие, ахмаклар һәр кавемнәрдә бар һәм булып тора. Саф мөселманнар анларны гаеп итә, дәрвишлекне нәсаранннәр уйлап чыгарган, дип саный.

Левицкий дәшмәде. Фу-у, тукта, аның максаты йолкыш бер мулланың сүзләрен җөпләп утыру түгел ләбаса. Дилбегәне кулга алырга, һөҗүмгә күчәргә вакыт. Левицкий самавырга үрелде, саф кытай чынаягына хуш ис чәчеп торган чәй ясады:

— Авызыгыз кипкәндер, Батырша әфәнде, чәйләп җибәрик!

Авызы кибүе дә хак. Аннан да бигрәк инде күптән самавырдан агызып чын чәй эчкәне юк. Ымсынып куйды, кәсәгә үрелде. Әмма сәхра исләре чәчеп торган чәйне бер генә йотып куйды да, янә фәлсәфәсенә чумды:

— Диннәремезнең аерымлыклары, аларның кайсы яхшы, кайсы яман икәне диндарларның эшкә мөнәсәбәтендә дә бик ачык күренә, Ычтапан. Коръәндә: хезмәт кешеләргә аларны туендыру, мәгыйшәтләрен яхшырту вә гөлбакча итү, сәгадәтләрен арттыру вә һәм тәрәккыят, яңарыш өчен бирелә, диелә. Шуңа да иҗтиһад итү, сөенеп-очынып, җиң сызганып эшләү, хыянәтсез гадел хезмәт, тир түгү, ни дә булса бар итү, гыймарәт кылу — мөселманларыбызның асыл сыйфатларыннандыр, Ычтапан. Чөнки җиһанда маңлай тире агызып вә көч сарыф итеп табылган икмәктән дә ләззәтлерәк икмәк улмастыр. Бәнем остазым Гәбделрахман әтә торган иде: мәңге яшәрмен, дип тырыш, бүген үләрмен, дип гамәл кыл! Һәм халаекларыбыз шулай итәргә тырышалар да. Күңелеңә авыр алмагыл, Ычтапан, сезнең халык ялкау. Менә шуңа да падишаһ анларны крипаснуй правы дигән коллыкта тота. Безнең мөселманларыбыз исә, шөкер, крипаснуй правы дигән нәрсәне белмиләр. Чөнки болай да иҗтиһад итәләр, тырышып эшлиләр.

Монысы Левицкий өчен янә чын-чынлап яңалык иде:

— Туктагыз, сабыр...— дип бүлдермәкче булды ул Батыршаны. Ләкин тегесе гүя аны ишетмәде дә, үзенекен тукуында булды:

— Мөселманларыбызның тагы бер әгъләә сыйфаты — гыйлемлектер. Чөнки гыйлем тәхсил итү, ягъни белеклек туплау — һәр мөселман өчен

фарыздыр. Коръән Кәримдә гыйлемлеккә өндәү жиде йөз илле урында телгә алына.

— Анысы, Батырша әфәнде, бер генә дин дә уку-мәгърифәтне инкарь итми. Христианнарда да мәгърифәткә өндәгән китаплар бихисап.

— Бәлкем шулайдыр да, бән аларын белмәем. Күрмәдем, укымадым. Анын каравы, сезнен Иван патша Казанны алганнын соңында, мал-мөлкәт талау белән генә калмый, китапханәләрне, әллә ничә гасырлар жыелган елъязмаларны, шәҗәрәләрне, тәварих төпләмнәрен яндырта. Ханлыктагы дүрт йөз сиксән өч мәсжед белән бергә шул ук микъдарда мәдрәсәләр дә көл-күмергә әверелә...

— Сугыш — сугыш инде ул, мулла. Анда мал-мөлкәт кенә түгел, рухи хәзинәләр дә юкка чыга.

— Алаймы?! Ә 1742 елның сезнеңчә нуябернен унтугызынчы көнендә чыккан мәгълүм указ нигезендә, Казан өязендә дүрт йөз унсигез, Тубыл губернасында туксан сигез, Хажитархан йортында өч дистә мәзжед жимерелә вә яндырыла. Алар берлә бергә, әлбәттә, йөзләрчә мәдрәсәләр, бихисап китаплар да һәлак була. Болары да сугышмы?! Бән ул чорны үзем күреп беләмен, Идел-Урал төбәгендә олы кыргыннар булмады...

Искәндәр дә ярты дөньяны басып алган, мәгәр мәдрәсәләр яндырмаган, бәлки үзе яулаган жирләрдәге бөтен китапларны жыйдырып, Мысырда искитмәле китапханә ачкан...

Левицкийның башы үзеннән-үзе иелде, йөзе тимгел-тимгел кызарып чыкты. Ул инде бу авызына шайтан төкергән мулла белән бәхәс кузгатуына үкенә үк башлаган иде. Искәндәр дигәне — Александр Македонский! Күр, ниләр белә бу такырбаш!

— Барыннан битәр, — дип сөйләвендә булды Батырша, кызып-кызып, ислам — ярлыларны, изелгәннәрне, юксылларны һәм мәхрүм ителгәннәрне яклаучы дин ул. Безнең хак динемез гаделлекне, урталыкны, халаеклар тигезлеген, дуслык вә туганлыкны, нәфес тыюны хуплый, мал жыюны, байлыкны гаепли.

— Болары инде, Батырша әфәнде, бөтен диннәрнең дә әлифбасы.

— Белмәем. Сезнең түрәләр, завут хужалары вә һәм башка байларыгызнын кара урыслар берлән бергә чукынганнарын күргәнем юк бәнем. Жир-суларын басып алалар, үзләрен, телләрен, диннәрен кимсетәләр сәнең диндәшләр, Ычтапан, бәндәләрне кол итеп саталар. Әнә безнең Котлымөхәммәт морза да, муенына тавык тәпие тагуга, кол биләүчегә әйләнде. Шул булдымы тигезлек?!

Инде соңгысы, Ычтапан. Урысларда хөкем вә мәгыйшәт кануннарын, ягъни төрле указларны падишаһлар һәм хәкимнәр чыгара, хокук мәжмугалары диннән башка яши, чиркәвегез исә дини өйрәтүләр берлә генә чикләнә. Ә безнең мөселманнарыбызда хәкимият бүленми. Хак Тәгалә бердәнбер кодрәт вә хәкимият иясе булганы кебек, безнең динемез вә мәгыйшәтебез дә уртак. Сүзем шулдыр, Ычтапан, урыс дине — узган заманнар дине булса, безнекенең кулында — киләчәк!

Болары инде чамадан тыш иде. Тик барыбер Левицкий Батыршаны бүлдерәсе итмәде. Аңа диннәр белгече һәм булачак миссионерга бу акыллы мулланың фикер йөртүе һәм фәлсәфәсе бик кирәк. Алай да телдәр мулланы туктату чарасын күрә башларга вакыт. Һәм ул саналган чарасына ябышты:

— Күп сөйлисез, Батырша әфәнде — тамагыгыз кипкәндер. Әйдәгез, тагы чәйләп алыйк!

Сүзсез генә чәй эчеп куйдылар. Левицкий кабат чәй ясады. Тегесе исә, дөньясын онытып, каршындагы тәрәзәдән күренеп торган зиннәтле манарага карап тора иде.

— Шәп бит, ә, мулла, — диде Левицкий, соборга ымлап. — Нинди хозур! Сез аның эчен, иконастасын күрсәгез әле!

Батырша уянып киткәндәй булды һәм иренеп кенә әйтеп куйды:

— Сүз дә юк, чиркәүләрегез зиннәтле сезнең,— Теләр-теләмәс кенә әйткәне ойый башлаган фикерен уятып җибәрде бугай, ул, монысы да онытылып калмасын әле дигәндәй, ялгап алып китте.— Ие, пайтәхеттәгесен әйткән дә юк, хәтта ябай авыллардагы чиркәүләрегез дә купшы, мәһабәт — бер күрүдә кешене әллә нишләтеп җибәрә. Ул алтын тәреләр! Ул көмеш шәмдәлләр! Үтә дә купшы әллә ниткән сурәтләр, күмәкләп башкарылган җырулар, ымсындыргыч исләр, чаң кагулар... Сез — христианнар, шулар берлә бәндәләрнең хисләренә тәэсир итеп, анларны шаккатырмакчы. Безнең динемездә исә адәмнәргә тәэсир итү сүз ярдәмендә башкарыла. Болар икесе ике нәрсә, Ычтапан. Шуңа да нәсаранлар берлә мөселманлар арасындагы аерма — җир берлә күк арасы!

Стефан аның бу сүзләрен игътибарсыз калдырды, үзенең һөҗүм алды разведкасын җәелдереп маташты:

— Мөселманлар күп ләззәт вә рәхәтлекләрдән мәхрүмнәр...— диде.

— Ислам мөслим вә мөслимәләрне һәртөрле бозыклыклардан тыя: кешене җәберләү вә үлтерү тик, урлау-талау тик, зина кылмак вә хәмер эчмәк тик, гайбәт вә бөһтан сүздән тик. Китапларымызда хәләл вә хәрәм нәрсәләр бәйнә-бәйнә язылгандыр. Менә шуңа да дин тотучыларымыз күп кенә бозыклыклардан азатлардыр. Әйтик, хәмер эчүдән. Бәндә аракы эчми икән, башка гонаһларны да эшләми бит ул.

Таварих китапларында язылгандыр: әле борын заманда, сезнең урыс бабаларыгыз һотларга вә кирәмәтләргә табынып яшәгән мәлдә, безнең ислам динле болгар бабаларыбыз Кияү каласына, урысның бөек кенәзе катына барганлар. Анларны мөселман диненә үгетләү өчен. Бу хәл бөек кенәзне бик тә кызыксындыра вә һәм ул болгар илчеләрен катына чакыра, ислам дине хакында сүзләүләрен үтенә. Тегеләр сүзлиләр, үз диннәренең канун-тәртипләрен әйтеп бирәләр. Баштарак: «Әйбәт», «Бара», «Шәп»,— дип утырган кенәз, сүз аракы эчмәү вә дуңгыз ите ашамауга житкәч, аягына ук торып баса... Соңрак инде урыслар эчү-исерүне хуплый торган нәсарә динен кабул итәләр вә һәм инде йөзләрчә еллар буе эчәләр, исерек баштан бихисап бозыклыклар кылалар.

— Тагы үз динегезне кирәгеннән артыграк мактыйсыз, Батырша әфәнде,— дип кисте аны Левицкий.— Мәсьәләгә тирәнрәк карасак, ислам халыкларны бик күп кирәкле гамәлләрдән дә тыя ич. Әйтик, сурәт ясауны, музыканы, башка кавемнәрнең кием-салымнарын киюне һәм башкалар, һәм башкалар...

— Алары да кирәктер, кем, Ычтапан. Әнә шул тыюлар аркасында, халаекларыбызда үзгә мәдәни, әхләкый күркәм сыйфатлар барлыкка килгән, ул үзенчәлекләр исә безнең бик матур гореф-гадәтләребезне тудырган. Татарны гына алыйк! Аның туганнан алып, гүр иясе булуына кадәр — барысы өчен дә төрле йолалары әзер. Һәр татар үз баласын кавемнең бер ботагы, бер матур яфрагы итеп тәрбияли. Дәвамчылык турында кайгырту булганга, мәгыйшәтебез дә тотрыклырак, миһербанлырак, кешелеклерәк, матуррак, гаделрәк. Менә шуңа да, мөселманларыбыз татулыкны, дуслыкны, тигезлекне өстен күрә.

Кайчан кергәндер, Левицкий янында чем-кара озын җиләнле бер бәндә пәйда булды. Ул иелеп, Стефанның колагына нидер пышылдады, тегесе агарып китте, керүчегә баш какты һәм урыныннан кузгалды.

— Безгә бүгенгә хушлашып торырга туры килә, мулла! — диде.

Ялгызлык, билгесезлек, шыксызлык, өметсезлек эчендә калды Батырша. Әйа, тагы кызды, тагы тыелып кала алмады, урыс динен хурлап, исламны яклады. Янә ялгыштымы?! Әллә йөрәге кушканча дөрес эшләдеме?! Сөйләгәннәре тегеңә ничек тәэсир иткәндер, мәгәр, әлеге бәхәстән соң, Батырша үзендә иманы яңаргандай тойды. Ул инде төшендечит-ят динне юрамалый гына да кабул итәчәк түгел. Хәтта башын саклап калу исәбенә булса да.

Алар өченче тапкыр да шул ук бүлмәдә очраштылар. Левицкий аны шулай ук тәкәллефле, нәзакәтле кабул итте:

— Мин сезне күп тыңладым,— диде ул.— Бүген исә мин сөйлим.

Ул, урыныннан кубып, тышка ук чыгып китте. Батырша аңа иярде, артларыннан ике сакчы да кузгалды. Левицкий туп-туры Петропавел чиркәвенә таба бара иде. Батырша манарага карап алды. Монда әле төзәтү эшләре бетмәгән. Вә әй хәсрәт, аны гомере буе эзәрлекләгән Каракош карачкысы түгелме соң бу?! Хак, шул бугай — Рәсәй Каракошы бар халаеклар өстенә канатын җәйсен дип юраулары шул микәнни?!

Ләкин аңа ныклап карап бетерергә лә, фикерен ныгытырга да бирмәделәр — сакчылар артына ук килеп төртелделәр. Һәм алар, бары бер йодрык булып, эчкә уздылар. Батырша үз гомерендә беренче тапкыр патша сараена килеп кергәндәй булды. Әйа, монлагы зиннәт, алтын-көмеш, бизәк-сурәт! Башта ул аларның кайсына карарга белми, югалып калды. Левицкий исә, урталыккарак үтүгә, сүз башлады:

— Шулай итеп, мулла, христиан дине — дөньядагы өч зур диннең берсе һәм иң абруйлысы, затлысы, шанлысы, вә данлысы!..

Аның гыййлемлегенә таң калды Батырша һәм, чыннан да, нәсара диненең олуглыгына ышана башлагандай иде. Шунысы аяныч, Левицкий сөйләгәннәрнең кайберләрен төшенеп бетмәде мулла.

Шул рәвешле зур һәм мәһабәт чиркәү буйлап йөрделәр. Батырша бүген үз гомерендә ишетмәгәннәрне ишетте, ымсынып-ымсынып та куйгалады, мәгәр иманы чатнамады. Башындагы аек акыл аңа: «Ышанган бул, урыс динен макта, юрамалый чукын — мәхбүслектән котылу юлы шунда»,— дип, тукып торды һәм ул инде зиһене белән муенына тавык тәпие тагарга да әзер иде. Ниһаять, Левицкий янә телгә килде:

— Йә, ничек, Батырша әфәнде, христиан диненең асылына төшендеңме бераз? — дип сорап куйды.— Менә чукынырсыз, безнең гыйбадәтләргә даими йөри башларсыз...

— Бән болай да күп нәрсә белдем, Ычтапан, рәхмәт! Вакыйган, урыс диненең лә асыл яклары байтак икән. Вә ләкин бер нәрсәне һаман да ачыклап җитмәдем, Ычтапан.

— Сорагыз, сора. Аңлатырмын. Ни-нәрсә ул?

— Әйт әле, Ычтапан: алай бик затлы вә асыл булгач, ничән нәсара динен халаекларга көчләп тагалар?

— Мин... мин сине аңлап бетермим, Батырша әфәнде?

— Мөселманлар үз диннәрен берәүгә дә көчләп такмаганнар вә һәм такмыйлар, аны вәгазьләү, үгет-нәсихәт юлы белән генә тараталар. Коръән Кәрим тәфсирләренең берендә мондыен хикәят бар: Мөхәммәт рәсүлуллаһ Мәккәдән Мәдинәгә күчеп килгәндә, аның сәхабәләре арасында Әнсар дигәне дә була. Бераздан монда Әнсарның уллары да күчеп киләләр. Баксаң, анлар нәсара дине тоталар, имеш. Аталары аларны ислам диненә күчерергә ант итә. Тегеләре исә, исламны кабул итмибез, үз динебездә калабыз, диләр. Бәхәс куба. Ата, аны хәл итү нияте белән, Мөхәммәт хәзрәтләре катына килә, хәлне аңлатып бирә һәм әйтә: «Кыямәт көнендә гаиләмнең бер өлеше оҗмахта рәхәтләнүен, икенчесенең тәмугта газаплануын күреп ничек түзәрмен?» — ди. Рәсүлуллаһ аңа улларын тынычта калдырырга куша: «Диндә көчләү юк, тугры юл болай да бик яхшы аерыла»,— ди. Безнең болгар бабаларыбыз да исламны үз ирекләре, үз теләкләре берлә кабул кылганлар. Анларны көчләүче булмаган.

Левицкий елмайды, сабыр гына дәшми торды, аннан әйтте:

— Гарәпләр сугышы хакында укымагансыз икән...

— Укыдым, нишләп укымаем, ди? — Батырша кабат чәчрәп төште.

Очрашканнарыннан бирле беренче тапкыр бугай, Левицкий мәсхәрәле көлеп җибәрде:

— Ха-ха-ха! Ә җиһад?! Исламның каферләргә каршы изге сугышка чакыруы — шул ук үз диненне көчләп тагу бит инде ул, мулла!

— Юк! Җиһад ул — гадел сугыш. Мөселманлар, гадәттә, бигрәк тә үзләрен рәнҗетеп диннәрен мыскыллаганда гына, җиһад игълан итәләр.

Сән, Ычтапан, әлеге сөалең берлә бәңа таш аттың. Ие, без куптык, кузгалдык вә җинелдек. Моңа безне сез, урыслар, мәҗбүр иттегез, Ычтапан.

— 1755 ел тугызынчы октябрь указы белән Лука Канашевич Белгородка күчерелде, Казанга аның урынына Коломнадан Гавриил Кременицкий китерелә, Батырша әфәнде. Сильвестр Гловатский да эшеннән алынды. Ә, әйе, сез әле ишетмәгәнсездер: 1756 елның егерме өченче августында императрица җәнапләре исламның христиан дине белән тигезлеген таныган, мәчетләр салырга рөхсәт ителгән.

— Эттән бер тотам йон!

Левицкий төксе генә әйтеп куйды:

— Мин сезне аңламый башладым, мулла. Үзегез кабул итәчәк мөхтәрәм дингә пычрак атасыз. Ташлагыз, әйдәгез, дуслашыйк!

— Югинде, Ычтапан, баскынчыларның әшәке динен кабул итә алмаем. Иманымны сатмаем! Иман сату — анаңа хыянәттән дә яманрак!

Левицкий кара янып чыкты, сакчыларына ыслады:

— Алыгыс-с-с бу фанатикны! Черсен таш капчыкта!..

Ниһаять, җәйге матур көннәрнең берсендә аны тышка алып чыктылар, богау чыңы астында каядыр алып киттеләр. Нindидер тимер капка янына икән. Менә ул шөкәтсез шырыйлап ачылды һәм Батырша алдында суга төшә торган шыксыз таш баскыч пәйда булды. Шул мизгелдә генә ул үзенең дәрья өстеннән алты сажин чамасы калкып торган утраудагы кальгада тоткынлыкта ятуын төшенде. Вә ләкин бүген соңгы көне, имеш. Аны җыйнак,җиңел корабка кертеп утырттылар, богау чылбырларын утыргыч тактасына кадаклап куйдылар һәм тагы да шыксызрак, шөкәтсезрәк кальга-зинданга — Шлиссельбургка алып киттеләр.

Кораб кузгалганда, Невада 1757 елның ак төне хакимлек итә иде.

## Дәһшәтле төн

Ул коточкыч тынлыктан уянып китте. Юк, бер генә аваз-өн дә ишетелми.

Кинәт җилкәсен борып чеметеп алгандай булдылар, ул да түгел, шул җире үзәкләргә төшеп кычытырга тотынды. Мулла, башын бер якка бора төшеп, сул кулы белән җилкәсенә үрелмәкче булды. Әмма анысына тагылып, уңы да кузгалды — зынҗыр чыңлап алды. Әһ, бу богаулар! Бер генә көнгә, һич югы бер сәгатькә, котылып булыр микән шулардан?! Ул ятагында торып утырды.

Кашынуыннан арынып, кабат урынына ятты, янә тыңлап-тыңлап торды. Юк, су чыпылдавы да, аралыкта аяк тавышлары да, ишек катында сакчының кыштырдавы да ишетелми. Тынлык кына да түгел, әллә нинди дәһшәтле өнсезлек бу. Кай вакыт икән соң: көнме, төнме, таң алдымы? Шуны чамаларга тырышып, Батырша башын ишек ягына борды, озак кына дөп карангылыкка карап торды. Ниһаять, шәйләде, ишек ярыгыннан сизелер-сизелмәс кенә төшкән яктылык саргылт түгел, аксыл иде. Димәк, төн узган.

Дөньяга яңа көн тууы турындагы нәни генә хәбәр аны шыксыз уйларыннан арындырып җибәрде. Әйа, исәбенчә, бүген аның янына сакка изге күңелле Гришка басарга тиеш. Үз уеннан үзе канатланып, сәкесенә торып утырды, йөрәге нindидер куаныч белән өртелде. Гришка сакта көнне, Батырша өч тәүлек «ураза»дан соң, авыз ача, үзенең бәндә икәнлеген онытмаслык булса да сөйләшкәләп ала.

Тукта, үзе кая соң әле бу Гришка? Әллә соң ялгыштымы, бүген аның кизү чираты түгелме? Алай дисәң дә... Ишек катында, гел генә сакчы утыра торган җирдә берәү дә юк бугай ла.

Шогыльсезлектән интеккән Батырша кабат сәкесенә сузылып ятты. Бу юлысында инде ул соңгы вакытта көн-төн жанын талап торган мөһим уйларына чумды. Ие, Гришканың әйтүенә караганда, хәзер тышта, урыс исәбе белән, 1762 ел уртасы. Нәтиҗәдә ни килеп чыкты? Чәчләре житен сүсе булып агарды да маңгаендагы буразналары тирәнәйде — нибары шул. Әллә хатлары барып иреш мәде, әллә инде падишаһ аларны кулына алып та укырга теләмәде? Әйа, тәхет өчен бер-беренең жанын кыярга, хәтта кем. Гриша әйткәнчә, хәлал жефетен бугазлатырга житкән ул азгын хокемдарлардан ни көтәсең?! Димәк ки, аның яңа бөреләнгән нияте дөрес — качарга, фәкать качарга!

Аралыкта гөр итеп көлешергә тотындылар, мәгәр артыгын иркенли алмадылар, бер офицерның хәтәр авазы Батыршаның жиһаннан тибәрелгән хөжрәсендә үк аермачык ишетелде:

— Это еще что такое? А-ну, разойдись!

Ошбу авазларны вә әмерләрне нәрсәгә дә юрарга өлгермәде, камераның ишеге ачылып ябылды:

— Батыршаһ, уяндыңмы инде, төш житә бит,— дип пышылдады Гриша.

Мулла богауларын шалтырата-шалтырата торып утырды, һәм, уянганын хәбәр итү нияте белән, тамак кырып куйды.

— Йә, хәлең ничек, Батыршаһ? — Ул тоткын сәкесенә үк утырды.

Батырша дусты өчен куркып китте:

— Нишләвең бу, Гриша, кабарсың бит?!

— Курыкма! Бүген монда ярминкә. Сарайдан ниндидер түрәләр килгән, бер бик тә мәгълүм тоткынның хәлен белергә. Башлыкларның һәммәсе, сыныкны сылтау итеп, әлеге мәхбүсне канцеляриягә озата.

— Алай да сак бул, Гришка. Сән әле бәңа бик кирәк!

— Нәрсә, йомышың бармы?

— Бар, Гришка. Ике дилбегә тап! Качам, Гришка, ярдәм ит!

— Син нәрсә, чынлапмы?

— Юри-мырый сүзли белмәем.

— Дилбегәдән эш калмас, Батыршаһ. Анысын мин киләсе кизү көнне үк алып керә алам. Кием эченнән билгә урап.

— Аңларны монда алып кермә, төн ягындагы дивар ярыгына, тал үсеп чыккан үлән арасына яшер.

— Ярый уйланган! Дилбегә булыр. Тик бу хакта бүтән дәшмә!..

Байтак кына сүзсез утырдылар. Батыршаның күңеле нечкәреп китте, бу игелекле бәндәне кочагына алып рәхмәт әйтәсе, йөзеннән сыйпыйсы килде. Кызык, бите-чырае нинди икән Гришканың? Бар шул, каферләр арасында да бар чын кешеләр. Мулла сорап куйды:

— Сезнең ниткән ат кәмите анда бүген?

— Тычканга үлем, мәчегә көлке, Батыршаһ.

— Аңламаем. Төшендереп сүзлә!

— Белмәсән, бел: күршедәге казаматта, синең кебек үк мәхбүс булып, падишаһ утыра, Батыршаһ. Император Иван Алтынчы. Инде күп еллар. Аңар көн саен хәмер эчереп торалар — хәлен жинеләйтәләр, янәсе. Хәлбуки, бу аны тилертү өчен эшләнә. Явызлар максатларына ирешәләр бит тәки...

Батыршаның авызы ачылып калды, бу сүзгә ни диярга дә белмәде:

— Дивана! Падишаһлар зинданда утыра, ди мени?!

— Ай, Батырша, без белеп бетермәгән әллә нәрсәләр бар...

Тарих битләреннән. Имчәк яшендәге экс-император Иван Антонович, ягъни Иван Алтынчыны һәм аның гаиләсен чит илгә олактыру хакында 1741 елның 28 ноябрә указын игълан иткәннән соң, тәхеткә яңа утырган Елизавета Петровна уйланып калды һәм кылганына үкенә башлады. Аның үзе һәм варислары өчен хәтәр булган элеккеге императорны Россия контроленнән ычкындырып ялгышмыймы ул? Нәни падишаһның

туганнары бихисап, әтисе исә принц Антон-Ульрихның бертуган сеңеле-се — Дания королевасы...

Брауншвейгскийлар гаиләсен Ригада тоткарладылар һәм алар шунда күзәтү астында калдылар. Әмма үзе өчен куркыныч булган әлеге гаиләне ярым иректә тоту Елизаветаны гел генә борчып тора иде. Һәм ул җәберләнгән гаиләне шуннан ерак булмаган Динамюнд крепостена күчерергә һәм көчле сак астында тотарга әмер бирде.

Тынгылык дигәнең моның белән генә дә килмәде. 1744 елның январенда ошбу мәшәкатьле гаиләне Рәсәй эченәрәк — Воронеж губернасының Ораненбург каласына олактырдылар.

Ләкин Брауншвейгскийлар гаиләсенә Воронеж губернасында да, аннан соң да тыныч кына яшәү насыйп булмады. Елизаветаның шиге аларны гомерләре буе эзәрлекләде. Җәен Ораненбургка императрицаның якыннарыннан Корф килеп төште. Анна Леопольдовнаны һәм аның гаиләсен Соловки монастырена озатырга тиешлеген белдерде. Дүрт яшьлек Иван Антоновичны исә ата-анасыннан аерып алырга, исемен Григорий дип атап, Соловкига озатырга кушылган иде.

Көзге яңгырлардан тәмам эштән чыккан юллар фәйтуннарга Ак диңгез ярына барып житү мөмкинлеге бирми. Корф ошбу кыерсытылган гаиләне вакытлыча гына Холмогор каласында калдыру һәм мондагы әрхәрәй йортында тоту фикерен Петербургка житкерә һәм императрицаны күндерә.

Бәхетсез гаилә монда озак елларга туктап кала һәм тоткынлыкта утыз алты ел (1744—1780) гомерен үткәрә.

Тәхетнең төп дәгъвачысы Иван Антонович гаиләдән аерым тотыла. Шулай итеп, Холмогорда, махсус комендант һәм аның командасы күзәтчелегендә торып кала. Дөрес, тоткыннарга яшәү өчен акчаны һәм малны кызганмыйлар, әмма икенче яклап алганда... Елизавета патшалык иткән егерме ел гомер эчендә бу бәхетсез гаилә бер генә рәхәт көн дә күрми. Бала-чага гына түгел, аларны карарга тиешле ялчылар да — һәрчак бик астында. Мәхбүс императорның тоткындагы эне-сеңелләре гарип-гораба булып үсәләр.

Иван Антонович шул ук Холмогорда тотылса да, гаиләгә аның кайдалыгы мәгълүм булмый. Аның каравы, Елизавета беләͅ тәхет варисы — Иван Алтынчы монда да куркыныч тоела аңа. 1756 елның 26 январенда комендант Вындомскийга элеккеге императорны кичекмәстән Шлиссельбург крепостена күчерү турында указ килеп төшә.

Иван Алтынчы Шлиссельбург зинданына Батыршадан чак кына алдарак килеп эләгә...

Төнне Батырша, керфек какмый, сәкедә аунап үткәрде. Хәер, йокысызлыгы — бер бүген генә түгел. Аны барыннан битәр җәфалаганы — әлеге дә баягы, карчыга борынлы иләмсез Каракош. Ул, төн саен, Батырша янына килеп, аның йөрәген, яисә башын чукый.

Адәм баласын өмет яшәтә, диләр. Хактыр. Батырша мәсхәрәләнгән, кимсетелгән, җәберләнгән кешеләрнең берсеннән-берсе аяныч хәлләрен күреп, чыгырыннан чыгар, балтага ябышыр минутларны күп кичерде. Әмма түзде, сабыр итте. Нигә дисәң — өмете бар иде. Бер-берен таш курчаклар мисалында алыштырган падишаһлар үзләренең гамьсезлекләре, игътибарсызлыклары, адәми затларны чүпкә дә санамаулары белән аның әнә шул изге өметенә балта чаптылар. Шул хакыйкатьне ачыклаганнан бирле сабыр канатлары сынды аның, шуннан бирле өзгәләнә, бәргәләнә, гасабилана Батырша.

Кичә аның бәйрәме булырга тиеш иде. Вакыйган, Гришка билгеләнгән вакытына кизүлеккә килеп басты — Батыршаның таланган-йолкынган йөрәге басылып, тынычланып калды. Менә җаен табып сөйләшерләр, миһербанлы сакчыдан ул ил-җир хәбәрләре ишетер һәм көне, Гришка белән булган башка чаклардагыча, юаныч-куаныч, сөенеч белән үтәр.

Әмма кизүлеген кабул итеп алганнан соң, Гришка, алай-болай итүгә, җаен чыгарып, ишекне ачып карады, якын-тирәдә кеше-кара югына инангач, ашыга-кабалана хәбәрен тоткынга җиткерде:

— Дилбегәләр булды, Батыршаһ. Алар — сөйләшкән урында.

Шуны әйтте дә, каядыр чыгып та китте Гришка. Дилбегә хәбәре аңа олы шатлык та, бер үк вакытта, тау кадәр хафа да алып килде.

Аның нияте бик тә гади иде. югыйсә: һава алырга, дип чыккач, богау чылбыры белән сакчының башын сугып ярырга да, тиз арада, дилбегәләрне эләктереп, диварлар өстенә менә торган юлга ташланырга. Тик быел тоткыннарны әле бер тапкыр да һавага чыгарганнары юк. Салкын җәй, имеш.

Ул, тешләрен шыгырдатып, урыныннан кузгалды һәм, көндәлек гадәте буенча, бәрелә-сугыла, кабер урыны кадәр генә җирдә таптанырга тотынды. Ул, бар дөньядан ваз кичеп, үзенең сагыш вә хәсрәт тулы уйларыннан сыгылып, сәкегә барып утырды. Урынына авып, йоклап киткәнен сизмәгән дә.

Мулла кычкырып сөйләшүләрдән уянып китте. Ишек катында ике сакчы иркенләп гәпләшәләр. Тавышларыннан таныды Батырша: сөйләшүчеләрнең берсе — иртәдән кизү торган солдат булса, икенчесе — теге явыз Хомутов.

Хомутов салмыш иде. Кәефенең шәп икәнен үзе дә расларга ашыкты солдат.

— Йә, князь, хәлләр гөл кебекме? — дип сорады.

— Дуңгыз янындагы эт мисалында,— диде Батырша.

Хомутов, караңгыда капмаланып, сул кулы белән мулланың киндер күлмәге изүеннән алды, йодрыкланган уңы белән тоткынның йөзенә китереп сукты.

Исерек кулыннан ничек кирәк алай котылып, Батырша таш диварга борылды, сиптереп кан аккан борынын күлмәгенең итәге белән томалады.

Булып алган хәл Батыршаның болай да алгысыган йөрәген ярсытты гына. «Аяктагы богауларны салырга да, шыпырт кына барып, буып ташларга кирәк бу кабахәтне, аннан ни булса — шул»,— дип кайнарланды мулла. Ул инде уң аягындагы тимер боҗраны шуытып чыгара үк башлаган иде. Шулчак Хомутов нидер мыгырданды, сүгенеп алды. Батырша шым булды, эченнән генә догасын укырга, аллаһыдан сабырлык сорарга тотынды.

Сәгать чамасы үтте микән, сакчы:

— Сиңа да салкынмы, такырбаш? Болай булса, туңып үләрбез бит,— дип бакырды.

Батырша җавап кайтармады. Хомутов чыгып китте. Күп тә үтмәде, ишек кабат ачылды. Утын алып кергән икән. Кочагында балтасы да булган, күрәсең, шакы-шоkы чыра телергә, эре агачларны яргаларга тотынды.

Менә ул, балтасын зыңгылдатып таш идәнгә атты да, кабат чыгып китте. Батыршаның аңына керде: балта — аны ирекка алып чыгачак нәрсә!

Батырша, үзе дә сизмәстән, торып утырды, ашыга-кабалана аягындагы богауларны салып атты һәм балтага омтылды. Нәкъ шул мәлдә ишек ачылды, Хомутов килеп керде. Батырша ятагына чигенеп өлгерде, йоклаганга сабышты.

Сакчы, күмерен мич эченә бушатты да, аның өстенә чыралар куеп, пуф-пуф итеп өрә башлады. Батырша күзенә исә шәүләләр биешкән мич буенда яткан балта гына чалынды. Ниятен тормышка ашыру өчен моннан да форсатлы мизгел булмавын сизенде Батырша. Ул, богау чылбырларын күкрәгенә кысып иңләп кенә урыныннан торды, ялан аяклап песи кебек кенә, мич янына китте. Күренеп калган балтага иелде һәм... зынҗыры шалтырап куйды.

Хәтәрлекне сизенеп, Хомутов башын мичтән алды, ләкин соң иде инде. Әкияти әңгер-меңгердә, утын ярырга җыенгандай, балтасын ике куллап башы өстенә күтәргән коточкыч бәндәнең шәүләсен күреп алды сакчы һәм шырыйлап кычкырды.

Батырша, канлы балтасын тоткан хәлдә, ишеккә ташланды. Әмма аны ачарга өлгермәде, аралыкта аяк тавышлары ишетелде. Тоткын, диварга сыенып, теге бәндәнең үтеп киткәнен көтте. Саран гына яктылыкта аның капрал Никитин икәнлеген абайлап алды. Тегесе, шәм яктысыннан кергән уңайга, берни күрми, һаман — сузылып-сузылып каравында. Кан исеннән исереп киткән тоткынга шул гына кирәк иде. Ул, бар көченә кизәнеп, капралның муенына чапты — йөнтәс баш сәкегә таба чәчрәп китте.

Аралыкта йөгерешкән тавышлар ишетелде, әмма Батыршага барыбер иде инде. Кыяфәтендә — кыюлык һәм тәвәккәллек: йә сакчыларны чапкалап-тураклап бетерә дә ирекә чыгып ычкына, йә чын яугирларча көрәшеп үлә!

Кайсыдыр ишеккә килеп капланды — солдат Лазарев бугай. Бусаганы атлап үтәргә өлгермәде, алдында балта күтәргән өрәк күреп, туктап калды. Тик чигенергә соң иде инде. Канлы балтаның ажгырып өстенә төшүен күрүдән бигрәк, ничектер тоеп, Лазарев башын артка ташлап өлгерде, үткер тимер аның корсагын ярып керде — тирә-юньгә нәҗес исе чәчелде.

Батырша, канга һәм пычракка баткан балтасын тартып алып, тураеп баскан гына иде, йөгерешеп килгән сакчыларның дүртенчесе — Епифанов дигәне аның өстенә сикерде. Әмма, елгырлыкка килгәндә, мулла да — төшеп калганнардан түгел. Ул бер якка тайчынды һәм җан ачуы белән тегенең башына орды.

Вә әй хәсрәт, балтасы мәрхүмнең муен сөягенә эләгеп калды. Шуны тартып алырга маташкан арада, сакчыларның тагы берсе аның сыртына сикерде, тоткынны буып алды. Батырша хәрәкәтләнүдән мәхрүм иде.

Шул вакыт, ачык ишектә, кулына янып торган ике шәмле шәмдәл тоткан берәү күренде — хөҗрә эче тулысынча яктырды. Керүче камера уртасындагы солдатларның урталыкта калган чал чәчле башка сугып-сугып алуларын күрде һәм кычкырып әмер бирде:

— Отставить!!!

Сакчыларның башта берсе, аннан икенчесе, башкалар, нишләптер, оеп калган мәхбүсне калдырып, читкәрәк китеп бастылар. Менә соңгы солдат та янынннан китте. Баштанаяк канга баткан Батырша, бераз чайкалып торды да, гөрселдәп таш идәнгә ауды.

Солдатларның берсе аңа ташланды, өстенә иелеп, иңеннән алды. Тик нигәдер тоткынны күтәрмәде, кулларын каккалый-каккалый, акрын гына турайды һәм шыпыртлап диярлек әйтте:

— Ул сап-салкын, әфәнделәр...

Казаматта кабер тынлыгы урнашты. Солдатлар тын алырга да шикләнеп торган арада, ишек катындагы офицерның мыгырданганы ишетелде:

— Йөрәк параличы! Актны шулай язарга кирәк.

## Ун елдан соң

*(Эпилог урынына)*

Батырша һәлак булганга ун ел үтеп китте. Тарих өчен — ун ел, әлбәттә, диңгезнең бер тамчысы, мизгел генә ул. Мәгәр шул мизгелдә дә Рәсәй хәтле Рәсәйдә ниләр булмас?! Телгә алып сөйләрлек хәлләрнең иң

зурысы — әлбәттә, төрле мәкер һәм кан коюлар белән, законсыз тәхеткә килеп, курка-өркә генә патшалык итә башлаган Екатерина-Сания власте-нын ныгып житүе, морза-дворяннарның һәртөрле хокуклары киңәюе, кара халыкның тагы да ныграк изелүедер мөгаен. Россия чикләрен киңәйтү һәм ныгыту өчен яңа сугышлар барды, фән-сәнагъ сизелеп алга китте, яңа каһарманнар үсеп чыкты: Суворов, Ушаков, Румянцев, Орлов, Потемкин...

Әмма тәхет өчен калтырау, шүрләү Екатеринаны гомеренең ахырына кадәр эзәрлекләде. Тәхет дәгъвачыларының берсеннән бик ансат котылды ул, дөресрәге, ходай үзе саклады аны. Бу хәл Батырша үлеменең икенче елында булды. 1764 елның алтынчы июлендә гаярь офицерлардан Мирович дигәне, тоткындагы император Иван Алтынчыны коткару максаты белән, Шлиссельбург кальгасының дәһшәтле казаматларына үтеп керде, һәм инде ниятен тормышка ашыра язды, диярлек иде. Әмма өч сакчы сабый чагыннан зинданда газап чиккән «падишаһ»ны суеп ташлыйлар — күрсәтмә шундый. Ләкин Иван Антоновичның Холмогорда эне-сеңелләре бер көтү бит әле. Тик алардан котылу җаен да таба императрица — Брауншвейгскийларны чит илгә олактыра. Тик әнә Павел егет булып килә, тәхетне анардан ничек саклыйсың?!

Сүз бара торган елларда Екатерина Алексеевнаның кылган гамәлләреннән иң шау-шулысы — 1767 елда яңа законнар чыгару өчен комиссия төзүе һәм пайтәхеткә илнең бөтен почмакларыннан депутатлар җыюы булгандыр, мөгаен. Бик шәп законнар чыгарырга дип, башкалага килгән йөзләрчә депутатлар арасында безнең иске танышыбыз — Гәйнәдә баш күтәргән халыкны куып таратуда мөһим урын тоткан мөртәт старшина Туктамыш Ишбулат углы да була.

Падишаһның шул ук елда Казанга килүе дә тарихка теркәлеп калган. Аның 1782 елда Казанны төзүнең генераль планын ансат кына раславын шул сәяхәт нәтиҗәсе дип карарга кирәктер. Императрица, Казанда чагында, татарлар мәчет салырга рөхсәт сорап, мөрәҗәгать итәләр. Екатерина әле күптән түгел генә булып узган Батырша восстаниесен исенә төшерә һәм Казанда таш мәчет салырга рөхсәт бирә. Пугачев җитәкчелегендәге крестьяннар сугышы башланып, анда катнашучыларның иң күбесе татарлар икәнен белгәч, патшабикә Казанда кылган гамәленең дөреслегенә тәмам инана, татарларга һәм җирдә мәчетләр салырга мөмкинлек тудыра һәм тагы бераздан — 1789 елда мөселман эшләренә җитәкчелек итү өчен Диния нәзарәте булдыру һәм Рәсәйнең беренче мөфтиен раслау турындагы указга кул куя.

1766 елда Тирсәдәге тыныч һәм шактый гауталы утарында туксан бер яшьлек Котлымөхәммәт Тәвкилев дөнья куя. Ничә еллар халәекларны кан елатып җыйган мал-мөлкәтне үзе белән алып китә алмый морза. Утары да, Баржы буендагы бакыр заводы да, кол крестьяннары да, йөзләрчә дисәтинә җирләре дә башкаларга кала. Мәгәр алар да хәрәм малның игелеген күрә алмыйлар — тагы биш елдан соң купкан мәхшәрдә крестьяннар ул мирасның көлен күккә очыралар. Кансыз морзадан аны каһәрләп чыгарылган үзәк өзгеч «Тәфтиләү» җыры гына кала.

Вакыйгалар Батырша үлеменең унберенче елында тагы да куерып китә. 1773 елның сентябрендә Екатеринаның «сөекле» улы Павел Дармштадт принцессасы Вильгельмина — булачак Алексеевна белән ярәштерелә. Бу олуг вакыйга уңае белән бөек князь Павел Петровичның, ягъни тәхет варисының, тәрбиячесе граф Никита Панин фельдмаршал чины, жалованье һәм бихисап бүләкләр ала.

Шулвакыт Петербургтан ике мең чакрым ераклыктагы Оренбург янында Пугачев яугирләре Яман каланы камап ала. Гадел «патша» явына күп кенә татар һәм башкорт егетләре дә кушыла. Әмма бу батыр йөрәкле халыкларның уллары Пугачевка гына түгел, падишаһ армиясенә дә кирәк. Казан, Оренбург, Уфа калаларыннан авылларга чапкыннар ашыга. Шуларның берсе Урал таулары арасындагы Шайтан-Күдәй илә-

венә килеп җитә. Йөзләп егетен чакырып ала Юлай һәм аларны, гаярь углы Салават җитәкчелегендә, Эстәрлетамакка озата.

Салават исә әмерне үзенчә үти, ике меңгә якын татар-башкорт егетләрен «яхшы падишаһ Петр Өченче» ягына алып чыгарга була. Оренбурга җитәргә җитмеш чакрым җир калгач, ул Биккул авылы янында туктала, яр өстенә сикереп менә һәм ялкынлы сүз әйтә:

— Без Үр тамагында үтерелгән биш мең башкортның, Минзәләдә үтерелгән Әнгар, Килмәт, Әлшәй, Юлдаш, Әминнең, хәбәрсез югалган Батыршаның үчен Пугачка кушылу белән генә алырга тиешбез!..

Шушы ук көздә, төгәлрәк әйтсәк, 1773 елның 11 ноябрендә, Нева буенда зур тарих өчен әһәмияте булмаган бер вакыйга теркәлә: сиксән бер яшьлек Неплюев дөнья куя.

Ярсыган халыкта исә Неплюевлар кайгысы юк: ул, Пугачев җитәкчелегендә, Каманы кичә һәм 1774 елның июне ахырында Әгерҗе-Тирсә тирәләренә җитә. Баксаң, Тирсә крестьяннары Пугачев килгәнне көтеп ятмаганнар, гомер бакый җаннарына тигән морзаның утарын былтыр ук пыран-заран китереп, Осип Тәвкилевнең чибәр кызын үзләре белән алып киткәннәр. Үзләренчә, иректе мәмләкәт төзегәннәр, башлык итеп гадел, үткен һәм гайрәтле Әбҗәлил Солтановны сайлап куйганнар. Тирсәлеләр Пугачевка морзаның гүзәл оныгын бүләк итәләр.

Пугачев июльнең беренче төнен Алабугадан җиде чакрым чамалы Саралы авылында, заводчы Красильников өендә үткәрә. Кичен ул иң гаярь егетләрнең берсе — Карп Карасьны кабул итә һәм аңа Тәвкилев кызын бирә.

Шуннан инде олы яу Казанга таба кузгала, түрәләргә нәфрәттән ярсыган яугирләр арасында меңләгән татар егетләре дә була. Пугачев явына сиксән меннән артык татар катнашуы мәгълүм. Аларның күбесе — әлбәттә, Батыршаның кыздырмак вә егетләмәк хатын укып, аның иманлы сүзеннән гайрәтләнгән азаматлар...

# ШИГЪРИЯТ

## Роберт Әхмәтҗан

### Туу

Ап-ак өстәлемдә
илһам шәмем янды!
Төн уртасы куйды
Елны елга ялгап...

Кыш
ак ятагында
тапты Яңа Елны!..

Күкләр карыныннан
коела
ак ялгак...

* * *

*Бар да үчә:*
*Сириус та, урмәкүч тә...*

Ницше.

Кичәсең, Сириус, чиксез киңлекләрдән,
Үрмәкүч тә үрли күкләргә.
Ницше, күрәзәче, әйткән иден,
Дөнья, әлбәт, кала күпләрдән...

Үчә икән бар да — сөйгән яр да,
ат та, арбалар да бу дөньядан...
Үтеп китсәң, гомер, яңадан кил,
барысын да башла өр-яңадан...

Сүзләрең рас: үткән иде бар да
концлагерьлар камчысы аша.
Сириус балкый, үрмәкүч үрмәли,
җирнең карынында
миллион әрвахлар ыңгыраша.

Яктыр, Сириус, бөҗәк күләгәсен
олы итеп күрсәт бар җиһанга.

---

Роберт ӘХМӘТҖАН (1935) — *шагыйрь, татар һәм рус телләрендә дөнья күргән күп санлы шигырь китабы авторы. Казанда яши.*

Әмма дөнья фани диеп җырлау
азык түгел инде һич илһамга.

Сириус та үчәр, үрмәкүч тә,
син дә, Ницше, үчтең бу дөньядан.
А, куаныч! Кыш наркозын җиңеп,
җирнең бер ләләсе уянган!

Бухенвальдның капкасында сүзең:
«Һәркемнең дә үзенә дигәне».
Бу да язмыш микән: Батырлыкның
кылычларга башын игәне?

Ышанасы килми...

* * *

Авылдан адашып кергән
шәһәр күгенә тургай.
Мин сагынганны белгәндер,
мине эзлидер бугай,
авылымнан бер тургай...

Балачагымнан килдеңме,
Тәрбели тугаеннан,
Якташым дип котларгамы,
туган көн уңаемнан?..

Үз ягында — син яшь, таныйм
тавышыңнан әле дә мин.
Бүген шәһәрдә адашкан
бер тургай хәлендә мин.

Рәхмәт, якташ, булсын һәрчак
Якты болытлар оян...
Чернобыль тургайларының
хәлләрен уйлап куям,
хәлләрен уйлап куям.

* * *

Кичке кояш
уйчан баткан чакта
бөтен җилләр тына,
кабатланып тора
изге бер йола:
уйсу җиргә ятып,
үзәннәрдә мүкәләп,
ташлар дога кыла,
ташлар дога кыла:

«Кояш, ташлама,
чык иртәгә, синсез
безнең газиз башлар
көнен ничек башлар?
Юкса,
күләгә дә төшмәс бездән
бәпкә үләненә,
салкын булырбыз, өнсез
синсез...»

Көнбатышка баткан кояшка
сәҗдә кылып,
таш гомерләрен,
гомерлек таш тынлыкларын
багышлыйлар ташлар.

Изге тынлык. Кояш сүнә.
Кузгалалар ташлар...

* * *

И туган ил, кем каргады сине,
тургай эзләп йөрим даланнан?..
Таланган йорт бит син, туган илем,—
каракларың хәтта таланган!

Синдә бүген гүя ау фасылы,—
тыелмаган кеше аулары...
Бөлгенлеккә төшмәс идең болай,
узсалар да магыл яулары!..

Күзләреңә канлы шәфәкъ төшкән,
и билчәннәр баскан багыңны...
Дөньякүләм янгыннар да болай,
яндырмаслар иде җаныңны!..

...Таң алдыннан гөлләр сагынып елый
ерак калган җиләс таңыңны...
Синдә минем җаным елый,
сагынып
пәйгамбәргә ышанган чагымны!

## Даһилар чишмәсе

*Гете эчкән*
*чишмәләрдән эчәм...*

Сибгат Хәким

Бу якларда кайнап чыга сулар,
Гете эчкән... житкән һәркемгә...
Үзе тапкан чишмәләрен, ятып
эчкән — Сибгат, эчкән — хакимнәр...

Мин Лермонтов чишмәсеннән эчәм,
эчәм ятып — кемнәр эчмәсен?..
Тимер Суда[1] кайнар сулар эчтем,
искә алып Хәким чишмәсен,
хәтерләдем «Фазыл чишмәсе»н...

Гете эчкән — киткән,
Лермонтов та...
Киткән алар, ә без — ятимнәр.
Соңгы йотым ятимнәргә булсын,
диеп әйткән
Сибгат Хәкимнәр.

P. S.
Көмеш сала суга ятимнәр...

[1] Тимер Су — Железноводск, анда Лермонтов суын эчкән чыганак бар.

## Карт парк

Төштә күргән гүзәл яшь чакларын
кояштан да көтми Карт Парк.
Хәтерләрен эзләп карт пар йөри,
карт паркны йөри актарып...

Ниләр диеп кенә кагыла икән
таяк очы сары яфракка?
Фани дөнья байлыкларымы соң —
сары алтын сипкән туфракка?..

Чал юкәләр тып-тын, тып-тын парк,—
элек булган диләр каберлек...
Күпме буын гомерләрен йоткан
каберлекне түгел тапырлык.

Һавасы ук үзгә, йоклый кошлар,
тик уяна рухлар кичләрен...
Сөялә дә яшьләр чал юкәгә
эшләп китә
эшләр эшләрен...

Син дә, күңелем, шул парктай, тынып,
Онытылдың гүя мизгелгә...
Карт парктай сабыр, күндәм булсак,
санарлармы безне изгегә?

* * *

Бәхет ул
жиңел аяклы —
килгәне сизелми дә!..
Бер инеңә кагылса да,
ике канат — иңеңдә!

Килми ул хәзер...
Ә элек
янымда иде һәркөн...
Бәхет адымы!
Белә моны
Яшьлеге килгән һәркем!

* * *

Үтте дә китте,
китте, ераклашты...
Быелгы жәй яфракларын
сагыш жиле үпте,
зәгъфрандай итте...

Сарыларын элде ул
жаным түрләренә.
И жилферди, өзелә
бәгырьләрем лә!

Жәй үтте, күрмәдем
аның эзләрен дә...
Сыкраныл жан бирде, бәгърем,
синең тезләреңдә!

* * *

Җиксетте бу шыр агачлар,
ялангачлар,
оча алмый калган кошлардай,
тавышлары — җилләрдә!..

Тәрәзәгә сарыла җил:
«үксемәгез,
ир булыгыз
сабырланып тамырланган,
яшьнәп үскән җирләрдә!..»

* * *

Нигә шигырь?
Тормыш шигырьдән дә
катлаулырак икән, ләбаса.
Нигә мунча, нигә ләүкә сина,
төнлегендә йолдыз янмаса?

Нигә яздым шигырь?
Башны ватып,—
бу заманга шигырь — ни аңа?
Ходай үзе гарешләрдән сөргән
явыз кавем кайта дөньяга.

Без, китәбез,
жырлый шовинистлар,
сатаналар килә —
өр-яңа!..

## Элегия

Җете иде әле гөлнең тажы,
Яшь йолдызым яшел болында...
Күңелемдә балкып калды назы,
жан жылысы янды кулымда!

Гөлләр белән болын бәхилләшә,
күбәләкләр китә эңгергә...
Шат йолдыздай яшьлек, нурын чәчеп,
китеп барды... бөтен гомергә!

Җиләс җилдә уйнап моңлы сазын,
сусәрделәр инде кылганнар...
Тузганаклар булып очты —
язын
чәчәк булып җиргә кунганнар!

Әнәс Галиев

# АВЫЛДАШЛАР

РОМАН

## I

Өйдән чыкканда, әнисе Әлфияне җиңеннән тартып туктатты да Ленин башы төшерелгән кызыл утызлык акча бирде, кулына бер чиләк йомырка тоттырды.

— Акчасы үз кирәгеңә булыр. Йомырка апаңа. Сынауларың беткәнче, аларда торырсың. Үз сөягең тарсынмас, сыйдырыр,— диде дә борылып күз яшьләрен сөртте.

Тимер юл станциясенә Әлфия җәяү барды. Атлы кеше очрамасмы, дип, артына борыла-борыла атлады, соңрак борылмас булды, бәхете юк икән. Егерме чакрым араны узганчы, куллары өзелеп төшә язды. Җәяүләргә янчык та авыр, ә аның кулында чиләк тутырук күкәй.

Ни арыса да, Әлфия юлда ял итмәде, бу турыда хәтта уйлап та карамады. Станциягә чакрым чамасы калгач кына Казансу буенда чиләген җиргә куеп туктады. Аяз күккә, кояшка күтәрелеп карады. Иртә әле, кояш офыктан калкынып маташа, ә ул утырып китәсе поезд сәгать җиделәрдә генә киләчәк.

Болында түгәрәк печән чүмәләләре тезелеп киткән. Кыз, иң дәү чүмәлә артына кереп утырды, талган аякларын рәхәтләнеп сузып җибәрде. Печәннең куе хуш исе аны исертте, йокысы килә башлады. Йокларга ярамый иде, ул йокысын качырыр өчен бер иелде, бер турайды, күкрәктә кыштырдаган ят нәрсәне абайлап сискәнеп китте. Яшерелгән утызлык аның учына күчте, акчаны ышкып таслады, Ленин бабай рәсеменә карап торды. Гүя, тере кеше инде... Күзләр нурлы, ягымлы. Аңласа, бары ул гына аңлар дип, кыз яшерен серләрен аңа сөйләргә тотынды.

«Ленин бабай, бәгырем, сиңа гына әйтәм. Безгә би-ик күп итеп налог салдылар. Түләргә акчабыз юк, әниемне көн туса кәнсәләргә чакырып, эт итеп сүгеп кайтаралар. Син исән булсаң, ятимнәрне җәберләтмәс идең. Әни миңа актык акчасын бирде. Әллә бу утызлыкны кире җибәрим микән? Киңәш ит, поездга билетсыз гына утырсам, ярамасмы? Юк, ярамас, ак тәүбә, кара тәүбә! Ач, ялангач булсам да, чыдармын, хәрәмләшмәм, алдашмам... Имтиханнарны да бирә алсам!..»

Беренче августтагы беренче имтихан — химиядән... Әллә ни курыкмый Әлфия, өлгергәнлек аттестатында бу фәннән «бишле» чәчрәп тора. Тукта, ни булды соң болай? Нигә болай авыр йокы басты? Күз кабак-

---

*Әнәс ГАЛИЕВ (1920) — әдип, «Тормыш бакчасында», «Йолдызлар шаһит», «Намус кушканча» һәм башка китаплар авторы. Казанда яши.*

ларына гер асканнар мыни, гел аска тартылалар. Станциягә барып житеп, поезд килгәнне шунда гына көтсә ярамаганмы? Кеше арасында йокы да ачылыр, йоклап китсә, уятырлар.

Ул торып тагын да авырайган чиләкне кулына алды. Чиләк бавы учына пычактай кисеп батты. Чүп өстенә — чүмәлә, дигәндәй, үкчәсен түфлие кырган. Оегын жәлләп яланаякка гына кигән иде. Менә сиңа, мә, килгән шәпкә сизмәгән икән, хәзер атлар хәле юк. Саранлансаң, шулай була икән! Авылда йон оек белән чабата киеп өйрәнелгән, чабата әйбәт, үзе жиңел, үзе йомшак, күпме чапсаң да аякны кырмый.

Институтка да чүт кенә чабата киеп чыгып китмәде, әнисе котк...рды, туфлине тамактан өзеп, берәмтекләп жыйган йомыркага алмаштырып алганнар иде. Ярар, йөри торгач, рәтләнер әле, үкчә сызлый дип елап утырыр көн түгел, тишелсә, ямавы үзендә.

Казанга барасы булмаса, Әлфиягә туфли гомергә дә эләкми иде. Үзе сорамады соравын, әнисе тыкырдатты, тырышты. Кеше арасында кызын ким-хур итәсе килмәде. Шәһәр кадәр шәһәргә жибәр дә, туфли дә кигертмә, имеш.

Ятим шул Әлфия, ятим. Әтисе сугыштан каты яраланып кайткан иде, үлгәненә быел ун ел тулды. Алар әниләре итәгендә берсеннән-берсе кечкенә биш бала белән калдылар. Әле шулардан тик берәвесе — апасы гына үзбаш көн күрә. Әлфия шул апасына барып төшәчәк. Кияүгә чыкканнан соң апасын күреп сөйләшкәне юк әле Әлфиянең. Парлап авылга кайтканнар иде, өйгә кагылып кына чыктылар, эшебез күп, дип, ут капкандай ашыгып китеп тә бардылар. Әлфия, жизнәсенә күренергә оялып, апасы белән сөйләшә алмый да калды. Апасыннан шикләнми, ул үз кеше, менә жизнәсе ничек каршылар? Ачык чырай күрсәтерме? Суконный ягындагы тирән erганак эчендә кача-поса йорт салып маташалар бугай, әнисе шулай аңлаткан иде. Озак эзләргә туры килмәсә инде...

Ул, шундый авыр уйларын ияртеп, әкрен генә кузгалды, кырылган үкчәсе тоз сипкәндәй әрнеп авыртса да, аксамаска тырышты.

Станциянең ераклыгы үзәккә үтә, авыллары кире якта шул аларның, ник бер атлы очрасын! Ничә чыксаң, тыр-тыр йөгерергә, тәпи-тәпи атларга туры килә. Күпер аша чыгып үр менгәндә, аны бер ир кеше куып житте. Әлфия аны уздырып жибәрергә чамалап адымын әкренәйтте. Теге адәм узмады, кызның хәлен уртаклашырга теләп, кызганулы тавыш белән сүз кушты.

— Ерактан киләсез, ахрысы. Йә, бирегез чиләгегезне.

Гадәттә, Әлфиянең үзен кызганган кешене жене сөйми иде, ятимлек күп нәрсәгә өйрәтте, ни гажәптер, бу юлы киреләнеп маташмады, авыр чиләк юлдашы кулына күчте. Хәер, ул кызның жавабын көтеп тә тормады бугай, чиләк бавын тартты да алды.

— Кайсы авылдан киләсез?

Әлфия ирексездән юлдашының аягына күз төшерде. Аякларында ялтырап торган туфлиләр. Өстендә елык-елык иткән өр-яңа костюм. Керләнмәгән якалы ак күлмәгенә кара галстук таккан. Юкарак борыны астында сызылып киткән кара мыек. Күзләре... Чират юлдашының күзләренә житкәч, Әлфия капылт аска карады, янып чыкты. Юлдашы, дустанә көлемсерәп, аны күзәтеп бара икән.

— Шүрәле каргаган авылдан,— диде кыз, туган авылының исемен әйтмичә генә, ә үзе, эченнән генә: «Белми торсын әле!» дип куйды.

— Алдашмагыз, ул авыл жир йөзендә юк инде!

Юл өстендә Ямаш исемле кечкенә генә бер авыл бар иде элек. Хужалык саны кырык-илледән берчакта да артмаган, шуңа күрә авылны «Шүрәле каргаган» дип атап йөрткәннәр. Утызынчы еллар башында, ни сәбәптәндер, ул авылны икенче жиргә, Кырлай урманы буена күчергәннәр... Авыл истәлеге булып зират кына калган. Юлдашының, алдашмагыз, дигән сүзен ишеткәч, Әлфиягә уңайсыз булып китте.

— Сез бу як кешесе мени? — дип сорады.
— Әйе. Мин шул авылда туганмын.
— Мин сезне чит яктан килгән дип уйлаган идем.
— Нигә?
— Безнең як кешеләренә охшамыйсыз,— диде кыз, юлдашының кыяфәтен, өс-башын күз алдыннан үткәреп.
Юлдашы бу хакта кабат сүз кузгатмады.
— Авылыгыз булмагач, нигә бу тирәләрдә йөрисез!
— Әби-бабайлар янына кайттым.
Әлфиянең сөрмәле күзләре зур булып ачылдылар, ул юлдашының сүзен аңлап бетермәде.
— Нәрсә, ышанмыйсызмы?
— Алар сезнең белән күчмәделәр мени? Кайсы авылда калдылар?
— Үзебез белән алып китеп булмады,— дип көрсенде Әлфиянең юлдашы.— Туган-үскән җирдә туфрак булып калабыз, диделәр.
— Ә-ә,— дип сузды кыз һәм чак кына юлдагы ташка абынмады.
— Ел саен кайтып әйләнәм шулай.
— Дога кыла беләсезме соң? — диде кыз кинәт.
Егет елмайды.
— Зиратка кайткач, дога уку мәҗбүримени?
— Әбиләр шулай диләр...
— Әбиләр сөйләшә алмый шул! Бик кызганыч! Югыйсә, каберләреннән сикереп чыгып, замана кешеләренең йөзенә төкерерләр иде. Алар исән чакта зиратыбыз зур тын бакча иде. Ә хәзер карарлык җире калмаган. Коймасы җимерелгән, каберләр өстендә мал-туар йөри, пычрата.
— Безнең авыл ияле булса да зират коймасы юк. Зират әйләнәсенә берничә кат тегәрҗеп сузып, үрмәкүч оясы итеп бетерделәр инде. Бала-чага шулай уйныймы, белгән юк.
— Нәзер әйткән кешеләр маташтыра. Зиратка койма койдырырмын, дип нәзер әйтәләр дә, соңыннан хәлләреннән килми. Исеме җисеменә туры килсә ярый, ходай кичерер, дип зират әйләнәсенә җеп сузып чыгалар.
— Ходайны алдамакчы булалар икән.
Икесе дә кычкырып көлеп җибәрделәр, адымнары бер мәлгә җинеләйде, станциягә килеп җитүләрен сизмәделәр.
Егет сәгатенә карап алды.
— Уху, бик иртә икән әле! Сәгатьтән артык вакыты бар!
Касса урнашкан бер катлы таш бина алдында поезд көтүчеләр өчен эскәмия бар. Иртә булса да, аны халык сарган. Егет эскәмиягә барып житәрәк буш җиргә чиләкне куйды.
— Рәхмәт, абый,— диде Әлфия оялып кына.
Аргы башта тагын бер эскәмия бар икән, анысы буш диярлек. Дүрт хатын кулларын болгый-болгый нидер сөйләшәләр. Алар яшь кыз белән чип-чиста киенгән егетне күзәтеп сүздән тыелдылар, тасыраеп карап каттылар.
— Әйдә, без дә утырып ял итик.
Егетнең тәкъдиме Әлфиянең күңеленә хуш килде, чиләкне аяк очына җиргә куеп, янәшә утырдылар.
— Шәһәргә йомырка алып барабыз, диген.
Егетнең күз читләрендә очкыннар уйнады. Әлфия ни әйтергә белмичә аптырап калды.
— Нигә алай дисез?
— Бу чиләктә йомыркадыр бит?
Әлфиянең бите тагын кызыша башлады, спекулянт, дип уйласа, хурлыгы ни тора?!
— Мин аны күчтәнәчкә алып барам.
— Кемгә, егетегезгәме? — дип сүзен дәвам итте кызның юлдашы.

Бусы бөтенләй көтелмәгән, йогышсызрак сүз иде.

— Сез бигрәк инде! — диде Әлфия, битен ике кулы белән каплап.

— Алып барсагыз да, гаеп эш түгел.

Эскәмияне биләп утырган хатыннар шыпырт кына аларны күзәтәләр иде.

— Миңа егетләр белән чуалырга иртә әле,— диде Әлфия, егеткә карамаска тырышып.— Апама күчтәнәч болар.

Егетнең һаман шаяртасы килә иде.

— Апаң да үзең кебек чибәрме?

Әлфия чыннан да гүзәл иде. Нәзек билле нәфис гәүдә, тулышып килә торган күкрәкләр, дугаланып торган кара каш астындагы сөрмәле күзләр, кул-аяк дисеңме, бер генә дә килмәгән җире юк. Бу гүзәллекне сизәрлек яшькә җитмәгән кыз һәр мактау сүзен үртәү, мыскыллау дип кабул итә иде. Тәрләп диярлек утырган әлеге егет тә юри мутлана, дип уйлап, аңа арты белән борылды.

— Менә кирәк булса! — диде егет һаман бәйләнеп.— Үпкәләттем! Чибәр кызларга үпкәләү килешми.

— Сез кешедән көләргә оста икән!

Әлфия, барыннан да бигрәк, киемнәре иске булуыннан кимсенде. Юа-юа кыскарып беткән күлмәк итәген тарткалап тезләрен каплады. Баягы хатыннар, егетнең чаялыгыннан, туры сүзеннән читенсенепме, дәррәү кузгалдылар да касса ишеге янына барып бастылар. Алар киткәч, Әлфия читкәрәк тартылды, аякларын эскәмия астына яшерергә чамалап, гәүдәсен алгарак чыгарды. Егет туфлиләр эчендәге кырылган үкчәләрен үтәли күрә кебек тоелды.

— Ялгышасыз, чибәр кыз. Кешедән көлә торган гадәтем юк. Чын күңелдән әйткән сүзләрне кирегә алмагыз.

Алар шактый вакыт тын утырдылар. Халык җыела торды. Егет кызны ничек тә җайларга тырышты.

— Апагыз кайсы урамда тора?

Әлфия аның бу соравын җавапсыз калдырырга уйлаган иде, егет торып каршысына килеп баскач, әйтмичә булдыра алмады.

— Әй, беренче тапкыр баруым, кайсы урамда икәннәрен белеп тә бетермим.

— Без барып җиткәнче караңгы төшә, төнгә каршы, белмәгән урамны эзләп йөрү читен булыр, дим.

— Суконный ягында, трамвайдан төшкәч ерак барасы түгел бугай.

Аның бу сүзләре егетне бераз тынычландырды.

Янәшә эскәмияне сарган юлчылар берзаман пыр тузындылар, савылып кассага ташландылар.

— Билет сата башлаганнар! — диде Әлфия, кыбырсып, җилкенеп кассага керергә җыенды.

— Үзем, үзем,— диде егет һәм ашыгып китеп тә барды.

Ул киткәч, Әлфия җинел сулап куйды. Җайлап кына күкрәгендәге утызлыкны эзләп тапты да, йомырка чиләгенә тотынгач, уйга калды. Ишле халык арасына чиләк күтәреп барып керсәң дә инде... Йомырканы ватып бетерерләр! Чиләкне монда калдырса, ничек булыр икән? Хуҗасыз чиләкне алып китәрләр дә кебек тоелды, азмы шук куллы бәндәләр. Станция тирәсендә урлашканнарын әнисе телдән төшерми торган иде. Ул арада егет әйләнеп тә чыкты. Әлфия егеткә каршы китте.

— Ә сез кая барасыз?

— Мин дә кереп билет алып чыгыйм әле.

Егет кулындагы ике билетны аңа күрсәтте. Әлфия башта аңламыйчарак торды, аннары шикләнеп кенә:

— Әллә миңа да алдыгызмы? — дип сорады, егеткә кабаланып утызлыгын сузды.

— Кайтарып бирергә акчам юк.

— Нишлибез алайса?

— Вак акчагыз булгач, бирерсез.
— Берәрсе вакламас микән, сорап карыйм әле.
— Юк белән башыгызны катырмагыз.
— Алай ярамый. Мин сезне тагын кайчан күрәм?

Әлфия егеттән читләшергә, җай чыкса, бүтән вагонга утырып күзеннән югалырга ниятләгән иде. Хәзер, нишләргә белмичә, каударланып исен җуйды. Еракта паравоз гөрләгән тавыш ишетелде. Казансу елгасы буенда кара төтеннәрен болгый-болгый килүче тимер айгыр үзе дә күренде. Ул күренүгә көтеп зарыккан пассажирлар, капчыктыр, чиләктер, кәрзиндер күтәреп, этешә-төртешә поездга каршы ыргылдылар. Әлфия, чиләген ике куллап тотып, кешеләр арасына барып керде, күз чите белән генә егетнең дә үзеннән калмавын абайлады. Вагоннар берәм-берәм үтә торды, поезд халык көткәннән шактый алга барып туктады. Ул чакта әле хәзерге кебек вагонга керер өчен платформалар юк иде. Җыелган халык иң арттагы вагон тирәсенә барып бөялде, китте этеш-төртеш, талаш, вагон ишегенә башта кешеләр менде, аннан кәрзиннәр, төенчекләр очты. Кемдер егылды, кемдер абынды, кемдер чыр-р итеп елап җибәрде.

Качарсың чая егеттән, әгәр ул булмаса, Әлфия вагонга эләгәсе түгел икән. Егет очып кына өскә менде дә:

— Бир чиләгеңне! — дип кычкырды һәм чиләк артыннан кызны да беләгеннән тартып меңгерде.

Олыраклар утырган, урталыкта һәм тәрәзә кырыйларында яшь-җилбәзәк баскан, кулларында дәфтәр-китап, әллә укыйлар, әллә юри тотканнар да рәвешен китерәләр инде.

Үз ишләрен күргәч, кыз күңелендә аңлашылмый торган сәер бер хис уянды. Ничек тырышалар, юлда да вакыт әрәм итмиләр, әзерләнәләр. Әлфия үзе белән дәфтәр-китап та алмаган. Бу турыда уйлап та карамады. Хәзер инде хәтерләми, кайдадыр укыдымы яки кемнәндер ишеттеме, имтиханнар алдыннан башны ял иттерергә кирәк, дигән сүз колагына кергән иде. Шул киңәшне тынлап, авылда чакта ныклап әзерләнде. Һич шикләнми, бөтен фәннәрдән шытырдатып җавап бирәчәк. Рус теле генә шикләндерә.

Юлдаш егет тә булачак студентларга игътибар иткән икән, башы белән ишарәләп:

— Тырышалар! — диде. Әлфия сискәнеп китте.— Бик уйга калдыгыз, нәрсә исегезгә төште.

Соңгы сүзләр аңа уйларын яшерергә мөмкинлек бирде.

— Юл буендагы агачларны күзәтәм,— диде кыз, имтихан бирергә баруын ачарга теләмичә.

— Күзәтерлек ние бар аларның?

— Бик бәләкәй идем әле мин. Әти мине атка утыртып шәһәргә алып барган иде. Сугыш беткән ел иде бугай. Бу агачларны утыртып кына маташалар иде.

— Агачлар үскән,— диде егет уйчан гына.— Сез дә житкән кыз булгансыз.

Паровоз уфылдап-ашкынып вагоннарны алга өстери. Тагын бер тукталыш, тагын бер... Халык ишлерәк станцияләрдә ул озаграк тора, аннары, соңга калмыйм тагын, дигән сыман, тырышып-тырышып тәгәри башлый. Вагоннарда инә төшәр урын да юк, халык өстәлгән саен егет Әлфиягә якынрак килә. Кыз читкә тартылырга тырышып, аяк очларына басып як-ягына карана. Кая ул!..

Соңгы станцияләрдә утырган, аларны уртага алып кысылышкан хатын-кызлар маржалар иде. Әлфия егетнең алар белән русча сөйләшүенә сокланып барды. Хатыннарның берсе бик текәп Әлфиягә карап торды да:

— Бу кыз сезнең кемегез була? — дип сорады.

— Сеңлем,— диде егет, күп уйлап тормыйча.

Мондый җавапны ишеткәч, Әлфия җир тишегенә керердәй булды, егеттән читкә китеп, аның ярым шикланып елтыраган күзләреннән югаласы килде.

— Сеңлегез бер дә сөйләшми, борыны бик югары ахры,— диде хатыннарның икенчесе.

— Юк,— диде егет,— оялчан ул.

Әлфиянең хатыннарга ачуы килде, аларның үзен тикшереп, чәйнәп баруларын ошатмады.

Алдагы станцияләрнең берсендә поезд бик озак, сәгатьтән артык торды. Тиз йөрешле поезд сонарган да шуны үткәреп җибәрә, диделәр. Башга ишеккә якынрак торганнар җиргә төшеп сибелде, алар бушаткан урыннарга вагондагылар күчте, тора-бара алар да саф һава суларга чыктылар. Басып торыр хәле калмаган Әлфия бушаган урыннарның берсенә барып утырды, егет аның янына килде.

— Син минем бер туган сеңлем булдың, үзең исемеңне дә әйтмисең.

Әлфиянең җеп өзәр хәле дә юк иде, ясалма елмайгандай итте.

— Сез дә әйтмисез ич! — диде.

— Мин Мансур исемле булам. Мансур Сабитов.

— Мин — Зәйтүнә.

Әлфия алдавын сизмичә дә калды, теленнән апасының исеме ычкынган икән.

— Менә шулай, Зәйтүнә сеңлем, таныштык та...— Егет әзрәк уйланып торды.— Хәзер апаннарга бергә барсак та була!

Әлфия утырган урынында сикереп алды: «Нинди кеше бу, ә? Ябышкак сагыз, дисәң, йөзе ягымлы!»

— Анысы булмас! — диде ул, кистереп.

— Ярамыймыни?

— Ярамый! — диде Әлфия коры гына.

Зарыгып көтә торгач, тиз йөрешле поезд да килеп җитте, ул монда туктап тормады, тизлеген дә киметмәде, буран уйнатып, ыжгырып китеп барды.

Шәһәргә барып җиткәндә кич булды, лампаларга ут алынган иде инде. Вокзал аша үтеп урамга чыккач, тыз-быз чабышкан халыкны күреп, Әлфиянең башы әйләнеп китте, иртә таңнан аяк өстендә йөреп, бер тәгам ризык капмавы исенә төште. Чиләгендә бер кыерчык ипие бар иде барын, Мансур алдында авыз күтәреп ашап барырга оялды.

Урамда тиз-тиз юлдашыннан аерылырга ашыгып алга тартылса да, барыр юлын анык белмәгәч, ирексездән туктап калды, ерак erганак төбендә утырган йортны таба алырмы, юкмы бит әле. Шулай да куркуын Мансурга белдертмәскә тырышты.

— Рәхмәт инде сезгә, Мансур абый,— дип, чиләген егет кулыннан алырга теләде.— Мин хәзер трамвайга утырам.

— Апаң Суконныйда дисез, мин шул якта яшим, трамвайга бергә утырырбыз.

Мансурның төнгә каршы Суконный ягына, белмәгән җиргә Әлфиянең үзен генә җибәрәсе килмәде. Анда төрле халык яшәгәнен белә ул, иске шәһәр, халык чуар, базар тирәсе «козгыннары». Юл уңае булмаса да озатып куярга теләде.

Егетнең һаман иярергә тырышуы Әлфиянең шиген арттырды.

— Мәшәкатьләнмәгез, абый. Бусы өчен дә зур рәхмәт, үзем дә табармын әле.

— Сез барасы яклар куркыныч, шикләнмәгез — апагыз янына кермәм.

Алар дүртенче трамвай белән азакка кадәр бардылар. Трамвайдан төшкәч, Овражный урамын эзләргә кирәк иде. Чыннан да, юлдашы ярдәм итмәсә, Әлфия үзе генә таба торган түгел икән, җәһәннәмдә икән ул урам! Исеменнән аңлашылганча, урам тирән erганак эчендә булып чыкты. Бер яклап тактадан салган шырпы тартмасы кебек вак-вак йорт-

лар тезелеп киткән. Йортларга номер да сугылмаган. Теләсә-теләмәсә дә, Әлфия Мансурга җизнәсенең исем-фамилиясен әйтергә мәҗбүр булды. Егет йорттан йортка кереп сораша торгач, үзләренә кирәклене эзләп тапты. Бу вакытта Әлфия Мансурны кочаклап үбәргә әзер иде. Бар икән дөньяда мәрхәмәтле кешеләр, дип сокланды кыз. Үзе белән бергә өйгә керсә дә каршы тора алмас иде бу минутларда. Әллә, рәхмәт йөзеннән, берәр дистә күкәй бирим микән, дип тә уйлады, ләкин кыймады.

Мансур вәгъдәсен бозмады, кермәде, кызга уңышлар теләп, китеп барды. Аның кылган яхшылыгын аңлый алмыйча, Әлфия озак баш ватты.

## II

Әлфия барып кергәндә, апасы йокларга әзерләнеп йөри иде. Ул аны гаҗәпләнеп каршылады.

— Күземә күренәсең дип торам,— диде.— Болай төнгә калып йөрмәсәң, булмаганмы! Ничек эзләп таптың? И-и, бала, бала...

Тиз-тиз генә хәл-әхвәл белеште, әнисе, туганнары турында сорашты.

Яшь аралары бер генә ел аларның, шулай да Әлфия апасын бик олы санап хөрмәт итә. Апасын күрү белән күңелендә кызгану хисе уянды. Апасы нык ук юанаеп киткән, буенда бар икән, бите тимгел-тимгел.

— Тапкансыз урынның асылын! Монда чокыр-чакыр эченә, җәһәннем түренә кереп йорт сала башламасагыз, бүтән җирдә урын беткәндер,— дип ризасызлыгын белдерде Әлфия.

— Урыныбыз менә дигән, тапкан өчен җизнәңә рәхмәт әйт!

— Үзе кайда соң?

— Хәлим икенче сменага йөри. Эштән такта-токта кыстырып кайтырга җайлы. Төнлә аулак безнең тирә, кеше-кара йөрми.

Өй эченең рәте юклыгын Әлфия күзе ияләшә төшкәч кенә күрде. Бүлмәләр яртылаш кына эшләнгән, мич акшарланмаган, бер почмакта әрҗә такталары өелгән. Кая карама кадак, тимерчыбык кисәкләре аунап ята.

— Бу чүп-чар такталарны нигә монда кертеп тутырдыгыз? Мичкә ягаргамы?— дип сорады кыз.

— Син нәрсә? Әллә безне байлык белән йорт сала дип беләсеңме? Җизнәң әнә шундый такталардан, тартма-әрҗә ватып оештыра.

Зәйтүнәнең йорттан риза икәнлеге чыраена чыкты.

— Әле күрерсең, курчак өе итәчәкбез! Бу төштә зал, аңда йокы бүлмәсе булачак.— Ул кулы белән ишарәләп өй эчен бүлгәләп күрсәтте.— Такта кирәк, такта! Хәлим кухня эшләргә дә уйлый.

Кучкарда яныл утырган лампа төти башлады.

— Кадалгыры, керосины бетә. Барырга вакыт юк. Иртәгә мин эшкә киткәч, кибеткә чыгып керсәң, әйбәт булыр иде. Ерак түгел.

— Шәһәрдә торуыгызны әйтер идем.— Әлфиянең чырае сытылды.— Мин киткәндә авылга электр кертергә калдылар. Сезне нишләп болай караңгыда тоталар?

— Әкренләп булыр әле. Монда безнең, ерганак буенча, бар да качырып, законсыз салынган йортлар. Бернича мәртәбә трактор китертеп җимерә башлаганнар иде. Без җимертмәдек! Җизнән бер төн эчендә мичен чыгарып куйды. Килеп карадылар, ә безнең моржадан төтен чыга. Ургылып, ургылып чыга!— Зәйтүнәнең сүзе иртәнгә кадәрле сөйләсә дә бетәсе түгел икән.— Әй, тузыналар, әй, сүгәләр! Моржадан төтен чыккан йортны җимерергә хаклары юк икән!

Әлфиянең өзелеп карыны ачкан иде.

— Морҗалы өйдә капкаларга ризык табылырмы?— дип сорады.

Утырып ашарга өстәл дә юк икән. Зәйтүнә мич янындагы тәрәксез урындыкны сәнлесе алдына китереп куйды да ана гәжит җәйде. Өялдына чыгып, җамаякка салып мул гына эремчек алып керде. Эремчекне каймакка бутаган иде ахрысы. Әлфия аптырап китте.

— Әллә сыерлары да бар инде боларның?

Эре-эре телемнәргә ак калач турап маташкан Зәйтүнә кычкырып көлде.

— Сыерсыз торып буламы, исәр? Бар, бар! Колхоз базарында тотабыз сыерны.

Әлфия аның соңгы сүзен колагына элмәде, комарланып ашарга керешге.

— Эремчеге, эремчеге! Телеңне йотарлык. Әйбәт сыерга юлыккансыз икән.

— Шыр тиле инде син. Каян килсен ди безгә сыер? Базар каймагы! Син минем базарда эшләгәнне белмисең шул. Базардан алып кайтам.

— Анда да бушка бирмиләрдер.

Бу сүз кинәнеп карап утырган Зәйтүнәгә ошамады. Ошамады гына түгел, ачуын чыгарды.

— Юк җирдән бет эзләп азапланма! Ашавыңны бел! — диде ул, коры гына.

Әлфия алдына куелган ризыкларны ялт иттерде. Почмактагы чиләктән кружка тутырып су эчте. Ул шунда гына үзенең тәмам йончыганын, арып хәлдән тайганлыгын сизде. Апасы, өй һәм такта хакында сүз озайтып, урын көйләде. Идәнгә сырма җәеп, баш астына йодрык хәтле генә мендәр салды. Өскә ябынырга әйбер табалмыйча аптырап торды да үзләренең караватыннан ак җәймә алып бирде.

Әлфия яту белән йокыга китте. Бер нәрсә белешмичә йоклады, апасы эшкә киткәнне дә сизмәде.

Зәйтүнә эшкә бик иртә китә, җәй көннәрендә сәгать биштә үк эш урынына барып басарга кирәк. Киткәндә сеңлесенә йомыш кушарга чамалап төрткәләп караган иде, кая ул, Әлфия селкенмәде дә! Дәфтәр битенә язу язып, аны Әлфиянең баш очына куеп калдырды.

Тәрәзәдән төшкән кояш нурлары күзен капшый башлагач кына уянды Әлфия. Шактый вакыт аңына килә алмады. Ул үзен авылда, үз өйләрендә дип хис итә иде. Акшарланмаган мичкә, караватта яткан ярым ялангач таза гәүдәле иргә күзе төшеп чак кычкырып җибәрмәде. Өнме, төшме икәнен аера алмыйча шактый газапланды. Йокы белән ул үзенең шәһәргә килүен онытып иде. Әкеренләп барысы да исенә төште тагын. Юллар, поездлар, чыр-чу, карангы шәһәр урамнары... Иң азактан юлдашын хәтерләде. Мансур Сабитов... Кайда икән ул хәзер?

Хатирәләр онытылды, җәймәсенә ныграк төренергә тырышып ул караватта ятучы ир кешене күзәтте. Җизни дигәннәре шушы була микәнни, дип уйлады. Теге вакытта, алар әзгә генә авылга кайткач, оялып, качып калуына үкенеп куйды. Менә хәзер теләсәң-теләмәсәң дә күренергә туры килә. Ярый әле, авылдагы кебек чишенеп ятмаган иде. Эчке күлмәктән генә булса, ят кешегә ничек күренер иде? Юк, болай суйлакланып ятып эш чыкмас.

Ул торып утырды. Җайлап кына чәчен тарады. Бигрәк куе инде чәчләре. Үргәч, калын учма кебек була. Әллә кистереп ыргытырга инде? Юк, ярамый. Андый калын толым бөтен кызларга да тәтеми!

Баш очына апасы куеп калдырган язуга күзе төште, аны алып укыды. Ул Хәлимгә кичке якта, Әлфия белән бергә, үзе янына базарга килергә кушкан иде.

Әлфия аяк очларына гына басып җизнәсе яткан карават янына барды һәм язуны аның өс-киемнәре өелгән эскәмиягә куйды.

Вакытны белергә теләп як-ягына каранды, өйдә сәгать юк иде. Җизнәсенең беләгендә сәгать бар икән барын, циферблаты күренми. Имтиханына соңга калса! Кыз шыпырт кына чыгып сызарга ниятләде.

Тамакны ныгытып алганда зыян итмәс иде дә, әйдә, калып торсын! Кеше йортында иснәнеп йөрерме Әлфия? Үлмәс әле. Ишек тоткасына ябышам, дигәндә генә җизнәсе калкынды, уяу икән лабаса ул, йоклап яткан гына була икән.

— Кая барасың болай? Ашагач китәрсең.

Әлфия уңайсызланып ни диярргә дә белмәде.

— Авылда ни хәлләр? Әбекәй исән-сау калдымы?

— Күп итеп сәлам әйттеләр. Кызу урак өсте бит, эш күп.

Хәлим торып утырды, ул майка белән трусиктан гына иде. Әлфия арты белән борылды, алай да шәйләп алды: җизнәсе таза бәдәнле, матур кеше икән. Киң күкрәкле, беләк мускуллары кабарып-кабарып тора. Әллә көрәшче дә инде? Артык яшь тә түгел икән, чигәләренә чал йөгергән. Апасыннан шактый олы яшьтә булса кирәк. Ул тиз-тиз торып киенде дә, керосинкага чәйнекне утыртты.

— Балдызны да күрер көн бар икән! Без авылга кайткач качып калган булдың.

— Оялдым...

— Җизнидән оялалармы? Беләсең килсә, җизни — иң олы туган.

— Хәзер оялмыйм ич инде.

— Гел шулай кирәк. Оялып яшәсәң, бу дөньяда уңам, димә! Тормыш кыюларны ярата!

— Укытучыбыз, Мәдинә апа, намуссыз кеше генә ояла белми, дия иде.

Хәлим, иртәнге әңгәмә болай еракка кереп китәр, дип уйламаган иде, сүзне тиз кыскартты.

— Анысы башка чут,— диде.— Ник әбекәйне үзең белән алып килмәдең?

— Кая ди аңа өйне ташлап чыгу? Үзегезне чакырып калды, кайтсыннар берүк, диде.

— Һич бушап булмый. Иң әүвәл йортны җиткереп бетерергә кирәк.

— Эш качмый ла,— диде Әлфия, кулын селтәп.

— Безгә ашыкмыйча булмый, кыш җитә бит, кыш!

Хәлим Әлфиягә бәрәңге әрчергә кушты, үзе колбаса турарга тотынды.

— Әйдә, апаң югында сыйланыйк әле. Алар базарда гел кунак сыенда яшиләр! Безгә дә хәрәм булмас.

Ул бәрәңгеләрне турап табага тездә дә колбаса кушып, ут өстенә куйды. Моңа кадәр ир-атның ризык әзерләгәнен күрмәгән Әлфия җизнәсен кызыксынып күзәтте.

— Балдыз, укырга керергә ниятләп яхшы иткәнсең. Ныклап әзерләндеңме соң?

— Үземә күрә укыган булдым инде.

— Ишеткәнсеңдер, хәзер укырга керүләр бик авырлашты, диләр. Бер урынга дүрт-биш кеше, имеш. Сугыштан соңгы елларда ансат иде ул. Укырга керергә чакырып торалар иде. Гариза илтеп бирсәң, шул җиткән дә иде.

— Җизни, син ник укымадың алайса?

— Мине алмадылар. Укыйсым килгән иде.

— Имтихан бирә алмадыңмы?

— Юк ла... Бүтән сәбәпләре килеп чыкты.

Әлфия «ә-ә» дип кенә куйды, сәбәпләр белән кызыксынып, төпченеп тормады. Керосинка өстендәге таба әкрән генә чыжларга тотынды, өй эченә тәмле ис таралды. Тиз-тиз ашап-эчкәч, Әлфия институтка китте, ни вакытта имтиханга килергә кирәклеген белеште дә, кире борылды. Ул кайтканда җизнәсе ишегалдында яныш-пешеп такта ышкылап маташа иде.

— Бер үзеңә авыр түгелме?

— Булыш, әйдә!

— Булышам. Бергәләп ышкылап карыйк.

Хәлим мондый җавап көтмәгән иде, балдызына сәерсенеп карады.

— Әрҗә такталарын икәү ышкылап булмый, кыскалар. Озын такта юнәткәч чакырырмын.

— Манма тиргә баткансың, бераз хәл җый. Кая, мин ышкылап карыйм.

Хәлим сынау нияте белән кулындагы ышкыны Әлфиягә бирде. Ул кызның ышкылый алуына ышанмады, әрҗә такталары чат ботак, теләсә кайда су эчендә, балчык арасында аунап калҗайганнар. Аларны таза ир кеше дә көч-хәл белән ипкә китерә.

Әлфия бик җиңел тотынды. Эшкә кулы ябышуын күреп, Хәлим гаҗәпкә калды. Балдызы ышкылаган такталар аның үзенекенә караганда да чистарак, шомарак кебек, иде.

— Валлаһи: ирдәүкә икәнсең. Кайда өйрәндең болай оста ышкыларга?

— Атнага бер хезмәт дәресе керә иде безгә. Шунда өйрәттеләр. Өй арасында да бушап торган юк, әле коймага такта кирәк, әле капканы төзәтәсең.

Әлфия эш белән маташкан арада Хәлим өйгә кереп өс-башын алыштырып чыкты.

— Әйдә, апаң янына базарга барып кайтабыз.

— Син үзең генә бар, мин такта ышкылый торам.

— Юк, бергә барабыз. Апаң сине дә алып килергә кушкан. Бармасаң икебезгә дә эләгер.

Әлфия эш белән мавыгып керосин алып кайтырга кирәген онытып җибәргән иде, хәтерләп уфылдарга тотынды.

— Минә миңа эләгәчәк! Бөтенләй онытып җибәргәнмен. Керосин алып кайтырга кушкан иде бит.

— Базардан кайтышлый керосинга да керербез.

Алар базарга җәяүләп кенә бардылар. Эре-эре атлап барган җизнәсе артыннан Әлфия чак-чак өлгерде. Җәрәхәтле үкчәсе тагын котырып сызларга тотынды.

Базарның гөрләп торган чагы иде. Нәрсә белән генә сату итмиләр монда! Төрледән төрле яшелчә, җиләк-җимеш — базар күтәреп торырлык түгел. Ак алъяпкыч ябып, ак җиңсә кигән хатыннар бер-берсе белән ярышып, төрле тавышка товарларын мактыйлар. Сатучы алучыдан күбрәк. Шулай булмыйча хәле юк, табигатьнең иң бай чагы, бөтенесе өлгергән, халык үзеннән артканын да, күп вакытта авызыннан өзеп тә җиләк-җимешне акчага әйләндерергә тырыша.

Әлфиянең шәһәр базарын күргәне юк иде, ана мондагы хәлләр үтә сәер тоелды. Җизнәсе як-ягына карап тормады, алар туп-туры бер лабазга барып керделәр. Ит лабазы икән. Зур-зур лабазда ит бер генә урында. Хәлим лабаз түрендәге ишек төбенә барып туктады. Ишек эчтән бикле икән. Эчтән кемнәрнеңдер сөйләшкәне, ара-тирә көлеп куюы да ишетелде. Хәлимнең чырае карангыланды, ул әз-мәз таптанып торгач кына ишек шакыды. Бераздан кысып кына ишек ачтылар, ярыкта Зәйтүнәнең гәүдәсе күренде, ул аларны эчкә кертмәде, үзе чыкты һәм бер читкәрәк алып китте. Прилавка астыннан дыңгычлап тутырылган ике сумка алып Хәлимгә тоттырды.

— Миндә кунаклар бар, тизрәк таегыз, күргәннән күрмәгәннәре яхшы.

Әлфия берни дә аңламады. Нинди кунаклар? Кунаклар эш урынына да килә микәнни? Эштән соң өйгә килсәләр ярамаганмы? Җизнәсе бер сүз дә кайтарып сорамады, сумкаларны эләктерде дә тиз-тиз лабаздан чыгып ычкынды.

— Алар нигә шулай бикләнеп утыралар? — дип сорады кыз.

Хәлим авыр сумкаларын җиргә куеп тирен сөртте, кулын селтәде.

— Эте-бете шунда җыелып ята! — Тикшерергә, дигән булып киләләр дә тыгынып китәләр!

Әлфия җизнәсе сүзеннән тагын берни дә аңламады: нинди тикшерүчеләр? Нигә аларны сыйларга кирәк?

Юл уңаеннан керосин кибетенә кагылдылар, аннан чыккач, бу хакта сүзне дәвам итмәделәр. Беренче күргәндә көчле, ягымлы булып күренгән Хәлим җизнәсе бер минутта йончып, картаеп калды, аның маңгаена тирән сырлар ятты.

## III

Әлфия имтиханнарны татар телендә тапшырды. Эше башта бик уңышлы барды: «бишле»дә «бишле»! Җизнәсе шаккатты:

— Кара син, ә? Булдырасың икән! Көтмәгән идем!

Алай да тырыш кыз институтка үтмәде. Рус теленнән «икеле» алып кайтты. Укырга керә алмавына Әлфия әллә ни кайгырмады. Үтмәгән иптәшләре приказ эленгән тактага ябышып үкереп елаша башлагач, күзеннән бер-ике яшь тамды да, тынды, язмыштан узмыш юк, диләр, шулай язгандыр, дип үзен тынычландырды.

Укырга керә алмаса да, шәһәрне ташлап кайтырга теләмәде. Авыл үзенең фәкыйрь тормышы белән аның җелегенә төшкән иде инде. Кыз күңеленә яңа уй килде — ничек итеп, нинди юл белән шәһәрдә төпләнеп калырга? Мәсьәләнең а ырлыгын зирәк кыз чамалый да башлаган иде, әмма алда көткән мәшәкатьләр аны куркытмады. Калырга, шәһәр кызы булырга! Кире авылга кайтмас өчен, теләсә нинди кыенлыкларны да җиңәчәк Әлфия! Колхозда тамак туйдырырлык эш табу хакында уйларга да ярамый. Бөтен карап торганнары — өй янындагы бәрәңге бакчасы. Шул егерме биш сутый бакчадан алган керемнән беренче чиратта дәүләт алдындагы йөкләмәләрне үтәргә кирәк. Алар, саный башласаң, әз түгел! Авыл хуҗалыгы налогы, үзара салым, ит, йон, ә сыерлы кешедән сөт тә түләтәләр. Исемнәрен дә санап чыгарлык түгел. Өстәвенә ел саен заем! Ихтыяри-мәҗбүри түләүнең иң авыры монысы. Шушы түләүләрне үтәгәннән соң, егерме биш сутыйдан алган керемнән йортка ни кала? Анысы берәүне дә кызыксындырмый, анысын йорт хуҗалары гына белә. Тормыш ашау белән генә чикләнми бит, өс-баш төткәзергә дә кирәк. Дөрес, быел көз хезмәт көненә йөз граммнан уңыш бүленәчәк дип сөйлиләр. Хәер, урып-җыйганда андый сүз былтыр да йөрде, өченче ел да вәгъдә иттеләр. Быел да буламы-юкмы...

Шәһәр халкы җәннәттә яши, дип уйлады Әлфия. Сигез сәгатен эшләп кайта да тук корсагын уып ял итә. Ялкау булмаганы эштән кайткач та тик ятмый. Ә кулын кыймылдаткан кешегә акмаса да тама икән монда.

Әлфия җизнәсенең уңганлыгына сокланып бетә алмады. Булса да булыр икән оста кул! Чыралыкка да ярамаган әрҗә такталарыннан менә дигән йорт оештырган да куйган. Авыш ярда өй урыны әзерләп, тау-тау балчыкны аска күчергән, юлны тигезләгән. Элегрәк такталарны иңенә күтәреп ташыган, хәзер атка төяп тә алып кайтып була. Үзенә дә шундыйрак кияү табылса, төкерер иде Әлфия авылга! Апасы бәхетле икән аның, кияүдән егылып уңган икән. Юк, көнләшмәде Әлфия, андый гадәте юк, апасының бәхетен күреп ихлас сөенде ул.

Тора-бара Әлфия җизнәсен кызгана да башлады, эше авыр, пычрак икән Хәлимнең. Йөкче булып эшли икән. Станциягә килгән вагоннарны бушаталар икән алар. Хәлим күмер бушаткан көннәрдә кап-кара булып, корымга, тузанга батып кайта. Күзе генә елтырый. Әлфия ул кайтышка су җылыта, юынганда чүмеч белән коеп тора. Аның болай кул арасына кереп, булышып йөрүе Хәлимгә бик ошый. Бер көнне ул:

— Балдыз, йөрмә авылга кайтып, үзебездә генә кал,— диде.

— Рәхәтләнеп калыр идем дә...
— Эш нәрсәдә соң?
— Апа риза булмас.
— Аңа калса, көйлибез аны! Анысы вак мәсьәлә!

Өй эшләре Әлфия кулына күчте. Хәзер иднне ул юа, су китерә, көн саен апасы янына базарга барып ул әзерләп куйган сумканы алып кайта. Сумкада нинди генә тәмле ризыклар булмый! Эремчек, каймак, җиләк-җимеш, төрледән-төрле яшелчә, яңа бәрәңге, җаның ни тели — барысы да бар. Апасы аларны каян ала, нинди тылсым белән юнәтә, авыл кызы бу хакта уйламый иде.

Бар мәшәкате кулдан китте Хәлимнең, балдызының базарга барып йөрүенә ул шатланып бетә алмый. Аның үзе өчен базарга барып кайту мең газап иде. Хатыны анда эшләмәсә, ул базар ягына әйләнеп тә карамас иде. Базардан кайткан сумкаларны күрүгә күңеле болгана башлый аның. Әгәр йорт-кураны җиренә җиткереп бетерсә, хатынын бер минут анда тотачак түгел ул. Бер минут та!

Әлфия исә базарга теләп йөри, җырлый-җырлый бара да, бии-бии кайта. Төс керде кызга, тазарып, тагын да чибәрләнеп китте. Барысыннан да бигрәк кызга базардагы муллык ошый. Моңа кадәр мондый муллыкның аның төшенә дә кергәне юк иде. Базардагы муллыкны күреп очып йөри хәзер кызыең! Базардан кайта да жизнәсенә булышырга тотына. Аның хәзер бер нәрсәгә генә кәефе китә — шундый уңган, акыллы җизнәсе нигә дип эт типкәсендә, иң пычрак эштә йөри? Белеме, аңы да бар Хәлимнең, дөнья хәлләрен сөйләшә башласалар, Әлфия гел-гел җиңелеп кала, җизнәсе белгәннең чирегеп дә белми. Хезмәт хакы бүтәннәрдән өстен булса икән, юк бит, аена биш-алты йөздән артмый.

Беркөнне шулай, Хәлим эшкә китәргә җыенып йөргәндә, аларга милиционер килеп керде. Аны күргәч, Әлфиянең коты очты. Кызыл һәм бетчәле борыны астында җеп итеп калдырган сары мыегы, мәченеке төсле түгәрәк күзләре куркытты аның. Җитмәсә үзеннән шундый тәмсез ис аңкый, Әлфия борынын тотып чыгып китәргә җыенган иде дә нигәдер тыелып калды. Милиционер черт-черт көнбагыш ашый, кабыгын Әлфия әлерәк кенә юып чыгарган идәнгә төкерә. Хәлим аны үзенчә олылап каршы алды.

— Уз, уз, Мәхмүт дус, уз. Байтактан күзгә-башка күренмисең. Юксынып тора идем әле.

Милиционер Мәхмүт аның сүзенә игътибар итмәде, Әлфиягә ымлап:
— Бу нинди кош тагын? — дип сорады.
— Кунак кызы, балдыз.
— Паспорты бармы? Читтән килгән кешегә шәһәрдә өч көннән артык пропискасыз яшәргә ярамый.
— Авыл кызына паспорт каян килсен? — диде Хәлим, балдызына нидер ишарәләп.
— Бар, җизни, минем паспортым бар! — дип, Әлфия милиционер каршысына килеп басты, Хәлимнең «сыз тизрәк!» дигән ымын аңламады. — Укырга барам, дигәч, паспорт бирделәр!
— Мине ялганчы итә яздың бит. Каян килсен сиңа паспорт дип уйладым... Кем бирсен аны авыл җирендә? — Хәлим шулай сөйләнә-сөйләнә мич казнасыннан бер шешә тартып чыгарды. — Йәле, Мәхмүт, якташ, утыр. Көпе-төпе аяк өстендә йөреп арыйсыңдыр. Сиңа мотоцикл бирергә җыеналардыр? Бирерләр, синдәй егеткә дә бирмәсәләр...

Шешә күргәч, Мәхмүт Әлфия турында сорашудан туктады.
— Аракыңның кайдалыгын белдем. Елап эзләсәң дә таба торган түгел икән! Беркөнне кердем, үлеп баш авырта! Махмыр! Тапмый гына бит хатының...

Милиционер белән Хәлим бергә көлгәндәй иттеләр, хуҗа кырлы стаканны тутырып аракы койды.
— Ә үзең?

— Ярамый, икенче сменага барам.

Хәлимнең эчмәвенә милиционерның куануы күренеп тора иде. Ул кабарга ризык әзерләгәнне дә көтмәде, стаканны бушатып куйды.

— Тагын биримме?

Милиционер стенага җилкәсе белән сөялеп күзен йомды, беравык шулай басып торды, борын өстенә бөрчек-бөрчек тир сибелде. Кул аркасы белән маңгаен сөртеп алды.

— Кабарга бир!

Хәлим өстәл астыннан мае агып торган селедка кисәге чыгарды.

— Беткән баш беткән, чөмерәм мин моны! — диде Мәхмүт, шешәне үз кулына алып.

Әлфия милиционерның аракыны күзен дә йоммыйча эчүенә шаккатты. Аңа ул баскан җирендә егылып калыр кебек күренде. Мәхмүт бик тәмләп, хуҗа куйган балыкны ашап бетерде дә китәргә җыенды.

— Кара аны, аң бул! Мин сезгә кермәдем. Бу кызыйны кисәтеп куй — ул да мине күрмәде!

— Тыныч бул, без тәртипне беләбез.

Милиционер киткәч, уйга чумып шактый вакыт тын утырдылар. Әлфия нәфрәтен эченә җыеп тора алмады.

— Моңарчы сездә шешә-мазар күргәнем юк иде. Җизни, ни дип шушы җенне сыйладың?

— Сыйлап та таманга килә әле.

— Кем соң ул кадәр? Алланың кашка тәкәсе түгелдер ич?

— Участковый. Күрдең ич, бәйләнергә генә тора.

Базар муллыгы, апа-җизнәсенең юмартлыгы белән дөньясын онытып торган кыз шәһәрдәге тәртипне моңарчы күз алдына да китерә алмаган икән. Җизнәсе ачылып китеп, сөйләп күрсәткәч тә аны бөтен житдилеге белән аңлап бетермәде. Пропискага керү дигәннәрен ишеткәне бар иде барын. Әмма аны бик ансат кына үтәлә торган эш дип уйлый иде. Җизнәсе:

— Пропискасыз яшәгән өчен бер мәртәбә түләдем инде,— дигәч, аптырап калды.— Һәр нәрсәнең рәте бар,— диде Хәлим сүзен дәвам итеп.— Менә шулай участковыйны көйләп-чөйләп яшәп ятабыз әлегә. Алдагысын алла белә...

— Нишләп пропискага кермисез соң?

— Рөхсәтсез салынган йорт булгач, йорт кенәгәсе бирмиләр.

— Ә мин сездә тора калсам?

— Менә шуны күздә тотып сыйлыйм да инде мин ул адәм актыгын!

Тәмам югалып, куркып калган Әлфиянең, бу сүзләрне ишеткәч, эченә җылы керде, аның шәһәрдән бер дә, бер дә китәсе килми иде. Әгәр бөтенләйгә торып кала алса, искиткеч яхшы булыр иде. Шәһәрдә аңа һәммә нәрсә якын, моны әйтеп аңлата торган түгел хәтта. Авылда изаланып көне-төне эштән арынмаган әнкәсе күз алдына килгәч, тырнак астыннан кер эзләп йөргән милиционер да якын булып тоелды. Аны авызлыклау җае бар икән ләбаса! Аның җизнәсеме, теләсә...

Хәлим балдызын күзәтеп утыра икән.

— Нәрсәдән көләсең? — дип сорады ул.

— Исерек милиционердан.

— Кирәкне бирер әле ул бәдбәхет. Йортны салып бетергәнче имәчәк. Әле чакырып алып бәдрәфләрен тазарттырды. Бер каныкса, җанынны суырмыйча туктамас.

Бу сүзләр Әлфиянең сөенечтән тыпырдаган йөрәгенә энә булып кадалды.

— Шул этне авызлыкларлык закон юкмыни соң?

— Закон бар. Законны санга сукмыйлар. Кәгазьдә кала закон.

Хәлим тамак ялгап алды да китәргә җыенды.

— Бигрәк әз ашыйсың инде, җизни. Шундый авыр эштә эшләп, тәнеңдә җанны ничек асрыйсыңдыр.

— Апаң күп ашарга кушмый.

Хәлим бу сүзләрне әйтте дә ялт кына балдызына карап алды. Әлфия ышанырга да, ышанмаска да белмәде. Җизнәсе чыгып киткәч, минем апа шундый шәфкатьсез микәнни, дип уйлап утырды. Авылда чакта кече күңелле, мәрхәмәтле иде ич апасы.

Зәйтүнә кайтырга әле шактый вакыт бар иде. Тизрәк су ташып куярга да әз-мәз такталар ышкыларга кирәк. Әлфия ике кулына ике чиләк тотып суга китте. Кое шактый ерак, олы урамда иде. Мәзәк инде бу шәһәр кешеләре, су ташырга көянтәләре дә юк. Базарда көянтә сатканнарын күргән иде Әлфия, ападан алдыртасы калган икән, дип уфылдады.

Әлфия, каршысына баягы милиционер килеп чыккач, чак егылып китмәде. Ике кулын җәеп кочакларга килә явыз!

— Чибәркәй, чибәр кыз! Тукта диләр сиңа, сарык!

Туктыймы соң Әлфия, чиләкләрен селтәп, алга сикерде. Борылып караса, милиционер мәтәлеп төшкән, торып маташа, мүкәләгән килеш Әлфиягә йодрык күрсәтә. Кайтканда күзне ачыбрак йөрисе булыр, диде кыз үз-үзенә һәм көлеп куйды. Тоттырганнар иде ди синең ишегә! Кешеләрнең сүзе ничек бер-береннән аерыла — Мансур абыйсы да аны «чибәр» дип атады. Кәефе кырылган булып кыланса да ул чакта кызның бөгърен нидер телеп үтте. Ә бу кабахәтнең «чибәр» дигәнен ишеткәч, косасы килде...

Суга чират торалар иде, краннан су тамчылап кына ага, чиләк тутырыр өчен озак кына көтәргә кирәк. Әлфия бүген өйдәге буш савыт-сабаларны су белән тутырып куярга исәпләгән иде. Барып чыкмый инде болай булгач, җитмәсә, чират һаман өстәлә тора.

Икенче мәртәбә су алып кайтканда, юлда апасы очрады. Алланартлап сумка аскан. Тәмам әлсерәгән. Зәйтүнә көннән-көн юаная, соңгы вакытта бик авыр йөри башлады.

— Борыныңа җиткән корсагың белән шул хәтле күтәреп йөрмәсәң,— диде Әлфия аны шелтәләп.— Аяктан калсаң, күрерсең менә.

— Безнең монда авылдагы кебек өй артында үсеп утырмый, иң башында ташып тамак туйдырабыз.

— Шәһәрегезне әйтер идем, суга да чират.

— Шәһәрне гел яманлыйсың, үзеңнең, китәм, дигәнең юк, ябышып ятасың!

Әлфия авызын йомды, сөйләшә белмәсәң, шулай була ул. Валлаһи кызык инде, апасы белән кара-каршы утырып бер серләшкәннәре дә юк ичмасам.

Әлфия Зәйтүнәнең үзеннән бигрәк иненддәге ризыкларны җәлләп апасын битәрләде. Зәйтүнә ризыкны күпләп ташый, сакларга урын булмаганга ул тиз бозыла. Әлфиянең моңа эче поша. Түзмәде, апасының яратмасын белсә дә, һаман үзенекен тукыды.

— Күрмәгәндәй кыланганчы, чама белән алып кайтсаң ярамаганмы? — диде.

Зәйтүнә сеңлесен беренче мәртәбә күргәндәй чөләеп карап торды.

— Бер дә акыллы сүз белмисең икән син. Әллә акыл өләшкәндә качып калгансың инде,— дип, шелтәләде.— Шәһәр чарламаган әле сине, пешекләмәгән.

— Кусагыз да китмим мин шәһәрдән! Монда калам.

— Монда калып нишләмәк буласың?

— Эшем авыр, дисең ич, сиңа булышырмын. Тора-бара күз күрер тагын. Без дә күчәрдән төшеп калган чәкүшкә түгел.

Сеңлесенең соңгы сүзе Зәйтүнәне уйга калдырды — бу юлы акыллы фикер әйтә бит Әлфия! Зәйтүнәгә бер караңгыдан икенчесенә кадәр эшләргә туры килә. Йөкле килеш көнозын аяк өстендә тору авыр. Ул базарга сату итәргә килгән кешеләргә үлчәү, лоток, халат, җинсәләр биреп тора. Алары бер хәл, базар җыемы талоннарын сату да ана

йөкләнгән. Көнозынга үлчәү, гер күтәреп куллары әзелеп төшәр хәлгә житә. Базар җыемы алмыйча гына хәрәмләп сату итүчеләрне куа-куа көне буена хәлдән тая. Кычкырыш, талаш, каргау, гауга куба. Көн саен шул хәл. Дөрес, ул үзе генә түгел, берничә хатын эшлиләр, сәүдә беткәч, базар мәйданын җыеп чистарту да аларга йөкләнгән. Хезмәт хакы ипи-тозлык кына, аена өч йөз алтмыш сум түлиләр. Бер ягы бар инде — базарда акмаса да тама.

Әлфия апасының базарда нинди эш башкарганын белми иде моңарчы, ул сорашмый, апасы сөйләми, кайта да ава. Кыз апасының үтә йончып кайтуын, эше авырлыгыннан түгел, ә йөкле булуы аркасында, дип уйлый иде.

Зәйтүнә аңа:

— Алай бик шәһәрдә каласың килсә, иртәгә минем белән базарга бар,— дигәч, аптырап калмады, горур гына:

— Барам, ник бармаска? — диде.— Син эшләгәнне булдыра алмам мәллә?

Зәйтүнә җавап кайтармады, йөзе бозылып караватка сузылып ятты, аруы шулкадәр җиткән, телен әйләндереп сүз кайтарырлык та хәле калмаган иде. Бераз уфылдап яткач кына Зәйтүнә телгә килде.

— Синең карының ачтыр. Әнә анда, сумкада, тәмле-тәмле ризыклар бар, үзең карап ал шунда.

— Без ашадык. Бүген дә мине җизни сыйлады.

— Кара син аны! Сез бик дуслашып китәсез түгелме?

Әлфия канәгатьлек белән чыркылдап көлеп җибәрде.

— Әллә көнләшкән буласыңмы?

— Көнләште ди берәү! Ул ужым бозавыннан көнләшкән ди!

Әлфиянең Хәлимгә карата бирелгән бу бәядән җаны әрнеде.

— Әй, хәсрәт капчыгы! Үзең кем соң син? Җизни менә дигән егет! Ничек итеп сиңа өйләнгәндер ул.

— Ярый инде, мин җүләрбаш ризалашып аңа кияүгә чыккан! Йөрер иде гомере буе ялгызы. Хатын табарлык ирме ул?

— Ник тапмасын? Аның кай җире кешедән ким?..

— Ким шул, ким. Син белмисең генә...

Зәйтүнә чүт кенә елап җибәрмәде.

— Кулыннан килмәгән эш юк, үзе акыллы, укыган.

— Укыган кеше күмер бушатып йөриме? Акыллы кеше, участковыйдан шүрләп, аның йомыш-юлына чабамы?

Әлфия апасының үз ирен эт итеп яманлавын һич анлый алмады. Нигә инде гомерлеккә яр итеп сайлаган кешеңне болай хурларга? Эчми, тартмый, бозык юлда йөрми. Эшли дә эшли. Тагын ни кирәк икән бу хатынга?

— Апа, чыннан да, нигә берәр яхшырак эшкә керми ул?

— Бик керер иде, алмыйлар.

— Ни өчен?

— Германда пленда булган.

— Абау, бик яшь күренә, фронтта булырга да өлгергәнмени?

Хәлимнең кырык биешенче ел башында, атасының һәлак булуы турында хәбәр килгәч, үзе теләп фронтка киткәнен Әлфия белми иде әле. Ул вакытта егеткә унҗиде яшь тулар-тулмас була, яшен зурайтып күрсәтә. Буе-сыны таза булгач, ышаналар. Армиягә алгач та озын-озак өйрәтеп маташмыйлар. Венгриягә, Балатон күле тирәсенә, алгы сызыкка, өзеклеккә илтеп тыгалар. Хәлим беренче бәрелештә үк контужен булып әсир төшә. Әсирлеге дә инде, ташка үлчим, өч атна чамасы дәвам итә.

— Әтәч Фәхри булып йөрсәң, ни белән бетәчәге билгеле. Ярый әле дөмектермәгәннәр.

Җизнәсенең сугышта булганын ишеткәч, Әлфиянең аңа карата хөрмәте тагын да артты. Менә бит ул дөнья ничек,ниләр килеп, ниләр китми егет башыннан! Ул сугышка киткәндә, Әлфиядән яшьрәк булган.

Йөрәк тә бар икән үзендә, әй! Сугыш әсирсез булмый, диләр акыллы бәндәләр. Нигә һаман әзәрлеклиләр икән анын жизнәсен? Апасы үз сүзен түгел, кеше сүзен сөйләп маташа икән әле!

— Син, апа, жизнине алай кимсетмә. Андый егет күп кызларга тәтеми.

Зәйтүнә торып утырды, чынлап ук кыза башлады.

— Әтәч белән күке сыман бер-берегезне мактышасыз, берәр хәл бар ахры сезнең арада!

Әлфия иреннәрен турсайтты.

— И апа, әллә жүләрләнә башладыңмы инде? Сезнең арага керергә кем дип беләсең мине? Егетләр кулы тотып караганың бармы, диген?

Зәйтүнә сеңлесеннән чынлап торып көнләшә, матурлыгыннан көнләшә, уңганлыгыннан көнләшә. Ул, Хәлимне юри яманлап, сеңлесенең гайрәтен чигерергә тырыша. Дөреслектә, көнләшер өчен бер генә сәбәп тә юк югын — Әлфиянең дә, Хәлимнең дә үз хәлләре хәл, гыйшык тоту турында уйлар чакларымы соң? Әлфия шәһәрдә тамак хакына гына калмады калуын, югары белем барыбер алырга ашкынуын ул әлегә сер итеп саклый, апасына да, жизнәсенә дә ачылып бетмәгән юк. Хәлимнең дә күңел түрендә шул хыял: элек институтка алмаганнар икән, хәзер бер-бер җае чыкмыйча калмас. Балдызының китап-дәфтәрләр белән әвәрә килүе, белем алу зарурлыгы хакындагы сүзләре аны да жилкендереп җибәргән иде. Хәлим дә, балдызы кебек, шашынып-очынып әзерләнеп йөргән иде ләбаса. Әсирлектә булганнарга бездә урын юк, дип теләгән кырт кистеләр. Номерлы заводта хезмәт хакы әйбәт, дигәч, аларның капкасын кагып карады, сөреп чыгардылар. Кайларга барып сугылмады, кемнәргә генә йөз суын түкмәде — һәр җирдән кире бордылар. Аптырагач-йөдәгәч, йорт салырга тотынды Хәлим. Заманалар үзгәрә башлагандай булды, күптән түгел аңа, хәрби комиссариатка чакырып, «1941—1945 елларда Ватан сугышында Германияне җиңгән өчен» дигән медаль бирделәр. Соң булса да уң булсын. Исерекбаш Мәхмүт медальне күргәч, сатып алган син моны, дип бәйләнде. Документын чыгарып күрсәтергә туры килде. Насыйп булса, медальле Хәлимне институтка да алырлар әле. Озакламыйча әти буласы кеше. Үз йортын җиткергәч, читтән торып та укыр Хәлим! Балдызы белән парлашып йөрерләр.

— Син, апа, бу җәһәттән әнигә охшарга тырышма.

— Нәрсә, нәрсә?

— Ул да, шулай бер дә юкка көнләшеп, әтинең җанын ала торган булган.

— Син аны каян беләсең?

— Әни үз теле белән сөйләде, үкенеп утырды. Көнче хатын үзе ут эчендә яши, ирен дә эштән чыгара, диләр.

— Һай аллам! Карап карарбыз, үзең ничек булырсың икән. Барын белгән булып сөйләшеп утыра.

— Фи, мин кияүгә чыкмыйм да чыкмыйм анысы. Әгәр чыга калсам, аның үзен көнләштерәм.

— Алла, диген! Иртә кычкырган күкенең башы ярыла.

— Апа, җаным, юкка бәйләнмәсәнә! Иртәгә эшкә алып барам, дисең. Йоклыйк рәхәтләнеп.

Бүтән кичләрдә Әлфия башы мендәргә тию белән мәче баласы кебек таралып йоклый торган иде, бүген озак кына борсаланып, әйләнгәләп ятты.

— Апа, ә теге милиционер Мәхмүт, теге исерекбашны әйтәм инде, һаман-һаман жизнигә бәйләнәчәкме? — дип сорады.

— Булды инде бер сыткый сагыз. Ачкүз. Авылдаш әле җитмәсә.

— Авылдаш?! — Әлфия сикереп торып утырды. — Нигә авылдашлар турында сорашмады соң ул?

— Аның әтисе колхоз оештырган. Аны районга алганнар. Иптәп кенә Казанга күчергәннәр. Аталары үлгән, а малае юньсез бер бәндә булып чыккан.

Йокысы тәмам качты Әлфиянең, як-якка боргаланып ята торгач тәрәзәгә беренче таң нурлары төшкәнне сизмәде. Хәлим җизнәсе аның шушы урында йокласын белгән кебек, кояш төшәрлек итеп шушы якка иң олы тәрәзәне уйган шул! Рәхмәт аңа!

## IV

Җәй көннәрендә көн яктырыр-яктырмаста базар капкасы төбендә сәүдә башлана. Күпләр, вак-төяк әйберләрен базар җыемы түләмичә генә сатып, тиз-тиз китеп тә баралар.

Бүген халык аеруча күп иде. Авыллардан ат җигеп килгәннәр, ит лабазына баш тыга торган түгел. Катык, сөт, май сатучылар да күп. Аларның лабазы аерым — уң якта. Бәрәңге, яшелчә, җиләк-җимеш белән ачык һавада сату итәләр. Зәйтүнә шуларның барысына да хезмәт күрсәтә, үлчәү, җиңсә бирә. Базар җыемы ала. Җыем — ике сум. Аның махсус талоны бар, исәп-хисап ясавы ансат. Үлчәү, җиңсә биреп торган өчен квитанция язарга кирәк. Бәһасы сатыласы товарның күләменә бәйле, товарың күп икән — күбрәк түлисең.

Зәйтүнә белән Әлфия нәкъ алты тулганда килеп җиттеләр. Ларек ишеге төбенә үлчәү алырга теләүчеләр шактый бөялгән иде инде. Ларек ишеге ачылуга тавыш кечәйде. Зәйтүнә җиңнәрен сызганып квитанцияләр язды, Әлфия үлчәү, герләр биреп торды. Башта бик кызык күренгән бу эш тора-бара Әлфияне әлсерәтте, чират кимемиме, дип тышка сузылып карады. Үлчәүләр, герләр торган саен авырая бардылар һәм шунда гына апасының көннәр буена ничәшәр тонна тимерне кулыннан үткәргәнен аңлады Әлфия. Җитмәсә, бердәнбер ару күлмәген кигән иде. Алмашка күлмәге дә юк шул аның, апасы да бирәр искесен бирү турында уйламаган. Майлы үлчәүләрне, катык-сөткә манчылган герләрне күтәрәтөшерә торгач, күлмәге шундый керләнде, Әлфия үзе чиркана башлады. Түш турысында зур-зур таплар чуарланды. Кешеләр күлмәк табына түгел, тап астыннан аермачык беленеп торган түгәрәк күкрәкләренә карыйлар сыман тоелды. «Бу килеш җизнәсе күзенә ничек күренер?!» Ул апасына тапны төртеп күрсәтте, Зәйтүнә шаркылдап көлеп җибәрде.

— Үзең әйтмисең, мин ачык авыз! Мә, халат ки!

Ул аңа өстәл астыннан чиста ак халат алып бирде. Ак халат янында күлмәк тагын да ямьсезрәк күренде, Әлфия әрнеп апасының кулын читкә этәрде.

— Эш узгач! Кирәге бар халатыңның!

— Киреләнмә. Халатны киеп куй. Эш башлана гына әле.

Әлфия коелып төште — тагын нинди эш бар икән? Моннан ары тагын ни булуы мөмкин? Зәйтүнәнең сүзен раслап, товарларын сатып бетергән кешеләр үлчәүләрен кире китерә башладылар. Әүвәл китерүчеләр оста сәүдәгәрләр, мондагы даими клиентлар икән. Алар көн туса базарда кайныйлар, дип аңлатты апасы. Ул аларның һәркайсына исеме белән атап елмаеп эндәшә, үз чиратларында тегеләре дә Зәйтүнәне якын итәләр икән, марҗалары «джаным» дип, татарлар исә «матуркай» дип бишкә бөгеләләр. Үлчәү-гер өчен залогка калдырган акчаларын алалар да, базар җыемы талоны белән хезмәт күрсәткәнгә түләнгән акчага төрелгән квитанцияләрен кире биреп, шыпырт кына таялар. Зәйтүнә алар калдырган талон, квитанцияләрне берәмтекләп түшенә шудыра.

— Ник җыясың шул пычрак чүп-чарны? — диде Әлфия ачуланып.

— Алдыңа кара да атыңны куала! Күпне белсәң, тиз картаерсың.

Иртән сатучылар сабыррак булган икән, хәзер алар, эш бетте, өйгә ашыгам, дип ярсып киләләр дә Зәйтүнә белән Әлфияне өзмәс тыкыр-

даталар. Берәүләр үлчәүне китерә, икенчеләре алып китә, эшнең һич туктары юк сыман. Хәзер Зәйтүнә квитанцияне язып та тормый, кулы уйнап тора, колак төбендә өзлексез «джаным-матуркай»лар яңгырый. Зәйтүнә күкрәгенә яшергән квитанцияне алып бирә дә акчаны эчке кесәсенә шудыра.

— Әйдә, базарны бер әйләнеп килик әле.— Зәйтүнә үлчәү бирә торган тәрәзәдәге капкачны ябып куйды.— Минем арттан калма, күзең алда да, артта да булсын — яхшылап күзәт! Сорашма. Бүтән чакта мин эшләгәнне син башкарырсың.

Ул ларек ишегендәге йозакны шартлатып бикләде дә кырмыска оясы кебек мыжлаган халык арасына кереп китте. Өстәлләр артына җыен вак-төяк белән сату итүчеләр тезелгән. Күпчелек, товарлары әз булу сәбәпле, базар җыемы алмыйча гына сәүдә итә. Зәйтүнәнең шәүләсе күренүгә, өстәлгә җәеп салган товарларын тиз-тиз җыеп алалар да качып бетәләр. Зәйтүнә акырып-бакырып тараканнар, качасызмы, дип кычкырып, талон алмаганнарны куарга, әрләргә тотынды. Бер карчыкның сатарга алып килгән гөмбәләрен кәрҗине белән җиргә тондырды. Әлфия аның бу ят кыланышларын сабыр гына карап йөри алмады, әлбәттә.

— Әллә акылдан шашасыңмы?— дип апасын пешекләргә керешге.

Күз яшьләрен түксә дә, авыз ачып каршы әйтергә базмаган карчыкка гөмбәләрен җыярга булышты. Зәйтүнә әтәчләнеп сеңлесен этеп җибәрде.

— Яхшы чакта тай моннан, күземә күренәсе булма!

Әлфия апасының чәрелдәвенә гарьләнеп, битен кешеләрдән яшереп, иелә-иелә китеп барды. Ларек ишеге төбенә килеп баскач, авыр уйлар тозагына төште. Апасының кыланышына, дорфалыгына өзелеп-өзелеп күңеле әрнеде. Авылда чакта һич андый түгел иде Зәйтүнә апасы, шәфкатьле иде, тәмле телле, холкы белән бүтәннәрдән нык аерылып торган яхшы күңелле иде. Әнисе әйтмешли, әллә кешеләрне җен алыштыра микән? Гөмбәче карчыкны кызганудан аның күз төбенә ачы яшьләре килеп тыгылды. Әгәр нужа басмаган булса, бәлтерәгән карчык базарда гөмбә сатып йөрер идеме? Гөмбәсен сатып китсә, кемгә ни зыян?

Аның янына көттә генә киенгән бер ир кеше килеп басты. Ишектәге йозакны күрсә дә тартып карады, китәргә ашыкмады, кызның сөзепсынап каравын абайлап читкәрәк, сатучылар рәтенә тартылды. Шактый озак бер-берсенә карап тордылар.

Ниһаять, авыр-авыр атлап Зәйтүнә кайтып җитте. Әлеге ирне күрүгә, аның кыяфәте үзгәрде, авызы ерылды, ачу уты сарган күзләренә елмаю чыкты.

— Озак көттегезме?— диде ул төче тавыш белән.— Һай, сез киләсен белгән булсам, әзерләнеп торган булыр идем! Күрәзәлегем юк шул! Бүген иртәдән халык шашына! Әле базар эченә кереп, үземә күрә, тикшергәләп йөри идем. Нишләргә инде бу талонсыз сату итүчеләр белән? Ни кылырга? Юныс абый, җаным! Бер-бер чарасын күрегез инде, сезнең кулдан килмәгән эш юк.

Үзе туктаусыз сөйләнде Зәйтүнә, үзе күгәргән йозакны ача алмыйча интекте, кулы калтыранды. Юныс дигәннәре үзләренә ияреп ларекка кергән Әлфиягә карап йөзен чытты.

— Нигә монда чит кешене кертәсең?— дип Зәйтүнәне хуҗаларча шелтәләде.— Күпме кисәтергә була?

— Юныс абый, җаным, чит кеше түгел. Бертуган сеңлем. Авылдан килде.

Әлфия апасының түбәнсенеп, төчеләнеп сөйләшүен өнәмәде. Ни дип шушы кадәр юхалана торгандыр! Әллә шәһәрдә сөйләшү формасы шул микән, дип тә уйларга өлгерде, җизнәсенең милиционер алдында биегәне исенә төште.

Юныс Әлфияне башыннан аягына кадәр күзеннән үткәрде дә:

— Сеңлең үзеңә охшаган икән,— дип, иренен ялап алды.

Чыннан да, Зәйтүнә белән Әлфия төскә-биткә бер-берсеннән чак аерылалар. Зәйтүнә яшьрәк чакта, корсак күтәрмәгәндә, авылда аларны янәшә бастырып, игезәкләр, дип тә әйтәләр иде.

Тышкы охшашлыклары булса да, Әлфиянең холкы-фигыле бүтәнчә булыр, Юныс шикелле әрсезләргә буйсынып, баш биреп, юхаланып тормас ул!

Шулай уйлады Әлфия, Юнысның гадәттән тыш мут, оятсыз күзләренә чалынмаска тырышты.

Зәйтүнә сеңлесенә карап-карап торды да, прилавка астыннан бер шешә аракы тартып чыгарды. Тиз-тиз генә кыяр, помидор турап салат әзерләде. Салат янына пешкән бөтен тавык куйды. Ничек булса да, Әлфиядән беравыкка котылып торырга кирәк иде, сәбәбен тиз тапты Зәйтүнә, кулларын чәбәкләп:

— И, сантый, безнең икмәк юк икән бит! Барчы, Әлфия, йөгереп кенә алып кайт.

Әлфия, мондый шакшы күлмәк белән кеше арасыннан ничек өйгә кайтып керермен, дип пошынып тора иде.

— Кайда монда ипи кибете? — дип сорады.

— Сора, тел нәрсә өчен бирелгән.— Аннан үзенең артык кыркулыгын, дорфалыгын тоеп, Зәйтүнә бераз йомшады.— Ерак түгел. Ике атлап, бер сикерсәң, барып та җитәсең. Базар капкасыннан чыгуга уң якта. Бикле булса, көтеп тор, ярыймы?

Кибетнең бу сәгатьләрдә ябык икәнен Зәйтүнә белә, кылчык Әлфия генә күздән югалсын, сеңлесе китеп никадәр озаграк торса, Юныс өчен дә, үзе өчен дә яхшырак булачак!

— Бармыйм,— диде кинәт кистереп Әлфия.

— Нәрсә, нәрсә?!

— Бармыйм да, йөрмим дә.

— Оho! — диде Юныс авызын ерып.— Сеңлең өйрәтелмәгән кырыкмыш тай икән синең!

— Ипине кайтышлый алырбыз! — диде Әлфия, ачуыннан шартларга җитешеп, һәм, җәһәт кенә чыкты да, базар читенәрәк китеп, лабаз артына үтте, шунда аулакта апасын җәлләп елап җибәрде.

Чит кешегә сеңлесеннән зарланырга Зәйтүнә яхшысынмады, Әлфиянең эзе суынганны да көтмәде, яшергән җиреннән бер бөтен ипи тартып чыгарды.

— Башың эшли үзеңнең,— диде Юныс, аны арттан кочаклап алмакчы булды.

Зәйтүнә ишекне эчтән элде.

— Һаман шул элекке гадәтләреңне ташламыйсың!

Күпме хатын-кыз эшләп чыкмады базарда! Берсенең дә Юныс теләгенә карышканы булмады, кая ул, үзләре аның кочагына атылып тордылар. Бер Зәйтүнә чыгымчы ат сыман аңа бирешмәде, Юныс базарга Зәйтүнә өчен генә килеп йөрде, аны тозакка төшерергә тырышып ниләр генә кыланмады, алдады, юмалады, куркытып карады, әмма сылу хатын баш бирмәде. «Бер килеп төшәр төшүен асылкош, Юныс үз сүзен итәр, аның оста кулыннан син генә котыла алмассың!..»

Килгән саен шушы уен ныгытып китә торган Юныс бүген икеләнеп калды. Олы бүксәле, битенә тут кунган Зәйтүнә янында басып торган сеңлесе азгын ирнең һушын алды. «Менә мал дисәң дә мал! Ярым кыргый, күрче, апасына ничек карап алды! Күзе белән ут уйнатты! Менә кем итәгенә салып башны югалтасы иде!» дип уйлады ул. Юныс аракыны авызына китергәндә, тышкы яктан ишек шакыдылар, ул, учы белән стаканын каплап, Зәйтүнәгә карап җимерелде. Зәйтүнә Юнысны капларга тырышып тәрәзәне ачты, тышта базар директоры Николай Семенович басып тора иде. «Козгыннар!» дип күңеленнән сукранды Зәйтүнә. Николай Семенович Юнысны күреп алды.

— О олы кунак бар икән,— дигән булды.— Зоя, кая, ишекне ач әле! Әүкәтле кунаклар килгән икән.

Зәйтүнә буш чиләк өстенә бернича халат салып директорга урын әзерләде, ләкин базар хуҗасы утырырга ашыкмады. Юнысның барлыгын да оныткан кебек, Зәйтүнәне шелтәләргә тотынды.

— Бу ни эш, понимаешь? Ярты халкың базар җыемы түләмәгән! Сорашам, пнимаешь, талонсыз сату итәләр! Дәүләт планы турында уйлыйсыңмы син, юкмы? Һәммәсе өчен мин баш ватарга тиешме, пнимаешь?!

— Әле йөреп кердем, Николай Семенович! Нишләтим соң аларны? Юнис Гыйльметдиновичка да шул хакта зарлана идем. Тыңлатып булмый халыкны!

— Зарланудан ни файда? Җыем түләтергә кирәк? Буйсынмыйлар икән, милиция чакыр!

Зәйтүнәгә мондый кискен әрләүләр үтә таныш булса да, ул күзен мөлдерәтеп Юныска карап тора башлады. Николай Семенович, аның Юныска аркаланырга маташуын күреп, һөҗүмен тагын да көчәйтте:

— Юнис Гыйльметдиновичка аңа нәрсә! Ул барысын миннән таләп итә. Мин алардан сезне яманлап котыла алмыйм. Аларның җавап бер, син директор, син эшләт, диләр, пнимаешь, ясно?

Зәйтүнәнең сөмсере тәмам кырылганын күреп, директор аңа күз кысты, начальство алдында бераз тузынып алу кирәк, янәсе. Зәйтүнә шым булды, баягы шешәне көнгә чыгарды, кулын халат итәгенә сөртеп, симез тавыкны ботарлап ташлады.

— Эш вакыты инде, Юнис Гыйльметдинович, шешә тоту да килешеп бетми, мәгәр бездәге хәлләрне ныклап уйласаң; эчмичә дә булмый. Йөрәген шартлар, икмәктер менә, пнимаешь! Начальство хуплагач, рәхмәт инде! Сезнең саулыкка!

Директор стаканны тиз генә бушатты, тавыкка үрелмәде, кулы белән иреннәрен сөртте.

— Минем бераз эшем бар! Сез утырыгыз.— Чыга башлагач, Зәйтүнәгә борылды, аерып кисәтте.— Кара аны, Зоя, кунакны яхшылап сыйла. Эшли белмисең икән — сыең шәп булсын!

Юнис белән директор, өйрәтеп куелгандай, бергә хихылдадылар.

— Эт ялкавы!— дип сүгенде Юнис.— Монда эчте, тыгынырга бүтән җиргә бара. Мин килгәнне сагалап кына тора. Танавын чөеп йөри башласа, арт сабагын укытмый да булмас. Утлы табага басканы юк, башы яшь! Зәйтүнә! Син аның артыннан күзәткәләп йөр. Андый-мондый кыңгыр эше, кыек сүзе юкмы? Иплэп кенә язып миңа җиткерерсең. Хөкүмәткә, властька каршы сүз ычкындырмасмы? Сүз әйткән көнне, урынын, янында кемнәр булганын төп-төгәл теркәп бар! Бугаз киереп сиңа кычкыра, ә?!

Юнис тагын бер стакан аракыны йотып куйды да Зәйтүнәнең ник кына җәелгән артына учы белән берне шапылдатты. Зәйтүнә аның кулын читкә этәрде.

— Бигрәк кыргый инде үзең! Бер тотканнан укаң коеламы?

— Юнис абый, җаным, кагылма, дип әйттем ич инде. Мин андыйга өйрәнмәгән.

— Өйрәнмәгән булсаң, потың бер тиен иде. Бөтен кыйммәтең шунда, өйрәнмәгән булуыңда! Мин сине беләм!

Зәйтүнә күзен уйнатып:

— Минем арттан да күзәтүче куйдыңмы?— диде.

— Синең арттан күзәтәсе юк. Синең...

Зәйтүнә каушап торган арада ул аны арт ягыннан килеп кочаклады, шул вакыт ике бөтен ипи күтәреп Әлфия килеп керде. Юнисның кыланышын күреп, ул ачыргаланып кычкырып җибәрде.

— Тимә минем апага! Апа, валлаһи, җизнигә әйтәм!

Зәйтүнә оятыннан җир тишегенә керердәй булды. Юнис тамагын

кыргалап, һич читенсенмичә, шешәгә тотынды, ашыкмыйча, йотымлап, калган аракыны эчеп бетерде.

— Бу кызый синдә торырга килдеме?

— Кая барсын, Юныс абый, җаным...

— Теңкәгә тиячәк бу черки, җаныңны алачак. Бу бит, беләсеңме, күзгә чебен, борча бу...— Юныс тавык ботын читкәрәк куеп, Әлфия каршысына барып басты.— Әй син, юбалгы! Шакшы күлмәк! Авыл гадәтләрен ташларга кирәк! Кыргый булмаска, кеше арасына керергә, ярашырга, сыярга! Тагын ниләр эшләргә кирәк әле, Зәйтүнә?

— Вакыты житкәч, өйрәнер әле. Дөнья — нужа ул, өйрәтә! Өйрәнер! Килгән шәпкә генә шулай кыланасын аны!

Әлфиянең: «Өйрәтә алмас! Мин аны үзем өйрәтермен!» дип кычкырасы килә, әмма апасыннан шүрли, болай да канына тоз салды, кайтуга куар да чыгарыр. Бу хатын Әлфия өметләнеп килгән, аның яраткан апасы Зәйтүнә түгел!

Әлфия Юнысны өнәмәгән иде, кызыл күзле директорны да күргәч, бөтенләй йөгеннән ычкынды — кемнәргә идән мунчаласы булып эшләп йөри икән апасы! Аның бер минут тормыйча апасы янына керәсе, Зәйтүнәне усаллардан йолып аласы килде. Керү өчен ипи алып кайтырга кирәк иде. Очты кыз, кибет ачылган гына иде, ул чиратта торучыларны як-якка селтәп ташлады да ишектән беренче булып керде. Җыелганнар башта койрык күтәрергә җыенганнар иде, алдагы рәтләрдән берәү — «Җүләрдер бу! Шашкандыр!» — дигәч, кибеттәгеләр шым булды.

Әлфиянең тузгыган толым очлары җилфер-җилфер килә, йөзе яна, өс-башы пычрак, күзендә ут, тиле дип уйларлык та шул. Ул ике бөтен ипине элдерде дә очты гына!..

Юныс Әлфиянең кибеттән тузынып кайтып кергәнен күрмәде дә бугай, Зәйтүнәнең буш кулына карады да:

— Юл аягын оныттыңмы әллә? — дип сорады.

— Юныс абый, җаным, бүген керем бөтенләй булмады.

— Йә, йә,— дип җикеренде Юныс Зәйтүнәнең мескен тавышына игътибар итмичә.— Үземә дип беләсеңме? Анда хуҗа көтә! Хуҗа! Күптән күңелен күргән юк. Кара янып йөри. Берәр тамаша кылып ташлавы бар!

Зәйтүнә ыңгырашып, авырыксынып кына түшеннән ике унлык тартып чыгарды.

— Юныс абый, риза булып бүгенгә шуларны алып тор инде.

Юныс йөзен чытты.

— Өстә. Бер яртылык та булмаса, хуҗага ни күзем белән күреним? Закускага ни булса да табармын.— Зәйтүнәнең икеләнүе аңа көч бирде, ул тавышын көрәйтте.— Синең өчен дә тырышам лабаса! Үзебезнең халык, дим, күрердәйне дә күрмим, тынычлап эшләсеннәр, дип читтән-читтән йөрим. Сезне тотып пыран-заран китерү чүп кенә миңа! Ачуымны китерсәң, хәзер чытырдатып акт төзим! Ярты халкың — танышларың — талонсыз сату итә! Алардан кергән акчаны бер башың чумырып идеңме? Шалишь!

Зәйтүнә коелып төште, чыннан да аның башка кәгазь акчасы юк иде. Ул көмеш-бакырларны санарга тотынды. Җәмгысы биш сумга җыелды.

— Ас, кис, бүтән бер тиенем дә юк. Актыккысын кырып-себереп бирәм.

— Нишлим мин синең ул хәерче акчаң белән? — Юныс лач итеп идәнгә түкерде.— Чатта утырган, дип уйларлар.

Зәйтүнә Әлфиягә карап алды, Әлфия кул хәрәкәтләре белән апасына нидер әйтергә маташты. Алар бер-берсенә карап тынып калдылар. Ниһаять, Зәйтүнә, бөтен кыюлыгын җыеп, беренче мәртәбә Юныс тәкъдименнән баш тартты.

— Күреп торасың, Юныс абый, җаным, аягымны көчкә өстерәп йөрим, халыкны тыяр, тыңлатыр хәлем калмады.

Ул акчаларны шыбырдатып кырыйда торган үлчәү тәлинкәсенә

илтеп салды. Юнысның күзе-кашы жимерелде, нидер әйтә башлаган иде, Әлфияне абайлап тыелды, авыз эченнән мыгырданып, көмеш-бакырларны сыпырып кесәсенә төшерде. Шуннан соң гына Әлфиягә зәһәр чәчеп карады, йодрыгын йомарлады.

— Син! Берни күрмәдең, берни ишетмәдең! Югыйсә бер көн тотмам, шәһәрдән сөрдерермен!

Әле чыгып китеп, аяк эзләре тынгач та апалы-сеңелле ни әйтергә белмичә ишелеп утырдылар. Юныс нык изгән иде аларны.

— Нигә шул эттән басымчак иттерә торгансыңдыр,— диде Әлфия бик кызганулы тавыш белән.— Кем булган ул кадәр?

Зәйтүнә йөрәгенә чыдый алмыйча елап җибәрде.

— Катышма, зинһар. Син берни аңламыйсың!

— Аңлыйм! Тәгаен бер-бер яшерен эшегез бар сезнең! Бурлыктыр әле?

Бу сүзләрдән Зәйтүнә тагын да ныграк ярсыды. Әмма сеңлесенә аңлаешлы җавап бирә алмады. Юнысның китүен өзлексез сагалап торган директор шома гына кабат килеп керде. Зәйтүнәнең күз яше белән елаганын күреп, дорфа гына:

— Ни булды?— дип сорады.

— Сорыйсың тагын... Монда утырган кешене күреп чыгып киттең ич.

— Бәйләнәме?

— Юл аягы сорый. Җыелган акчаның тиенен кадәр сыпырып алды.

— Ник бирдең соң?

— Бирми кара! Себер олактырыр.

Николай Семенович йодрыкларын йомарлап тирән сулады. Арьяк базарында ит чабучы булып эшли иде ул, җаны тыныч, кулы эштә иде. Чапкан һәр түшкәдән тәмле-тәмле калҗалар аның тирән тагарагына чәчрәп төшә тора иде. Бәжасын базарлар идарәсе управляющие иттеләр дә, ул «фронтын ныгытырга» тотынды, Николай Семеновичны монда директор итеп җибәрде. Чиләнә менә хәзер.

— Аның кыланышларын язып бирәсеңме әллә?

Зәйтүнә әсирлектә булып кайткан ирен, законсыз салынып яткан өен, муенына камыт булып төшкән сеңлесен уйлап телен тешләде.

— Николай Семенович, мин бүген бер тиен дә акча тапшыра алмыйм,— диде ул тагын да мескенрәк тавыш белән. Директорның әз-мәз йомшаруын күреп, хәленә керер дип өметләнгән иде Зәйтүнә.

— Син ни сөйлисең?— Директор күтәрелеп бәрелде.— Әгәр базар идарәсеннән тикшерү килсә! Пычакны минем муенга салачаклар! Килү ихтималлары бар, дип әле мин синнән акча өметләнеп кергән идем.

— Нишлим соң?

— Тап! Тәҗрибәң бар, кыюлыгың җитәрлек.

— Әйтергә ансат.

— Утыр, санап чыгар. Кулыңда күпме акча булырга тиеш, тиененә кадәр булсын!

Директор шулай диде дә, буш шешәне почмакка ыргытып, чыгып китте. Шешә чыңлап ватылды.

— Тапкансың эшнең асылын, ай-һай,— диде Әлфия.

— И, бала, бала! Минем хәсрәтләрем сиңа була күрмәсен! Әйдә, лыгырдап вакытны алма, чыгыйк, халык таралып беткәнче акча җыеп калырга кирәк.

— Чык та җый! Кеше белән талашып, исәр, җүләр, дип тамгаланасым килми.

Зәйтүнә шактый озак торып керде, ул арада Әлфия шешә ватыкларын җыйды, иске чиләккә тутырып аларны түгеп керде. Базар бетмәгән иде әле, һаман кайный, исерекләр күбәйгән, тавышлар куркынычка әйләнгән иде. Кара коелып чыгып киткән Зәйтүнә балкып диярлек кайтып керде.

— Кычкырып жыласаң, сукыр күздән дә яшь чыга, и агай...

Ул куеныннан, халат кесәсеннән эреле-ваклы акчалар чыгарып үлчәү тәлинкәсенә салды.

— Апа, йөрмә болай кеше талап! Ташла бу эшеңне!

— Кем әйтә мине кеше талый дип? Мин алардан бер тиен артыгын алмадым, тиешлесен түләттем. Күбесе миннән файда да күрә әле, яртысын гына түли, уртаклашабыз.

Әлфиянең берни аңламыйча аңгыраеп утырганын күргәч, Зәйтүнә кайбер нәрсәләрне аңлатуны тиеш тапты.

— Эшли башлаган шәпкә мин дә аңгыра баш идем! Кешеләрне җәлләп, аларны яклап маташтым. Базарның үз законы бар аның, җанашым, китереп кыса ул! Тез астына суга. Яхшылык та, начарлык та акча белән үлчәнә. Акчамы? Акча ул!.. Хәзер остардым! Эт мин хәзер, җир астыннан да иснәнеп табам! Ходай кушса, минем урынга калырсың, мене.

— Әйтмә дә, сөйләмә дә! Базарыңа якын да килмим.

— Шәһәрдә калам, дисеңме? Ничек яшәмәкче буласың алайса? Җизнәң белән күмер бушатырга барасыңмы? Әллә сасы милтонга түшәк булып ятырсыңмы?— Бу сүзләр Әлфиянең башына тимер таяк белән суккандай тәэсир итте.— Ник дәшмисең? Әллә телеңне йоттыңмы?

— Кем соң ул Юныс абый дигән кешең? Бигрәк оятсыз бәндә икән, тефү, кабих. Корсагы таудай хатынга кул суза. Сине дә әйтер идем, идән мунчаласы белән чыраена чәпәсе урында...

— Шаяра гына! Аңа миннән башка да хатын-кыз бетмәгән.

— Шаяруның да чиге бар!

Чыннан да, жык күрерсең бу очлы күз белән, дип уйлады Зәйтүнә.

— Йә, ярый, әпчи карчыгы булма.

— Мин аның бәбәген чукыр идем!

— Чукытыр! Беләсеңме кем ул? Бик зур нәчәлник.

— Нәчәлник икән, үзен тота белсен! Ничек аны эштән кумыйлардыр.

— Аның каршында ярты Казан дер калтырап тора. Кул астында эшләүчеләр юлында юрган булып яталар.

— Кем булып эшли соң ул? Базарга ни катышы бар?

— Районда өлкән инспектор! Безнең барыбызны да тикшерүче.

— Фи-и... Аның кыланышларын югарырак оешмада утыручылар ник күрми икән?

— Югарырак утыручыларның да тамагын ул туйдыра шул, ул ашата.

Әлфия бу сүзләргә ышанмады, аның уйлавынча, югары оешмаларда утыручылар барысы да фәрештә кебек гөнаһсыз, гаделлек өчен көрәшүче, тугрылык сагында торучы илаһи затлар иде. Мәктәптә укыганда ун ел буена аның колагына шуны тукыдылар, әнисе дә ике сүзнең берендә өстәгеләр белән телгә килмәскә, бер сүзсез аларны хөрмәт итәргә өндәде. Кемгә-кемгә, ә ул укытучыларына чын күңелдән ышана, инде әнисен әйткән дә юк. Ялгыша апасы йә алдый, югары оешмаларда утыручылар базардагы хәлләрне белмиләр, белсәләр, Юныс ишеләрнең койрыкларына басарлар иде. Әлфия бүтәнчә фикер йөртә белми торган гади авыл кызы иде әлегә.

Көн зарыктырып булса да кичкә авышты. Товарларын сатып бетереп, сәүдә кирәк-яракларын кире китерүчеләр күбәйде. Даими рәвештә базарга сату итәргә йөрүчеләр буш кул белән килми икән монда. Үлчәүләр, герләр белән бергә, Зәйтүнәгә «адарынган өлешләрен» калдырып, тавышсыз-тынсыз гына китеп баралар.

— Иртәгесен сату итәргә яхшы урын алу өчен аванс түлиләр,— дип аңлатты йөзе ачыла барган Зәйтүнә.

Җыелган эремчек-каймакларны, бүтән ризыкларны күреп, Әлфиянең башы әйләнде, бу кадәр азык-төлекне кая куеп бетерербез икән, дип тә

кайгырды. Шулай шаккатып, авызын ачып торганда, Зәйтүнә ана чиста җиңсә һәм алъяпкыч тоттырды.
— Бар, тиз генә каймак белән эремчекне сатып кер!
Әлфия:
— Булдырып булыр микән, бер дә сату иткәнем юк,— дип мыгырдый башлаган иде, апасы:
— Өйрәнерсең! — дип бер генә җикерде.
Тышкы яктан бер хатын тавышы ишетелде:
— Кызым, Зәйтүнә, син мондамы?
Зәйтүнә җитез атлап тәрәзә алдына килеп басты.
— Абау, Гөлсем апа, нигә анда торасың, әйдә, эчкә уз.
— Вакытым юк, менә бу дүрт чирек сөтне сатам да китәм, мә, сәдакасын алчы.
Ул ике сум акча сузды. Гөлсем апа дигәннәренең алъяпкычы, җиңсәсе үзенеке икән. Өс-башы чиста, пөхтә, җилкәсенә татарчалап кардай ак яулык япкан. Өстендә кыска җиңле крепдишин күлмәк, аякларында табәнәк үкчәле туфлиләр. Өлкән булса да, гәүдәсе нәфислеген, күзләре нурын югалтмаган. Апасының төче тавышына карап, әллә тагын бер-бер юлбасар-начальник килгәнме, дип уйлады да, Гөлсем апаның гади бер карчык булуын күргәч, Әлфия җиңел сулап алды.
Зәйтүнә ул биргән ике сумны алмаска матаашты:
— Бар инде, зинһар, талонсыз гына сату ит,— дип үгетләде.
— Хәрәмләшергә яратмавымны беләсең, Зәйтүнә. Кая, бир талонының.
Әлфия чыгар җиреннән чыкмыйча, үз колакларына ышанмыйча, аптырап басып торды, базарда да тугры адәмнәр бар икән, дип гаҗәпләнде.
Гөлсем күздән югалгач, Зәйтүнә үзе Әлфиягә эндәште:
— Бу апаның кем икәнен шәйләмәдеңме?
— Юк. Күргән кешем түгел.
— Безнең авылныкы ул, әниеңнең ахирәт дусты.
— Дусты?
— Син укыган мәктәп шулар йортында иде. Алар авылдан киткәндә, без тумаганбыз тууын...
— Ә-ә, белдем, белдем. Теге әллә кем кулак кызы... Иеме?
— Бик әйбәт апа ул. Шәфкатьле. Шәһәргә килгәч, яртты елдан артык мин шуларда тордым. Эшкә дә ул урнаштырды, рәхмәт төшкере.
Зәйтүнә сеңлесен базарның кайнап торган җиренә чыгарып бастырды да каядыр китеп барды. Әлфия кыяр-кыймас сату итәргә тотынды. Сатып алучыларны бер дә ошатмады. Килүләр дә эремчек-каймакка танаулары белән төртеләләр, иснилер, буяулы шакшы тырнаклары белән эләктереп алып кабып та карыйлар. Әнисе, ризык иснәү — зур гөнаһ, дип өйрәткән иде аны. Ә монда...
Кичке базарның кызган мәле иде, Әлфиянең товары да үтте. Ул бушаган савытларын күтәреп ларекка керде, акча санарга тотынды. Акча шактый күп җыелган икән: арада бер кызыл утызлык белән яшел унлык та бар. Аның туып үскәннән бирле шушы кадәр акчаны тотып караганы юк иде. Кечкенәдән әнисенең кул арасына кереп, җәйләр буе колхозда эшләсә дә, аңа беркемнең бер тиен түләгәне булмады. Бүген менә тир түкмичә, җиңел генә шушы кадәр акчага хуҗа булып алды. Әгәр шушы кадәр акча аның үзенеке булсамы...
Ул сызлаган аякларын сузып, күзен йомды, хыялга чумды.
Иң элек кыйшык өйләренә терәү юнәтерләр иде. Өй түбәләренә салам кайтарырлар иде. Аннары әнисенә укытучы апалары кигән төсле плюш жакет, яңа кофта, яңа күлмәк алыр иде. Күрше авылның Саниягә заказ биреп, кәҗә мамыгыннан гөбердәп торган шәл бәйләтер иде. Кешелеккә кияргә дә нәрсә-карасы юк әнисенең. Көзен-язын пычракта киеп йөрергә әнисенә ялтыравыклы кара галуш апкайтыр иде. Председа

тель хатыны киеп йөри торган галуштан бер дә ким булмасын! Энесеңелләргә аркага аса торган җиңел букчалар... Һәрберсенә яңа киемнәр, бүрекләр, җылы итекләр... үзен дә буш итмәс иде Әлфия! Чуктай киенер! Хөрти кием белән күпме йөрергә була?..

Зәйтүнә, кайтып керүгә, сеңлесе кулындагы акчаларны тартып диярлек алып, түшенә яшерде.

Мондый озын, матавыклы көн үткәргәне юк иде әле Әлфиянең. Моңарчы, шәһәрдә калам, авылга кайтмыйм, дип кытакласа да, бүген базардан кайтышлый күңеленә уйларның төрлесе килде. «Әле бер көн эш арасында булып «исәр, акылдан шашкан» дип атадылар. Бәлки, аның табигате шундый йомшактыр? Шәһәр һавасы килешмидер аңа? Эшли алмас, иярләшмәс, тәки акылдан шашыр...»

Уйларның төрлесе килсә дә, кайтам да ятам, җеп өзәр хәлем дә юк, дип кабат-кабат күңеленә сеңдерде. Ял итәргә кирәк иде Әлфиягә, шикшөбһәләрен бергә җыйнарга бик вакыт иде. Җизнәсе аш өлгертеп торган икән, табын янына утырмыйча булмады. Сүз Әлфиянең киләчәгенә барып ялганды.

— Кайтырмын да китәрмен! — диде Әлфия алдын-артын уйлап бетермичә.

Һич көтмәгәндә, апасы аны куәтләде:

— Авылда да кеше үлми, әнигә дә җиңелрәк булыр,— диде.

Җизнәсе күтәрелеп бәрелде.

— Нинди кайту ди ул тагын?! Укырга ниятләгәнсең икән, кер дә укы. Яшьлекнең кадерен белергә кирәк. Беркая да китмисең! Апаң тиздән декретка чыга. Кибет белән базарга бик чаба алмас, аңа булышырсың.

Ир белән хатын, капма-каршы фикерләр әйтеп, озак кына чәкәләштеләр.

— Кайтсын! — диде Зәйтүнә.

— Кайтмый торсын әле! — диде Хәлим, моңарчы күрелмәгән ныклык күрсәтеп.

Әлфия җизнәсенең сүзен, үгетләвен өстен куйды.

— Китәргә, дисәм, кайчан да соң булмас, әлегә калып торам,— диде.

Жизни белән балдыз бер сүздә булгач, Зәйтүнә дә артыгын тырпылдап маташмады.

Йокларга яткач та кыз тиз генә тынычлана алмады, бүген иртәдән кичкә кадәр күргән-ишеткәннәрен, очраткан кешеләрне, явыз Юнысны, ачкак директорны кат-кат күз алдыннан үткәрде, апасын җәлләп балавыз сыгып та алды. Иң азактан аның күз алдына пөхтә киенгән, ягымлы йөзле Гөлсем апа килеп басты. Авылдаш, ди бит, теге милиционер да аларның авылдашы икән. Кемнәр кая китеп кенә югалмаган да кемнәр кайларда нинди язмыш кичереп яшәп ятмыйлар...

Күзенә йокы эленгәндә дә Әлфиянең күз алдыннан кайнап торган базар китми торды, иң ахырда күңелгә тагын Гөлсем апа килеп китте. Кай ягы беләндер ул аңа бик якын тоелды. Әнисенең ахирәт дусты булгангамы әллә?..

## V

Гөлсем Шакирова ишле гаиләдә туып үсте. Алар бөтенесе тугыз бала булып, иң олысы ул иде. Революциядән соң крестьянны тернәкләндереп җибәргән бәрәкәтле берничә ел булып алды. Җир җан башыннан — хатын-кызларны да исәпкә кертеп — бүлеп бирелде. Башлары гомергә нуҗадан чыкмаган, әмма эшкә хирыс кешеләргә көн килде. Гөлсемнең әтисе Сәфәр абзый үтә уңган, тырыш кеше иде. Нинди хикмәтләрен белгәндер, нинди тылсымы булгандыр, Сәфәр ел саен һәйбәт уңыш ала килде. Ни чәчсә — шул уңды. Игенне бөтен хасиятен китереп чәчте, күп

еллардан килгән тәҗрибәсенә таянып икте. Күп итеп терлек асрады, бүтәннәр мал-туардан калган тиресне буш ерганакларга, чокыр-чакырларга илтеп аударсалар, ул бөртеген дә әрәм итмәде, иген басуына кертте. Бер тубал көлен дә әрәмгә чыгармады, басуына ташыды.

Мал-туарны да юктан бар итте. Иң әүвәл кырыкмыш тай белән тана сатып алды, бер елдан атлы, сыерлы булды. Тора-бара атны ике, сыерны өч үк итте.

— Балалар, балаларым хакына! — диде ул, үзенен арыш умачына тиенә алмыйча эч күптереп алабута суы суырганнарын хәтерләп.— Алар хакына! Тугыз җан бит!

Кием-салымны еш яңарта алмасалар да, тамаклары тук булды Сәфәрнекеләрнең. Хуш ис аңкып торган нарат бүрәнәләрдән алты почмаклы йорт житкереп тә җибәргәч, Сәфәрнең башы күккә тиде. Иске йортны сүтеп, аскы бүрәнәләрен ашлап, келәт иттеләр, бакча түренә мунча да салып җибәрделәр.

Сәфәр абзый җәен-кышын бер кат киндер ыштаннан йөрде, аягыннан ыштыр-чабата төшмәде. Балалары да юньле кием күрмәде. Гөлсемгә, олы кыз буларак, ялтыравыклы галуш алып биргәч, эне-сеңелләре көнләшеп еладылар.

— Балалар, тамагыгыз тук, тук кешенең күнеле көр була. Кием нәрсә? Туза ул, ертыла,— дип юатты Сәфәр балаларын.

Тамакларын тук иттем, өс-башларын да карармын, дип юатты ул хатынын. Шундый матур хыяллар, зур өметләр белән ару-талуны белмичә эшләгәндә, көннәрдән бер көнне чәлпәрәмә килеп җимерелде. Утызынчы елның җәендә аларның бар мөлкәтләрен тартып алып, үзләрен авылдан сөрделәр.

Әнисе телен тешләп, әтисе дөп-дөп тезен төеп утырды, житкән кыз Гөлсем гаиләгә нинди хәсрәт ябырылганын ярты сүздән аңлады. Ул авылда иң матур кызларның берсе иде. Нечкә бил, зифа буй, озын чәчләре, аның белән тиңләшерлек кыз авылда юк иде. Авыл егетләре арасыннан аңа сүз катмаган берәү дә калмагандыр, әмма арада иң өрсезе, иң ябышкагы Фәтхи булды. Фәтхи чын күңеленнән гашыйк иде, тик кыз аңа тартылмады. Кардәш-ыру, күрше-тирә дә егетне кызга тиң санамадылар. Нинди сөйкемсез сөягә булгандыр Фәтхинең, нечкәләп хурлаучы да булмады, мәгәр аның исеме чыгуга бик күпләр йөзләрен җыерралар иде.

Фәтхинең атасы ул бала чакта ук вабадан үлгән, егет ятим, ялгыз әнисе белән фәкыйрьлектә яши иде. Кәҗәдән башка маллары, тавыктан бүтән куанычлары булмады. Атадан калган салам түбәле өй көчлерәк җилдә, менә авам, менә авам, дип калтырап утыра. Соңгы елларда гына үзләренә тигән имананы, ярлылар комитеты ярдәме белән, үзләре игә башладылар. Аңа чаклы җирләрен дә уртакка чәчтерәләр иде.

Фәтхи Гөлсемнән ун яшькә олы иде. Инде үсеп җитәм, тернәкләнәм, дип өметләнгәндә генә егетне гражданнар сугышына алып киттеләр. Сугышкан Фәтхи, Колчак тылында партизан булып та йөргән. Йөргәнлеккә кызыл кенәгәсе дә бар. Ул кайтканда яшьтәшләре өйләнеп тормыш корып җибәргән, бергә үскән кызлар кияүгә таралганнар, чәкүшкәгә иңнәре белән орынып йөргәннәр җитеп беткәннәр иде. Гөлсемне күрде дә аһ итте Фәтхи.

Гөлсем аңа өйләнеп тә карамады, кичке уеннардан соң бүтән егетләрдән озаттырды. Фәтхи чакырганда, түгәрәк уртасына чыкмады. «Фәтхи-Гөлсем» исемнәрен кушып җырласалар, болай дип җавап бирде:

Биек тауның итәгендә
Үсәдер карабодай.
Үзен түгел, исемен дә
Әйтмәгез моннан болай.

Егерме сигезенче елда авылга Шәмси атлы яшь укытучы килде, ул коммунист иде. Килү белән тагын ике кешене партия сафына тарттырды. Шуларның берсе партизан Фәтхи иде. Алар өч кешелек партячейка оештырдылар. Беренче эш итеп, колхоз төзергә тотындылар. Халыкның күпчелеге күмәкләшергә риза түгел иде. Тазарак хәлле хуҗалыклар колхозга кермәскә чарәшеп каттылар. Мең газап белән, кара тир түгеп тапкан малларны бераүнең дә уртак итәсе килмәде. Башта үгетләп карадылар, аннары куркытырга ук керештеләр.

Коммунист Фәтхи, көн-төн чабып арык бурзайга әйләнсә дә, Гөлсемне хәтереннән чыгармады, кыз аша Сәфәр абзыйга сүз ишеттерде: «Колхозга кермәсә, эш бик хәрти булачак!» — диде. Бу авыр сүзләрдән соң, Гөлсем Фәтхине җен, убыр урынына күрә башлады.

Вакыйгалар көннән-көн кискенләште, хәвефле хәбәрләр авылдан авылга кушылып йөрде, ниһаять, Гөлсемнәр авылында да ике атлы, ике сыерлы кешеләрне, кулак дип игълан итеп, бөтен мал-мөлкәтләрен тартып алдылар, үзләрен Себергә сөрергә карар чыгардылар.

Иртә таңнан унбер гаилә сөрелә, дип җан калтырап торганда, кара төн уртасында Сәфәрләрнең ындыр як тәрәзәсен кемдер сак кына шакыды. Бәхетсезлек юлдашларыннан берәрсе килгәндер, дип бакчага чыккан Сәфәр, өй почмагында посып торган егетне күргәч, телсез калды. Фәтхи урап-чурап тормады, турыдан бәрде:

— Гөлсемне миңа биреп калдыр, Сәфәр абзый, ким-хур итмәм,— диде.

Уйлар йомгагына уралган Сәфәр егетнең чыраена тондырырга теләде, тик тиз үк акылына килде. Асылда Фәтхи баш баласы, олы кызы язмышы өчен ныграк кайгыра түгел идеме? Кыз чибәр, юл билгесез, язмыш караңгы, ә аңа кияүгә чыгып үз оясын корырга бик вакыт! Гөлсем Фәтхи коммунистта, Фәтхи партизанда кала икән, бу инде авыл белән ара бөтенләй үк өзелеп бетми, дигән сүз. Йорт-җир, каралты-кура кала, үткен кыз читтән-чоттан булса да күз-колак булыр...

Сәфәр акыллы кеше иде. Чак кына уйланып торды да үзләре янына кызын чакырып чыгарды. Гөлсем, әтисе каршысында басып торган шәүләнең Фәтхи икәнен шәйләп, арты белән борылды.

— Әти, бәгырем, теләсәң нишләт, үләргә риза, аңа кияүгә чыгарга риза түгел! — диде ул, эшнең нидә икәнен белгәч.

— Тукта, кызым, алай кызып китмә, кырт та кисмә,— диде Сәфәр абзый калтыранган тавыш белән.— Алда ни көткәнен беребез дә белми. Тагын нинди газаплар күрергә язгандыр. Сез тугызау... Бөтен ил йөз чөереп безне сөргәндә, бу егет ярдәм кулы суза... Усаллыгын белә идем Фәтхинең, йөрәгендә шәфкать бөртеге дә калган икән әле. Аның тәкъдимен кабул итәргә кирәк, кызым. Әгәр син бүген Фәтхулладан баш тартсаң, иртәгә өзелгәнне ялгый торган түгел.— Ул каушаган кызының җавабын көтеп тормады, эшне хәл ителгәнгә санап, сүзен дәвам итте.— Улым, Фәтхулла, сиңа олы бер үтенечем бар. Ата-бабадан калган изге йоланы онытмыйк. Әгәр бәхетле яшисегез килсә, никахсыз килеш кызыма кул сузасы булма. Син коммунист кеше, ата партизан, бәлки, ул эш сиңа ярамыйдыр да, мәгәр үтенечем бер, бел, укыт никах! Кызым никахлы хатын булсын сиңа. Әгәр Гөлсем кызымны чынлап яратасың икән, сүземне җиргә салып таптама.

Фәтхи ике куллап Сәфәрнең артык кулын тотып алды.

Гөлсем таш кебек каткан иде. Фәтхи аңа шыпырт кына:

— Яктырганчы безгә моннан китәргә кирәк,— диде.

Гөлсем әткәсе белән күрешергә, саубуллашырга кирәклеген дә онытып, тубалга әйләнгән башы белән Фәтхи артыннан атлады.

Авыл читендә, таллыкта, аларны җигүле ат янына баскан егет, Фәтхинең иптәш егете Гариф көтә иде. Гөлсемне түргә утырттылар да өерттереп чабып киттеләр. Бөтенләй кире якка, чит авылга барып кергәнче, Гөлсем авызын да ачмады. Ят урамга кереп бераз бардылар, көн

яктырды, Гариф тирләгән, ак күбеккә баткан атны тирә-ягы тыгыз койма белән корылган, тәрәзәләре ишегалдына караган йорт янына китереп туктатты, хуҗалар чыкканны көтеп тормады, тиз генә тарантастан төште дә капканы җилтерәтеп ачып эчкә узды. Ул арада өйдән урта яшьләрдәге, укалы кәләпүш кигән бер ир чыкты.

— Әйдүк, әйдүк! Хуш килдегез, мәрхәба! — дия-дия, тарантастан төшеп кенә өлгергән Фәтхи белән Гөлсемне, икесен ике ягына җитәкләп, өйгә алып кереп тә китте.

Фәтхи үтенече буенча, Гариф ике көн алдан ук килеп, йорт хуҗасы Гаяз белән килешенеп куйган икән. Гөлсем кече якка, чыбылдык артына кереп китте, ир-атлар өстәл тирәсенә җыелып киңәш-табыш иттеләр. Гөлсемне ят күзләрдән качырырга, беразга булса да яшереп тотарга кирәк иде. Авыл җирендә бу җиңел хәл түгел. Эт өргәнне дә, бет йөргәнне дә сизәләр авылда.

Качырырга кирәге мәгълүм ни әйтсәң дә, Гөлсем кулак кызы, гади кулакмы әле сиңа, Себергә сөрелгән кулак кызы! Аларның тамыры корырга тиеш. Ә монда кулак кызын коммунист Фәтхи аяп алып кала. Әгәр белсәләр, яшен яшьнәп кенә калмас, зилзилә кубар!

Фәтхи үзенә көн бетәчәген яхшы аңлый иде, мәгәр ул хәзер беркемнән курыкмас хәлгә җиткән, аны Гөлсемнән аермасыннар гына. Әтиләрен авылдан сөрсеннәр, аннан тагын күз күрер.

Фәтхи кулакларны җибәрергә кайтып җитәргә дә тиеш. Алар берәр чынаяк чәй эчеп, аннан-моннан капкалап алдылар да Гариф белән киттеләр. «Кичкә мин монда булырмын!» — диде Фәтхи Гөлсемгә.

Бер кич килде Фәтхи, ике кич, өч, Гөлсемне һич игә китерерлек түгел иде. Гаяз хатыны ниләр эшләп карамады, ниндиен генә тәмле сүзләр әйтеп кызны юатмады, Гөлсем ашамады-эчмәде, юньләп йокламады, тәрәзәдән күзен алмады, елый-елый шешенеп бетте. Көйләнмәсә көйләнмәс икән кеше дигәнең!

Өч көн рәттән килә алмады Фәтхи, дүртенче кичтә Гөлсем аны болдыр баскычына чыгып каршылады.

— Утырыйк шунда,— диде ул янбакчаны күрсәтеп.

Артсыз эскәмиягә янәшә утырдылар, беркавым сөйләшмәделәр. Фәтхи кызның уттай янган кулларын үз кулына алды, кыз карышмады.

— Әни бик елаганмы? — дип сорады кыз, беренче сүзе итеп.

— Еламады. Хикмәт шунда, китүчеләрнең берсе дә еламады. Вагонга кереп беткәнче карап тордым. Әткән борыла-борыла мина карады, саубуллашып кулын болгады. Аларны Урал ягына алып киттеләр.

— Фәтхи,— диде бераз тын утыргач кыз,— әтинең сүзен сүз итәргә кирәк.

— Изге йола,— дип хуплады эченә җылы йөгергән егет.

Эшне Гаязга сөйләп бирделәр.

— Аның бит хәзер никах укырлык мулласы да юк,— диде Гаяз аптырап.

— Карт мулла абзыйны дәшеп карыйбызмы әллә? — дип сүзгә катышты Гаяз хатыны.

— Аның урыныннан тормаганына ничә ай!

— Кулакларны озатканда авыл башына кадәр барган әле,— дип ачыклады хатын.— Бар, сөйләш.

Никах укыр өчен ике якның да ризалыгы кирәк, шул ризалыкны раслар өчен кыз ягыннан да, егет ягыннан да шаһит кирәк.

Күп баш вата торгач, җайланды тагын. Гаяз һичнәрсәне яшермичә мулла бабайга хәлне ачып салды. Әүвәл аяк терәп каршы торган карт хәзрәт, кызның нинди мөшкел хәлгә тап булуын белгәч, ризалашты. Кичке караңгыда Гаяз аны өеннән ат белән барып алып кайтты.

Гөлсем ягыннан Гариф, Фәтхи ягыннан Гаяз шаһит булды.

Бичара «кулак кызы»на ай буена Гаязларда качып яшәргә туры килде. Ул үзен читлектәге кош кебек хис итте. Әгәр Гаяз хатыны

Мәдинәнең күңеле кин булмаса, Гөлсем анда бер көн дә тора алмас иде. Аның куләгәсен күреп калган кешеләр ишәйде, авыл арасына сүз чыкты. Фәтхи караңгы төннәрнең берсендә Гөлсемне үз йортына алып кайтты. Авылда да иркен генә яши алмадылар яшьләр. Кулак кызын сөргеннән йолып калганы өчен, Фәтхине кат-кат районга чакырдылар, партизан, дип тормадылар, партиядән кудылар. Бу хәлләргә ул түзеп тора алмады, ярсулы җанын иартеп, хатынын җитәкләп, шәһәргә китте.

Шәһәрдә күптәнге бер танышы бар иде, Колчакка каршы бергә сугышып йөрделәр, килгән шәпкә шуңа барып сыендылар. Йөри торгач, урам себерүче булып эшкә ялланды Фәтхи. Фатир бирделәр.

Фәтхи бер ел эчендә шәһәр читендә үз йортын өлгертте. Урын бик җайлы булып чыкты. Тау кырые, аулак, җир иркен, көчеңне генә кызганма! Күпме телэсәң шул кадәр бәрәңге утырт, бакча үстер.

Үз куышына кереп утыргач, Фәтхи урам себерүне ташлады, ат юнәтеп, йомышка-юлга йөри башлады. Атны аңа шәһәрнең азык-төлек сәүдәсе оешмасыннан бирделәр. Бик бетәшкән, сыңар күзле арык алаша иде, Фәтхи аны өч ай дигәндә рәткә кертте. Бераздан бар да көйләнде, Фәтхи базадан кибетләргә товар ташыды, ат аның тугры хезмәтчесе, сердәш-юлдашы да булды.

Гөлсемгә дә эш табылды — сыер сатып алдылар. Сыерны карау, ашату тулысынча аның өстендә булды. Печәнне генә Фәтхи чаба, Гөлсем малкайны ашата-эчертә, сөтен сава, сөт-майның үзләреннән артканын базарга чыгарып сата. Гөлсем базар белән беренче тапкыр шул елларда очрашты, базарның кайнап торган хәрәкәтен, шау-шуын яратты. Базар аларның тормышын көйләде, аларга рух ирегә, яшәү мөмкинлеге бирде. Базардан тыш ул үзләре янындагы кибеткә җыештыручы булып керде. гаилә дә ишәйде — бер малай, бер кыз тапты. Талиясе әтисе сугышка киткәндә туып кына калган иде.

Фәтхи йортны тактадан, ике стена арасына пычкы чүбе тутырып корган иде. Фәкыйрьлек белән, ашыгып-кабаланып курка-курка төзегән куыш. Йорт нык булмады, кышкы салкыннарда парланып тиз череде. Яңа йорт, нык, озак бәхеткә исәпләнгән йорт салырга кирәк иде. Фәтхи бу юлы ашыкмады, уйлап, акыл белән эш итте, төзү кирәк-ярагын әкренләп җыйды. Җае чыккан саен бер-ике бүрәнә алып кайтып аударды. Ат аңа иптәш, ярдәмче булды.

Сугыш Фәтхине бик тиз эзләп тапты, Гөлсем ике бала белән утырып калды. Улы Мохтар икенче класста укып кул арасына керә башлаган иде инде. Улы ярдәмендә Гөлсем бөтен көчен куеп сыердан аерылмаска тырышты. Сыердан аерылмас өчен, тол хатын борыны белән таш тишәргә дә риза иде. Фәтхи китте дә югалды, көзге кичләрнең берсендә Гөлсемгә «Ирегез батырларча сугышып үлде» дигән кәгазь кисәге китереп тоттырдылар. Хәзер өчәү, өч ятим сыер күзенә карап яшәргә калдылар. Сыер аркасында ач та, ялангач та булмадылар. Ике баласын да тук йөртте, әйбәт киендереп үстерде Гөлсем. Укытты. Икесе дә югары белем алдылар. Хәзер үз тормышлары, Талиясе кияүдә, Ташкентта яши. Улы Себер ягында — зур заводта инженер. Улы әнисен гел үз янына чакыра. Барамы соң Гөлсем! Әгәр йорт-җирен бетереп улы янына күченсә, сыер төшенә дә керәчәк түгел. Сыерсыз, сөтсез, мәшәкатьләрсез ул ничек яшәр? Ни белән юаныр? Фәтхи сайлап алган, нигез-кура корган җирне ташлап китәсе дә килмәде аның. Бар көчен җыеп, мая туплап, Фәтхидән калган кирәк-яракларны эшкә китереп, яңа йорт салдырды. Алты почмаклы йорт. Авылдагы йортка бик нык тартым йорт. Аның таза тормышын күреп дуслары сөенде, дошманнары көнләште. Ятимлеп булса да иренең нигезен таратмады, ирләр белән азынмады, тапканын юкка-барга исраф итмәде.

Гөлсемнең чыгып киткәннән бирле авылына кайтып күренгәне юк. Әгәр кайтса, туган нигезен күреп йөрәге ярылыр төсле тоела аңа. Атасының мең газап белән корган йорты-җире, мал-туары кызганыч түгел аңа.

Хәзер ул төшендә, дөнья малы — дуңгыз каны икән ул. Бүген бар, иртәгә юк. Йорт-җир, таланган маллар турында уйлап та карамый, газапланып әти-әнисен сагына.

Кайда сез аның мәрхәмәтле дә, кырыс та әти-әнисе? Сезнең белән бергә сөрелгән сабыйларның ни гаебе бар иде? Исәннәрме сез? Кайда йөртә сезне язмышлар... Юк, юк, исән булсалар, берәвесе булса да кайтып күренер иде.

Казанда яши башлагач, Гөлсем авылдашлары белән очрашудан бик нык курка иде. Урамнарда як-ягына карангалап йөри, базар ыгы-зыгысында авылдашларын хәтерләткән күләгә шәйләнсә, шунда ук бер читкә чыгып йомыла иде. Соңгы елларда кая барса да күзе белән авылдашларын эзли торган булды — әгәр туганнарыннан берәрсе бу якларга кайтып төшсә, алар Гөлсемне каян эзләп тапсыннар? Авылдашлары очраганда, аларга адресын әйтеп җибәрә торган булды — белсеннәр, кирәге чыкса, белдерсеннәр дә...

Адресы мәгълүм булганнан соң, Гөлсемнән авылдашлары өзелмәде. Тегe яки бу йомыш белән шәһәргә кем генә килмәсен — аларда тукталa иде. Йорты зур, ишегалды иркен, күңеле киң. Ат белән килсәләр дә урын житәрлек. Атыңны туар да, алдына печән сал, йөр аннары тыныч кына шәһәр буйлап. Үз авылларыннан килгән ат та кадерле хәзер Гөлсемгә. Ул керт-керт печән кимергән ат янында сәгатьләр буе басып тора ала, хайванның ялын тарый, җылы су эчертә...

Көннәрнең берсендә авылдан Зәйтүнә килеп төшкәч, Гөлсем өчен олы бәйрәм булды. Зәйтүнәнең әнисе Хәбирә белән Гөлсем яшьтәшләр, балачактан бергә уйнап үстеләр. Гөлсемнең күрше авылда, Гаязларда качып ятканын бер Хәбирә белде, сатмады, киресенчә, шыпырт кына янына килеп китте, алмашка күлмәк тә алмаган Гөлсемгә кием-салым калдырды. Онытамы соң Гөлсем андый яхшылыкны?!

Зәйтүнә белән сөйләшеп сүзләре бетмәде. Зәйтүнәне беркая чыгармады, түренә утыртып кунак итте.

Кызны кияүгә биреп, аны базарга эшкә урнаштыручы да Гөлсем апасы булды.

* * *

Кыенлык беренче адымнан ук башланды — Зәйтүнәнең паспорты юк иде. Авыл Советы рәисе — авылның алласы да, мулласы да булган кеше кызга паспорт алырга белешмә бирмәде. Башта Зәйтүнә үзе йөреп карады, ялынды, йөз суын түкте. Эш чыкмагач, бәлки, олы кешенең гозерен үтәр, дип рәис янына Хәбирә үзе китте. Тол хатыннар һәм шешә яныннан сирәк ычкына торган рәис Борһан, күз яше түгеп, тилмереп әйтелгән сүзләрне колагына да элмәде.

— Югарыдан рөхсәт юк! — дип кырт кисте.

Ялынып-ялварып эш чыкмагач, Хәбирә ярсый-ярсый рәисне каргады.

— Имансыз икәнсең! — диде. — Хәлебезнең хәл икәнен күреп торасың. Берсеннән-берсе кечкенә биш бала, әтиебез юк. Ятимнәрне тилмерткән өчен, алланың ачы каһәре төшсен синең явызга! Бик кәперенеп йөрисең йөрүен, бел, кикригең шиңәр әле! Кеше рәнҗеше төшә ул, төшми дип уйлама! Ачка үләр хәлебез юк, барыбер кызымны шәһәргә җибәрәм. Паспортсыз җибәрәм! Алланың шәфкатьле бәндәләре бардыр әле, калгандыр. Бөтен дөньяны синдәй иблисләр басмагандыр!

Ана ялгышмады, шәфкатьле бәндә табылды. Озакламый Хәбирә үзе дә килеп, кунак булып китте. Ахирәтләр елый-елый күрештеләр, саубуллашканда, Хәбирә Гөлсем алдына башын иде.

— Берсе булса да шәһәрдә кала алмасмы, дигән, илем, ахирәт. Авылда түзәр әмәл калмады бит! — диде.

— Җан биргәнгә җүн бирә, дигән борынгылар, рәте чыгар, бетеренмә! — дип озатты Гөлсем Хәбирәне.

Ул елларда паспорт режимын саклау буенча бик еш тикшерү үткәрәләр иде. Беренче вакытта Зәйтүнә авылдан утырмага килгән кунак кызы булып яшәде. Тик закон каты, кунак кызы булмый, әллә кем бул — пропискасыз өч көннән артык яшәргә ярамый! Беренче облавада кыз сыер абзарында, салам арасына күмелеп качып калды. Сизмәделәр. Икенчесендә тотылды. Паспорт режимын бозган өчен, Гөлсем апасына штраф түләттеләр. Яшәү хәвефлегә әйләнде. Тора-бара рәте чыкты тагын.

Зәйтүнә кая барып сугылырга белмичә ишекле-түрле йөренгәндә аларга тавышсыз-тынсыз гына атлап бер ир кеше килеп керде. Төскә-биткә ягымлы гына, өс башы арзанлы булса да, пөхтә киенгән кирза итекләре ялтырап тора. Гәләфи чалбары гына аңа ниндидер ят, сәер төс бирә. Бер нәрсә — күлмәк якасының каралган булуы — аның буйдак икәнлеген искәртә иде кебек.

Кыз, керүченең сүзсез югалып калуыннан файдаланып, аны башыннан аягынача күзеннән үткәрде. Башта ул, тагын паспорт тикшерүче түгел, микән дип шикләнгән иде. Сүз башлау белән шиге юкка чыкты.

— Гөлсем апа кирәк иде,— диде егет кыюсыз гына.

— Өйдә юк шул.

— Озак йөрер микән?

— Әйтмәде алай. Күршеләргә генә кермәде микән?

Сүз шуның белән бетеп тә куйды. Егетнең китәргә исәбе юклыгын күреп, Зәйтүнә аңа урын тәкъдим итте.

— Утырыгыз. Аның озак йөри торган гадәте юк.

Егет кыяр-кыймас кына якындагы урындык читенә барып утырды.

— Сез кеме буласыз соң аның?

— Сеңлесе.

— Һә,— диде егет, серле елмаеп,— моңарчы күзгә-башка күренгәнегез юк иде.

— Авылдан мин, кунакка гына килдем.

Егетнең төпченә башлавы Зәйтүнәгә ошамады, әлбәттә. Авылдан килүен ычкындырды, әлләниләр сораша башламагае, дип, кече якка керде, шигәеп, тагын кире чыкты, юеш чүпрәк алып гөл чүлмәкләрен сөртергә кереште. Иртән генә чүлмәкләрне арулап чыккан иде югыйсә. Курка да, егетне чыгарып җибәрәсе дә килми, менә кызык!

Ул арада йөткергәләп Гөлсем апасы кайтып керде, егетнең ялгыз утыруын күреп:

— Зәйтүнә, кызым, кайда син? — дип кычкырды.— Нигә минем Хәлим энемне ялгыз утыртасың? Ярамый, ярамый! Шулай егетләрдән качалар мыни?

Зәйтүнә егет янына чыгарга кыенсынды, һаман күренмәде, Гөлсем чәй куеп җибәрде. Хәлим аның тыз-быз йөри башлавын күреп:

— Гөлсем апа, минем өчен булса, зинһар, мәшәкатьләнмә. Вакытым юк, йомышымны йомышлыйм да китәм, диде.

— Әллә нидә бер килеп, юкны сөйләп утырмасана! Хәзер кунак кызы белән кара-каршы утыртып, чәй эчертәм әле үзегезгә.

Гөлсем өстәлгә бал, май утыртты, табак тутырып ак калач кисте.

— Хәлим энем, нигә болай Гөлсем апаңны ташладың? Әллә үпкәләттемме? Рәнҗеттемме?

— И Гөлсем апа! Синме кеше рәнҗетә торган җан? Бушап булмый. Шул гына. Ятрәк йортны җиткереп бетерәсе иде.

— Булып чыгамы инде ул йорт дигәнең? Бер барып карарга җыенам әле.

— Түбәсен яптым, мич чыгарырга кирпеч табып булмый әле менә. Һич юнәтер хәл юк!

— Аңа гына калгач, эш терәлмәс! Кирпеч кечкенә мәсьәлә.

— Юк шул! Беркаян таба торган түгел. Бүтән материалларны чумарага китерәләр, кирпеч юк!

— Ашыкма,— дип көлемсерәде Гөлсем,— ашыккан житмәс, боерган житәр.

— Ашыкмый да булмый шул! Түбәсен япкач, йорт еракган ук күренә башлады. Мич чыгармасам, килеп жимереп ташларлар, дип куркам.

— Йорт кадәр йортны ничек жимерсеннәр ди?

— Сөйләшеп тә тормыйлар. Рөхсәтсез салынган, дип урамның аргы башындагы ике өйне пыр туздырдылар.

Гөлсем яшьләргә сөтләп куе чәй ясады.

— Миндә бер мич чыгарырлык кына кирпеч бар барын...

Егетнең йөзе яктырды.

— Үзенә кирәк булмаса, биреп тор, Гөлсем апа! Ипидер, кирпечләтә түләрмен.

— Мунча мичен сүтәрбез, дигән идем. Хәер, анысы ашыгыч түгел, сабыр итеп торырмын. Кирәк булгач, тәя дә кит, Хәлим!

— Озак тотмам! Мунча мичеңне дә чыгарырмын, Гөлсем апа! Чумарага табылыр әле!

«Чумара» — ул заманнарда иң таралган сүзләрнең берсе иде. Кибетләрдә әйбер бик сирәк була, һәркем урлаша яисә урланганны сатып ала, әнә шул «чумара» дип атала торган иде.

Егерменче съездан соң халык беравык жинел сулап алды. Шәһәрнең төрле ягында, елга үзәннәрендә, язгы ташкыннар киңәйткән чокырларда, сазламыклар өстендә, чүплек тирәләрендә, шифалы яңгырлардан соң үскән гөмбәләр кебек, шырпы тартмасыдай вак-вак йортлар — «насыпушкалар», такта алачыклар калкып чыкты. Авылдан, каһәрле колхоз кысасыннан ычкына алган тәвәккәл башлар тиз арада йорт өлгертеп керделәр. Халык торак тәэмин итүне, ниһаять, «үз кулына алды». Рөхсәтсез салынган йортлар көннән-көн ишәйде. Нинди закон булгандыр, әгәр хужа мич чыгарып өлгерсә, ул йортны жимертми башладылар. Эш шуңа барып житте ки, кайбер үткенрәк хатыннар, өйнең кысасы өлгерсә, матчага казак кагып, бишек элделәр. Андый йортларга да тимәделәр.

Зәйтүнә үз каршысында утырган егеткә күтәрелеп тә карамады. Гөлсем белән егет, өй салу, кирпеч, мич чыгарулар хакында сөйләшсәләр дә, алмаш-тилмәш аңа карыйлар кебек тоелды. Бер агарды, бер күгәрде кыз, бал белән майдан авыз итәргә оялды. Коры чәен калак белән болгатып тик утырды.

— Син нәрсә бүген, утырмага килгән кунак кызыдай кыланасың? — диде ярым әрләп Гөлсем апасы.— Күрсәтергә куймаган, балдан, майдан авыз ит.

— Гөлсем апа, бу чибәр кыз сиңа кем була? — дип сорады Хәлим, сүз сөрешен үзгәртеп.

— Үз кызым.

— Шаяртма.

— Охшамаганмы әллә?

— Охшамаган, дип...

— Авылдашым бу минем. Ахирәт дустымның кызы. Мәнә шәһәргә килеп чыкты.

Хәлим чәен эчеп бетереп тустаганын читкә куйды.

— Пар булсын, тагын берне эч,— диде Гөлсем, Хәлимнең ай-вайга карамады, тутырып тагын берне ясады.— Хәлим энем, сиңа бер сүзем бар, өйләнергә уйлыйсыңмы, юкмы син?

Хәлим, үзе дә сизмичә, Зәйтүнәгә карап алды. Зәйтүнә аның күз карашын очратып сискәнеп китте.

— Торыр урын булсын әле, аннары карарбыз.

— Мичеңне чыгар да аллага тапшыр.

— Син бик тиз.

— Кая инде тиз? Тагын күпме йөрергә була?

— Алай бик өйләндерергә теләсәң — кыз тап!
— Һәй, егет кешегә кыз тапмый буламы?!
Гөлсем күзе-кашлары белән Зәйтүнәгә ымлады.
— Вакыт юк, Гөлсем апа!
— Соңарма,— диде һаман үгетләп Гөлсем.— йөрерсең аннары суган суы суырып.

Хәлим Гөлсемнең ишарәсен аңлап тагын бер тапкыр Зәйтүнәгә күтәрелеп карады. Кыз чыннан да чибәр иде. Дугаланып киткән кашлар астында кус сөрмә каймалаган зур күзләр. Сөйләшкәндә мамык кебек күпереп торган бит уртасында нәни генә чокыр хасил булып, йөзен тагын да ямьләндереп җибәрә. Буй-сыны да килешле. Ләкин бик яшь күренә, сабыйлыктан яңа чыккан җан, ай-һай, тиз генә кияүгә чыгарга риза булырмы икән? Аннары, акыл ягы ничектер?

Шикле уйлар ничек кенә борчымасын, Хәлимнең йөрәгенә ут үрләде. Тик ничек сүз башларга? Яше утызга житеп килә, кызлар кулы тотып караганы булмады, тәҗрибәсе юк. Сәбәбе — нужа бабай. Туя ашамаган кеше кызлар хакында уйлый аламы соң?

Гөлсем кирпеч күрсәтергә Хәлимне ишегалдына алып чыкты, Зәйтүнә табынны җыештырып калды. Гөлсем сүзне кыска тотты:

— Бүген үк кинога ике билет ал! — диде.— Җитәр, буйдак булып күп йөрдең, төтен куып! Йортны бергәләп төзеп бетерерсез.

Зәйтүнәнең исеме телгә алынмаса да, Хәлим сүзнең кем турында барганын аңлады.

— Ул минем белән кинога барырга теләр микән соң?

— Син билетыңны гына юнәт, калганын үзем карармын. Аң бул, кулыңда кунам дигән асыл кошны очыра күрмә!

Менә сиңа, мә, кирпечкә, дип килеп, кәләшле булып китә түгелме Хәлим? Дөньяда шундый танышу да була икән, гаҗәп! Моңа кадәр хатын-кызга әллә ни исе китмичә ваемсыз йөргән егетнең башына уй төште. Мәсьәләне текә куйды Гөлсем апасы: йортны да төзеп бетер, өйлән дә!..

Хәлим ашыгып барып әүвәл башта ике билет алды, кичке сеанска. Билет алгач кына аңышты, кичкә кадәр вакыт бик күп икән әле. Калган вакытны нишләтергә? Майлап-баллап һаман чәй чөмерергәме? Хәлил бер минутын да бушка уздырмаска тырыша торган егет «Бирәм, ал!» — дип торганда, кирпечне ташып куярга иде, бер олы эш бетеп торсын. Җае да чыкты, бәхете бар икән Хәлимнең, узып баручы машинаны тотып, шофер белән килешеп тә алды.

Кирпеч лапас түренә, утын яркалары артына өелгән икән. Өйрәтәсе юк, Гөлсем апа дөнья хикмәтләрен белә, усал күзләрдән яшереп, хәзинәне шулай ерак олактырган. Машина лапаска керә алмады, житмәсә, шоферы да бик коры туры килде, ашыктыра, сүгенә.

Гөлсем булышырга Зәйтүнәне чакырды. Чыгар алдыннан кисәтеп куйды.

— Кара аны, ишетсен колагың, тырышып эшлә! Егет бер дигән, сыната күрмә!

Кирпечне машинага носилка белән ташырга туры килде. Хәлим оч-дүрт кирпеч салды да кызны кызганып:

— Күп булмадымы? — дип сорады.

Зәйтүнә рәхәтләнеп, лапасны тутырып көлеп җибәрде.

— Кичкә кадәр төяргәме исәбең, Хәлим! Авыл кызы ич мин, эшне күргән бар! — диде.

Егет носилкага күп итеп кирпеч өйде.

Шофер, тартырга алам, дип кибеткә чыгып киткән иде, кайткач, кирпечнең төялеп бетүен күреп, күзләренә ышанмады.

— Кечкенә, эче тулы төш кенә икән бу кыз! — диде Зәйтүнәне мактап.— Билләһи, әгәр өйләнмәгән булсам, бүген үк алып китәр идем!

Бу мактауны ишеткән Хәлимнең йөрәге сулкылдап куйды. Хәлим Зәйтүнәдән алдарак өйгә керде, Гөлсем апасына кино билетларын тоттырды.

— Кичке сигезгә! — диде ул ашыгып.— Мин хәзер кирпечне илтеп бушатам. Аннары тиз үк килеп җитәрмен! Син әзрәк... көйлә инде!

Ул арада шофер машинасын акырта башлады. Хәлим Зәйтүнәгә кул болгады да атылып кабинага сикереп менде.

Кирпеч эше — майлы ботка ашау түгел. Зәйтүнә шактый арган иде, алай да Гөлсем апасына арганлыгын сиздерергә теләмәде, идән юып алырга җыенды.

— Ял ит, бүген юмасаң да ярар,— диде Гөлсем серле тавыш белән.

— Юа торган көн ич!

— Иртәгә дә көн булыр.— Гөлсемнең тавышы тагын да серлерәк ишетелде.— Хәзер Хәлим килә.

— Нигә килә тагын?

— Билет алган. Сине кинога алып бара.

— Кинога?

Кыз коелып инде.

— Әзерлән.

Зәйтүнә шәһәргә килеп егет кеше белән кинога баруны күз алдына да китерә алмый иде әле. Шуңамы, Гөлсемнең сүзе аңа сәер тоелды, ул аны шаярта дип уйлады.

— Абау, бик карт ич ул! Минем белән кинога барганын белсә, хатыны чәчен йолкып бетерер!

— Бер дә карт түгел, өйләнмәгән егет. Чакырганда баруыңны бел, үкенмәссең.

— Куркам ла...

— Андый сазаган егетләр куркыныч булмыйлар. Син яшь-җилкенчәктән сагай!

— Белмәгән, күрмәгән ят кеше. Җитмәсә, үзе миннән олы...

— Олы икән — тормыш итәргә ышанычлы булыр. Минем дә картым күпкә олы иде. Өрмәгән җиргә утыртмады.

Үзенә бик якын ике кешенең язмышы хәл ителү мөмкинлеген уйлап, Гөлсем бу фикер белән мавыгып, яшәреп китте, Зәйтүнәгә Хәлимнең уңай якларын тезеп бирде.

Зәйтүнә икеләнә калды.

— Ачуланма, Гөлсем апа, бер дә күңелем тартмый. Мин кинога бармам ахрысы. Өс-башым да бик хөрти. Яшәр урыным да юк, торыр җирем дә ачыкланмаган.

Зәйтүнәнең еламсыраганын күреп, Гөлсем аның аркасын сөеп какты.

— Кинода өс-баш салып утырмыйлар. Мин сиңа Талиянең плащын кигертәм. Ал, үзеңә булыр. Башыңа менә бу ефәк кыйгачны бәйлә.

Талиянең плащы Зәйтүнәгә таман гына иде, аны кигәч, кыз бөтенләй үзгәрде, биегәеп, тагын да зифаланып китте. Плащ якасы өстенә ефәк кыйгачны да салгач, кыз әкияттәге су кызына охшады. Гөлсем аны әйләндереп-әйләндереп карады да кулын чәбәкләде.

— Урлап качарлык сылу булдың, Зәйтүнә бәгырем! Әнкәң күрсә дә танымас иде! Көзгегә кара, таныйсыңмы үзеңне? Менә кием кешене нишләтә! Хәлим кебек егет чакырганда кинога бармыйлармы соң? Сыер абзарында качып ятып кына эш чыкмас. Дөньяга кыюрак атлап керергә кирәк.

Үгетли торгач Зәйтүнә күнде, күнегер өчен яңа киемнәрен тиз генә салмады, Гөлсем апасы күрмәгәндә көзге алдында бөтерелде, үзенә үзе карап туймады.

Гомерендә беренче мәртәбә егет белән кинога китте Зәйтүнә. Хәлим дә өс-башын арулаган, ор яңа күлмәк кигән. Кинотеатрда егет Зәйтүнәне буфетка алып керде, үзенә сыра, кызга мороженый алды. Ашадылар, эчтеләр, сөйләшергә сүз генә табылмады. Егет юаш, кыз кыюсыз иде.

һәркайсы үз уе белән мәшгуль булды. Хәлим ничек тә Зәйтүнәгә ярарга, күңелен күрергә тырышты. Зәйтүнә исә, мороженый белән лимонад хакын сораса, акча каян алып түләрмен икән, дип кайгырды.

Хәлим тагын мороженый алмакчы иде, Зәйтүнә аны кисәтте:

— Алсаң, үзеңә генә ал, минем кабар җирем калмады,— диде.

— Мин тагын, син мороженый яратасың, дип торам. Үзем өнәп бетермим, тегесен дә синең хакка гына ашадым.

Кинода халык күп иде, урын җитмәгәч, стена кырыйларына урындык тезеп утырдылар. Һинд фильмы күрсәттеләр. Кино Зәйтүнәгә ошады. Һиндстанның табигать күренешләрен аеруча ратып карады. Кулга иләштерелгән акыллы, сабыр филләр, ажгырып торган ерткыч арсланнар аны таңга калдырды. Ә җырлары... Нинди матур икән алардагы җырлар! Моңландыра да, дәртләндерә дә. Кино дәвамында Зәйтүнә дөньясын онытты, үзенең паспортсыз сукбай икәнен дә, йортсыз-нигезсез хокуксыз бер җан икәнен дә исеннән чыгарып торды...

Хәлим Зәйтүнәне Гөлсем апаларына кадәр озата барды. Юл буе кинода алган тәэсирләрен уртаклашып кайттылар, бер туктаусыз сөйләштеләр, сүзе дә әллә каян табылды, ике үксез җан ирексездән бер-берсенә тартылдылар.

## VI

Мич чыгарырга атлыгып йөргән егет, барган җирендә гүзәл кыз белән танышты. Язмышмы бу? Аллаһе тәгалә шуны теләдеме?.. Кем кавыштырды аларны? Мәрхәмәтле, һәрчак адәмнәргә ярдәмгә ашыгып яшәгән Гөлсем апаларымы?..

Хәлим шәһәрдә туса да, төп чыгышлары авылдан. Ата-анасы егерме беренче елгы ачлыкта шәһәргә килеп сыенган. Күпләр еракка, икмәкле Ташкент ягына агылып җан саклаганнар, Хәлимнең әти-әниләре Казанда туктап калганнар. Алар икесе дә сабын заводында эшлиләр иде. Фатирны да аларга завод биргән. Ул ике катлы агач йортның чарлагында иде. Заманына күрә яхшы фатир, уртача зурлыкта ике бүлмә, бүлмә саен икешәр тәрәзә. Иркен өйалды. Бөтен артык-пыртык, чүп-чар шунда сыя. Тәрәзәләр Кабан күленә карый. Күлнең теге ягында, күбесе бер катлы агач йортлар арасыннан, мәһабәт булып мәчет манарасы калкып тора.

Җәен Хәлим су буеннан кайтып керми, коена, кышын көннәр буена тимераякта шуа. Еш кына аргы як малайлары белән эләгешеп тә алалар, сүздән сүз чыга, аннан тукмаша ук башлыйлар. Олылар арага кермәсә, канга батып беткән чаклары да була иде. Яшьтән үк кыйналып үсте Хәлим.

Фәтхи авылыннан куылып диярлек китеп, урам себерүче булып эшкә кергәч, аларга фатирны Хәлимнәр яшәгән йортның подвалыннан биргәннәр иде. Ике гаилә бик тиз дуслаштылар, бер-берсенә ярдәм итеп, тату яшәделәр.

Гөлсем Хәлимне үз баласыдай якын күрде, анда-монда барган чакларда малайны ияртеп, дөнья белән таныштырып, кайда акыл биреп, кайда әрләп, кисәтеп йөрде. Хәлим сугыштан соң Гөлсем апасына кайтып егылды. Хәлим фронтка китеп ике ай уздымы икән — әнисе вафат булды. Бердәнбер улының хәбәрсез югалуын күтәрә алмаган бичара, төнлә, дөнья тыныч чакта, бәхетлеләр тәмле төшләр күргәндә, ялгызы газапланып җан биргән. Күзгә-башка күренмәгәч ишеген ватып керсәләр, кап идәнгә сузылып яткан мәрхүмә...

Аларның хатын ягыннан да, ир ягыннан да туган-тумачалары егерме беренче елгы ачлыкта кырылып беткән. Хуҗасыз калган квартирага күп балалы бер гаиләне урнаштырганнар. Әсирлектән кайтып егылган Хәлимне алар ишеккә якын да китермәделәр. Җиде бала берьюлы дөнья

бетереп акыра башлагач егет үзе дә фатирны дәгъвалап йөрмәде. Арыбире сугылып, юридик консультациягә кинәшкә кереп караган иде, әсирлектән кайтканын белгәч, ишеккә күрсәттеләр.

Хәлим бик бетеренгән, хәле чиктән тыш авыр, аягын көчкә өстерәп йөри. Әсирләр лагеренда атналар буе ач тору, тәнгә ябышкан чир-чорлар аны шул хәлгә төшергән иде. Гөлсем апасы булмаса, ай-һай, аякка басар идеме икән егет? Гөлсем апасы аны карады, Гөлсем апасы аны кеше итте. Әлеге дә баягы шул сыер коткарды, көн саен җылы сөт эчте Хәлим. Сөтнең куесын, имчәк төбен җәлләмәде юмарт хатын.

Кигән киеме сәләмәгә әйләнгән иде, Гөлсем апасы аларны салдырып янган мичкә ыргытты. Ире Фәтхидән калган күлмәк-ыштаннарны, костюм-чалбарны кигертте.

Хәлим елга якын ватан сугышы инвалиды булып йөрде. Пенсия дә түләделәр. Дөрес, пенсиясе зур түгел иде, карточкага бирелә торган азык-төлекне алырга гына җитәрлек, туктатмасалар, бик ярап тора иде, туктаттылар аны, әсирлектә булган кешегә пенсия түләнми, диделәр.

Бетә иде Хәлим, тәпиен суза иде, чуар сыер сөте, Гөлсем апасының җылы күңеле савыктырды аны. Аякка чак кына басу белән ул эш эзләргә тотынды. Һөнәре юк иде югын, эзли торгач, эше табылды — авиаотрядның механика мастерскоена өйрәнчек булып керде. Слесарьлык һөнәрен бик тиз үзләштереп башы күккә тиде, хезмәт хакы да ярыйсы, эше дә җайлы. Эшлә дә эшлә генә! Әсирлектә булуы беленгәч, мастерскойдан кудылар. «Уяу булырга кирәк. Самолетлар тирәсендә йөри Хәлим. Корткычлык эшләп ташласа, кем җавап бирә?!»

Квартира тиз алырга була, дип ишеткәч, ул хәрби заводның кадрлар бүлегенә сугылып карады. Сөйләшмәделәр дә. Эшсез яшәү мөмкин түгел иде. Тол хатын исәбенә күпме дөнья көтәргә була? Ахыр чиктә Хәлим тимер юл станциясенә йөк бушатучы булып ялланды. Алар илнең төрле почмакларыннан килгән вагоннарны хәрби заводның хуҗалык мәйданында бушаталар. Нәрсә генә килми монда: бүрәнә, такта, кирпеч, төрле тимер-томыр, ташкүмер, известь... Санап бетерә торган түгел! Кайсы көннәрдә яртышар тәүлек тоташтан эшләтәләр. Ял көннәрендә дә чакырып алалар. Йөк вакытында бушатылмаса, бригаданың җанын алалар, штраф белән җәфалыйлар, эштән куабыз, дип куркыталар.

Сугыштан соңгы авыр еллар... Йөкнең теләсә кайсысын кулында йөртеп, иңенә салып бушатырга кирәк. Таза-сәламәт ирләр юк, иптәшләре Хәлимнең үз ишләре, кайсысының социаль чыгышы начар, кайсы сугыш чуалышларында тапланган, берсен дә рәтле эшкә алмаганнар, ничарадан бичарага бу тәмугка килеп ялланганнар. Күпчелекне дөнья аңгырайткан, аларга ни, дөнья бер — уртасы камыр, гомер буе кара эштә чыныкканнар, кусалар — баралар, кумасалар — туктыйлар. Аракы булсын да аларга, закускага балык койрыгы бетмәсен. Таныш хатыннарын шунда вагон ышыгында да әвәләп алалар...

Хәлим Рәхимҗан атлы егет белән якынлашты. Ул бер яшькә олы, саңгырау, сөйләшә башласа нык ук тотлыга. Табигать көчне җәлләмәгән бахырдан, дүрт потлы капчыкны уйнатып йөртә Рәхимҗан, бүрәнәләрнең төп башына тотына, ял-алны белми. Мәктәп бусагасын атлап кермәгән Рәхимҗан, кул куя белми, хезмәт хакы алганда тамга сала. Тамгасы шундый матур, акчадагы имзадан бер дә ким түгел. (Ул чакларда зур купюрлы кәгазь акчаларда җаваплы кешеләрнең имзасы була торган иде. Аннан соң гына кадерсез, имзасыз акча заманалары китте!)

Рәхимҗанны армиягә алмаганнар, колакайлыгы аны сугыш җәһәннәменнән аяган. Сугыш беткән елда авылның бер чая хатыны аны шәһәргә ияртеп килгән. Хатын Рәхимҗаннан күпкә олы булса да, алар икәү бер-берен яратышып, олылап яшиләр. Хатын житез булып чыкты, ел саен бәби алып кайта, хәзер балалары бишәү булган! Бишесе дә кыз бала!

— Алтынчысы, шаять, малай булыр иде... Алып кайтырга базмыйбыз — торыр жир юк... Хатын кысырга калганчы йортлы булсакмы!..— дип көлдерә иптәшләрен саңгыраү Рәхимжан.

Хәлим гаиләчел, тырыш, рыясыз Рәхимжан белән тиз дуслашты. Чын дуслык һәрчак жимеш бирә торган була, Хәлимгә дә язмыш елмайды.

Станция белән янәшәдә генә, халык телендә Бакалтай дип йөртелә торган зур, тигез болынлык башлана иде. Ул заманда бөтен шәһәрнең чүбен шушы болынга китереп аударалар иде.Ниләр генә булмый иде ул чүплектә: иске-москы, ташландык арасында бүрәнә, кирпеч, төрле ватык жиһаз, әржә такталары тау-тау булып өелеп тора иде.

Хәлим игътибар итә башлады — әз генә буш вакыты булдымы, Рәхимжан шул Бакалтай чүплегенә йөгерә. Эштән соң да шунда чаба, әбәт вакытында да тик утырмый. Нигә бара, ник ашыга, ни файдасын күрә — серен берәүгә дә ачмый, сорашсалар, колагын күрсәтеп авызын ера: ишетми, янәсе! Хәлим беркөнне Рәхимжанга ияреп Бакалтайга төшә. Чүплектә ул жыеп, бер кырыйга өеп куйган бүрәнәләрне, әржә такталарын күреп шаккатты.

— Тиле таш жыяр, нишлисең бу бүрәнә башлары белән?

— Күбрәк булсын иде мондый мал! — диде Рәхимжан, авызын ерып.— Күбрәк булсын иде!

Ул тынмады, чүп арасыннан таза бүрәнә башы тартып чыгарды, әржә такталарын жыеп китерде.

— Күрәсеңме? Менә дигән төзү материаллары. Сатып алам, дисәң — юк, уларга кулым бармый, ә безгә малай алып кайтырга кирәк.

— Малай?!

— Йорт булса — малай кайта.

Эштән соң Рәхимжан Хәлимне алтынчы трамвайга утыртып үзе белән алып китте. Трамвайдан төшкәч, суы кипкән тирән елга үзәненә барып керделәр. Рәхимжан белән Хәлим килгәндә, үзән эче гөрләп тора иде. Халык мәж килә! Кем ничек тели, шулай жир кисеп алганнар да йорт салалар. Рәхимжан кишәрлегенә житкәч, Хәлимнең ике күзе дүрт булды: йорт кысасын күтәреп тә куйган колакай! Ул зурдан купкан, биш кызга биш бүлмә булырга тиеш, ди. Эшкә кулы ябыша икән егетнең. Хәлим ул төзеп яткан йортны бик ошатты.

— Балта эшенә каян өйрәндең? — дип сорады.

— Башыңа төшкәч, башмакчы буласың!

Ерганак үзәнендә тырышып-тырышып йорт житкезеп маташкан кешеләрнең, күпчелеге авылдан чыгып ычкынган кичәге крестьяннарның эш нәтижәсен күргәч, Хәлим уйга калды. Ул да ир кеше, башкалардан ким жире юк, нигә тәвәккәлләмәскә? Нигә һавадан өмет көтеп ятырга? Рәхимжан янында жайлы гына буш урын бар, ярның текәрәк урыннарын ишеп уйсу жиргә тутырсаң... Жире зур түгел түгелен, алай да житәрлек. Хәлимнең әлегә биш кызы юк, кашы да күзе, нужасы да үзе. Барына риза булырга кирәк!

— Кемнән рөхсәт алырга соң? — дигәч, Рәхимжан баш бармагы белән күккә күрсәтте.

— Ходайдан!

Хәлим шул минуттан көеп-кызып эшкә тотынды. Бүрәнәсен, тактасын туры килсә ат белән, туры килмәгәндә иңенә күтәреп ташыды. Һәйбәтрәк материалларны Рәхимжанның өй ышыгында, тотты,бер жәйдә өй кысасын өлгертте. Тиз тотып толь белән түбәсен япты.

Мич чыгарырга йөргәндә Зәйтүнә чибәргә тап булды. Ул моны яхшыга юрады, бер-ике тапкыр киногa барып кайткач, алар бер-берсенә нык ук ияләштеләр. Икесендә дә эшкә комарлык бар иде.

Гөлсем эшне куыра белә, икесен бергә туры китергәч, тимерне кызуында сукты.

— Вакыт әрәм итеп йөрмәгез, өйләнешегез! — диде.

Зәйтүнә ык-мык килеп маташкан иде дә аны да ипкә китерде Гөлсем.

— Егет менә дигән, урта бармак, үкенмәссең!

Шул тирәдә йорт житкезеп маташкан Сәләхи мәзинне чакырып, никах укытты Гөлсем, яшьләрне бер генә көнгә авылга озатты.

— Шәһәрдә паспортсыз никахны теркәмиләр. Кияүгә чыккач, Зәйтүнәгә паспорт бирми калмаслар. Авылда паспортлы да булырсыз, никахыгызны ЗАГСта беркәтерсез!

Чыннан да, никахларын теркәгәч, Зәйтүнәгә өч айлык вакытлы таныклык бирделәр. Хәзергә ул да бик ярап тора, әле монысы да юк иде ләбаса. Прописка юк та юк инде, ул як һаман чатак калды. Өч айлык кәгазь кисәге кулга кергәч, икесе дә чамасыз шатландылар. Законлы документ, моңа кадәр Зәйтүнә чүп кисәге иде, хәзер адәм санына керде. Күкрәк киереп: «Менә мин кем!» — дип әйтә ала. Документсыз син беркем түгел, сине эшкә алмыйлар, сайлауларга катнашмыйсың, кеше исәбендә йөрмисең.

Алар авылда озак тормадылар, көнен әйләнеп кайттылар. Әлфия сылу аларга күренмәде. Кайту белән үз йортларына күчтеләр.

Үз йортлары. Үзләренеке! Зәйтүнәнең әнисе ике мамык мендәр, зур юрган биреп жибәрде. Гөлсем су чиләге, ике кашык, ике стакан, таба бүләк итте. Хәлим кибеттән керосинка сатып алды. Шуннан ары ни кирәк аларга бүген? Үз түбәләре астында, үз керосинкаларына утыртып, үз табаларында күкәй тәбәсе куырдылар да идәннәренә үз мендәрләрен түшәп, авылдан килгән йомшак юрганны ябындылар. Бар кайгылар онытылды, үзләрен жәннәткә кергән кебек хис иттеләр.

Тирә-як тынды, юнышь, балта тавышлары ишетелмәс булды. Алардан башка бу дөньяда бер жан иясе дә калмады, алар рәхәттә фәкать икесе яшәп калдылар. Моннан да жайлы, моннан да рәхәт урынның булуы мөмкин түгел, дип исәпләделәр. Аларга бүген зиннәтле сарай да, ефәк чатыр астындагы тирбәлчек караватлар да кирәк түгел, әйдә, затлы сарайга күчегез, дисәләр, Хәлим белән Зәйтүнә, бүгенге урыннарын һич алыштырмаслар иде. Төн кыскарды, бер минут кебек булып кына тоелды. Көндез Зәйтүнә өйдә үзе генә кала. Башта көннәрен бик тыныч, бик рәхәт итеп үткәрә иде, Хәлимне эшеннән көтеп ала, аш-су әзерли, өйне, өй тирәсен жыештыра, су ташып куя, һич тынмый, көне буе аяк өстендә булса да, һич арымый иде яшь хатын...

Беркөнне Хәлим эшкә китүгә үк, бик куелмаган ишекне аяк белән тибеп ачып, аларга милиционер килеп керде. Түргә узды, комсыз күзләре белән почмакларны капшап чыкты, идән тактасын күтәреп базга карады, шуннан соң гына ике тәрәзә арасына басып, арты белән стенаны терәп калтыранып торган яшь хатынга карады.

— Ирен кайда?

— Эштә.

— Йорт салырга кем рөхсәт бирде?

— Мин белмим, ирем белә.

— Кайчан кайта?

— Кич инде, сменадан соң...

Милиционер Зәйтүнәгә текәлеп торды да:

— Паспортың бармы? — дип сорады.

— Бар,— диде каушап хатын.

— Йөле, бир әле!

Милиционер һәр хәрефен йотардай булып кәгазь кисәген укып чыкты да:

— Бәй, авылдаш икәнсең син минем! — диде.

— Мин сезне белмим бит,— диде Зәйтүнә паспортын күлмәк изүенә шудырып.

— Белерсең! Белдерермен! Ирең кайткач та әйт, иртәгә шушы вакытта кереп чыгармын. Яртысы өстәлдә булсын! Югыйсә... өегезне ишеп кенә төшертермен!

Зәйтүнә яман усал авылдашының кем икәнен белмәде. Иртәгесен килде милиционер, тагын, тагын керде, аның Мәхмүт исемле булуын, аракыны чиксез яратуын, җай чыкса, хатын-кызга кул сузарга әзер булуын Зәйтүнә яхшы белә иде инде хәзер. Ул өйдә ялгызы калырга курка башлады.

Истә-оста югында килеп керде Мәхмүт, Зәйтүнә, су җылытып, кер җебетергә куеп маташа иде. Мәхмүтнең артыннан тотып алуы булды, Зәйтүнә чырыйлап кычкырып җибәрде. Күршең үзеннән яхшы булсын, дигәннәр, Зәйтүнәгә бәла янаганын саңгырау Рәхимҗан каян ишеткәндер, чырыйлап кычкыруына Рәхимҗан кереп тә житте. Бала башы хәтле йодрыгын Мәхмүтнең танау астында йөртеп:

— Тагын бер күрсәм! Бел, үтерәм! — дип кисәтте.

Мәхмүт кереп йөрүен сирәгәйтте, куркуы чын булдымы, Рәхимҗанны җавапка тарттырып йөрмәде, әллә оятына көч килдеме, кергән мәлләрдә Хәлим өйдә чакны сайлады, Зәйтүнәгә бәйләнеп маташмады.

Шулай да эшкә кермичә ярамый. Хәлим эшли эшләвен, хезмәтенә күрә хакын да түлиләр. Ләкин аның хезмәт хакын, ничек кенә сузма, житкерә торган түгел. Өй салганда күпме материал кирәк буласын Хәлим күз алдына да китермәгән икән. Кадак-кодак, ишек-тәрәзәгә күгәннәр, тагын әллә нәрсәләр, әллә нәрсәләр! Бакалтай чүплегеннән аларны таба торган түгел. Зәйтүнә эшкә урнашып, әз-мәз акча китерә башласа, бер дә начар булмас иде булуын.

Эшкә керер өчен прописка кирәк. Прописка용ның да шәһәрнеке булуы шарт. Дөрес, ул хәзер Хәлимнең законлы хатыны. Гамәлдәге тәртип буенча аны ире янына пропискага алырга тиешләр. Әмма Хәлимнең әллә кайчан пропискасының срогы чыккан. Аны әсирлектән котылып кайткач, мең бәла белән Гөлсем йортына вакытлыча язганнар иде. Хәлим исә прописка турында бүтән кайгыртмады, шул килеш йөри бирде, власть оешмаларына барырга җаны тартмый, ишек кагарга йөрәге җитми иде. Үз йортын сала башлагач, вакыты да житенкерәмәде, кыен хәлдән яшьләрне тагын Гөлсем апалары коткарды.

Шәһәргә орынып торган зур бер авыл — дәрвишләр авылы бар иде. Янындагы шәһәр территориясенә керә торган хәрби завод эшче көчләр кытлыгын шул авыл исәбенә бик ансат бетерә барды. Авыл саналса да, халкы күптән шәһәр кешесе булып бетте. Эшләргә кешесе калмагач, аларның җирләрен күрше колхозга куштылар. Ә авыл үзе һаман искечә, территориаль яктан район буйсынуында кала килде. Паспорты бар кешегә җиңел генә шунда пропискага керергә була иде. Тик фатирга кертүче генә табарга кирәк!

Гөлсем Хәлим белән Зәйтүнәне үз йорты белән шул авылда яшәүче бер маржага пропискага кертте. Алар маржа белән базарда сөт сатканда танышып, дуслашып киткәннәр икән. Гөлсемнең сыеры — чуар, маржаныкы да чуар. Маржаның сыеры сөтләч, Гөлсемнеке дә чиләк-чиләк куе сөт бирә. Дуслык өчен кайчагында шул да бик житә.

Прописка бушка түгел, әлбәттә. Яшьләр ай саен хуҗа хатынга иллешәр сум түлиләр. Бу очракта йөз сум да булдымы мал! Шатлыгы ни тора икесе дә шәһәр кешеләре хәзер алар!

Пропискага кереп күп вакыт үтмәде, дәрвишләр авылын шәһәргә куштылар. Хәлим белән Зәйтүнә дә шәһәрнең тулы хокуклы кешеләре булдылар. Хәзер Зәйтүнәгә эшкә урнашасы гына калды.

Зәйтүнә башта шәһәр базарлар идарәсенә ярты ставкага курьер булып кергән иде. Ул елларда шәһәрдә уннан артык базар бар иде. Шуларга базар идарәсеннән боерыклар, күрсәтмәләр ташыды, бүтән вак-төяк ашыгыч йомышларны үтәде. Аның житезлеге, кушканны җиренә житкереп эшләве, идарә башлыгының күзенә тиз чалынды, беркөнне ул Зәйтүнәне үз катына чакыртты. Кайдан килүен, белемен, гаилә хәлен сорашты. Зәйтүнәнең кияүдә икәнен белгәч, сиңа ничә яшь соң, бала, дип сорады. Иренең кем булуы белән дә кызыксынды. Ахырда ул Зәйтүнәдән:

— Сине базарга сборщик итеп күчерсәк, риза булырсынмы? — дип сорады.

Зәйтүнә «сборщик»ның кем икәнен, эшенен нидән гыйбарәт икәнен белми иде. Шулай да югалып калмады.

— Ирем белән киңәш итеп карармын,— диде.

Начальникка аның бу сүзе дә ошады.

Хәлим дә базарда сборщикка нинди эш йөкләнгәнен белми иде. Руслар телендә «базарная баба» дигән сүз барлыгын ишеткәне бар иде барын. Эченнән генә: «Минем хатын шул базарная бабага» әйләнә микәнни?» дип пошынып та уйлады. Шулай да, Зәйтүнәнең хезмәт хакы ике мәртәбә артачагын исәпкә алып, ризалык бирде.

— Эшләп кара, ошамаса — ташларсың! — диде.

Зәйтүнә тәвәккәлләп эшкә тотынды. Беренче мәлдә бик кыен булды. Ярый әле, атна буена Гөлчирә исемле хатын белән парлап эшләделәр. Гөлчирә таш астыннан чыккан, телгә беткән, кыю, чая хатын. Аның бөтен гомере базарда узган. Кем белән ничек сөйләшергә белә. Кешеләрне бер күрүдә таный, үзен дә, сату итүчеләрне дә ким-хур итми. Хуҗалар белән дә арасы әйбәт.

Зәйтүнә башта карт-корыдан, бала-чагадан, гариплардән базар җыемы түләтми маташты.

— Болай булсаң, сине монда озак тотмаслар! — диде Гөлчирә, кискен итеп.— Иң элек үзең турында уйла, яхшы атлы булып, кеше жәлләп маташма! Безнең эштә жәлләү юк. Өйрән!

Кызык! Моңарчы Зәйтүнәнең тәрбиячеләре — әнисе, туган-тумачалар, өлкән яшьтәге күрше-колан гел-гелән: «Адәм балаларына шәфкатьле бул, кешеләрне жәллә, үзең турында гына уйлама!» — дип өйрәтәләр иде. Ә монда кистереп: «Жәлләмә!» — диләр. Тегеләрнең үгете сүздә, уй йөрткәндә була иде, Гөлчирә аны эш өстендә тәрбияли.

Шактый олы яшьтә инде Гөлчирә, юанлыгы тагын да картайтып күрсәтә. Әмма туп кебек тәгәрәп кенә йөри, тәмле ашарга ярата, әз генә буш вакыты булса, табын хәстәрли, аш алдыннан бер чакта да аракы эчмичә калмый, бер юлы күп эчми, йотып-йотып кына куя, әмма иртән ачылган шешәсе кичкә бушап кала. Исе таралмасын өчен, өзлексез канәфер суыра. Дус-иш, таныш-белеш дигәндә ул базарның чемпионы, аны белмәгән, ишетмәгән кеше юктыр. Кавказлылар, Урта Азиядән килгән сатучылар гел аның тирәсендә кайнаша. Шәһәр кибетләрендә эшләүчеләр дә кирәктә аның янына баш орып киләләр. Кесәсеннән акча өзелми, бай хатын, эш бетәр алдыннан кәстрүл тутырып ит пешерә. Дус-ишен сыйлый, вакытын жәлләми, аларны сыйлагач кына өенә кайтып китә.

Әнә шундый елгыр, мут хатын кулына килеп эләкте Зәйтүнә. Атнаун көн эчендә Зәйтүнә аңардан эшнең байтак нечкәлекләрен өйрәнеп өлгерде. Гөлчирә белгәнен яшереп тормады, көчле һәм таләпчән тәрбияче булды. Иң беренче чиратта, базар җыемын түләмичә генә сату итәргә өйрәнгән базарчылар белән талашырга өйрәтте. Бу җәһәттән Гөлчирә үз эшенең остасы иде. Качып-посып сату итеп маташканнар аның күләгәсен күрүгә коелып иңәләр. Гөлчирә исә мондый чакта акча гына түгел, тәм дә таба иде! Зәйтүнә дә аңардан калышмаска тырышты, чөнки Гөлчирә остазы телендә бер сүз булды: «Жәлләмә! Жәлләмәскә! Безне жәлләмиләр!»

Юаш кына Зәйтүнәнең тиз арада тә-тә-тә талашырга өйрәнүен күреп, каршы як бу үзгәрешне үзенчә хәл итте, аны кулга иялаштерергә, ана буйсынырга тырышучылар күзгә күренеп артты. Үзенә баш иеп, буйсынып торганны кем ошатмас, Зәйтүнә дә акча тапкан эшеннән тәм таба башлады.

Зәйтүнә беренче көннәрне тотылган талоннарны ялагайлар кулыннан курка-курка гына алды, алган берен Гөлчирә апасына бирә барды. Ә ул талоннарны ике, өч кат сатып акчасын сыйга, аракыга тотты. Эте-

бетенә, вак-төяк тикшерүчеләргә дә аракы эчерделәр. Ил өстендә, базар тирәсендә контроль кешеләренең күплеген күреп Зәйтүнә баштарак гаҗәпләнсә дә, тора-бара күнекте.

— Тормыш шулай бара ул, дустым! — дип кочаклап үпте аны остазы.

Гөлчирә апасы үзә-төтә кыстагач, бер мәртәбә Зәйтүнә дә ярты чәркә аракы йотып караган иде, килешмәде, көне буе укшып, косасы килеп, эче авыртып йөрде. Салкын әйрән эчте, Гөлчирә апасы көне буе рәхәтләнеп көлде ичмасам!

— Башта гына шулай авыр ул! Бер күнеккәч, эчәсе килеп, эч үзе кыткылдап тора!

Гөлчирә кызны тәмам үзерләде, хәзер алар алмашлап эшлиләр. Бер атна тоташтан базарда булсаң, икенчесендә ял итәсең. Икесе дә эшне тигез эшлиләр, планнарын үтиләр, хезмәт хаклары да тигез — аена өч йөз алтмыш сум, әмма тормышлары, көнкүрешләре — җир белән күк арасы.

Ял иткәндә дә Гөлчирә базарга кагыла, андый чакта аны танырлык түгел. Нинди генә киемнәр кими ул! Бар да ефәктән каткан, кыш көннәрендә өстеннән затлы тун төшми, профессор хатыннары да алай киенә алмый торгандыр.

Зәйтүнәне аның өйдәге тормышы бик кызыксындыра иде. Алар базардан ерак түгел генә үз йортлары белән торалар. Кемнәре бар, ничек яшиләр, яхшыдан, яманнан авыз ачып бер сүз әйткәне юк Гөлчирәнең. Зәйтүне читтән-чоттан кыеклатып сорашса, авызын ера, турыдан сорашырга Зәйтүнә кыймый әлегә. Берәр сылтау табып Гөлчирәләргә керәсе килә, җае чыкмый.

Гөлчирә акчаны бик иркен тота, саран түгел, сораган кешегә әҗәткә күпме кирәк — шул кадәр биреп тора. Ниһаять, Зәйтүнәнең Гөлчирә апасына йомышы төште.

Читтән килгән ике кара хатын яшереп кенә йон кофта сатып йөриләр иде. Кофталары Зәйтүнәгә бик ошады. Киеп тә карады. Аңа үлчәп бәйләгәннәр диярсең, таманның тамане! Бәһасе әлләни кыйммәт түгел. Зәйтүнә кофтаны алырга ниятләде. Ләкин янында җитәрлек акчасы юк иде. Гөлчирәдән сорап торса ни булыр? Ул йөгереп Гөлчирәләргә кереп китте.

Аларның өйләре тирә-юньдәге бүтән каралтылардан нык аерылып тора. Биек, тәрәзәләре алагаем зур, түбәсе калай. Ишегалды тыгыз, биек койма белән әйләндерелгән. Койма өстеннән өч рәт чәнечкеле тимер чыбык сузылган.

Зәйтүнә кыңгырау төймәсенә башта курка-курка гына баскан иде, эчтә тавыш-кара ишетелмәгәч, ныграк басарга тотынды. Бераздан ажгырып эт өрә башлады. Капка ачылуга юлга аркылы басып торган бозау хәтле овчарканы күргәч, Зәйтүнә артка чигенде.

— Тими ул, тими! Акыллы ул безнең. Кемнен кем икәнен аера,— дип Гөлчирә Зәйтүнәне култык астыннан үткәреп эчкә кертте, капканы ябар алдыннан, муенын сузып урамга, уңга-сулга карады.

Киң ишегалдын тарайтып бөтен почмакларга тау-тау әрҗәләр өелгән. Әчкелтем-төчкелтем җимеш исе борынны яра. Кавказ, Урта Азия якларыннан килгән базарчылар үз мал-мөлкәтләрен менә кайда тота икән, дип уйлады Зәйтүнә һәм ялгышмады.

— Юк, юк,— диде ашыгып Зәйтүнә, Гөлчирәнең өйгә керергә кыставына каршы.— Керә тормыйм. Йомышым тәҗел!

Гөлчирәнең йөзе ачылып китте. Зәйтүнәнең өйгә керергә теләмәвен ошатты бугай, телгә дә юмартланды. Зәйтүнә сораган акчаны да кызганмыйча чыгарып тоттырды.

— Бу яхшылыгыгызны гомергә онытмам, Гөлчирә апа,— диде Зәйтүнә, башы күккә тиеп.— Мең рәхмәт сезгә!

Аның беренче тапкыр әҗәткә акча алып торуы иде...

Зәйтүнәнең туып-үсеп, кияүгә чыгып йон кофта кигәне булмады. Алуын алды, эченә пошаман төште — өйдә ире бар бит әле. Хәлим ни әйтер? Әүвәл кофтаны Хәлимгә күрсәтмичә торырга уйлады. Ничек тә бер җае чыгар, шунда ризалыгын алыр...

Өйгә кайтып кергәндә, аның шатлыгы эченә сыймый иде. Якын кешедән шатлыкны яшереп булмый икән, яшь хатын шуны аңлады. Хәлим аны күрүгә сизенде.

— Авызың белән кош тотканга охшыйсың әле син,— диде.— Ни булды?

— Берни дә юк,— дип авызын бөрде дә Зәйтүнә пырхылдап көлеп җибәрде — кая ул, малны күрсәтмичә түзәрлекме соң. Хәлимне дә сөендерергә кирәк ич.

— Ачуланмасаң, әйтәм,— диде.

— Ачуланырлык икән — әйтмә.

— Синең шул булыр инде,— диде Зәйтүнә турсаеп.

Вакытны сузар өчен, базардан кайткан сумкасын озаклап бушатты, кофтаны кадерләп иң аска салган иде.

— Үпкәләргә оста икәнсең син! — дип көлемсерәде Хәлим.— Хәзер кылтаерга торасың. Ни булды, әйт, һич ачуланмыйм.

—Мин үземә йон кофта алдым. Бер дә юньле киемем юк. Кеше арасына чыга башласаң, бәла!

— Әй җүләрем, минем җүләрем! Кем ачулансын кием алганга? Бик яхшы булган! Акча ничек юнәттең?

— Әҗәткә алып тордым, акрынлап үзем түләрмен әле.

— Мин түләсәм, ярамыймыни?

— Син болай да акча җиткерә алмыйсың.

— Бары бергә, югы уртак.— Хәлим аны биленнән кочып алды.— Булдырасың инде үзең! Йәле, киеп күрсәт.

Зәйтүнә сумка төбеннән төргәкне җил уйнатып тартып чыгарды. Төргәк берничә кат ялтыравыклы кәгазь белән төрелгән. Кәгазьгә латин хәрефләре белән сүзләр дә язылган икән. «Чит илдән кергән товар!» диде шул кара хатын, андый-мондый гына түгел! «Мондый затлы товар сирәк була, син базарчы булганга гына сатабыз, кайчан исә бер кирәген чыгар!» — дип өстәде кара хатыннарның икенчесе. Үз хезмәте белән эченнән генә мактанып та куйган иде Зәйтүнә.

Төргәкне пычаксыз сүтеп булмады, баш-башын пычак белән кисәргә туры килде. Аның болай серле итеп, кат-кат төрелүе Хәлим күңеленә шик төшерде.

— Син кофтаны киеп карамадыңмыни? — дип сорады.

— Карадым. Киеп караганнан соң төрде ул аны. Күз алдымда.

Төргәк эченнән чыккан, җиңнәре өзелеп төшкән сәләмә кофтаны күргәч, Зәйтүнә коелып инде. Гүя, аяз көнне чартлатып яшен сукты, бөтен әгъзалары электр тогына тоташкан кебек куырылып торды. Бу хәлгә һич ышанасы килмәде, сумка төбен кат-кат актарды.

Аны алганда ул үзе генә түгел иде бит, берничә хатын алдында киеп карады лабаса. Арадан берсе, юантык карасы: «Ал, ал! Затлы әйбер, алган алганда кала, үкенмәссең!» — дип җиңнәрен тарткалап, җилкәсен сыпырып торды. Бу нинди коточкыч алдау?!

Гөлчирә дөрес әйтә икән: «Кеше кешегә — бүре! Хәзер миһербанлы, шәфкатьле җаннар юк. Берәүгә дә ышанма! Миңа да ышанып бетмә, тотармын да алдармын йә!»

Ул яшь бала кебек үксеп елый башлады. Акчасын кызганып түгел, гарьләнүдән елады. Ире алдында хур булды.

— Өзгәләнмә шул хәтле. Баш китәрлек берни булмаган. Исәнлек-саулык кирәк. Әле кофтаның менә дигәнен алырбыз.

Хәлим аны ике битеннән үбеп алды. Аның мәрхәмәтле, олы җанлы булуы Зәйтүнәне тагын да ныграк үксетте, ул елый-елый шешенеп бетте, йокларга яткач та төне буе керфек йомып карамады. Алырга кыстаган

хатыннарның бердәй кап-кара булуларын хәзер генә абайлады. Йокы алмагач, ишегалдына чыгып йөреп карады, барыбер файдасы тимәде. Яткач кына сиздеике йодрыгы да йомарланган иде аның, әгәр теге каралар базарда тагын күренсә... баш түбәләрен чүкер Зәйтүнә, боерган булса. Сынатмас! Алдатмас!

Шушы алданудан соң, Зәйтүнә көнелендә базарда сату итүчеләрнең бөтенесенә бетмәс нәфрәт туды. Кем булуына карамастан, ул аларны рәттән кырыкты. Картмы, яшьме, гарипме, үзенең хәләл хезмәте белән эшләп тапкан әйберен сатамы, урлапмы, аның өчен хәзер барыбер — сатучы. Сатучылар арасында бүре законы хөкем сөрә. Бу ялгыш фикердән ул котыла алмады. Тора-бара заманның, базарның, шулардан оста файдаланган Гөлчирәләрнең гамәлләрен аңлады аңлавын. Ләкин хәзергә аны бу фикереннән бернинди юл белән дә айнытырга мөмкин түгел иде.

Зәйтүнә көпә-көндез алдануы турында беркемгә дә сөйләмәде. Хәлимен дә кисәтеп куйды.

— Кеше арасында мине көлкегә калдыра күрмә! — диде.

Үзең базарда эшләп, кемнең кем икәнен таный торып, юньләп урысча да белмәгән кавказлы кәкре аяклар сине карачкы көленә утыртып китсеннәр инде! Ул андый жуликларны бер чакрымнан танып алырга тиеш! Гөлчирә апасы болай ди: адәмнәрнең яртысы жулик, икенче яртысы жуликлыкка әзерләнә торганнары!

Гарьләнде Зәйтүнә, нигә базарга эшкә кердем икән? — дигән көнгә төште. Хәзер аңа бу эштән китү дә мөмкин түгел, Гөлчирәдән алган бурычы бар, аны алдаганнар икән, ул да моннан ары йоклап йөрмәс!

Хәзер Зәйтүнә җыем талоннарын, товарларын сатып бетергәч, кире китерүчеләргә елмаеп, рәхмәт әйтеп карый, кергән акчаны да Гөлчирә кесәсенә шудырмый, үз калтасына агыза. Инде эшләр көйләнә, инде бурычтан котылам, дигәндә генә Зәйтүнә башына тагын бер тукмак төште.

Көтмәгәндә райбашкармадан тикшерү килде. Тикшерүне районың өлкән инспекторы Юныс Гыйльметдинов оештырды. Зәйтүнәнең, сарык бәрәненең, усал ерткыч бүре белән беренче очрашуы иде бу.

Алар, алты кеше оешып, сәүдәнең иң кызган чагында, Зәйтүнәгә сиздермичә генә, базар рәтләрен йөреп, сорашып чыкканнар. Берничә рәттә бер сату итүче дә ул көнне җыем талоны алмаган иде әле. Нәфес дигән нәрсә уянса, чикне белми, көннән-көн котыра бара. Зәйтүнә ул рәтләрдән, эш бетерер алдыннан гына, талон биреп тормыйча акча җыеп, үз кесәсенә шудырырга уйлаган иде. Инде берничә көн шулай эшләгән иде дә ул. Чаманы белмәсәң, эләгәсеңне көт тә тор икән! Йокыдан торып, иәңгә сул аягы белән басуга күз кабагы тартышкан иде Зәйтүнәнең, күрәчәгенә икән.

Төрле сәбәп тапкан булып, Зәйтүнә акланырга тырышып карады, барып чыкмады, тикшерүчеләр тиз генә чытырдатып акт төзеделәр дә кул куйдырдылар.

Көн уртасында Зәйтүнәне директор кабинетына чакырттылар. Эшнең уен түгел икәнен Зәйтүнә директорның көзгә төн кебек кара чыраена күзе төшү белән аңлады. Аның кашы-күзе җимерелгән, идән буйлап читлектәге арслан кебек марш атлап йөри. Зәйтүнә кергәч өстәл уртасында җәелеп яткан актны кулына алды да, иң әүвәл, тозлап-борычлап хәтәр итеп сүгенде, аннары:

— Хәзер үк Юныс Гыйльметдиновичны эзләп тап, икенче акт төзләр. Әгәр кушканны эшләмәсәң, мин сине иртәгә эштән куам! Болай гына кумыйм, кулыңа кәҗә билеты тоттырып чыгарам! Йөр аннары эш эзләп! Бер кайда да эшкә алмаслар, белеп тор. Хурлык! Позор!

Зәйтүнә телсез калды. Ничек итеп Юныс Гыйльметдинович — өлкән инспектор — икенче акт төзесен?! Каян эзләп табып була аны? Кәҗә билеты дигәннәре нәрсә?!

Аның бер минут тормыйча авылга, әнисе янына кайтып китәсе килде... Кайтыр да иде... ә ире? Хәлимнең җан тирләре түгеп салып яткан йорты? Укыйм барыбер, дигән өметләре? Болар барысы да киселәме?!

Директор яныннан чыккач, аулакта посып утырып, бик озак балавыз сыкты Зәйтүнә. Нишләргә? Кемгә барып егылырга? Һай, нәфес! Адәм балаларын нинди хәлләргә генә төшермисең икән син?!

Башын кая куярга белмичә авыр уйларга чумып утырганда, аның янына Гөлчирә килеп басты. Коткаручы фәрештәме әллә ул?!

Гөлчирә аның кызарган куян күзләренә карап торды-торды да:

— Шулкадәр комсыз булалармы? Берәүгә дә талон бирмәгән идеңмени соң? — дип сорады.

Бу сүзләргә Зәйтүнә соң дәрәҗәдә гаҗәпләнде. Тикшерүчеләр килгәндә, Гөлчирә юк иде, үз хәлен ул беркемгә дә сөйләмәде, каян белеп бетергән бу чая хатын базар хәлләрен?!

Гөлчирә үз соравына җавап көтеп тормады, директор әйткән фикерне кабатлап, Зәйтүнәне ашыктырырга тотынды.

— Ничек итеп булса да, Юнысны көйләргә кирәк, юкса эшең харап.— Юныс егет кеше. Батыра торган гадәте юк. Көйләсәң, көйләнми торган ир буламы бу заманда?

— Мин аны беренче тапкыр күрдем, таныган кешем түгел. Авылдашмы ул миңа, кардәшме?

— Җайласаң — бөтен кеше сиңа авылдаш, майласаң — бөтен кеше сиңа кардәш. Йоклама! Бар, тиз үк аракыга йөгер. Хәзер үзен монда, ларекка алып керәм. Бераз сыйлангач, кесәсенә почмак акча тыгарсың.— Бераз уйлап торды да:— Почмакны азсыныр, кызганма, илле сум ит,— дип өстәде.

Шушы көнгә кадәр Зәйтүнәнең үз кулы белән аракы сатып алганы юк иде, башыңа төшкәч, аласың икән, кибеткә барырга туры килә, ят ирләр арасына.

Ул йөзен ертып кибеттән кайтканда, Гөлчирә белән Юныс ларекта икәүдән-икәү генә утыралар иде. Тик утырмаганнар ахрысы, йөзләре килгән, көлешәләр. Сменасы булмаса да, Гөлчирә эшкә дә керешкән, базар җыемы талоннары сата. Үлчәүләр бирә. Ни арада өлгергәндер, базар рәтләре арасына чыгып җилкенеп тә кергән икән. Бер Юныска, бер Зәйтүнәгә карап мактанып та алды.

— Тикшерсеннәр әнә! Түләмәгән берәр сатучыны табарлармы?— һәммәсеннән каерып алдым!

Юныс аның симез аркасына шапылдатып сукты.

— Безнең Гөлчирәме? Безнең Гөлчирә ул!..

Акт төзегән кансыз Юныс юк иде хәзер, ул үзгәргән, танырлык түгел. Гомумән, Гөлчирә белән Юнысның үзләрен тотышы Зәйтүнәгә сәер тоелды. Алар бер дә тартынып тормыйлар, ялт кына кочаклашып та алалар, әллә иреннәре иренгә тиеп тә китә инде. Юныс Гөлчирәнең текә күкрәгенә дә үрелә, тегесе дәшмичә авызын ерып карап тора. Зәйтүнә, ниһаять, аңлады: болар гади танышлар гына түгел!

Һәм Зәйтүнә чынлыктан бер дә ерак түгел иде. Гөлчирә сугыш беткән елда Себер ягыннан кайткан бер иргә капыл-копыл гына кияүгә чыкты. Молдовадан эвакуацияләнгән Мандрус Лейб Моисеевич белән никахлашмасалар да, алар тату гына яши башладылар. Инде шактый вакыт бергә торалар, әмма бала-чагалары юк, Мандрусның элекке хатынында бер кызы, бер улы бар. Алар Себер ягында әниләре белән калганнар. Җәй көннәрендә Казанга, әтиләре янына кайтып китәләр. Гөлчирә тарсынмый, көнләшми, аларны ачык чырай, такта чәй белән кабул итә. Тиешле тәрбиясен дә күрсәтә. Мандрус, чит хатынның улы белән кызын үлеп яратуын күреп, куанып бетә алмый.

Таныш-белешләре, аралашкан кешеләр аны Леша дип йөртәләр, күпчелек аның чын исемен дә, фамилиясен дә, каян килеп, ничек урнашуын да белми. Бүтәннәргә ияреп, Гөлчирә дә аңа Леша дип кенә дәшә.

Җиңел дә, телгә дә рәхәт. Гөлчирә күпне күргән карт диярлек яһүд белән кушылгач, аның исеме тирәсендә йөргән гайбәтләр тагын да куерды. Ул шәһәр читендә бер карчыкта фатирда тора иде. Бөтен кешене гаҗәпкә калдырып, шул йортны сатып алды Гөлчирә. Элгәре бу йортта шәһәрнең бик бай, үтә атаклы адвокаты яшәгән. Адвокат кинәт вафат булгач, аның гомер-гомергә беркайда да эшләмәгән елак вә иркә хатыны, ашык-пошык йорт җирен ярты бәясенә сатып, Мәскәүгә, генералда кияүдәге кызына күчеп киткән.

Бай хуҗадан калып, кулдан-кулга күчкән хәтәр йортны базарда эшләүче тол хатын сатып алсын әле! Йорт — урамында бер! Янында зуп-зур бакчасы бар, алма-чия үсә, төрле җиләк-җимеш, әйтеп бетерә торган түгел. Ялгыз хатын каян акча юнәтеп шушы байлыкка ия була алган соң? Бу гаҗәп хәлнең төбенә төшәргә дә өлгермәделәр, йорт сатып алуына ярты ел да үтмәде, Гөлчирә чит-ят ирне йортка кертте. Каян, ничек иснәшеп өлгергәннәрдер — монысы томан эчендә иде.

Мандрусны ат белән йөк ташучы итеп базарга Гөлчирә урнаштырды. Яһүдләр бай халык, акча табарга оста адәмнәр, мөгаен, йортны Мандрус акчасына алганнардыр, дигән сүзләр йөрде. Алай гына да түгел, Гөлчирә яһүд диненә күчкән икән, алар ирле-хатынлы төнлә кычкырып яһүди китаплар укыйлар икән, дип тә сөйләделәр. Күпләрнең башына шик төште, ай-һай, яһүди ир үз акчасына алынса, йортны Гөлчирә исеменә яздырыр идеме икән, диештеләр. Гайбәтләргә чик тиз куелды. Гөлчирә, шәһәрдә үзе белгән абыстайларны җыеп, бик зурлап коръән укытты, акча кызганмады, сәдакәне мулдан өләште. Абыстайлар да бурычлы калмадылар, елый-елый дога кылдылар, изге теләкләрен җиткерделәр. Гөлчирәнең вакытсыз үлгән ата-анасы, читкә чәчелгән туганнары белән рәттән, Лешаның Молдовада фашистлар үтергән туганТумачасын да искә алдылар. Кемнең кайсы дингә күчүе турындагы сүзләр шунда киселде.

Леша базар атын җигеп, шәбәеп кенә йөри башлады. Озын итәкле киемнәрен салып ташлады, бик җилле сырма сатып алды. Сакал-мыегын да татарлар төсле итеп кыскартты.

Базар таралгач, көн дә берничә олау чүп җыела. Вакытында Бакалтайга төшереп түкмәсәң, кирәгеңне бирәселәрен көт тә тор, санэпидстанциядән базарга махсус беркетелгән врач хәзер чәчрәп килеп җитә. Чүп түгелмәгән көннәрдә врачның сумкасын шыплап тутырып озаталар. Ит-май да эләгә аңа, врач катык-сөттән дә йөз чөерми, каймакны да бик ярата.

Гөлчирә сатып алган йорт хуҗасы адвокат элгәрге заманда үзе дә ат тоткан булса кирәк. Ишегалдында бүрәнәдән салынган, җылытып эшләнгән ат абзары да бар иде. Соңгы елларда йортта дүрт аяклы мал асрамасалар да, абзарны сүтмәгәннәр, бөтен килеш саклаганнар. Базар аты шушы абзарга күчте. Леша, абзарына аренда хакы алмыйча, атны үзе карарга риза булды. Ризалашырга аны Гөлчирә өйрәтеп куйган иде.

Атка базардан чүп түгүдән бүтән эш юк, Леша ул эшне коры тота, юырттырып Бакалтайга өч-дүрт тапкыр барып кайта да туп-туры вокзалга юнәлә. Шәһәргә ит, бәрәңге, җимеш-яшелчә сатырга килүчеләр дүрт күз белән көтеп торалар. Җәй көннәрендә Леша пристаньга да барып чыга. Аның ныклы расписаниесе бар, үз клиентлары җитәрлек, тора-бара якын әшнәләре дә була башлады. Сатырга төрле юллар белән китерелгән товарны базарга илтергә җитәрлек транспорт шәһәрдә юк иде әле.

Леша күбрәк Кавказ, Урта Азия кешеләре белән эш итәргә ярата. Бер танышып, әшнәләшеп киткәч, ул аларның склад мөдире дә булып китте. Кичләрен килеп төшсәләр, әрҗә-әрҗә җимешләрне, капчык-капчык чикләвекләрне үз ишегалдына алып кайтып бушата. Бу очракта акыллы яһүд икеләтә файда күрә. Алып кайткан өчен генә түгел, саклаган

өчен дә түлиләр. Өйләренең базарга терәлеп үк торуы — хуҗалар өчен чат файда.

Гөлчирәнең киң ишегалды үзенә күрә бер базага әйләнде. Ул заманда дәүләтнең сәүдә оешмалары базаларында да мондагы кебек җиләк-җимеш сакланмагандыр. Күнче күршеләр бу хәлгә түзеп тора алмадылар, әлбәттә, төрле оешмаларга имзасыз хатлар язарга тотындылар. Ләкин хәйләкәр яһүд эшне тиз юллады, ишегалдын вакытлыча арендага биреп тору законда каралган икән, ул, финанс органнарыннан язу алып кайтып, күнчеләрнең авызын каплады. Алган доходыннан тиешле налогны берчакта да түләмичә калдырмады эшлекле яһүд. Санитария нормаларын да җентекләп күзәтте. Гөлчирә иренең ни эшкә тотынса, шуны башкарып чыгаруын күреп куанды, хәйләгә, кеше белән аралашуга күп нәрсәне аннан өйрәнде.

Район финанс бүлегенә имзасыз хат килде. Өлкән налог инспекторы Юныс Гыйльметдинов исеменә язылган хатта коточкыч хәбәрләр теркәлгән иде. Юныс хатны алуга ышанырга да, ышанмаска да белмәде. Ачу, үчлек белән язалардыр, дип әйтер идең, фактлар күзгә кереп, чәчрәп тора. «Көч түкмичә, кыл да кыймылдатмыйча, ходаның һәр бирмеш көнендә кесәгә биш йөз тәңкәне салып яшәүче күселәр дә бар безнең арада»,— диелгән иде анда.

Хат имзасыз булса да хәбәрләрне урынга барып тикшермичә ярамый. Гадәттә райфога кергән һәрбер кәгазь аерым кенәгәгә теркәлә. Теркәлгән кәгазьләрнең тикшерү срогы да билгеләнгән. Югары финанс органнары ревизорлары иң башлап шул кенәгәне сорап алалар. Бу юлы Гөлчирә өстеннән язылган хат Юныс өстәлендә ятты, ул аны теркәргә дә, барып тикшерергә дә ашыкмады. Ни сәбәпле шулай булуын үзе дә аңлатып бирә алмас иде, мөгаен. Ниһаять, вакытын үзгәртеп акт төзеп кайтырга уйлап, Юныс юлга чыкты.

Юныс килгәндә, хатта телгә алынган өйдә Гөлчирә үзе генә иде. Ул аны күтәреп алгандай итте.

— Нинди шәфкать җилләре безнен түргә затлы кунакны китерде! Үзем чакырып алырга читенсенеп йөри идем, Юныс Гыйльметдинович, килүегез үтә дә шәп булган! — диде.

— Сез бу йортта нишләп йөрисез? — диде Юныс соң чиктә гаҗәпләнеп. Алар бер-берсе белән базар аша байтактан таныш булсалар да, Юныс моңарчы Гөлчирәнең шәхси тормышы белән кызыксынмады, аны базарда эшләп йөрүче, күзгә әлләни чалынмый торган гади хатын итеп саный иде, фамилиясен дә белми, мондый затлы йортта бай хатын булып яшәп ятуын да күз алдына китерми иде.

Гөлчирә сорауга җавап биреп тормады, кунакны өйгә керергә кыстады, Юныс исә керергә артык ашыкмады. Тау кадәр өелгән капчыклар, әрҗәләр янына барып туктап калды.

— Болар кемнеке? Сезнең ишегалдында берәр сәүдә оешмасының базасы, дисәм, нигә мин белмим аны?

— Һәммәсе җүләрем Леша эше инде. Кеше күңелен күрәм, дип, Каф тау артыннан, чүлләр түреннән килгән җисен әтрәк-әләм бичараны ул җыеп ята. Уйнап кына тотынган иде, хәзер базарчылар муенына менеп атландылар тегенең. И сүгәм беркатлы ахмакны, ишегалдында борылыр җир дә калмады, дип зарланам. Иртәгәдән бөтенесен куып чыгарам, алла боерса.

— Кем соң ул Леша?

— Кем, дип... ирем, дисәм...

— Кемең, кемең?

— Син сорама, Юныс, мин әйтмим. Ир кисәге инде шунда. Син аны беләсең, бездә бар ич бер сүрәбәт, ат белән йөк ташый...

— Һем,— диде Юныс серле итеп.— Йорт кемнеке?

— Икебезнеке дә. Уртак мал. И, Юныс җаныем, уртак малны эт җыймас, диләр, хак икән. Җык күрәм инде шул тиле-миле белән.

Ул арада зур капканы хуҗаларча ачып ишегалдына бәләкәй арба тарткан өч ир килеп керде. Өсләрендә керле чапан, аякларында кыршылган читек-кәвеш, берсе нәзек кара мыек җибәргән, өчесе тиң гипсә тимер өзәрлек таза егетләр. Алар уртада басып торган Юныс белән Гөлчирәгә әйләнеп тә карамадылар, арбаларына әрҗә төяргә тотындылар.

Капкадан чыкканда Юныс аларның юлына аркылы төште.

— Стоп! Бераз сабыр итегез.

— Сез кем буласыз!?

Юныс эре кыланып, куен кесәсеннән куе кызыл катыргыны чыгарып күрсәтте.

— Бу әрҗәләрне монда тоткан өчен күпме түлисез?

Тегеләр бер-берсенә карашып тынып калдылар. Ниһаять, байтак уйланып торгач, мыеклы телгә килде.

— Хуҗабикәдән сорагыз, без белмибез.

— Күпме түләвегезне минем сезнең үзегездән ишетәсем килә.

Капка төбенә чәчрәп Гөлчирә килеп җитте.

— Нинди түләү? Бер тиен түләмиләр! Чәй эчәргә кара җимеш биреләр. Шулай бит, юлдашлар?

Юныс монда ачыктан-ачык сөйләшеп булмаслыгын тиз аңлады.

— Бирегез әле паспортларыгызны,— диде ул җимеш хуҗаларына.

Берсенең дә паспорты юк икән, тору урыннарыннан бирелгән, үзбәкчә-урысча бутап язылган, пычранып-майланып беткән белешмәләре генә бар. Юныс белешмәләрне папкасына тыкты да китәргә җыенды.

— Иртәгә тугызда өчегез дә райфога килегез, шунда аңлашырбыз.

Ул капкадан чыгып ун метр да китмәде, үзбәкләрнең берсе аны куып җитте.

— Юлдаш, шашмаңыз, шашмаңыз, бер гәп бар, керик әле,— диде.

— Иртәгә райфода сөйләшербез. Гәбе шунда булыр, бүген вакытым юк.

Юныс сату итәргә килгән үзбәкләр кулындагы белешмәне алырга хакы юклыгын бик әйбәт белә, бу эш законга сыймый, бу, юристлар телендә, вазифаңны үтәгәндә законда каралган хокукны арттыру, дип атала. Мондый эш өчен җинаятьләр кодексында махсус статья бар... Ләкин ертлач бүре законда каралган андый тыюларның берчакта да чынбарлыкта үтәлмәгәнен бик шәп белә. Вак-төяк закон бозулар өчен аны — райфоның өлкән инспекторын берчакта да җәзага тартачак түгелләр. Чикләнмәгән аның хокуклары. Күпне күргән базарчы үзбәкләр дә иртәгә райфога барып йөрмәячәк, аларның чапан кесәләре төбендә кульяулыкка төрелгән шундый ук белешмәләре юк дип кем әйтә ала?

Ә болай әлегә ул хаклы, киртәсенә керсә — ярый. Дөресме аның гамәле, хатамы, налог суммасы гына күбрәк булсын, югары финанс оешмалары бары тик шуны кайгыртачак, күпләп налог чыганагы эзләп тапканы өчен, аны мактаячаклар гына! Акча кирәк, акча!

Ул үзбәк белән тарткалашып торган арада капка төбенә атлы арба килеп туктады. Гөлчирә аны борып та җибәрмәкче иде бугай, олаучы китмәде, Юныс, йөгереп барып, атның тезгененнән тотты.

— Җибәр, иптәш Гыйльметдинов, атны тотма. Мин беркая да китмим. Без дә ак белән караны аера беләбез.

Бу Мандрус иде.

## VII

Ул татарча чибәр генә сукалый икән. Вокзалдан җиләк-җимеш төяп кайткан. Товар хуҗалары күренми, олауда ялгызы, базарчылар артта калганнармы, Юнысны абайлап як-якка тайдылармы шунда.

Мандрус озын буйлы, киң җилкәле, күрәк куллы тап-таза ир икән. Яше кырыклар тирәсендә генә булса да, башы тап-такыр, тирләгән битен

картузы белән сөртә башлаган иде, дөнья яктырып китте. Өстендә плащ палатканы бозып теккән киң кожан, аягында төсе чыккан кирза итекләр. Ул нишләргә белмичә аптырап басып торган үзбәкләргә үз телләрендә нидер әйткән иде, тегеләр арбаларын өстерәп, тиз генә китеп бардылар.

Бу кеше белән шаярырга ярамас, дип уйлап алды Юныс.

— Сез ничә тел беләсез?

Мандрус серле генә елмайды да:

— Үземә кирәкләрен әз-мәз җырмачлыйм,— диде.

Мандрус атны Гөлчирәгә тапшырды да кыстый-кыстый Юнысны өйгә алып керде. Юнысның үзбәкләргә чыккан ачуы басылды, ул юашланып, сабырланып калды. Мандрусның чем кара күзләре аны үтәли тишәрдәй булып капшыйлар, өйрәнәләр иде.

Алар залга уздылар. Зал җиһелгән Германиядән кайткан затлы җиһазлар белән туп-тулы. Диварларда кыйммәтле келәмнәр, идәннән түшәмгә кадәр рамлы көзгеләр эленгән, аяк астына күз явын алырлык палас җәелгән.

— Мин сезне беләм, сез өлкән инспектор Юныс Гыйльметдинов,— диде ихлас елмаеп Леша.— Белә идем һәм көтә дә идем. Нишләп килми икән, дип гаҗәпләнә дә идем.

— Сез әллә миннән көлмәкче буласыз инде?..

— Андый гадәтем юк, тик дөресне генә әйтәм.

«Сөйләтерсең синнән дөресне! Беренче сүздән үк башны түңкәйтергә чамалыйсың. Түңкәйтми тор, тот капчыгыңны! Юныс абзаң синнән шәбрәкләрне дә күп күргән!» Өлкән инспектор, Лешаның һәр ымын шик астына алып, шулай уйлады.

— Безне көтеп тормаска, доходыгыз турында райфога тулы декларация китерергә иде.

— Налогларны вакытында түләп барам.

— Сез доход налогы турындагы Указның утыз өченче статьясы белән таныштырсыз, дип уйлыйм.

— Юк, ул яктан мин шыр надан диярлек.

— Доходыгызны яшергән өчен җавапка тартылгач, һәммәсен белә башларсыз.

Лешаның гадәттән тыш тынычлыгы Юнысны гаҗәпләндерде.

— Сез беренче сүздән яный, куркыта башлыйсыз икән! Фикерләрне уртак итеп, яхшылап сөйләшсәк, арурак булмасмы? Нигә тора салып бер-беребезнең башын әйләндерергә? Дусларча сорашсагыз, һичнәрсәне яшермәм, әйтеп бирермен.

Атны туарып, эшне бетереп, Гөлчирә керде. Ул, залның ишеген ачып, бусагада тын гына басып торды да, эчкә узып, йомшак канәфигә утырды. Юныс папкасыннан чиста бланклар чыгарып акт төзергә тотынды. Ул Мандрусның паспортын сорады.

— Юк инде, хөрмәтле иптәш!— дип көлде Леша.— Мине бутама! Бу йортта мин батрак кына, ялчы и вәссәлам! Дәхелем юк, барысына әнә ул хуҗа!— Ул Гөлчирәгә төртеп күрсәтте.— Йортның бөтен документлары Гөлчирә Шәйхетдинова исеменә оформить ителгән. Шулай булгач, акт та аның исеменә язылырга тиеш.

Гөлчирә сервант тартмасыннан алып, паспортын сүзсез генә Юныска тоттырды. Юныс бик кызыксынып, паспорттагы мәгълүматларны кат-кат күзеннән үткәрде. Алар кордашлар икән...

— Бик кызыксындыгыз,— диде Гөлчирә уенчак тавыш белән,— әллә бер-бер гаеп бармы?

Юныс аның соравын җавапсыз калдырды, бик тырышып акт бланкысын тутыра башлады.

— Нигә паспортта сезнең атагызның исеме күрсәтелмәгән?

— Җилдән туганмын. Шуңа күрә күрсәтелмәгән.— Үз сүзләреннән тәм табып, түшәмне күтәрерлек итеп, Гөлчирә көлеп җибәрде. Аннары, житди кыяфәткә кереп, сүзен дәвам итте.— Авыл кызы мин. Авылда элек

ничек иде? Әти исемен сорап тинтерәтмиләр иде, кушаматың булса, шул бик житкән. Әтүтәннекеләр, диләр безне. Паспортка шуны язсыннармы?

Кәгазьгә күчереп бетергәч, Юныс паспортны Гөлчирәгә кайтарды.

— Йә, хәзер тәгәлен генә әйтегез инде, ишегалдыгызны арендага биреп торган өчен күпме доход аласыз?

Гөлчирә, Мандруска текәлеп, ни әйтергә белмичә югалып калды.

— Сезгә нинди доход кирәк? Күнлекме, айлыкмы? — диде Леша, тотлыкмыйча гына.

Юнысның кашлары жыерылды.

— Сез дәшмәгез. Катышмагыз да. Мин хатыныгыз белән сөйләшәм.

— Доходта хатынның катнашы юк, акчаны мин алам.

Юныс кычкырып жибәрде.

— Нигә минем башны әйләндерәсез алай булгач?!

— Йорт хатынныкы, иптәш Гыйльметдинов. Ишегалдын арендага ул биреп тора. Аренда хакын миңа түләсәләр дә, йорт аныкы булгач, акт аның исеменә язылырга тиеш, минемчә.

Мандрус законның бөтен нечкәлекләрен белеп, аңлы рәвештә актны Гөлчирә исеменә яздыра иде. Ул тыелган кәсеп белән шөгыльләнә, базар атын үз файдасына жигеп йөри. Дәүләт аты белән сулагайга йөреп керем алу, гамәлдәге закон белән катгый тыела һәм гаепле кеше жинаять жаваплылыгына тартылырга тиеш. Бетте — китте.

Юныс аның тел төбен тиз аңлады.

— Сез, аренда доходын Гөлчирә Шәйхетдинова исеменә яздырып, үзегезнең тыелган кәсебегезне яшереп калдырырга телисезме? Барып чыкмас, Мандрус. Аттан кергән доход турында сүз аерым булыр, онытмыйк. Хәзергә сез төгәл генә итеп ишегалды арендасыннан кергән сумманы әйтеп бирегез.Borгаланмагыз!

— Ат белән эшләү турында сүз өстәмә булыр, дисез икән...— Мандрус бераз уйланып утырды, елмаеп куйды.— Ана барып житкәч, күз күрер тагын,— диде тыныч тавыш белән. Аннары Гөлчирәгә:— Галя, авызыңны йомып утырма, яздыр! Уртача исәпләгәндә, көненә бер йөз чамасы чыга торгандыр бит? Шуның яртысыннан без налог түләп тә киләбез! Бүгеннән йөз тәңкәдән түли башларбыз, әйдә, китсә — безнеке китсен!

— Языгыз шулай, Юныс Гыйльметдинович, Леша дөрес әйтә. Бервакытта да йөз сумнан артык акча кергәне юк.

Юнысның башы әйләнеп китте. Ә хатта: «Көненә бишәр йөз сум алалар!» — диелгән иде. Йөз сум да зур сумма! Бик зур!

Ул елларда шәхси йортлар халык белән кырмыска оясы кебек мыжлап торалар иде. Һәрбер хужа фатирчы тота, ишегалдын кемгәдер арендага биреп тора. Уку йортларында тулай тораклар юк дәрәжәсендә иде. Күпсанлы студентлар, завод-фабрикаларга килеп урнашкан авыл яшьләре, шәһәр кунаклары шәхси йортларда фатирчы булып торалар иде. Кечкенә генә бүлмәләрдә унар-унбишәр кеше яши. Караватсаен икешәр студент, баш төртергә урын булса — шуңа канәгать алар.

Күпме хужалар белән алыш-биреш иткән Юныс, көненә йөз сум алабыз, дип икърар итүләрен хәтерләми.

Юныс актны кул куйдырып, папкасына тыкты да, китәргә кузгалды.

— Ат белән эшләвегез хакында әлегә сүз кузгатмыйм, сезне базар директоры белән бергәләп райфога чакырырга туры килер. Директорда да гаеп бар, ул да жавабын бирер!

— Чакыртасы юк, мин бүген үк атны базар конторасы янына илтеп бәйлим. Теләсә кая куйсыннар! Кат-кат ялынгач кына үземдә тотарга ризалашкан идем. Асрар урыннары юк.

Леша Гөлчирәгә нидер ишарәләде, сүзгә мавыккан, жиңү тантанасыннан исергән Юныс аның чыгып киткәнен абайламыйча да калды. Мандрус, жиңеләеп, юк-барны такылдарга тотынды, аягүрә баскан Юнысның юлына аркылы төште.

— Килгән-килгәч, безнең өйне дә күреп китегез инде, Юныс Гыйльметдинович,— дип, сул як ишеккә күрсәтте.

Житез Гөлчирә анда табын хәстәрен күреп тә өлгергән икән. Юныс табындагы ризыкларны күргәч, артка чигенде, Мандрус аның иңенә жылы, әмма каты кулын салды.

— Татарлар, аштан олы булырга ярамый, диләр. Килгән кунак бездән ризык татымыйча китми.

Ул, бизәкле коньяк шешәсенең бөкесен оста гына суырып чыгарып, бәллүр чәркәләргә эчемлек агызды.

— Гаепләштән булмасын, күп түгел, бар булганы бер тавык та, бер савыт. Ике ирнең тамак төбен юарлык кына!

Юныс икеләнә калды — сыйдан авыз итәргәме, юкмы? Эчсәң ни булыр? Әллә эчеп куяргамы? Иң әһәмиятлесе — керем дөрес исәпләнде. Өч йөз алтмыш биш көнгә йөзәр сумнан дәүләт файдасына утыз алтмыш биш йөз сум акча. Күзгә күренерлек керем! Ишегалдын арендага биреп торачак һәр йолкыштан шул кадәр каерсалар, Юныснын түшенә ел саен орден тагарлар иде! Буласы булган, акт кесәдә, тот, алдарсын Юнысны!

Бер рюмка эчкәч, Юныснын шиге кимеде, икенче эчкәч бөтенләй юкка чыкты. «Моның белән эш йөртергә була! — дип уйлады ул, Мандруска астан гына карап.— Шома күренә!»

Мандрус та аның уйларын сизгәндәй:

— Сез миңа ошап киттегез әле! — диде.— Дөньяны күп күргәнсездер, дип беләм.

Безнең заманда дөнья күрмәгән кеше бармы?

— Дөнья күрү — эшнең яртысы гына. Дөнья күреп тә тормышны аңламаган тинтәкләр күп!

— Килешәм,— дип сузды Юныс тавык ботын чәйни-чәйни.— Тормышны аңлау өчен акыл кирәк. Ә менә анысы күпчелектә юк.

Юныснын ике чәркәдән үк теле ачылып китүе Лешага ошады, алай да ул сак булырга тырышты. Кемне-кемне, Лешаны саклыкка өйрәтәсе юк, тәжрибәсе житәрлек.

Бер савыт белән бер тавык юкка да чыкты. Гөлчирә тагын бер коньяк шешәсен, тагын да затлырагын, тагын да кыйбатлырагын өстәлгә куйды. Ләкин бу юлы Юныс сыйдан баш тартты, эчмәде дә, ризык та капмады.

— Кадерле Юныс Гыйльметдинович,— дип сүз башлады Мандрус, моңарчы ишетелмәгән төче тавыш чыгарып,— әйтә алмассызмы, беренче взнос күпме булыр икән? Әзер торырга кирәк, сәгате суккач, сәмән эзләп йөрерлек булмасын.

— Күбрәк әзерләгез! — Юныс көлеп жибәрде.— Күп әзерләсәгез, ялгышмассыз.

— Алай да?

— Болай әйтүе кыен, үзем белән доход налогынын таблицасын алмаган идем.

Хужа көрсенеп куйды.

— Дәүләтнең тишеге киң. Миннән кергән юк-бар акча белән тула торган түгел.

— Тамчылап туплана дәүләт акчасы, тамчылап! Ишетә торгансыздыр, көн дә хәбәр итеп торалар. Идел буенда, Ерак Себердә нинди гигант төзелешләр башлап жибәрделәр. Империалистлар азына, ил чикләрен хәрби базалар белән урап алдылар. Хөкүмәткә акча кирәк.

— Үзебез турында онытып жибәрмибезме, Юныс туган? Дөньяда бер яшибез. Гомер ай-һай тиз уза.

Мандрус татарчалап, матур итеп «туган» дип эндәште. Шулай да Юныс сагая төште, хужаның кай якка каерганын аңлый иде ул.

— Моның белән ни әйтергә телисез? — дип сораган булды.

— Нигә мин түләсе акчадан үзегезгә өлеш чыгармаска? — диде Мандрус турыдан-туры. Бер шешә коньякның башына житкәч кунак белән

ачылып сөйләшсәң дә ярый, дип исәпләде.— Бөтенләе белән алсагыз да, хәрәм түгел.

— Сез мине кем дип беләсез?!

Юныс ачуланган булып сикереп үк торды. Бу сүзләргә Мандрусның мыегы да селкенмәде. Ул Юнысны үтәли күрә башлаган иде инде, үз-үзенә ышанып тагын да ныграк басым ясарга тотынды.

— Акчаны кемгә түләсәм дә, миңа барыбер. Җилкәм калын, кесәм буш түгел. Күпме китерсәгез, шул кадәр түлим. Нигә сәрмаяны җилгә җибәрергә? Нигә яхшы кешедән кызганырга аны?

Сүз шактый озынга сузылды, Юныс Мандрусның тәкъдименнән катгый баш тартты, күңеленнән генә сабыр итәргә карар кылды. Алгач-алгач, күбрәк каерырга, юк-бар белән пычранмаска кирәк, дип уйлады.

Ул Мандруска налог исәпләргә ашыкмады, актны эш өстәленең аулак тартмасына тыгып куйды. Хуҗаның тәкъдиме аны иләс-миләс итте. Кесәгә килеп кергән акчадан ансат кына ваз кичәргәме? Көнөнә йөз тәңкә керемем бар, дип чатнатып торучыларны күргәне юк иде аның моңарчы. Хатта язылганча, биш йөзне каеруы да бик ихтимал. Шуны күздә тотып, ул хуҗалар алдында хат турында ләм-мим сүз чыгармады.

Налогны бөтенләй үк бетерергә ярамый, әлбәттә. Калсын искечә, илле сумнан түли барсыннар. Ә калган илле сумын ала башласа, елына күпме җыела икән? Ат җигеп үз файдасына эшләп йөргәнен ачарга кирәк булыр! Димәк, ул үз тарафыннан барлык чараларны күргән булып саналачак.

Төрле яктан уйлап, төрле тарафтан исәпләгәч, ул актны яңадан язарга, дигән фикергә килде һәм Мандрусларга тагын барырга булды.

## VIII

Ул икенче килгәндә, Мандрус эштә, Гөлчирә бер ялгызы иде. Юнысны балкып каршы алды.

— Леша юк дип өйгә керми китәләрме? Әйдә, әйдә, монда мин хуҗа, аңардан башка эшне хәл итә алмабызмы?

Ул Юнысны култыклап алып, көчләп диярлек өйгә өстерәде.

— Һай, өс-башым аламә, кеше күзенә күренерлек түгел. Хәзер алмаштырып чыгам! — дип янәшә бүлмәгә кереп йомылды.

Шактый юанды ул анда, нидер идәнгә шапылдап төште, урындыкмы, өстәлме урыныннан күчте. Гөлчирә килеп чыккач, Юныс аны танымыйча торды. Иңенә салган ефәк халатының итәге идәнгә тия язган, җиңел, юка халат аша тәне үтәли күренә. Кыска кара толымнары таралып җилкәсенә яткан. Ул, кыйммәтле хушбуй исе таратып, туп кебек сикергәләп, Юныс каршысына килеп басты. Юныс тишеп керердәй күзләре белән аңа карап катты. Гөлчирәне җен алыштырган, диярсең, чибәрләнгән, дәртне котыртырлык дәрәҗәдә сылуланган иде. Халат астында күкрәкчәсе дә юк икән, тулышып торган күкрәкләре чак кына тирбәләләр, сөрмәле күзләрдән Юнысны яндырып-көйдереп ут чәчелә иде.

Гөлчирә аптырашта калган Юныска бер күз сирпеп алды да, кыланып, мутланып уң кул яктагы ишекне ачты.

— Рәхим итегез! — диде.

Киң агач карават өстендә җәелеп яткан атлас тышлы юрганны, кабарынкы мендәрләрне томалаган чигүле ак җәймәне күреп, Юныс артка чигенде.

— Кая алып керәсең син мине?

Кырыс булырга, ныклык күрсәтергә тырышты, тавышы җебеп чыкты, ишетелмәде дә диярлек. Гөлчирә күңелле көлеп куйды.

— Тартынмагыз, тартынма. Йокыдан торгач, җыярга өлгермәгәнмен. Хәзер тәртипкә китерәм.— Ул караватны буйдан-буйга юрган белән каплады да: — Менә рәтләнде,— диде.

Юныс, Гөлчирәнең мимылдык түшләреннән аерыла алмаса да, бүлмә эчен дә карап өлгерде, аның кара күңелен, тора белә кешеләр, диган уй гелеп узды. Кая карама кыйммәтле келәмнәр, Германиядән кайткан трофей кәкре аяклы керсиләр елык-ялык яналар, тәрәзәдә кыйммәтле әленкеләр, алтын путалы сервант эчендә күз күрмәгән фарфор савытлар, колак ишетмәгән фаянс сувенирлар, бүләкләр... «Юк, боларына бу быткыч хатынның көче дә, аңы да җитмәс. Мөгаен, Мандрус кыйландыра торгандыр... Юк, болар көненә йөз сум гына эшләми! Болар, болар... Казан халкын кычкыртып талыйлар!»

Тукта, Гөлчирә аны йокы бүлмәсенә алып керде түгелме? Күрче, ничек кабартма артын биетеп караватны сыпырып тора!

Юныс кискен генә борылып ишек тоткасына ябышты, Гөлчирә аның кулын тоткадан каерып алды, аның сулышы ешайган, күз чокырларына наз кереп тулган иде.

— Курыкмагыз. Леша ерак китте. Кайтып керү ихтималы юк. Кайтса да, хәвефләнергә кирәкми.

Соңгы сүзләр Юнысны аптырашта калдырды.

— Бернәрсә аңламыйм!

Гөлчирә юрганны ачып ташлады, биленнән кысып кунакны караватка утыртты, карават сыгылып китте, алар йомшакка янәшә аудылар.

— Хәзер аңлатам! — диде көлә-көлә Гөлчирә.

Ул карават кырындагы тәбәнәк шкафка үрелеп рюмкалар һәм бер шешә коньяк тартып чыгарды. Бүлмәгә хуш ис таралды.

— Чыннан да, Леша сезгә кем була?

— Дөреслектә, беркем дә түгел,— диде Гөлчирә җитдиләнеп.

— Алайса нигә монда, сезнең йортта яши?

— Киресенчә, Юныс Гыйльметдинович, мин аның өендә яшим.

— Йорт сезнең исемдә! — диде шикләреннән һаман аерыла алмаган инспектор.

— Шулай килеп чыкты. Ул минем койрыкны кысып тотмакчы иде, мин тоттырмадым. Шул гына.

Коньяк кан тамырлары буйлап йөгерде, Юнысны бераз тынычландыргандай итте. Тагын берне йотып куйдылар. Гөлчирә тәлинкәдән парда күперткән кара җимеш, эре-эре баллы өрек кисәкләрен, чеметеп алып, Юнысның юеш иреннәренә кыстырды. Юныс Гөлчирәнең кайнар кочагына елышты.

— Ир белән хатын кебек яшисездер инде?

— Юк! — дип кычкырып көлде Гөлчирә, Юнысның яңагын сыйпап.— Сәяркәләр кебек торабыз! Кирәк икән кавышабыз, кирәк түгел чакта һәркем үз юлында. Ул базарчы маржаларны кымтырыклый, ә мин җан сөйгәннәремне кочам!

Иреннәр иренгә ялганды, Гөлчирә оста, җитез куллары белән Юнысны чишендереп тә ташлады. Коньяк койды.

— Болай начар кеше түгел үзе. Саранлыгы гына теңкәгә тия. Мин иркен яшәргә яратам, ә ул... Булса да булыр икән кысмыр җан!

— Ничек кавыштыгыз соң?

— Җүләрлек аркасында! Уеннан уймак чыкты! Базар кемнәрне кавыштырмый да, кемнәрнең юлын кисештерми. Бер башлагач, сөйлим алайса, Юныс җаным. Син тынычрак булырсың... Яратмыйм куян койрыгы сыман дерелдән яткан ирләрне! — Гөлчирә чут итеп Юнысның кендегеннән түбән җирен үбеп алды.— Себер ягыннан килгән ул мәхлүк, хатыныннан качыптыр ахрысы. Бер урала базарда, ике урала, карыйм, базарда түгел, минем тирәмдә урала икән. Сораша башладым, килгән бу — торыр җире юк. Кунарга үзебезгә алып кайттым. Әле минем кеше җәлли торган җүләр чагым иде, Юныс җанашым. Кайттык, шәплән юындырдым моны. Юындырганда күрәм — ярыйсы гына ир бу! Кочаклашып яттык та йокладык. Никахыбыз шул булды! Минем чисталыгымны, пөхтәлегемне ошаттымы, чаялыгым көч бирдеме, Лешам яшәреп

китте! Һич туймый, каһәр!.. Беренче елны бик тату яшәдек. Тәвәккәлләп шушы йортны сатып алдык. Яһүд акчасыз буламы? Тик йортка минем шактый акчам кереп китте. Сездән яшереп тормыйм, мин күптәннән акчага мохтаҗ түгел. Мин акча табуның мең юлын беләм! Ә Лешам... мең дә берне белә икән. Татар-Яһүд капиталын берләштереп, җиһазлар сатып алдык, савыт-саба. Яшибез — тик мәхәббәт кенә юк!.. Юныс җаным, мин сине өлкән инспектор булганың өчен яратмадым, таза син, сәламәт. Бер яртыны йотып куясың, тының да чыкмый. Ике яртыны бөклисең — телең дә көрмәкләнми. Умырып ашыйсың, кикермисең дә. Егет булганың өчен яраттым мин сине, икмәктер!

Юныс нишләргә белмәгәннән генә сөйләшүне дәвам иттерде:

— Нигә язылышмыйсыз соң?

— Теге хатыны белән аерылышмаган, паспортында чабата хәтле пичәте ярылып ята. Ялгыш кына ычкындырды бер, тегендә дә шактый мая туплаган ахрысы шома яһүд! Аерылса — байлыгыннан колак кага. Себер — алтынлы яклар. Бер-бер этлеге бармы, белмим. Ул мине беркатлы дип уйлады башта. Шалишь, тутаң базарда байтактан эшли! Базарда мал кулдан үтсә, хәйлә йөрәк аша уза! Өйрәтте дөнья безне, татар хатыннарын!

Гөлчирә юри-мырый гына, кыланып кына суган сыгып алды. Ул ара-тирә, сүз арасында Юныска кагылып китә, аны котырта, әзерли. Икенче шешәне эчеп бетергәнне дә сизмәделәр, соңгы рюмкаларны чәкештергәндә алар атлас тышлы җиңел юрганны идәнгә очыртып, сыгылмалы караватта яталар иде инде. Карават эч пошырып озак һәм татлы шыгырдады...

Хәл алып таралып яткан Юныска Гөлчирә сокланып карады.

— Чәй китеримме?

— Бик куе һәм бик кайнар булса гына!

Термостан агызган куе, җимешле кайнар чәйне йотлыга-йотлыга эчкәч, Юныс беравык сүзсез ятты. Гөлчирә дә сүз башларга ашыкмады, шәрә килеш аның янына караватка утырды.

— Ә үзең, Юныс җанашым, хыянәт итәсең, күп хатыннарның койрыгы синең учта. Хатыныңнан курыкмыйсынмы?

— Нигә куркырга? — Юнысның куе кашлары җыерылды.

— Җәлләмисеңдәме аны?

— Җәлләп ни файда? Йөргәнемне белә ул.

— Белә? Белгәч, ничек түзә?

— Түзәргә мәҗбүр. Бүтәнчә җае юк.

Юныс бу сүзләрен усалланып, ярсып әйтте, Гөлчирә артыгын сорашырга курыкты, Юныс янәшәсенә сузылып ятып, аны тыйнак кына иркәләргә, үбәргә тотынды.

Юныс ачылып китмәде, хатыны турында берәүгә дә хагын сөйләгәне юк иде. Гөлчирәнең кайнар куенында чак ачылып китмәде. Соңыннан сөенде, ярый әле ачылып бетмәгән. Белми торсыннар әле! Хатыны белән булган араны Юныс үзе белән каберенә алып китәчәк!..

Ул сугышта, Ленинград фронтында йөргән чакта хатыны чит ирләр белән шаярган. Өйләнеп кайтуының икенче көнендә үк явыз күршеләр түкми-чәчми аңа барысын да җиткерделәр. Бәлки, арттыралардыр, дип уйлады әүвәл Юныс, ышанып бетмәде. Әмма хатын эче дөреслекне үзе дә яшермәде. Булган хәлне бәйнә-бәйнә сөйләп, тезләнеп гафу үтенде. Башын идәнгә ора-ора, кайнар яшьләрен агызып ялынса да, Юныс аны гафу итмәде. Гафу итәргә исәбе дә булмады. Ормады, сукмады, гаиләсен ташлап та китмәде. Алма кебек ике улы калкынып килә иде, шуларны кызганды. «Дөньяда болай да күпме ятим, тагын икене өстәргәме аларга?» — дип уйлады. Хатын элгәрге елларны елап үткәрде, хәзер, күңел яралары әз-мәз төзәлгәч тә иренең киределеген, баш бирмәслеген күреп, аерылып китәргә талпынды. Юныс җибәрмәде. Үч тәме аның акылын агулаган иде. Ул чит хатыннар

янына барып йөрде, кәнтәйләрне хатыны күрсен өчен өенә алып кайт-калады, кеше аша сүзләр ирештерде. Хатын ябыгып бетте, корыды, кипте, анда да Юныс аны аерып җибәрмәде. Хәзер гаиләне балаларга мәхәббәт түгел, әнә шул, туймас үч тойгысы ялгап тота иде. Хәзер аның биш-алты көн саен кагылып чыга торган дүрт хатыны бар иде, Гөлчирә дә шул татлы төркемгә килеп кушылгач, Юныс, бик якын әшнәсе белән аракы күлендә йөзгәндә:

Хәзер минем биш кешелек гаремым бар! — дип мактанды.

Гөлчирә Юныска теше-тырнагы белән ябышты. Ул аңа беркем күрсәтмәгән яхшылыклар эшләде, өс-башын рәтләде, кыйбатлы костюм сатып алды, ялтырап торган английский штиблетлар юнәтте, галстук-кулъяулыкларны Мәскәүдән кайтартты. Очрашу өчен аерым квартира тапты. Квартира яңа салынган күп катлы йортта иде. Туалеты, ваннасы бар, ин мөһиме — аулак тыкрыкта. Ачкыч икесенең дә кесәсендә. Гөлчирә Юнысның һәр минутын санап яшәсә дә, тегесе иплән-иплән бу җәннәт почмагына бүтән хатыннарны да алып килгәләде. Урынның яман күзләрдән читтә булуыннан файдаланмыйча ярыймы соң?

Хәйләкәр Леша һаман ат җигеп эшләп йөри, аны җавапка тарту турында сүз чыкканы юк, җаны тыныч, ишегалдын арендага биреп торган өчен налогны нәкъ ул теләгәнчә итеп китерделәр. Ул шуңа бик канәгать. Гөлчирәсенең кайда, кай сукмакларда, нинди «аучылар» белән сөрелгәнен чамалый Леша, ләкин сүз дәшеп, нервысын түгеп тормый. Ул Гөлчирәсенең Юныс белән бәйләнешкә керүен сизде, анда да тауга чыгармады. Вакыты җиткәч, актыккы сүзне Мандрус әйтәчәк. Һәм ничек, кенә китереп әйтәчәк әле! Икесенең дә тез астына сугачак! Ат белән икәү калганда гына ул аңа кайбер серләрен сөйли.

Ярый, тарих дәвамында гел-гел кимсетелгән Израиль улларына да бәйрәм килер әле! Килер!

## IX

Юныс белән Гөлчирәнең кыҗыр-быҗырлары шулай тигез генә акканда базарда Зәйтүнә пәйда булды, баш та, авыл кызы, тыйнак, дип аңардан читенсенеп, мөнәсәбәтләрен яшереп йөрделәр. Зәйтүнәнең бәбәй алып кайтырга җыенуын ишеткәч, Гөлчирә Зәйтүнәгә мөнәсәбәтен нык үзгәртте, көнләшә башлады. Кырыс-кырыс торган мәлләре булды, авыр-авыр сүзләр дә әйткәләде, Зәйтүнәнең үз эзләренә басып, аңа охшап үсеп килүен абайлап бер сөенде, бер көенде, ә Зәйтүнә рыясыз, гөнаһларга тирән батарга өлгермәгән татар хатыны иде.

Ниһаять, ул сагалап көткән минут килде, сәгате сукты, базар җыемы акчасын үз кесәсенә шудырырга әзерләнгән мизгелдә Зәйтүнә килеп капты, тәбе капкачы ябылды. Ачаргамы ул капкачны, юкмы, хәзер һәммәсе Гөлчирә кулында! Моннан болай ул үзенең гөнаһсыз күз карашы белән Гөлчирәнең җанын талкып монда йөри алмас! Эләкте, капты — шулай, бу дөньяда намус кушканча яшәп булмый, ярамый да. Нигә барчасы үз файдасын күреп яшәргә омтылганда, читтә калырга әле? Артта калганны тукмыйлар, читкә кагылганнарны арадан сөрәләр...

Гөлчирә Юныс белән үзе генә дә сөйләшә ала иде. Юныс, аның сүзен үтәп, Зәйтүнә өстеннән язган актны аркылы-торкылы ертып ыргыта ала иде. Әмма Гөлчирәнең тантана итәсе килде, ул Зәйтүнәне директор чакыртып алуга ирешге, директор аны, эшеңнән куам, дип куркытып чыгарды. Гөлчирә Зәйтүнәне директор ишегенә кадәр күз белән озата килде, вакытын белеп кенә поскан почмагыннан чакырып чыгарды. Аракыга да китте Зәйтүнә, дөнья йөртә ул, йөртү генә түгел, куа, изә, таптый, таптый. Нигә Гөлчирә генә кара тамга йөртергә тиеш? Зәйтүнә дә йөртсен! Үзе генә түгел, әле сеңлесе дә килеп эләгәчәк дөнья тозагына!

Бүтән чакта ларекта очрашканда, ул Юнысның кулларына һәм теленә ирек бирмәскә тырыша иде. Зәйтүнә карап тора, тәки берәр җирдә теле чишелеп китәр... Бүген Гөлчирә дөньядагы берәүдән дә курыкмый, аңа көч биреп, яңа канатларны әнә шул кечкенә йомыкый Зәйтүнә куйды. Әгәр Гөлчирә сазда ята икән, янәшәсендә Зәйтүнә дә быкырдый! Чибәр, диләр, сылу, диләр, саф, диләр... Моннан соң карап карарбыз, Зәйтүнә нишләр икән? Әгәр Юнысның табанын яла, дисәләр — бүген ялый Зәйтүнә, тук мәче кебек мырлый-мырлый ялый! Аргы чоландагы өч аяклы караватка сузылып ят, дисәң — сузылып ятачак. Чөнки ул — карак. Базар акчасын үзләштерүче бур! Менә ул кем!

Зәйтүнә, аракы шешәсен түшенә яшереп, кара тиргә батып ларекка кайтып кергәндә, Юныс нык үк исергән иде. Гөлчирә Юнысны Зәйтүнә янына алып килүенә үкенеп тә куйды, алып килмичә дә ярамый иде. Юныс белән Зәйтүнәне очраштырмыйча, тантана итә аламы соң Гөлчирә?! Ә аның чибәр, сылу, яшь Зәйтүнәдән, бәбәйгә узган, тиздән ана буласы Зәйтүнәдән ныклы үч аласы килә иде.

Килә килүен... ә Зәйтүнәнең борын очына сибелгән тир бөртекләрен сөртә-сөртә мышнап кайтып керүен күргәч, кызганып та куйды. Бер елады Гөлчирә, бер сөенде. Аның бу халәтен текә күкрәкләрен тоткалап утырган Юныс сизмәде, әлбәттә.

Гөлчирә Юныска аракыны эчертеп бетермәде, шешәне тартып алды да почмактагы әрҗәләр арасына тыгып куйды.

— Җитте сиңа, эшкә барасыңны онытма! — диде ул дорфа гына.

— Әллә миңа хуҗа булырга маташа инде? — диде Юныс, тонган күзләре белән ачулы карап.

Гөлчирә аның имиенә үрелгән кулына сукты. Юныс сискәнеп китте.

— Бетте, бетте! Аңладым!

Юныс биленнән кочакларга чамалап кулын сузган иде, Гөлчирә ике куллап аны читкә этәрде.

— Бер генә дә ояла белмисең инде!

— Кемнән оялыйм? Зәйтүнәдәнме? Үзебезнең кыздан оялып торган юк. Ул, беләсеңме, хәзер кайда утыра?! — Юныс учын җәеп җибәрде дә йодрыгын йомарлады.— Менә кайда ул безнең сылу Зәйтүнәкәй! Әгәр безнең күңелне күрмәсә, аны иртәгә үк моннан куачаклар! Әгәр бик теләсәм, мин аны рәшәткә артына илтеп тыгам! Шулай бит, җанашларым? Шулай бит, аккошларым!

Ул көчле куллары белән Зәйтүнәне тартып китерде дә алдына утыртты. Зәйтүнә әче тавыш белән илереп кычкырганын аңышмыйча да калды.

— Нишлисез сез?

Гөлчирә аларны тынычландырырга ашыкты.

— Ике җүләр, туктагыз! Базардагы халык, сугышалар икән, дип уйлар.

— Аларның үз хәлләре үзләренә җиткән! Базарда халыкның күзе тона, акылы иләсләнә, комсызлыгы котыра. Базарда адәм кеше булудан туктый.

Юныс шулай сөйләнә-сөйләнә Зәйтүнәнең яшерен җирләрен капшарга тырышты.

— Җибәр! — дип чәрелдәде Зәйтүнә.

— Әгәр болай тыпырчынсаң... Мин бит сезнең рөхсәтсез генә йорт салып ятуыгызны да беләм. Йорт саласыз, ә материалларга бер кәгазегез дә юк! Тагын нинди мәгълүматлар кирәк, ә?!

Зәйтүнә Юныс кулыннан ычкынып ишеккә ташланды һәм ларектан чыгып ук китте.

— Их син, башсыз! — диде Гөлчирә, уены-чыны белән Юнысның шәңкәйгән колагыннан тартып.— Син аны ексаң, ул сиңа аяк чалачак! Монда ничә шешә бушатканыңны белсәләр, арканнан сыйпамаслар!

Тәлинкә тотарга, юхаланырга гаять нык остарган Гөлчирә ара-тирә Юнысны да түбәнсетергә, аяк астына салып изәргә ярата иде.

Гөлчирәнең әйтелгән бу сүзләре Юнысны бермәлгә айнытып җибәрде. Чыннан да, ни шайтаныма шушы кадәр ачылып китте әле ул? Аның иң курыкканы — «эштән кусалар»... Эштән кусалар — харап, һөнәре юк, эш яратмый, мондый җайлы, төшемле эшне елап эзләсә дә табачак түгел. Берәүгә дә ачылып бетмәм, дип аек чакта күпме антлар эчте, шайтан суы корсакка кереп тула да башка хуҗа булып ала, теләсә ни кыла аннары.

Гөлчирә сүзне борырга вакыт җиткәнен аңлады, еламсыраган тавыш белән ялварырга тотынды.

— Кеше алдында кул сузма дип ни әйттем. Юк, аңламасаң да аңламассың икән. Үпкәләмә, җаным, үзең өчен әйтәм! — Юнысның сытык чыраен күреп, Гөлчирә аның иреннәренә капланды.— Бүген безнең көн, онытма.

— Нәрсәне онытма?

Йогышсыз сорау Гөлчирәнең кәефен җибәрде.

— Мин кавышуларны сәгате-минуты белән көтеп торам, синең ике ятып бер төшеңә дә керми.

Ул юри еламсырап арты белән борылды.

— Сез, хатын-кыз, һәммәгез бер чыбыктан сөрелгән! Үпкәләргә генә торалар, ипидер. Тырт та пырт! — Ул кулын Гөлчирәнең иңбашына салды.— Йөгерә-йөгерә килеп җитәрмен, курыкма.

Юныс ишектән чыкканда, чак кына Зәйтүнәгә килеп бәрелмәде, ул саубуллашырга теләп аның кулын тотмакчы иде, Зәйтүнә бакадан чиркангандай читкә тайпылды.

Юныс күздән югалгач та әле Зәйтүнә шактый вакыт ишек төбендә басып торды. Ачы нәфрәт хисеннән, көчсезлегеннән йөрәге ут кебек янды. Нәрсәгә дип соң әле ул газиз башын мондый эшкә бәйләде? Нинди йөрәк белән талон бирмичә базар җыемы алырга тотынды? Имеш, ансат кына, җиңел генә баеп китә! Юк, хәрәм акча иртәме-соңмы барыбер эчне тишеп чыгар. Нинди рәхәт кенә, тыныч кына яшәп яталар иде алар... Ач тамагы, тыныч колагы. Тамак өчен генә түгел, колак өчен дә яшәргә кирәк ләбаса! Шуннан да яхшысы юк. Кеше куян куа, дип куян куаргамы? Тәүбә, тәүбә! Әйе, Гөлчирә дөрес кисәткән, базарның үз законнары. Монда колагыңны торгызып йөрмәсәң, аягына тышауны шундук салалар икән. Бөтен мөнәсәбәтләр ришвәткә корылган. Гөлчирә хак әйтә: «Синең, ди, базарда начальствоны күргәнең бармы, ди. Алар, ди, кирәкякны урлап өйләренә ташыйлар, ди. Һәркем урлаша, ди. Тик урлашу һәркемгә дә килешми, ди. Миңа килешә, ди...» Ана килешәдер, килешмәсә, череп баемас иде. Ә Зәйтүнәгә килешми урлашу. Хәлимнең дә урлашканы юк. Ул әнә өй җиткереп куйды, эштән бер кадак алып кайтканы юк. Югыйсә, вагоннардан ни генә бушатмыйлар.

Зәйтүнәнең бүгенге кебек арыганы юк иде. Эшләп арыса икән, гарьләнеп арыды, җаны арыды, гәүдәсе кечерәеп, бәләкәйләнеп калды. Эшләп ару — бер нәрсә. Күтәрә дә хәзер Зәйтүнә, әйбер-караны кулда йөртергә дә гадәтләнде. Монда эшли башлагач, мускуллары шундый ныгыды, иртән торуга эшкә атлыгып торды. Үлчәүләрне бирүне хәзер чүпкә дә санамый Зәйтүнә, кайткач иренә булыша, такта юныша, өя, бушата. Кыек эшләргә җаны әрнеп арыды ул бүген!

Гөлчирә Юныстан калган аракыны ике рюмкага койды да берсен Зәйтүнә алдына этәрде.

— Берүк кыстый күрмә, исең дә иснисем килми.

— Җүләр син, әз генә эч. Аны эчкәч, бөтенләй икенче кеше булып китәсең.

— Миңа ярамаганын, буемда барын беләсең ич!

Буенда барын күзе белән күреп торса да, Гөлчирә бу хакта тагын үз колагы белән ишеткәч аңарда көнчелек хисе уянды. Юньле хатыннар бала таба! Бала белән юана! Ул гына кысыр! Хәзер яши яшәвен, ирләргә

мохтаҗлыгы да юк, шушы буй-сыны, төсе-бите, кайнарлыгы, осталыгы барында ул генералны да үзенә карата ала. Ә картлык килгәч, бу Юныслар, Лешалар, Мишалар, Хәйдәрләр, Госманнар, тагын бик күпләр кайда булырлар? Картлыгын кем бизәр, әҗәл алдыннан була торган боек көннәрен кем юатыр?! Картлык әллә кайларда еракта түгел, ул хәзер килеп җитәчәк! Ах, үзе гаепле, беренчесен төшермәскә иде. Табарга иде. Райвоенкоматта эшләүче майордан иде беренче көмәне. Бәбәй табасы иде дә майор хатынының итәгенә илтеп саласы иде. Тукта, әллә елый инде? Ничә яшьтә булыр иде икән хәзер баласы?..

Ул, йөрәген тынычландырырга теләп, рюмкаларның икесен дә бушатып куйды.

— Дөньяда дус-иш кирәк,— диде Гөлчирә, Зәйтүнәне түгел, үз-үзен ышандырырга теләп. Хәзер көмәнле Зәйтүнә алдында җиңелеп калмас өчен, аңа төпле дәлилләр кирәк иде.— Дус-ишсез кыймылдый да алмыйсың, аппагым. Хәзер башыңны ашыйлар! — Ул бик тәмләп Юныстан калган тавык сөякләрен кимерде.— Дус-ишне таба белергә дә кирәк. Юкса, буш-буйдак та хәзинәңне сыпырып алып китә! Ходай хатынкызның хәзинәсен ерак яшерсә дә, буйлары җитә әрсез ирләрнең! Җаен бел, матур күзенә кызыгып кына берәү дә сине дус итәргә атлыгып тормый. Акыллы да була бел! Саран булма! Ярамый! Биргән бигә яраган, дип байлар ныгытып әйтеп калдырган.

Тавык ите беткәч, ул зур бер кисәк колбаса чыгарды. Аны кулына тотып үлчәп карады да, умырып бер капкач, кәгазьгә урап дәү сумкасына тыкты.

— Адәм баласы саран булмаска тиеш, дип ни өчен әйткәнемне аңлыйсыңмы, юкмы? Бәбәй табарга җыенсаң да, бала әле син, бала! Хәзер менә белер вакытың җитте. Безнең хуҗалар катлы-катлы. Аларның һәммәсенең күңелен күрергә кирәк. Беренче чиратта аларның тормышын көйләү безнең өстә. Юнисны күрдең. Әгәр аның арбасын һәрвакыт майламасаң, күчәре шундук шыгырдый башлый. Бел, мин аңа синең исемнән өлешен биреп чыгардым. Моннан болай үзең белеп бирә башларсың.

Зәйтүнәнең коты чыкты, иреннәре тулышты.

— Ничек үзем? Шушы... корсаклы килешме?

Гөлчирә күзеннән яшь, танавыннан юеш атылып чыкканчы егылаегыла көлде.

— Акча бирергә кирәк дим, сантый! Сәмән! Коткардым мин сине, җаныкачкаем, коткармасам, артыңа тибеп, кәҗә билеты тоттырып куалар иде сине. Йөр идең аннары! Корсаклы килеш тә кочаклап ятыр идең, Юныс андый чакта да баш тартмас, туймас тамак ул, ходай акылны бирмәсә дә, көчне биргән. Минем Юныс белән дус йөргәнне кешегә сиздерә күрмә! Сыңар сүз ычкындырсаң да, ас ягыңны йолкып чыгарырмын! Ярыймы?!

Гөлчирә исерә башлады, күзләре сәер калайланды, сөйләгәненең элә-танагы калмады.

Гөлчирәнең үгет-нәсихәте Зәйтүнәнең бер колагыннан тырнап керде, икенче колагыннан җәрәхәт ясап чыга торды. Ул, бүгеннән базардан китеп, тынычрак эшкә урнашырга юл эзләп баш ватып утыра иде.

— Нәрсә, борыныңны ник салындырдың? Китәм, дип уйлыйсыңдыр, минем дә андый тиле чакларым бар иде. Бар, эш эзләп кара. Синең кебек кәттә татар кызлары меховойда, сабын заводында иза чигәләр! Көне буе цемент идәндә, тозлы суда басып торып, яп-яшь килеш буынсыз, аяксыз калалар. Пороховойда утыз биштән пенсиягә чыга татар хатыннары! Чыкмас иде, тешләре коелып беткән, чирләшкәгә әйләнгәннәр. Күреп торалар, барыбер килеп җәһәннәмгә керәләр. Үз ирекләре белән. Кермәс иде, бик эшләмәс иде, татар кызы кая барсын? Авылда укуы монда ярамый, тел белмиләр, начальствоның бөтенесе урыс. Шулар изә татар кызын! Әле, җаным, башта кулыннан уздыра, аннан эшкә дөмектерә. Ә

без монда саф һавада, теләгәнчә ашап, эчеп, чөгендер кебек бүртенеп йөрибез. Базардан ике төенчек тотып бөгелә-сыгыла кем кайта? Алай гынамы соң, акыллы кеше кулына акча йога монда. Синең сыман тиле булмаска гына кирәк. Ә меховой кызларына хезмәт хакыннан тыш сыбызгы эләгә. Сабын заводы кызлары корсак тутыралар. Киез итек фабрикасындагы кызлар чахут ала. Мә, күр! Актынны Юныстан алып калдым.

Ул эре кыяфәт белән Зәйтүнә алдына кәгазь бите ташлады. Зәйтүнә кәгазьне ике куллап күтәреп алды да ниндидер үчлек, рәнҗү, ачу белән кат-кат вак-вак кисәкләргә ерткалап бетерде.

Көн кичке якка авышып, базарны ябар вакыт якынлашты. Бөтен инвентарьны чистартып, иртәгә өчен әзерләп куярга кирәк. Озакламыйча, атына чөңгереп, Леша да килеп җитәр. Ул килешкә бөтен чүп-чар җыелып, арбага төяр өчен әзер булырга тиеш. Зәйтүнәнең кыймылдар хәле дә юк иде.

— Син бүген иртә мәлҗерәдең әле,— диде Гөлчирә аны кызганып.— Мондагы әйбер-караларны үзем рәткә китеремен, син бар, чүп-чарны җый, өеп куй да кайтып ял ит. Мондагы хәлләр монда калсын, ишеттеңме?

Чүп көндәгедән ишле булды. Зәйтүнә эшен бетереп кайтырга чыкканда, караңгы төшкән иде инде. Ул шулкадәр талчыккан, көчкә кайтып егылды. Үлгән кеше кебек йоклады, ярый, Хәлиме икенче сменада иде, хатынының кыяфәтен күрмәде. Төнге сәгать бердә Хәлим эштән кайтты, хатыны баш очында бераз басып торды да, уятырга кызганып, идәнгә урын түшәп ятты.

Иртәгесен алар йокыдан соң гына тордылар. Хәлим икенче сменада, станциягә төштән соң бара. Зәйтүнәнең ял атнасы башлана иде. Кичә Гөлчирәнең тиктомалдан килеп булышканын искә алып, бәлки, Зәйтүнә дә базар ахырына барып чыгар, бармаса да зыян булмас.

Чәй янына утыргач, Хәлим Зәйтүнәгә текәлеп карап торды да:

— Ни булды сиңа, авырыйсыңмы әллә?— дип сорады.

Зәйтүнә күз яшьләрен тыя алмыйча үксеп елый ук башлады.

— Бер-бер хәл булмагандыр бит?

— Базарда артык эшләр хәлем юк, китәм.

— Нәрсә, әллә җәберлиләрме?

— Җәберләүнең аръягында!

Зәйтүнә бу араларда үз башыннан үткәннәрне түкми-чәчми иренә сөйләп күрсәтте.

Хәлим бүлдермичә тыңлады, йөзе сүрелә барды.

— Анда эшкә керүеңне башта ук өнәмәгән идем,— диде ул.— Дөрес, йөрмә жуликлар оясында! Кит! Рәте чыгар әле.

— Китүен китәм... Ничек яшәрбез соң? Ни ашарбыз?

Хәлим хатынының соравына җавап бирә алмады, елмайды гына. Үзен авыр уйлар чолгады — йорт салынып бетмәгән. Ярар, кышкы салкыннарга кадәр Бакалтайдан ташыган такта-токталар белән тишек-тошыкларны ямаштырыр. Түш арасына да кыстырырга кирәк ләбаса! Тамакны һич алдый торган түгел. Шулар өстенә ишәергә дә торалар. Бәбәйгә арбасы кирәк булачак, бишеге, чүпрәк-чапрагы. Күптәннән кунак-мазар өндәгәннәре юк, бәбәй тууга Зәйтүнәнең анасы килеп җитәчәк. Андагы ыбыр-чыбыр балалар да җизниләреннән күчтәнәч, бүләк көтеп яталардыр. Алар да хаклы, җаннары бар ич.

Нишләргә?! Кая барып сугылырга?

* * *

Өй эшләрен аннан-моннан караштыргач, Зәйтүнә Гөлсем апасы янына барып кайтырга исәпләде. Гөлчирә тозагыннан арынып торырга теләгән мизгелләрдә барыр кешесе бар иде әлегә аның. Күптән күреш-

кәннәре дә юк, хәлен белешер, үз мәшәкатьләрен сөйләп эчен бушатыр. Берәр акыллы киңәш биреп куймасмы тагын.

Гөлсем янына баруын Хәлимгә әйтеп тормады, ул эшкә киткәч, иркенләп юлга чыкты. Кучтәнәчсез барып керү килешми иде, Гөлсем апасының шоколад, конфет яратканын белеп, Зәйтүнә юл уңаендагы кибетләргә керә-керә барды. Юк кына бит юньле конфет! Олырак урамга чыгып, көч-хәл белән алтын кәгазьләргә төрелгән кыйбатлы конфет үлчәтеп алды. Бара торгач, көн кичкә авышты. Гөлсем өй ишегеннән тимер көрәк белән терәткән, лапаста сыер сава иде.

Зәйтүнәне күргәч, аның бармаклары тагын да җәһәтрәк хәрәкәтләнделәр, эшен бетергәч, ул атылып диярлек кунак янына чыкты. Шулкадәр сагынган икән, нишләргә белмәде. Өйгә кергәч, тиз генә сөзеп, Зәйтүнәгә җылы сөт эчерде. Күләч күзләре белән аның бүлтәйгән корсагына ишарәләп:

— Эч, эч! Сиңа кирәк! — дип кабатлады.— Ташладыгыз, икегезнең берегез күренми. Мин сезне үз балаларым белән тиң күрәм, ә сезнең исегездә дә юк.

— Гөлсем апа, җаным, үпкәләмә инде, бер генә вакыт җиткерә торган түгел.— Зәйтүнә чишелеп китеп елый-елый үз хәлен сөйли башлады.— Базардан тәмам гарык булдым, борылып карыйсым да килми!

— Шулай ук булдымыни? Ул ала күз Гөлчирә белән яшәү читендер шул.

— Китәм мин аннан.

— Кая бармакчы буласың соң? — диде Гөлсем уйчан гына.

— Табылыр әле.

— Йөкле хатыннарны эшкә урнаштыру — мөмкин булмаган хәл. Бу кыяфәтең белән кем сине эшкә алсын? Ул турыда уйладыңмы? Хәлим белән киңәштегезме?

— Бүген әйттем дә, әле өзеп җавап бирмәде.

— Бирмәс тә. Озакламый өчәү буласыз. Ходай тәгалә исән-сау котылырга язсын. Бала — бәхет, әмма зур мәшәкать тә бала. Өч кеше бер хезмәт хакына яши алырсызмы икән? Син сабыр ит.

Зәйтүнә тыела алмыйча елады:

— Көн туса, кеше сыйла, акча бир, аракы эчерт! Хатын башым белән аракы ташыйм...

Гөлсем чак кына тынып торды, нидер уйлады.

— Син йөкле хатын. Йөкле хатынны эштән куа алмыйлар алар. Закон кушмый. Декрет ялыңа чык. Бәбәеңне табып тиешле акчасын ал. Иркенләп ял ит. Куышыгызны корып бетерегез. Аннары бер-бер әмәле табылмыйча калмас. Мин дә сиңа эш эзләрмен.

Гөлсем әллә ни әйтмәсә дә аның сабырлыгы, киңәшенең иплелеге Зәйтүнәгә шунда ук тынычлык китерде, үз чиратында ул да апасының хәле белән кызыксынды. Моңарчы сабыр гына утырган апа кат-кат көрсенеп алды, күз чокырлары юешләнде.

— Хәлләр мактанырлык түгел! Налогларны бермә-бер арттырдылар. Яңа закон буенча сыер тотучылар акчалата биш йөз сум өстенә йөз илле литр сөт түләргә тиешләр. Күпләр сыерларын егып суя да башлады инде.

— Әйтәм җирле базарда сыер ите күзгә күренеп артты.

— Сыерсыз дөньяның ни кызыгы кала миңа? Сыер миңа иптәш тә, сердәш тә иде.— Гөлсемнең тавышында ачулы аһәңнәр яңгырады: — Балаларны әйтәм, хат саен, бетер сыерыңны, интегеп ятма, дип язалар. Ни аңлый алар?

— Сыерның мәшәкате күп инде,— диде Зәйтүнә аны-моны уйламыйчарак.

— Ничек яшәрмен мин? Ничек тамак туйдырырмын? Менә син, эштән китәм, дисең. Тамагың хакында уйладыңмы? Ни планнарың бар?

— Гөлсем апа, мин уйлап бетермәгәнмен.

— Сыеры сыер инде,— дип уфылдады Гөлсем,— бакчаларга да яңа налог китерәселәр икән. Алма агачларын санап киттеләр инде. Әллә бу такыр баш бабай акылыннан шаша инде?

— Кемне әйтәсең? — дип сорады Зәйтүнә, апасының кемне каргавын чамаласа да.

— Бар бит инде берәү, ил хуҗасы...

Сыерга кагылган һәркем Гөлсем өчен дошман, ул андыйларны чәйнәп ташларга әзер иде. Алма агачларын санауларына да ул кадәр исе китмәде, сыерсыз калдырсалар, яман булачак менә.

Зәйтүнәнең күз алды бер яктырды, бер караңгыланды. Ул Юнысның кыяфәтен, кем булуын искә төшерде. Шуның өчен алып кайтты лабаса ул аракыны! Аның исәбеннән акчаны аңа бөдәгән бит Гөлчирә. Тукта! Моннан бер-бер файда чыгарып булмасмы?..

— Әллә берәр кеше белән сөйләшеп карыйкмы, Гөлсем апа?

— Нинди кеше ул тагын? Нинди сүз?

Зәйтүнә Юныс, Гөлчирә турында кыска-кыска гына сөйләп бирде. Гөлчирәгә әйтсәң, берне түгел, биш сыерны саклап алып кала инде ул. Ләкин Гөлсем кубарылып бәрелмәде, сүзне тиз өзде:

— Туып-үсеп бер чакта да хәрәмләшкәнем булмады. Картаеп беткәч кенә хәрәмләшеп тормам инде. Ходай каршына барыр вакытлар җитә. Болай да искәрмәс кылган хаталар, гөнаһлар җитәрлектер. Ходай ни язган, шул булыр. Бер миңа килгән каза түгел, ил белән. Бер очы чыкмый калмас.

Зәйтүнәнең күз алдына чәчрәп Гөлчирә килеп басты. Икесенең уй-фикерләрен янәшә куеп чагыштырып карады. Әгәр моннан бер-ике ай элек кенә чагыштыру Гөлсем апасы файдасына булса, бүген ул кайсының хаклы икәнлеген аерып кына әйтә алмады. Күңеле белән ул, әлбәттә, Гөлсем яклы иде.

— Нигә соң бу дөньяның кешеләре синең кебек түгел икән? — диде.

Икенче яктан килеп, чуалчык уйлар аның күңелен иләс-миләс иттеләр. Әгәр Гөлчирә булмаса? Әгәр ул Юнысны уч төбендә биетмәсә? Иртәгә Юныс төзегән акт директор өстәленә барып җитәчәк иде. Акт белән танышкач директорның ниләр кыласын кем белгән: һәр төрә үзенчә котыра.

— Дөньяда төрле адәмнәр бар, яхшысы бар, яманы да җитәрлек, ләкин дөнья намуслы, тугры кешеләргә таяна. Әгәр шулай булмаса, бөтенесе күптән тар-мар килер иде. Ачы тир түгеп тапкан хәләл акчага сатып алган икмәкне ашауга ни җитә? Тәмле дә була ул, аның кадерен дә беләсең. Син яхшы күңелле бала, ирең намуслы егет. Шулар өстенә син минем авылдашым да әле! Бик зур сүз бит ул — авылдаш!.. Менә әти-әниемнәрне җәһәннәмгә сөрделәр, башлары югалды аларның... Әгәр шундый бәхетсез юлларда авылдаш очраса, мөгаен, исән калырлар иде алар. Ишеттем, аларны нык таратканнар, диләр... Әгәр син, намуслы бала да, базардагы эшен ташлап китсә, түрәләрең сөенә-сөенә синнән котылачаклар, һәм тагын да ныграк азыначаклар. Иплән генә эшлә, декретка чык, кабатлап әйтәм, акчасын ал; китәргә ашыкма...

Зәйтүнә Гөлсем янынан икеле-микеле уйлар белән кайтып китте. Гөлсем аны саф күңелле авылдашы дип белә. Алай ук түгел шул! Алай түгел!

Кешенең кызык бер гадәте бар, күп йөри торгач, ул барысына да күнегә. Начарлык белән яхшылыкны аермый да башлый. Тормышта нәрсә генә эшләнмәсен, шулай кирәктер булып тоела. Зәйтүнә белән дә шулайрак килеп чыкты, башта сөймәгән базарына бик теләп, атлыгып йөри башлады. Хәзер «Китәм!» дип әтәчләнсә дә, күңеле базардан аерылырга риза да түгел иде. Күнегелгән эш, өйрәнелгән гадәтләр — яңа урында ни була бит! Анда да Юныслар, директорлар булмас дисеңме?!.

Ә монда хәзер һәммәсе җайланган, һәр җыючыга акча туплауның көнлек планы бирелгән. Шартла, ярыл — планны үтә! Планың тулса,

синең вак-төяк гөнаһларыңа беркем игътибар бирми. Игътибар бирми, дигәч тә, һәрнәрсәнең үз рәте бар. Тикшерүченең авызын капларга, директорның авызын майларга кирәк. Әгәр шул шартларны тотмасаң, планны биш тапкыр арттырып үтәсәң дә, шәфкать юк! Хатын-кыз эшенең тагын бер кыенлыгы бар — житәкчеләр үз кул астындагы хатынкызны кочакларына алмыйча чыдамыйлар. Эшләре юк, ашап-эчеп симереп яталар да айгырдай кешнәп хатыннарны уралар. Моңарчы Зәйтүнәне алла саклады, янәшәдә ирләр таләбенә һәрчак гаяр булган Гөлчирә бар иде, ул коткарды. Инде Зәйтүнәне «эшкәртергә» чират житте, дигәндә, бәбәйгә узды. Ул шушы хәлне тиз аңлады, корсагын дәүрәк күрсәтү өчен биленә иске шәлен урап йөри башлады.

Гелән-гелән кеше тамагын кайгыртып кына яшәп булмый, дөнья яшь хатынның кулын озайтты.

Әлфия апасының әнә шундый язмышка чумып яшәп ятканында аларга килеп керде. Ире, кит, котыл, диде. Үзе, китәм, котылам, диде, китәр вакыт житкәч, урынын ятларга калдырасы килмәде. Ике көн буе сеңлесен үгетләде, ире аша да сүз әйттерде, тәки Әлфияне үз урынында калдырды. Директорга ике ярты, төрле вак-төяк кыстырып кагылып чыгуын иренә дә, сеңлесенә дә әйтмәде, андый вак-төякне Гөлчирә генә белеп калды.

Ике атна дәвамында иртәдән кичкә кадәр ул Әлфиягә ияреп базарга барып йөрде. Эшнең хикмәтләре, ак һәм кара яклары белән таныштырды. Башта бик тискәреләнгән Әлфия, тора-бара күнегеп китте. Сабын заводында, мехкомбинатта эшләүче авыл кызларының язмышы турындагы хикмәтләр аңа тәэсир итмичә калмады. Аннары кызның жизнәсеннән аерыласы килмәде, Хәлим ике сүзенең берендә аны укырга кыстап, белем алырга дәртсендереп тора иде.

Зәйтүнәнең «буш кына» китүен бер Юныс кына өнәмәде. Ул яшь, чибәр хатынны үз «чиратына» беркетеп куеп, жайлы мизгелне генә көтә иде. Зәйтүнәне бурлык өстендә тоткач, ул аның үрмәләп, ялынып киләсен бик яхшы аңлый иде. Бата башлаган ахирәтен Гөлчирә йолып алды. Бер юлга түзде Юныс, эшне тирәнгә жибәрмәде, инде Зәйтүнәнең сеңлесен күреп, ул бөтенләй котырынып китте, көн дә диярлек базар тирәсендә уралды. Зәйтүнә юк чакны чамалап, Әлфиягә сүз катып, күзен уйнатып, кулын озайтып карады. Әлфия күп уйлап тормады, Юнысның яңагына үлчәү тәлинкәсе белән тондырды. Чибәр кыз кулыннан үлчәү тәлинкәсе дә алырга риза Юныс, көлеп куйган булды, ә теге тиле кыз ярты юлда туктап калмады, ларек ишеген ачып каравыл кычкырды. Юныс утлы табага басты, ничек чыгып йөгергәнен сизмәде.

Ул апалы-сеңелле чибәрләрне ераккарак «чират»ка күчерде. Әмма Әлфиянең каты кулы турында хәбәрдар тикшерүчеләр аның тирәсендә саграк йөри башладылар, ә Юныс байтак вакыт бөтенләй күзгә күренмәде. Ул күләгәгә посып ашыкмыйча гына кызны күзәтә иде.

## X

Әлфия кызып-кызып сату итүчеләргә базар жыемы талоны өләшеп йөри иде, шулчак аңа кемдер «Зәйтүнә!» дип эндәште. Ул аңа игътибар да итмәде, дөрес, кайчагында апасына охшатып аңа «Зәйтүнә!» дип эндәшкәлиләр иде, әмма бүген халык аерата күп булып, акча санаганда ялгышырмын, дип куркып, Әлфия үз эшеннән бүтәнне белми дә, белергә дә теләми иде. «Әзме бу дөньяда Зәйтүнәләр!» — дип уйлады да, базардагы бүтән берәүгә эндәшәләр, дип санап, тавыш ягына борылып та карамады.

— Сеңлем, әнә теге кәттә егет сиңа дәшә бугай! — диде бер хатын.

Әлфия шунда гына ялт итеп борылып карады һәм зур сумкасын күкрәгенә кысып, халыкны ырып-ерып үзенә таба атлаган Мансурны

күреп алды. Күз карашлары очрашкач, Мансур рәхәтләнеп бер елмайды да ярым үпкәләгән тавыш белән сүз катты.

— Кала кызы булгач, берәүләр артык һаваланган икән! Кычкырам, кычкырам, аның гамендә дә юк!

Әлфиянең ике бите комач булып кызарды. Җир тишегенә керердәй оялып, як-ягына каранды — ялганы менә кайчан тотылды кызның! Уеннан уймак чыгар дип кем уйлаган? Ул ни әйтергә дә белмәде, катып калды, эше онытылды. Гаҗәпләнергә чират Мансурга җитте.

— Әллә оныттың дамы, Зәйтүнә? Җәй көне станциягә бергә тәпиләгән идек бит,— диде ул.

— Онытмадым, Мансур абый. Нишләп онытыйм ди? Эшнең тыгыз чагы, мавыгып сезне күрмәгәнмен.

— Әллә монда базарга эшкә кердеңме?

— Укырга кереп булмады шул. Русчадан алдыра алмадым. Шулай яндырдылар.

Ике култык астына ике чирек сөт кыстырган тәбәнәк хатын аларның сүзен бүлдерде.

— Әлфия җаным, талоныңны биреп тор, акчасын сөт саткач та китерермен,— диде.

Әлфиянең җен ачуы чыкты, бүтән чакта, матурым, багалмам, дип дәшә торган төче хатын бүген, Мансур барында, үч иткәндәй исемен телгә алып маташа! Кирәк бит шундый чакта аяк арасына кереп чуалырга! Талонсыз гына сатып китсә, ни булган?! Очрашуның беренче минутында ук Мансурга кызның серен фаш итте.

— Синең чын исемең ничек соң? — диде егет аптырап.

— Әлфия лә!..

Кыз еларга да, көләргә дә белмәде.

— Хәзерге заман кызлары мәзәк икән — юлда бер исем, эштә икенче. Өйдә өченчеме?

Әлфия Мансурга ияреп тынычрак мәйданга чыгуларын сизмичә дә калган иде, аның төртмә сүзләреннән тагын да ныграк кызарынып:

— Юк ла... Теге чакта каян телемә килгәндер. Әлфия мин, исемем бер генә,— дип кат-кат кабатлады.

— Син базарда бөтенләй төпләнеп калдыңмыни?

— Хәзергә эшләп торам әле, Мансур абый.

Еламсырап әйтелгән бу сүзләр Мансурның күңел кылларын тетрәтте. «И татар кызы, авыл кызы! Милләтнең гомуми фаҗигасе сиңа да килеп кагылган икән! Изге теләкләрең сине туган төягеңнән кузгаткан... Өметнең җылысы сине татарның мәркәзе булган Казанга китергән. Казан — хәзер урыс шәһәре шул! Сиңа монда киң капкалар ачылмаган. Йә син кулдан-кулга китәсең, йә шәһәрнең иң кара, иң пычрак эшләренә тап буласың!..»

Үзе дә күпне күргән, күпне кичергән егеткә Әлфиянең бер сүзе, бер ымы җитте. Ул аның хәлен тулаем аңлап бетермәсә дә, күңеленнән: «Бу кызны моннан йолып алырга кирәк!» — дип уйлады. Теләге нык икән — ул укырга, институт тәмамларга тиеш! Ни өчен татар кызлары авылның сасы фермаларында тирес көрәүче булып кына калырга тиеш?

Ул, үзе дә сизмәстән, кызның беләгеннән эләктереп алды.

— Син кайчан документларың белән минем янга килә аласың?

Әлфия аптырап калды: ничек? кая? нигә? Бөтенләй чит-ят диярлек кешенең үз янына чакыруыннан Әлфия шөбһәгә калды. Мансур аның шикләнүен аңлап, тиз-тиз сүзен дәвам итте.

— Мин сине читтән торып укырга урнаштырып булыр дип ышанам. Иртәгә үк аттестатыңны, имтиханнар биргән кәгазеңне алып минем янга кил.

Әлфия тәмам югалып калды. «Минем янга, ди. Кем соң бу сәер абый?..»

— Бу атнада мин эштән китә алмыйм шул.

— Кайчан китә аласың?

Сорау кискен һәм туры иде.

— Бер атна эшләп, бер атна ял итәм.

— Бик яхшы. Алайса, алдагы атнада. Килештекме?

— Абый, сез кем соң? Кайда эшлисез?

Мансур дустанә итеп көлеп җибәрде:

— Әйтмәдеммени? Менә тинтәк! Финанс институтында мин. Хуҗалык мөдире мин анда.

Һәм егет үзен ничек табарга кирәклеген өйрәтеп китеп барды. Базарга ашыгыч йомыш белән кергән икән.

Көтелмәгән очрашудан, һич көтелмәгән тәкъдимнән Әлфия аптырап калды, кайту белән җизнәсеннән киңәш сорады. Җизнәсенең җабавы катгый булды:

— Мондый мөмкинлектән файдаланмасаң, ходайның каргышы төшәр. Бәхет кошын куркыта күрмә!

— Алай!.. Ә ул егет бозык бер адәм булып чыкса?

— Бозыкка охшаганмы?

— Түгел дә...

— Бер нәрсәне онытма, киләчәктә укымаганнарга сан булмас. Дүшәмбе көнне үк янына бар. Тап. Сөйләш. Ашамас, курыкма. Бозыклар белән эш итәргә тәҗрибәң бар!

Әлфия апасы белән җизнәсенә Юныс белән булган хәлне кайтып сөйләгән иде, икесе дә шуны хәтерләп көлеп җибәрделәр.

Мансур — буйдак. Өч дистәне тутырды, һаман өйләнергә исәбе юк иде. Беренчедән, тотрыклы фатиры юк, студентлар тулай торагында кечкенә генә бер бүлмәдә ялгызы яши. Ата-анасы Ерак көнчыгышта, сөрелгән җирдә үлеп калдылар. Күмелгән урыннары да билгесез. Аерым каберләре дә юк, меңләгән бичаралар бергә яталар, сөрелгәннәр каберлегендә...

Ниләр генә узмый адәм башыннын! Әгәр Мансурның шушы утыз ел эчендә күргәннәрен, кичергәннәрен бер җепкә тезә башласаң, җир шарын әйләндереп алырлык кайгы җебе барлыкка килер иде!

Илдән сөрелгәндә аңа нибарысы ун яшь иде. Әтисенең авылдашларыннан аерылып, күзгә кереп торырлык әлләни байлыгы да юк иде бит. Ат, бер сыер. Иманага тигән җирне дә халык белән тигез иктеләр. Нэп заманында әтисе нәни генә, котыйчык хәтле генә кибет ачып җибәрде. Тоз, шырпы, керосин алып кайтып сатты. Шул кибет харап итте аны. Кибет тә әтисенеке булмаган әле. Авылның хәлле кешесе, яшьтәше, таза тормышлы Гали бай акча биреп ачтырган. «Бала-чагаң ишле, тернәкләним, дисәң, сәүдәгә керешеп кара, сәвит үзе рөхсәт итә!» дип үгетләгәч, янача эш башлап караган. Шушы кибет аркасында халыкның тоз, шырпы, тәмәке, керосин кебек әйберләргә мохтаҗлыгы беткән, Мансурның әтисе Сабит абзыйны мең рәхмәтләр белән мактап йөри башлаганнар. Бәла-каза сизенгән Сабит кибетен ашык-пошык таратып та караган, ябышкак кара исем тиз генә юылмаган: «Кулак! Сәүдәгәр!»

Башта аларга каты налог салганнар, һич түләп бетерерлек булмаган налог. Атны, сыерны сатканнар. Аннары кара-каршы салынган йортка чират җиткән. Торги булган. Таза йортны арзан бәягә генә күрше авылның үзара ярдәмләшү ширкәте рәисе сатып алган. Сабитның гаиләсен мунчага күчергәннәр. Рәис мунчага да кызыккан. Нәтиҗәдә утызынчы елның апрелендә аларны авылдан ук сөргәннәр...

Дөбердәтеп-янап авылдан алып киткәч, аларны берничә көн Арча станциясендә тоттылар. Ачык һавада. Аннары товар вагоннарына дыңгычлап төяделәр. О, ул көннәр! Гомергә хәтердән җуелмый торган газаплы сәяхәт әле дә Мансурның төшләренә кереп йөдәтә.

Сабит гаярь кеше иде. Вагоннарга куып кертеп, ишекләрне тыштан бикләүгә үк, хатын-балаларының тилмереп караган күз карашларына чыдары беткән Сабит качу турында уйлый башлады, авылдашларын, үз

ишләрен котыртты. «Ераграк китик, эз югалырлык булсын, илдә чыпчык үлмәс, җан сакларлык ризык табыйк!» — дип көчләрәк ир-атны үгетләде. Почмаклары тимерләгән вагоннан качу әмәлен генә тапмадылар. Туган илләреннән ерагайган саен качу җаен эзләделәр. ниһаять, төнлә вагонның бер башын яндырырга булдылар. Ут дөрләп кабынмады, вагон куе, зәһәр төтен белән тулды. Бер карчык тончыгып шунда җан бирде. Мәетне тиешле урынга барып житкәнче алмадылар, бу вагонга ашарга-эчәргә бирмәделәр.

Ниһаять, эшелон туктады, тәүлеккә якын ишеккә бераү дә килеп карамады. Шунна соң гына аларга җиргә төшәргә боерык ясалды. Станция Встритинский дип атала икән. Янында нәни генә шәһәрчек тә бар. Монда аларга озак торырга туры килмәде. Вагон саен берәр чиләк су бирделәр, суны җан башына кашыклап бүлделәр. Зур баржаларга төяп, Енисейга коя торган Шилка елгасы белән алып барып, Кытай чигеннән ерак та түгел, яңа ачылган алтын приискасына илтеп бушаттылар. Мәңгелеккә, диде конвой начальнигы.

Прискада озынча, тәбәнәк баракган башка бер генә корылма да юк иде. Баракка халыкның чирегә дә сыймады. Житмәсә, алар килү белән тоташ яңгырлар башланды. Кем ничек булдыра ала, шулай урын хәстәрләргә тотынды. Күпчелек землянка казып керде. Мансурның әтисе җир идәнле, балчык диварлы землянкада яшәргә теләмәде, алар авылның хәллесе Гали белән йорт салырга тәвәккәлләделәр. Урман өскә ишелеп тора, балта-пычкың булса, бүрәнәгә кытлык юк. Сабит белән Гали, икесе дә тап-таза ирләр, агач аударып, житәрлек бүрәнә әзерләделәр. Өйне алты почмаклы итеп өйделәр. Түбәгә житкәч эш терәлеп калды. Такта ярырлык пычкылары юк иде. Түбәне салам белән ябарбыз, дип уйлаштылар, тик түшәм белән идәнгә барыбер такта кирәк иде. Каян, ничек яргыч пычкысы табарга?

Урман эчендә, моннан егерме чакрым ераклыкта бер татар авылы барлыгы турында ишеткәч, Сабит белән Гали пычкы эзләп шул авылга киттеләр. Алар монда, җәһәннәм артында, татар авылы барлыгына ышанмыйчарак барганнар иде, имеш-мимешләр дөрескә чыкты.

Әтисенә ияреп Мансур да барды. Малайны ияртмәскә дә уйлаганнар иде, кара урман юлыннан елый-елый тагылып килгәч, ташлап калдырмадылар.

Татар авылы шактый зур күл буена урнашкан икән. Йортлар бер урам итеп тезеп салынган. Һәркайсы нык капкалар, биек коймалар белән камалып алынган. Авыл уртасында мәчет. Мәчетне күргәч, Сабит белән Гали елап җибәрделәр. Татар кая барса да татарча тормыш итеп ята, дип куанышты лар. Безгә дә шундый тормыш насыйп булсын, дип ходайдан үтенделәр.

Җомга көн иде. Сабит белән Гали кая барып сугылырга белмичә аптырашып торганда, ирләр җомга намазыннан чыга башлады. И дөнья! Кемнәрне кайларда гына йөртмисең син! Мәчеттән чыгучыларның берсе, сакалы агарган, аркасы бөкрәйгән бер адәм, боларны күреп, кулларын җәеп, елмаеп, сөенеп каршыларына килеп басты. Яхшылабрак карасалар, ак сакаллы кеше авылдашлары Хәким икән! Хәким моннан байтак еллар элек Галинең чабыш атын урлап төрмәгә эләкте. Котылып чыккач, илгә кайтмады. Шушы жиде-ят җир уртасына утырган татар авылына килеп урнашты. Китүеннән эзсез югалган, инде җир куенына кергәндер, дип исәпләнгән кешенең тәкъва кыяфәттә каршыларына килеп чыгуы бер гаҗәп булса, Гали белән Сабитның монда күренүләре икенче бер гаҗәп иде, кул биреп күрештеләр дә, аптырашып сүзсез калдылар.

Аңга килгәч, Хәким аларның ай-ваена куймыйча, чәйгә алып кайтты, юлаучылар шактый нык хуҗалыкка, таза ихатага барып кергәч, тагын да ныграк сөенделәр. Хәким — авылдаш, ничек тә чит итмәс, белеш-танышлары бардыр, авыр чакта бер терәк булыр, дип уйладылар.

Хәким тәкә суярга ниятләгән иде, кунаклар ирек бирмәде. Мунча кереп чыккач, самавырны екканчы чәй эчтеләр дә кайтырга җыендылар. Куна калсалар, артларыннан эзли чыгарлар дип курыктылар. Болай да, егерме чакрым читкә китүләре фаш булынса, аларга нык кына эләгүе ихтимал иде. Мансур бала бит, урманга кергән дә адашкан, шуны эзли чыктык, дип әйтергә кинәшеп куйдылар.

Аларны Хәким ярты юлга кадәр ат белән озатты, артыгын барырга ярамый иде, моннан ары тыелган зона башлана.

Саубуллашкач, Хәким Галинең кулын ике учы белән кысып алды да:

— Гөнаһлар житәрлек булды, авылдаш. Кичер... Заманасы шул идеме, холкым шундый булдымы, белмим, мәгәр, атыңны урлап тотылгач, әнкәй мәрхүмә нык рәнжеде... Аның хакына кичерә алсаң, кичер мине. Мәчетне күрдегез, үз кулларым белән манарасын торгыздым, үз акчама аен меңгердем. Сезне очратуым яхшыга булсын! Без бит авылдашлар. Бер-беребезне ташлашмыйк,— диде.

Сәфәр уңышлы булды, кирәкле коралларны да Хәкимнән алып кайттылар, еракка чыгып керүләре хакында да ары-бире сүз булмады.

Гали белән Сабит көндез казна эшенә — алтын юарга йөрделәр, бушаган арада ару-талуны белмичә такта ярдылар.

Йорт житкергәндә Мансур әтисенең кул арасына керде. Башта кабык, йомычка ише вак-төяк җыеп йөрде, соңра такта яру пычкысына да тотынгалады. Юныш балтасы да кулына ипләнде, әз-мәз булса да бүрәнәләр чутлады, бау белән бура өстенә бүрәнә дә тартышты. Эш ятуы шул чакта ныгыды малайның. Бүтәннәр ашык-пошык, ордым-бәрдем, ике такта арасына чүп-чар, мүк тутырып юка өйләр житкергәндә, авыл уртасында аларның алтыпочмаклы өе балкып басты. Бер башына Сабитлар, икенче башына Галиләр кереп утырды. Яңа өйне котлап, Коръән укыттылар, карт-корыны дәшеп, сөтле токмач белән сыйладылар.

Галинең бала-чагасы юк, хатыны белән икәү яшәп киттеләр. Иркен, җылы өйгә кереп утыргач, җиңел суладылар.

Ләкин аларга бу йортта озак яшәргә насыйп булмады, тормыш җайлана, эзенә керә, дигәндә генә, барысын да баржага төяп, кире Встритинскийга кайтардылар. Аннан конвой белән бөтенләй кире якка, тайга эченә илтеп ыргыттылар. Монда землянка казып керергә туры килде, властька ышаныч калмаган иде.

Ул елны, үч иткән кебек кыш аеруча салкын булды. Суыкка, ачлыкка чыдый алмыйча, халык чебен урынына кырылды. Беренче нәүбәттә балалар үлде.

Шул кышны Мансурның әнисе Майшәкәр бәби китерде. Гаилә тагын бер кашыкка артты. Алар хәзер биш җан булдылар. Яңа туган балага Рәфгать дип исем куштылар. Сабит, бөтен йоласын китереп, азан әйтеп, улына исемне үзе кушты, намаз артыннан бик озаклап, өзелеп-өзелеп теләк теләде.

«И, газиз аллам, шул нарасый, гөнаһсыз баланың ризыгын мул кыл, тиз көндә барыбызны да мондагы җәһәннәм газапларыннан коткар!» — диде. Күңеленнән алла белән печтик кенә бәхәсләшеп тә алды: «Ярар, без икебез — Майшәкәр белән мин языклы да булыйк, ди. Балаларның ни гаебе бар, ходаем? Ни өчен аларга да җәбер-җәфалар җибәрәсең? Бер түгел, мең сынадың ич, ходаем!» Бераздан «Ходайга тел тидердем, кичер, ярлыка!» дип калтырап төште һәм, кичерүне сорап, тәүбә итәргә тотынды.

Рәфгать ачы тавышлы бала иде, көне-төне елады, тынмады. Бәрәңге имезлек каптырып карыйлар, имезлекне теле белән этеп кенә чыгара бичара. Ә өйдә бәрәңгедән бүтән ризык юк иде. Бәрәңгенең дә өшегәне, вагы.

Рәфгать бу ямьсез дөньяда өч ай яшәп калды, җомга таңнарының берсендә ходай аны үз янына чакырып алды. «Интекмәсен, дигәндер, әнкәсе...» Сабит хатынын юатырга теләп шул сүзләрне әйтте, юк жирдә

ясалган зиратка улын Мансур белән илтеп күмде. Көн елады Майшәкәр, төн елады, аңа ияреп Мансур белән Рәисә дә елаштылар.

Яз житеп, елгалар боздан әрчелгәч, аларны тагын баржага төяп алып киттеләр. Иң әшәкесе — авылдашларны төрле баржаларга тараттылар. Сабит таянычы булган Галидән, Гали ышанычлысы булган Сабиттан аерылды. Сәфәр бу юлы озакка сузылмады, тәүлек дигәндә аларны Енисейск шәһәренә китереп бушаттылар. Ашау һәр жирдәге кебек каткан икмәк белән суык су булса да, бу лагерь каты режимлы булуы белән бүтәннәрдән нык аерыла иде. Ир-атларны конвой астында урман кисәргә йөрттеләр. Эш чиктән тыш авыр булса да, көнлек ашау нормасы такы-токы иде.

Мансурның әтисе эче китеп жәфаланды, аннары салкын тидерде, колагы агып ишетмәс булды һәм озакламыйча дөнья куйды. Янәшә авыл басуында кышлаган бәрәңгене табып ашаганнар да әртилләре белән агуланып үлделәр. Уникe кешене бер чокырга илтеп аудардылар. Баласы вафатыннан тернәкләнә алмаган Майшәкәр, ирен жирләгәч, бөтенләй чарасыз калды. «Өч ятим нихәлләр итәрбез?» дип аһ орды.

Жәй көне аңа да тынгылык бирмәделәр, эшкә кудылар. Чүп утадылар, бәрәнге тәпкеләделәр, игеннәр өлгергәч, бер караңгыдан икенчесенә кул белән урак урдылар.

Майшәкәр бер авыз сүз урысча белми иде. Кайбер намуссыз кешеләр аны, тел белмәвеннән файдаланып, бик еш кыерсыттылар. Ул башкарган эшне бүтәннәр файдасына язу дисеңме, әбәдкә алып барган ризыгын урлап ашау дисеңме — берсе дә калмады. Яклаучысы юк. Майшәкәр үзе бу этлекләргә каршы тора алмый, кайтарып сүз әйтергә тел житми. Көн-төн кайнар күз яше түгеп, кешеләрнең аңа мәрхәмәтлерәк булуын сорап ходасына ялварса да, адәмнәр тагын да ныграк азындылар. Бичара толның яшәү кызыгы калмады.

Беркөнне Мансур катгый рәвештә:

— Әни, мин синең белән басуга эшкә барам! — диде.

Бу хакта Майшәкәр үзе дә уйлаштыра башлаган иде. Мансур урысча чатылдатып сөйләшә, эшнең кайсысына тотынса да, кулы ятып тора. Өч яшьлек Рәисәне кемдә калдырып торырга?

— Аны да үзебез белән алпарабыз,— диде Мансур кырт кисеп.

Майшәкәргә бу фикер дә ошады, ни әйтсәң дә ир бала башы эшли шул, дип улына сокланды ана.

Көннәр эссе, жир төннәрен дә суынып өлгерә алмый, көн уртасында дөнья тәмам кыза, эсседән баш мие кайнар хәлгә житә. Мансур хәлдән тайган әнисен чүмәлә күләгәсенә китереп утыртты да:

— Әзрәк ял ит, әни,— диде.

Үзе уракка тотынды. Карап торуга бик жиңел күренгән эш, бисмилласын әйтеп тотынса да, шактый четерекле булып чыкты. Мансур, әнисенең исен китәрергә теләп, ясканып ура башлаган иде, бер-ике учма гына урып өлгерде, сул кулының чәнчә бармагын кистерде. Китте кан, китте кан, коры туфрак сибеп көчкә туктаттылар. Бармагындагы ярасы корышып, кулы төзәлгәнче аңа Рәисәне уйнатып, чүмәлә күләгәсендә утырудан бүтән чара калмады. И әрнеде Мансур, әнисен жәлләп и бәргәләнде! Шулай да, беренче көнне үк файдасы тиде, әнисе урып куйган көлтәләрне урлаучы бер маржаны тотты. Тотып кына калмады, егетлеген дә күрсәтте. Хатын кат-кат малайның эченә типте. Мансур тегенең бармагын эләктереп алды да теше белән чәйнәде. И чинады хатын, дуңгыз суялармыни! Ул чиный, Майшәкәр, тимә бүтән, дип ялвара, Рәисәгә кызык, кулын чәбәкли-чәбәкли көлә.

Эссе көннәр шактый озакка сузылды, уракчылар кызуга чыдый алмыйча, теләсә нинди су эчтеләр, нәтижәдә халык арасында эч китү авыруы таралды. Аның да иң начары — йогышлысы, дезинтерия дигәне. Чир иң башта Рәисәне екты, аны басуга алып барып йөртүдән тук-

тадылар. Бик ялына торгач күрше барактагы татар карчыгы алып калырга риза булды.

Чир Майшәкәргә сикерде, аны бөтереп алды. Ике тәүлек эчендә ул көзге яфрак кебек саргаеп, өрәк кыяфәтенә керде. Эшкә йөрерлек хәле калмады, аяктан егылды. Тамагына берни капмады, су эчте дә су эчте.

Рәисәнең яшьлеге үзенекен итте, ул савыкты, Мансур китергән сохарины ашап бетереп барды.

Майшәкәр бер иртәдә җиңеләеп йокысыннан уянды, тәяммем ясап ике рәкәгать намаз укыды. Аннары бик озаклап, ихлас күңеленнән дога кылды. Яшәүдән өмете өзелгән иде бичараның. Ул ходасыннан тилмереп-тилмереп ятимнәрен шәфкатеннән калдырмавын сорады. Дога артыннан хәлсез куллары белән Мансурын куенына кочып тыела алмыйча елады. Соңгы сүзе итеп:

— Улым, күз нурым, ничек булса да сеңлең Рәисәне ташлама,— диде.

Авызыннан сүзләре ишетелер-ишетелмәс кенә чыкты, бүтән сүз дә әйтә алмады, урынына түнде. Мансурга әнисе бераз тынычланып йокыга киткән төсле тоелды.

Шул ятудан Майшәкәр башын күтәрмәде. Мансур белән Рәисә алмаш-тилмәш аның маңгаена суга чылатылган чүпрәк куеп карадылар, әниләре уянмады. Күрше карчыгы кереп Майшәкәрнең күз кабакларын япты да битенә ак яулык каплады.

## XI

Дезинтерия халыкны нык кырды, һәрбер йорттан диярлек мәет чыкты, аларга аерым кабер казып өлгермәделәр, лагерьдан бераз читтәрәк, урман эчендә тирән чокыр казып, бөтенесе өчен бер кабер булдырылды. Майшәкәрне дә шунда илтеп куйдылар.

Мансур белән Рәисә тома ятим калдылар.

Башта ул сеңлесен кая барса да ияртеп йөрде, бер башын калдырырга курыкты. Бер иртәдә Рәисәне тәмле йокысыннан уятырга кызганды, паек алырга ялгызы гына чыгып китте. Паекка чират ул уйлаганнан күпкә озын булып чыкты, шактый озак юанып өенә кайтты. Кайтса, Рәисә урынында юк иде. Күршеләрнең әйтүенә караганда, ул аның артыннан ук чыгып киткән.

— Гел-гел бергә йөргәч, бүген дә бергә йөрисездер, дип уйладык,— диделәр хафаланган күршеләр.

Никадәр эзләсә дә, Мансур сеңлесен таба алмады, кыз суга төшкәндәй эзсез югалды.

Күрше баракта яшәүче, әлеге дә баягы мәрхәмәтле татар карчыгы, Мансурга туган иленә кайтып китәргә киңәш итте.

— Авылда сезнең хәлләрне онытканнардыр да инде, бала-чаганы эзәрлекләп тормаслар. Тотсалар, әти-әни үлде, туганнар янына кайтам, диярсең. Туганнарың таралган булса, авылдашларың карар. Авылдаш ул кайчак туганнан да якын була. Юлда-мазарда әтиеңнәрнең сөрелгән булуын әйтмә, шахтада эшләделәр, диген, бер сүздә тор.

Карчык Мансурга киңәшен дә бирде, юлга чыгарга да әзерләде. Икесе бергәләп, иске-москы киемнәрне сатып, әз-мәз акча юнәттеләр, билеттан, вак-төяк ризыктан калган акчаны Мансурның күлмәк иңечենә тегеп куйдылар.

— Заман — кара төн, кешеләре — ерткыч-җанвар,— диде карчык.— Сак бул. Тычкан таяк белән йөрер вакыт, сакланганны алла саклаган. Берәүгә дә тәмам ачылып китмә. Акчаңны соңгы чиктә, инде үләм дигәндә генә чыгар. Авызыңны ачып йөрмә! — дип кисәтте иманлы карчык.

Мансур Омскига тикле тыныч диярлек кайтты, Омскида төшеп, икенче поездга утырырга кирәк иде.

Вокзал халык белән кым-кырыч тулы иде, айлар буе беркая китә алмыйча тинтерәгән башлар монда сансыз-исәпсез иде. Мансурга билетын компостировать итәргә кирәк иде. Касса янына барырлык түгел, кесә караклары кешеләргә күз ачарга да ирек бирмиләр. Көпә-көндез кычкырып талыйлар. Бала-чагага түгел, олыларга да рәт юк, теләсә кемне тибеп очыралар. Мансур уйлап-уйлап йөрде дә туп-туры милициягә барып керде. Аны теләмичә генә каршыладылар. Берәвесе ачуланып җилкә чокырын төеп куа башлаган иде, Мансур әче тавыш белән кычкырып аны туктатты.

— Мин илемә кайтам! Мине поездга утыртып җибәрегез! — дип кабатлады ул.

Тегеләр бот чабып көлделәр.

— Билетсыз кем сине утыртсын, җүләр!

— Билетым бар, компостировать итәргә генә кирәк.

Мансур законлы билетын чыгарып күрсәткәч, милиционер аптырап калды — олы кеше таба алмаганны бот буе малай каян билет юнәткән? Ул Мансурның иңбашын каерды.

— Каян чәлдердең, әйт!

Мансур карчык өйрәткәнчә сөйләп бирде, каушамады, милиционер теләмәсә дә ышанырга мәҗбүр булды. Коридорга карап, яман тавыш белән:

— Пантелеев! — дип кычкыргач кына, Мансур бу кешенең гади милиционер түгел, начальник булуын аңлады.— Шушы малай белән кассага барып билетын компостировать итегез!

— Кая ул! — дип киреләнде Пантелеев.— Кассага якын бараммы соң?

— Вокзал начальнигына керегез.

Пантелеев малайны йөгертә-чаптыра вокзал мәйданын үтеп кызыл кирпеч бинага барып керде. Вокзал хуҗасының ишеге бикле иде, байтак көтәргә туры килде, милиционер тәкатьсезләнеп Мансурны ташлап китәргә торганда гына, кабинет ишеге ачылып китте. Начальник эчтә бикләнеп, качып утырган икән. Ул «билет» дигән сүзне ишетүгә кулын гына селтәде. Мансур телгә килде.

— Белеп торыгыз, әгәр мине поездга утыртып җибәрмәсәгез, вокзалыгызда тагын бер кесә карагы артачак!

Бу сүз начальникның да, милиционерның да күңелен йомшартты.

— Күпне күргән малай икән бу!

Начальник өлкән кассирны чакырып кертте.

— Зина, менә бу батырга бер билет рәтләгез инде! — диде.

Зина да койрык борырга маташкан иде, начальник тагын бер тапкыр эндәшкәч, артыгын карышмады.

— Мәскәү поездына бер билет бар, ләкин ул купейный,— диде.

Начальник уйга калды.

— Нишлибез, чая егет,— диде ул Мансурга карап.— Урын кыйбатлы, акча өстәргә туры килә.

Мансур сүзне тиз тотты, күлмәген салып ташлап, эчтән бөти итеп теккән акчасын сүтеп алды. Моны күргәч, начальник тел шартлатты:

— Менә бу пацан дисәң дә пацан!

— Булдыра! — диде Пантелеев Мансур белән хушлашып.

— Ашыкма,— диде начальник Пантелеевка,— әгәр син кертеп утыртмасаң, купедагылар моны якын да китермәс!

Чыннан да, әгәр милиционер озатып куймаса, купедагы өч кеше дүртенчегә утырган сәләмә киемле малайны бөтенләй кертәсе дә түгелләр икән. Милиционер китеп тә өлгермәде, купедагыларның берсе, чүмәлә чәчле, сипкелле маржа:

— Бетең күпме? — дип төртеп алды.

— Житәрлек, — диде Мансур һәм буш ~~урынга, икенче~~ кат сәкесенә үрмәләде.

— Маленький нахаленок! — дип авызын кыйгайтты маржа.

Мансурның бирәүгә дә исе китмәде, билеты кесәдә, поезд ажгырып чаба, сәгать саен аның туган якларын якынайта. Ашамаска да риза Мансур, әчми дә түзәчәк, туган ягына кайтып кына житсен!

Яту белән сеңлесе Рәисә күз алдына килеп басты. «Сакла, ташлама!» дигән иде әнисе... Ә ул Рәисәне адаштырып калдырып кайтып бара. Күңеле шул кадәр вәсвәсәләнде Мансурның, вагоннан сикереп төшеп, кире китәрдәй булды. Күп уйлана торгач, илгә кайтыйм әле, аннары бер-бер чарасына керешермен, дип житди итеп, олыларча уйлады да бераз тынычланды. «Алда тагын күз күрер!»

Ул бер дә кузгалмыйча тәүлек буе йоклады, юлдашлары: «Әллә үлгәнме бу малай актыгы?» дип аны йолыккаламасалар, тагын күпме йоклар иде — билгесез. Мансур күзләрен ачты, үзенең кайда икәнен аңыша алмыйча, югарыга карап ятты, аннары купедашларына күзе төште. Кичәге чүмәлә чәч бит акшарын юган, чүмәләсен иңенә тараткан, янындагы иргә ягымлы гына эндәште.

— Володя, чая егеткә ашарга бирергә кирәк, ачтыр ул мескен.

Володя утыз яшьләр тирәсендәге ачык йөзле ир икән, ул аяк очында яткан чемоданны ачып, башланмаган бөтен икмәгеннән калын гына телем кисеп алды да Мансурга сузды. Ә хатын зуп-зур кисәк колбаса тоттырды. Колбаса тач май, авыздан су китереп хуш ис аңкытып тора. Мансурның күптән авызына бер тәгам ризык капканы юк иде. Ипи белән колбасаны минут эчендә юк иттерде, бүлтәеп чыккан яңаклары туктаусыз биеп торды.

Тамак ялгагач, сорашу китте: кем, каян, кая бара? Мансурның сүз бер иде, ул читенсенеп тормады.

— Әтием Енисейскидан ерак түгел алтын приискасында эшли. Мин авылга, әнине алырга кайтам. Әни урысча бер авыз сүз белми, үзе генә юлга чыга алмый. Әти үзе кайтмакчы иде, аны эштән жибәрмәделәр. Ударник ул безнең. Ул китсә, план үтәлми кала, — дип тезеп салды.

«Йә, ничек? Ышандыра алдыммы?» дип юлдашларына күтәрелеп карады, тегеләр, Мансурның батырлыгына сокланып, мактадылар.

Ниһаять, поезд мышный-мышный Арча станциясенә килеп туктады. Әле моңнан берничә еллар элек кенә әти-әнисе белән бергә товар вагоннарына төялеп киткән таныш жиргә баскач, Мансур дерелдәп куйды. Монда шул көннән бирле берни үзгәрмәгән кебек тоелды, тирә-якта капчык аскан, кәржин, әржә тоткан кешеләр мыжлап тора, чыр-чу, акыру-бакыру, елаш-талаш, бер-берсен тукмашу...

Ул бик озак, нигә икәнен үзе дә төшенмичә, станция тирәсендә буталып йөрде. Соңыннан гына аңлады: әти-әнисен эзли икән ләбаса! Менә-менә каршысына алар килеп чыгар кебек тоелды...

Хәзер аңа станциядән шактый ерактагы Ямаш авылына кайтырга кирәк иде. Исән булса, Ямашта әнкәсенең энесе яши. Сыендырса шулар сыендырыр. Шулай уйлады малай һәм ялгышмады. Аны жылы гына каршыладылар, хәле белән танышкач, утырышып елаштылар.

Садыйк белән Сараның балалары юк иде. Башта бу хәлгә нык кимсенделәр, кеше арасына чыгып йөрмәс булдылар. Ходайның язганы шулдыр, дип, тора-бара бу хәлгә күнектеләр, бер-берсеннән читләшмәделәр, киресенчә ир хатынга, хатын иргә ныграк тартылдылар. Тормышлары житеш, сыер асрыйлар, сарыклары байтак, атлары бар иде, узган ел колхозга кергәч, атны илтеп яптылар. Өйләре дә иркен, кыскасы, Мансур жылы ояга кайтып элгәште. Картаймыш көнебездә бер терәк булмасмы, — дип, Сара да Мансурны үзләрендә калдырырга каршы килмәде. Беренче көннән үк аны: «Улым!» — дип йөртә башлады. «Улым!» дип дәшә дә елап жибәрә...

Җәй азаклары иде, мәктәпкә йөрергә Мансурга яңа киемнәр юнәттеләр. Садыйк китап-дәфтәр тутырырга такта сумка ясарга тотынган иде, Мансур: «Үзем, үзем!» дип эшкә тотынды да сумканың менә дигәнен ясады. Буяп та җибәргәч, сумка авылда бер булды.

Аның беренчегә барырга яше ньк үткән иде, дүртенче сыйныфка барып керде. «Өченче классны бетердем», дип хәйләләде. Авылдан сөрелгән елда беренчедә укый башлаганда: «Кулак баласына бездә урын юк!» — дип куып кайтарганнар иде. Аннан-моннан китап юнәштереп укуын да, арифметикасын да алга җибәргән иде Мансур, тырышлыгы ярады. Кышын рәхәттә укыды Мансур, сәхнәләргә менеп Такташ шигырьләрен ярып салды, хорда да җырлады, биергә дә чыкты.

Ятим-ялпының болай күз өстендә каш булып балкуы кайбер күреқсез адәмнәргә ошамады. Бераү, «яхшылык теләп», аның турында тиешле оешмаларга хәбәр дә җиткерде. Май бәйрәме көнне Садыйкны кәнсәләргә чакырттылар. Сара да үзенчә бәйрәмгә әзерләнгән иде, Мансурга атап күкәй дә манды. Мич төбенә бәлеш утыртты. Аш әзер, ә Садыйк юк та юк, аптырап беттеләр. Сара кәнсәләргә барган иде, кертмәделәр.

Садыйк караңгы төшкәч кенә кайтып керде. Аягында чак басып тора, киндердәй агарынган, күзләрендә яшь. Ах-ух килеп урындыкка утырды да бармагы белән Мансурга төртеп күрсәтте. Шуннан соңгы сүзен дә әйтә алмады бичара, сәкегә барып егылды, Сара баш астына мендәр салганда, ыңгырашты да җан бирде...

Садыйкны җирләгәннән соң ике көн үткәч, Мансурны да кәнсәләргә чакыртып алдылар. ГПУ начальнигы аны аерым бүлмәгә алып кереп сорау алды. Бала дип тормады, акырды да бакырды.

— Син, кулак калдыгы,— диде ул,— чүп башыңнан закон бозып, качып кайткансың! Без сиңа күрсәтербез!

Мансур Садыйк абыйсының кинәт вафатыннан аңга килә алмаган иде, күзләрен мөлдерәтеп катып калды.

— Әллә телеңне йоттыңмы? Җавап бир!

— Минем качканым юк, абый. Әти-әни үлгәч, үзләре кайтып китәргә рөхсәт бирделәр.

— Күрсәт, рөхсәт кәгазеңне!

Мансур ни өчен икәнен үзе дә белмичә поезд билетын күкрәк кесәсендә йөртә иде.

— Менә! — дип шуны чыгарып тоттырды.

— Син, качкын, минем башны бутама! — дип начальник билетны идәнгә ыргытты.

Мансур иелеп алып, аны кесәсенә салып куйды.

— Миңа башка бер кәгазь дә бирмәделәр. Вокзалга кадәр озатып, билет алып бирделәр дә илгә кайтырга куштылар. Рөхсәтсез анда берәүгә дә билет сатмыйлар!

— Кара аны, тикшерербез. Әгәр алдашсаң, кул-аягыңны бәйләп кире озатырбыз!

— Анда дөнья тулы бур, карак. Кайтмасам, мин дә шулар кебек кесә карагы була идем!

Мансурның җавабы ГПУ вәкилен уйга калдырды.

— Бар, кайтып тор. Безнең рөхсәттән башка беркая китәсе булма!

ГПУның янауларын малай колагына да элмәде, аның башына бүтән кайгы төште, абыйсы үлгәч, Сара апасы аны тотармы, юкмы?

Сара иренең үлемен авыр кичерде, монда бөтен нәрсә аны хәтерләтә, дип, Садыйкның кырыгын уздырды да, йорт-җирен, мал-туарын сатып күрше авылдагы әти-әнисе янына кайтып китте.

Мансур тагын урамда калды. Шәһәрдә, Тегәрҗеп урамында, әнкәсе ягыннан кардәш тиешле бер карчык бар иде, ул шуны эзләп тапты. Мәфтуха әбисе ике катлы агач йортның подвалында яши иде.

— Караватл куярлык урыным юк, балам, идәндә ятып булсаң, хәзергә сыйдырырмын,— диде карчык сынап карап.

Яшәр җирем бар, дип сөендә Мансур, үзенә күрә бер кәсеп тә тапты. Чират торып «Пушка» папиросы ала да шуны берәмтекләп сата. Тамак туйдырырлык сәмән килә тагын! Сәүдә уңышлырак барган көнне Мәфтуха карчыкны да онытмый, көлчә-мөлчәләр алып кайта. Карчык дога арты саен аны мактый.

— Нинди мәрхәмәтле туганым барын моңарчы белмәгәнмен! — ди.

Алар өч ел буена бер-берсен аңлап, сыешып яшәделәр. Шушы дәвердә ул җиденчене тәмамлады. Буйга тартылды, тәскә-биткә үзгәреп, тавышы калынайды, егет кыяфәтенә керде. Ул атасына охшап, төптән юан чыккан иде. Җиденче класстан соң, финанс-экономика техникумына укырга керде. Техникумның тулай торагы бар иде, шактый изалангач, аңа шуннан урын бирделәр. Мансур шунда күчте, дәртләнеп укып йөрде, Мәфтуха карчыкны да онытмады, ял саен аның янына йөгерде. Утын кисте, ярды, су ташыды, ишегалдын себерде.

Техникум тәмамлаган елда аны армиягә алдылар.

Бу — дәһшәтле кырыгынчы ел иде, сугыш алды елы...

Мансур кырык бер, кырык икенче елларның чигенү авырлыгын бөтен авырлыгы, хурлыгы белән үз җилкәсендә татыды. Ике мәртәбә яраланды, соңгысы кырык дүртнең көзендә иде. Яшьлек үзенекен итте, госпитальдә озак аунамады. Берлин операциясе башланыр алдыннан ул фронтта иде инде. Рейхстагның таш стенасына имзасын куярга өлгерде. Сөенеченнән партиягә дә керде егет.

Бүләкләр төяп, ашыгып-канатланып Мәфтуха әбисен күрергә дип кайтса, өлгермәде, кайтырына атна элек кенә карчыкны җирләгәннәр иде.

Ул кайту белән институтка укырга керде. Бер үк вакытта шул институтның хуҗалык мөдире вазифасын үтәргә алынды. Тырышлыгын, намусын, тугрылыгын күреп, аны ректорның хуҗалык эшләре буенча урынбасары дәрәҗәсенә күтәрделәр. Институтны тәмамлады, аспирантурага керде. Хәзер диссертация язып яткан көне...

И гомерләр! Соңгы еллар бигрәк тиз үткән кебек тоела. Борылып карасаң, күпме сулар аккан да күпме җилләр искән. Өч дистәнс тутырып килә егет. Гаилә турында ныклап уйлаганы гына юк. Ә вакыт, бик вакыт...

Кыска-кыска гына танышып алган кызлары Мансурның элегрәк тә булгалады. Киногa барып йөрде, бәйрәмнәрдә утырдаш булды. Яңа елны күңелле төркемнәрдә каршылады, анда да кызлар була иде, әмма моңарчы бер кыз да аның күңел утын кузгата алмады. Чибәрләр дә бар иде арада, акыллылар да, әмма һич көтмәгәндә, очраклы күрешкән кыз егетнең һушын алды. Бер күрүдә ошатты ул аны, кызга гел яхшылык эшлисе килде, игътибарын яулап алырга тырышты. Казанның күп санлы ермакларының берсендә аерылган кичтән бирле, ул бу тирәләргә еш килде. Ләкин Хәлим оештырган такта йортка керергә кыймады. Зәйтүнә күптән авылына кайтып киткәндер, дип уйлады. Бәхете — якташ кызны, гүзәл авыл кызын очратты. Зәйтүнә түгел түгелен, мәгәр Әлфия исеме дә егетнең күңеленә хуш килде.

«Күз алдымда булсын!» дип укуга тартты, кызның укуы белән әзмәс кызыксынды, нәтиҗәдә, ул чокыр эчендәге җып-җылы өйгә, ачык күңелле кешеләр арасына барып йөри башлады. Балачактан гаилә җылысы туймаган боек күңелле Мансур Хәлим белән уртак тел тапты. Зәйтүнәнең хөрмәтен яулап алды. Сөйләшә-аңлата торгач, Хәлим белән уйлашканнан соң, ике ир-ат, Зәйтүнәгә дә, Әлфиягә дә базардан китәргә кирәк, дигән фикергә килделәр. Каярак китәргә, нинди эш сайларга бу хакта да уйлаштылар.

Әлфиягә эш табу кыен булмас, ул уңышлы гына укып бара. Финанс оешмаларының берәрсендә аңа эш урыны табылырга тиеш, менә Зәйтүнә белән нишләргә? Аны нинди кулай эшкә урнаштырырга? Белеме җиде класс, бер төрле дә төпле һөнәре юк.

— Апага һич кичекмичә укырга кирәк,— диде Әлфия бер көнне.
— Кит аннан!— дип чәбәләнде Зәйтүнә.— Бала күтәреп укып йөргәннәр иде ди бирәүләр!
Гомере буе белемгә, яктылыкка омтылган Хәлим:
— Әлфия сиңа хак сүз әйтә,— дип хатынына каршы төште.— Кирә алсаң, ничек тә укыр идең әле. Үзем булышырмын. Ятып калганчы, атып кал, дәреслекләр тап та караштыра башла.
Зәйтүнәгә дәреслекләрне Мансур табып бирде. Аны җиде класс күләмендә имтихан бирергә әзерләделәр. Бөтенесен онытып бетергән икән Зәйтүнә, мең газап белән, елый-елый укыштыра торгач, Хәлим, Мансур, Әлфия ярдәмендә ерып чыкты тагын. Аны кооператив техникумына читтән торып укырга урнаштырдылар.

* * *

Әлфиядә Мансурга карата үзе дә яхшылап аңламый торган бер хис туды. Берәр көн күрешми торсалар, өзелеп сагына, тизрәк очрашырга ашкынып, берәр сәбәп эзли башлый. Әллә чыннан да яратам микән, дип вәсвәсәләнә. Ничек инде үзеңнән күпкә олы ир кешене яратырга мөмкин? Оят билләһи! Әгәр кеше теленә керсә, бөтен дөньяга даның таралыр...
Ял көне иде. Иртүк ашыгып Мансур килеп керде.
— Ике билет алдым, киного барабыз,— диде ул Әлфиягә.
Әлфия кып-кызыл булды һәм апасына күтәрелеп карады. Җен ачуы чыкты. Мансур абыйсын әйтер иде, аны, кеше югында, үзенә генә күрсәтергә ярамаганмыни?
— Барыгыз, бар,— диде Зәйтүнә елмаеп.— Чын танышлык кинодан башлана. Һиндстан фильмы түгелме?
— Һиндстан! Бик шәп бара икән, билетларны бер атна элек сатып бетергәннәр, мин куллан гына эләктердем.
Хәлим белән Зәйтүнә парлап көлеп җибәрделәр. Дөрес, Мансур белән Әлфия бу сүздән берни дә аңламадылар, әмма җизнәсе белән апасының уңайга торганын күреп, Әлфиянең күңеле җылынды.
Ул үз гомерендә беренче тапкыр егет белән киного бара! Уңайсыз да, күңелле дә! Шатлыгы эченә сыймаса да, моны Мансурга сиздермәскә тырыша. Әгәр Мансур укымышлы олы ир булмаса ана җиңелрәк булыр иде дә... Хәер, ана бүген бик рәхәт, бик күңелле! Чынмы бу, әллә төш кенәме? Әнисе белгәч ни әйтер икән? Төптән уйлап карасаң, әнисе дә әлләни әйтмәс әле. Барлык кызларга да мондый егет эләкми, егетләргә кытлык заман хәзер.
Яраткан кешесенең уч кайнарлыгын тоеп, ара-тирә аңа карап алып, Радж Капур дөньясына ясалган сәяхәт анын тәнен кызыштырды, йөрәк тибүе еш ланды.
Беренче мавыгуларына шигәебрәк караган Мансур исә бәхет диңгезендә рәхәтләнеп йөзә иде. Әлфиянең ул көткән, җаны эзләгән кыз булуында аның шиге юк иде хәзер.
Кинодан чыккач, Мансур Әлфияне озата китте. Алар трамвайга утырып тормадылар, җәйгә гына атладылар. Вакыт тиз үтте, ерганак тирәсенә кайтып җитүләрен абайламыйча калдылар. Кемнәрдер аларга карап үтеп китте, кемдер Әлфия белән исәнләшеп узды, икесенең дә ой кысасына кайтып керәселәре килмәде — хәзерге мәлдә аларның күңелләре өйгә сыя торган түгел иде. Тынычрак почмак эзләп, бер читтәге агачлык кырына барып чыктылар. Мансур Әлфияне күкрәгенә кысты да иреннәреннән үбеп алды.
— Чү, Мансур абый,— диде башы әйләнгән кыз каушап,— нишләвең бу? Язык ич.
Үзе аңа якынрак елышты.

— Мөхәммәт өммәтендә өч тапкыр фарыз дия иде минем мәрхүмә әнкәй.

Мансур аны тагын ике мәртәбә суырып үпте.

— Үлдем, Мансур абый, беттем...

Мансур ни булды икән, дип куркып китте.

— Иртәгә кеше күзенә ничек күренермен?

— Безне беркем дә күрмәде ич, Әлфия.

— Берәүгә дә үптергәнем юк иде, Мансур абый.

— Шуның өчен үбәм дә мин сине. Бүтәннәр белән үбешкән булсаң, якын да килмәс идем.

Алар туктаган җирләрендә озак кына басып тордылар. Кайдадыр, якында гына җанга якын балта тавышы тукылдады, агачларда чыпчыклар чыркылдашты. Алар бер-берсеннән аерыла алмыйча озак кына шул тирәдә йөрделәр.

— Мансур абый, үбешкәнне кешегә әйтә күрмә инде,— дип ялварды Әлфия.— Безнең авылда берәр кыз егет белән үбешсә, шундук дөньяны сасыталар.

«Балалыгы чыгып та бетмәгән!» — дип куанды Мансур.

— Әйтәм, моннан соң һәр очраган кешегә, без Әлфия белән үбештек, дип әйтәм.

— Абау, Мансур абый, алай ук усал булма инде!

И бәхетле, садә чаклар!..

Шул көннән, Радж Капур киносыннан соң, аралар якынайды.

Тиздән Мансур Әлфиягә эш тапты.

— Райфо мөдире белән сөйләштем, сине эшкә алырга булды. Райфога урнашкач, институтка йөрергә дә кулайрак булыр. Тагын шунысы бар: институтны тәмамлагач та сиңа шул системада эшләргә туры киләчәк, әйдә, стажың бара торсын! Китү турында гаризаңны директорга кертеп бир!

Базар директоры Әлфияне тоткарламады, киресенчә, аның эштән китүенә шатланды.

*Ахыры бар.*



# Ркаил Зәйдулла

## Кичектергән сәфәр

Офыкларга уранып мин китәр идем!
Нигә алгысыта мине бу сәфәр?
Инешләргә иеләм дә юлны юрыйм —
Күрәннәрс күзләремне кисәләр.

Күрәсезме, монда йөргән өрәкләр дә
Зәңгәрсу ай нурларыннан өртелгән...
Азга гына ваз кичсәм дә бу сагыштан,
Гөләпләрнең керфегенә төртеләм.

Китәр идем дәверләргә әверелеп!
Мине алгысыткан ачык ишектән...
Ләкин җирдән баш калкыткан үлән аша
Гөрләвекләр челтерәвен ишетәм.

Чәбәләнә бер кош куак арасында,
Ни көтим мин канатланган куактан?
Дөнья минем бугазымнан кысып тотты,
Борчылма, дип, шул дөньяны юатам.

Гөмбәзләргә орынып, аһ, китәр идем!
Яфрак сыман коеп кеше сүзләрен.
Тик кем сөртер дымлы иреннәре белән
Офыкларда күз яшемнең эзләрен?

## Хәсрәт

Бу нинди дөнья булды соң?
Бу нинди... нинди... нинди...
Аның белән тураям дип,
Мин авыш булдым инде.

Кузгалганнан бирле юлга,
Җилләрен юллый...
ачы...

---

Ркаил ЗӘЙДУЛЛА (1962) — *шагыйрь, «Көчшлы күзләр», «Күрәзә» һ. б. китаплар авторы, М. Җәлил бүләге лауреаты. Казанда яши.*

Кыйблага йөзне борырга
Хет бер җилкән булсачы.

Башны куеп җиргә — үксим.
Тып-тын авыл зираты.
Мин дә соң әллә җиһанга
«Ят яратылган»нар заты?

Гүргә иңдердем әтине,
Ләхет төбе алкын су...
Чайкалды да күк гөмбәзе,
Кымшанып куйды басу.

Күккә сикерде чыршылар.
Сабырлык бир, и Аллам!
Каләмем сары мәтегә,
Алкын суга буялган.

Бу нинди дөнья булды соң?
Бу нинди... нинди... нигә...
Язны алып киләсе җил
Кырда ак кәфен тегә.

Ташлыйлар туфрак кабергә.
Ә мин... мин үксим, үксим...
Нигә шундый мәрхәмәтсез,
Шундый гаделсез Күк син?

Әтием, кадерлем минем,
Алкын су аккан якта.
Саклармы урманнар исен
Өстендә имән такта...

Бу нинди дөнья булды соң?
Бу нинди... нинди... ничек...
Үлгәнче барыр озата
Язмышым — кара көчек.

Без дә яшәгән булабыз —
Хәсрәтле, гамьле Адәм!
Һәр мизгел афәт сагалый,
Көтә бер читтә матәм.

Кем юата алыр инде? —
Сузылам да ишектән,
Яр буендагы талларның
Сулкылдавын ишетәм.

*6 апрель, 1990 ел.*

## Зиярәт

Килдем менә...
Беләм, беләм юкса
Зиратларда сагыш йогасын.

Кипкән үләннәргә сыенган да
Тын калган жил...
Кыла догасын.

Тыгыз һава иңнәремә баса,
Тубыктан ук инәм, и раббым!
Чабуына ябышам бу дөньяның,
Яраттым мин аны, яраттым.

Өянкеләр көянтәләр булып
Иеләләр.—
Татар холыгы...
Бугазымнан кайнар сумаладай
Акты төннең караңгылыгы!

Юксыну да зыңҗыр сыман икән!
Кысты туфрак, кысты аягым...
Авыр төштән уяткан күк,
Миңа
Син кул суздың, дөнья.
Аядың.

Эзләп киттем сине гомер аша,
Зират каенылай якты син!
Бугазымнан кайнар сумаладай
Акты төн... акты төн.

## Нәни бер сер

Жылы бүлмәдә салкын ылыстан
Бөркелә кышкы урман һавасы.
Сискәнә дә җан — җил булып исә,
Ап-ак кар булып килә явасы.

Күздән югала дуслар, танышлар,
Эзләрендә тик карлар тузаны...
Курантлар чыңын көтәм мин ялгыз,
Сизмим — сезнең күк! — гомер узганны.

Кемдер озата, кемдер каршылый...
Сынык күңелгә бармы дәвасы?
Жылы бүлмәдә салкын ылыстан
Бөркелә кышкы урман һавасы.

Ел саен безнең шул ук өметләр:
Килергә тиеш миңа дигәне...
Киткәннәргә мин күптән битараф,
Искәрмим инде юкса килгәнне.

Дөньяның ләкин нәни сере бар,
Минем өчен дә кемдер тырышкан:
Бөркелә кышкы урман һавасы
Жылы бүлмәдә салкын ылыстан.

## Төсләр

Балачакның күп төсләре җуелган,
Ә бу —
Бүген булган кебек тоела.
Суларда чайкады апа керләрен,
Карап тордым шуны, өйгә кермәдем.
Бәләкләгән чакта күзләр чагылды,
Яктыртты ул балкыш тирә-ягымны.
Агара икән кер агымсуларда.
Тик куллар гына никтер алсулана...
Күз алдымнан китми менә һич кенә
Ике кызыл кисәү ак кар өстендә.
Ут каба калса керләргә әгәр дә,
Өйдәгеләр әзер андый хәбәргә.
Мине генә борчый, очкын эләгеп
Янып китмәсен дим, юган күлмәгем.
Тәрәзәдән карый әнкәй килә дә,
Керергә вакыт җиткәндер өйләгә.
Мин, ахрысы, ул көн шуны искәрдем,
Суларда чайкады апа хисләрен.
Ут каба калса карларга әгәр дә,
Ике алма кайсы якка тәгәрәр?..

## Һәйкәлләр

*Двусмысленны все постаменты*
*на территории татар.*

В. Соснора. Терцины

Шәһәрдә эңгер дә үзенчә
Куера урамнар өстендә...
Беркем юк беркемнең исендә,
Нинди моң — һәйкәлләр күзендә?

Һәрвакыт төшәләр юлыма...
Аста җир сыкранып куя да,
Сак кына сөякләр уяна.
Шул сызлау күченә кулыма.

Казанда һәйкәлләр терелә!
Һәммәсе эңгергә уралган,
Вокзалга чабалар урамнан,
Мәскәүгә кайтырга, кирегә...

Түрәнең әмере бер генә:
Абдулла, ишеккә йозак ас!
... Беркем дә рөхсәтсез озатмас —
Һәйкәлләр мәңгелек сөргендә.

Кат-катлап сүгенә постта мент[1]...
Ленинны тота да бөтереп,
Синме бу? — ди, — тагын, и өтек!
Һәм әзли төн ката постамент.

---

[1] Мент — милиционер.

## Күк капусы

Яшел үләннәрнең бәгырендә ак кар.
Кыш буена дөнья болытларны аклар.

Җылы эзләп үлән җиргә сыгылган ла! —
Күккә карый икән ул да сыгылганда...

Сусыл ылыслардан оеп коела бәс,
Язга кадәр инде каплар безне гөмбәз.

Нарат пумаласы омтыла да өскә,
Күк капусын ясый манчып яшел төскә.

Хан тирмәсе кебек түм-түгәрәк ак өй...
Кем соң ул — төн ката шакый, шакый, шакый...

Яшел үләннәрем төренгәннәр акка...
Үлән җаны китә, ачылырмы капка?

## Эт — татар

*Спи, младенец! Не то злому*
*Псу-татарину отдам!*

М. Цветаева

Күтәр, төшер, менгер, татар!
Муенга ас!
Өстерә!
Мәгърипкә җит!
Шәрыкны ал —
Әнә хуҗаң өстерә.

Без беркемнең баласын да
Алмадык тартып ансы...
Йокласын ул төшләр күреп
Һәм елмаеп уянсын.

Үссен, типкәләсен безне,
Түзәрбез, димә, ничек? —
Койрыгы кисек этләр сез!
Һәм мин үзем дә көчек...

Куалар юлдан һай-һулап,
Җирдә юк безгә бәһа.

Безнең кан белән тукланган
Юха күптән аждаһа.

Сиңа дигән тәре, татар!
Җилкәгә сал!
Өстерә! —
Ишәйгән әнчекләреңне
Синең өскә өстерә.

Өрмибез инде, шыңшып тик
Көч сорыйбыз Алладан...
Ә алар безнең исемне
Бүки итә ич һаман.

... Йом күзеңне, беркем тимәс...
Тик бәхилләш, әй бала —
Алабуга өсләрендә
Шомлы гәүдә чайкала!

# КЕШЕЛӘРНЕ ЯКЛАП ЯШӘДЕ



Гомере буена шигырь язып, бу гүзәл һәм авыр иҗатка тугры калган шагыйрьләребез бармак белән генә санарлык дисәк, ялгышмабыздыр. Ярты юлда бүтән жанрларга күчеп иҗат итә башлаучыларны гаепләмим. Ә тугрылар оттырмады. Авырлык белән, газап белән булса да шигърият тавына менеп җиттеләр алар.

Нури ага Арсланов та шундый шагыйребез иде. Дөрес, ул күп еллар төрле редакцияләрдә рәссам булып эшләде. Шигырь тамак туйдырмаганлыктан, шагыйрьнең кайдадыр, кемдер булып эшләве безнең татарда табигый нәрсә.

Нури ага бәхетле булды, озын гомер кичерде. Тугрылыгы, турылыгы, киң күңелле булуы, бар барлыгы белән кешеләрне яклавы, халкыбызны канлы тарихы белән бергә яратуы — аның гомерен озайткандыр. Үз халкының бөтен әрнү-газапларын җаны аша кичергән, кайгы-шатлыклары белән яшәгән шагыйрь халкына зур мирас та калдырды. Олылардан — олы мирас кала. Ә әдәбияттагы кәрләләрдән берни дә калмый диярлек.

Ул дистәләрчә шәкертләр тәрбияләп үстерде, 3 томлык шигырь, 2 томлык югары дәрәҗәдәге тәрҗемәләр калдырды. Үзе исән чакта ук халыкның мең-мең рәхмәтен ишетте.

Шагыйрь гомере буена дөреслек өчен дөрләде-янды. Әгәр яшәешебездә дөреслек җиңеп килгән булса — ихтимал, ул әле йөзгә кадәр яшәр иде. Тагын шуны ассызыклап үтәсе килә: бу арслан җанлы шагыйрьдән үзе үлгәч куркучылар кимемәде. Куркып яшәгән булса, куркаклык аның гомерен бик күпкә кыскарткан булыр иде. Димәк, шигърият белән батырлык — бертуганнар. Аларны бер-берсеннән аерып булмый. Аерсаң — шигърият булмый. Шәкертләренә ул бу турыда бик еш сөйли иде.

Шагыйрь быелтыр 14 апрельдә фани дөнья белән саубуллашып, безне һәм шигъриятне ятим калдырып китеп барды. Соңгы көннәрендә ул шигърияттән, димәк, дөньядан аерылырга туры киләчәген уйлап моңайды. «Кара урман» җырын кат-кат җырлады һәм... елады.

Укучыларыбызга тәкъдим ителә торган әлеге шигырьләр шагыйрьнең архивыннан алынды. Бу шигырьләр — аның иҗатының бер юнәлешендәге сызмалар гына. Үзе исән чакта беркайда да бастырмаган ул аларны. Боларын да, тагын бик күп басылмаган шигырьләрен дә безгә укырга вакыт җитте. Алар шагыйрьнең зурлыгын аңларга ярдәм итәрләр. Мирас булып калган байлыгыбызны барлый белик.

**Рәшит ӘХМӘТҖАН**

# Нури Арсланов

## Тотыла

Акылсызлар — акыл сата,
Акыллы — башын кашый...
«Ялаган» гел килеп каба,
«Ашаган» һаман ашый.

Элек каракны бик ансат
Тотканнар: «Бүреген яна!»
Хәзер карак, бүреге янса,
Бүтәннең бүреген ала.

Үз-үзен «үлемсез» ясый
Бюрократ дигәннәре.
Урламаса, ришвәт ашый
Замана бирәннәре.

Корткычлар шулай бер мәлгә
Котыра котыруын..
Күпкә түгел — шөкер әл дә —
Тотыла тотылуын.

*3 декабрь, 1981.*

## Яхшы сабак

*М. Ә. чыгышыннан соң.*

Бер күргәндә, ике кулын кушырып:
Остаз, акын, диде.
Бер күргәндә, михрабымнан төшереп,
Сабак, акыл бирде.

Тәңрем! Бу кай ягы белән торган?
Тәмам телдән калдым.
Үзем сабак биргән «сабакы»дан
Яхшы сабак алдым...

Шул кирәк,
тайларга өер булып йөрмәссең!

*24 июль, 1979. Бакчада.*

* * *

Ничек инде
Шушы башым белән
Вакланырга?! — дидең.
Ә бит «шушы»ң
Синең башың түгел,
Утыра торган җирең.

*7 октябрь, 1978.*

## Кәрлә

*Әссагыйрәте фитнәтен.*[1]

Кәрлә дә бит тәңресенә бәндә:
Ис китәрлек эш мени бу әллә?!
Тик очрады берәү — җаны кәрлә,—
Юк бер мәгънә — теләсәң күпме әрлә...

*27 июнь, 1979.*

## Син беркем дә түгел

*Бер шагыйрьгә*

Баштанаяк бутафория элгән:
Татар кылычын, татар калканын
Кемдер аңа прокатка биргән,—
Сөйли «ничек Мәскәү алганын».

Сенсация өчен кәгазь сырлый,
Менеп экзотика үренә.
Рус телендә татар булып җырлый,—
Уйный татар батыры ролендә.

Бар мәйданы аның бер төп бүкән,
Орчык сыман шунда бөтерелә:
«Мин рус түгел, ди ул, нәселем бүтән,—
Казаннарга барып төртелә!»

Сакау кәкүк төсле кычкыра ул,
Татар булган булып кылана;
Сайрамый, тик эчне пошыра ул,
Шәҗәрә ни, халык ни аңа?!

Бүтәннәрне шаккатырмак булып
Йөри шулай илереп, каңгырып,
Өне чыкмый йөрәгеннән ургып,
Бугазыннан чыга карлыгып.

[1] Карсак кеше фетнәче була. Гарәпчә.

Арзан эффект — ансат кәсеп, шулай,
Сафсатаны җайлы сатарга.
Карап торам сиңа, син бит болай
Рус та түгел, түгел татар да.

*1975.*

* * *

Ике түрә: олысының буе озын,
Кәрләсенең озыннан да уе озын.
Икесен дә кабул иткән әдәбият,
Икесендә бер тамчы юк әдәп-оят.
Кәрләсенә бодай ярыгы да упкын,
Озынына ут кадерле түгел,— утын!
Кәрлә — бик сак, үз «упкыны» буйлап бара.
Ә олысы — гомер буе утын яра.

Ике түрә: берсе озын, берсе тапал,
Менә безнең башлар нинди хәлгә попал...

*Июнь, 1973.*

## Гөнаһе кәбаир

Утыз җиденчедә, агу биреп,
Син төрмәдә аны үтердең!
Илле җиденчедә әсәренә
Мактау сүзе язып китердең.

Кайда вөҗдан синдә? Нәрсә вөҗдан! —
Алар үлгән, алар белмиләр.
Доноска да акча түләделәр,
Намуска да, сатсаң, түлиләр.

*1957—1974.*

## Таяк бәете

Кавказдан таяк кайта[1],
Казанга карап кайта:
Пар аякка терәк таяк,—
Өченче аяк кайта.

Ерак кавказ яклары.
Дуслар сүзен аклармы?
Таянырга җайлы диләр
Унцукүл таяклары.

[1] *Нури абый, югалган таягың урнына Кавказдан менә диген таяк кайтартабыз үзеңә! диделәр миңа рәхмәт төшкере Рәшит Әхмәтҗановлар.*

Һай дусларым, дусларым,
Дуслар, тоар-ишләрем,
Таяк, таяк дип калсам так,
Ялгыз башым нишләрем!

Юк борчулар басмасын,
Дуслар кәефе качмасын,—
Кайтартсыннар гына таяк,
Үзем түлим акчасын.

*1980.*

* * *

Иген кырларына бәрәкәт кунмый
Басып китсә сарут, билчән генә;
Күп сүзнең дә игелеге булмый,—
Син дә чичән түгел, телчән генә.

*1972.*

## Аера күрмә

Язмыш! Игелек күрсәтмәдең бер дә...
Ярый әле бәндәң күнеккән:
Бәхетсез дә яшәп була җирдә,
Тик аера күрмә өметтән.

*18 май, 1988.*

## Ялгызлык

*Мин көтәм Җибрил килә, дип, бер матур илһам белән:*
*Ул килә, миндә тупас рух, нишләсен килгән белән?!.*

Сәгыйт Сүнчәләй.

Сүреләм инде, бөтенләй сүреләм,
Үземә—үзем сөйкемсез күренәм.

Коела инде гөлләрем, коела...
Карам ак, акларым кара тоела.

Алҗыдым бугай инде мин, алҗыдым,—
Аңламый башладым тормыш калҗынын.

Нуры юк инде күзләрнең, нуры юк,
Элеккедәй көр күңелле Нури юк...

Гаепли бугай кешеләр, гаепли;
Миңа инде хуплау ни дә, гаеп ни?!.

Әрни йөрәк, тәкатем юк, сызланам,—
Килеп житте шәхсән кызыксыз заман.

Яхшылыгым өстенлеген ташлады,
Яманлыгым өскә чыга башлады.

Күпме еллар хезмәт иттем хикмәткә,—
Җанварлыкны булмый икән нишләп тә.

Йөрәк әйтә: — Биздем инде, биздем,— ди.
Ә шигърият һаман килә сиздерми.

Карангалап карактай шигърем килә,
Рәнжү-сыкраулар белән шыгырым килә.

. . . . . . . . . . . . . . . . .
. . . . . . . . . . . . . . . . .

Бер бушаныр идем җылап,— яшем юк,
Күкрәгән дә була күгем, яшен юк.

Җилкенә җаным алай да, җилкенә,
Җилкенсә дә башкаларга җик кенә...

Яшел ярын табып булмый күземнең,
Зәгъфранын алып булмый йөземнең...

Ашыкмыйм, төшмим — хәзер күк тә, җир дә бер...
— Озак йөрмәссең, килерсең! — ди кабер.

*22 август, 1985*



## ДРАМАТУРГИЯ

**Туфан Миңнуллин**

# ИЛГИЗӘР + ВЕРА

ИКЕ ПӘРДӘЛЕ ДРАМАТИК ХИКӘЯ

**КАТНАШАЛАР:**

НУРХӘМӘТ — 75 яшьләр тирәсендәге татар карты.
ХӘЛИУЛЛА — 45 яшьләрдә, Нурхәмәтнең улы.
ДАНИЯ — 40—45 яшьләрендә, Хәлиулланың хатыны.
МАРИЯ — Нурхәмәтнең кордашы, рус карчыгы.
АЛЕКСЕЙ — Хәлиулланың яшьтәше, Мариянең улы.
НАТАЛЬЯ — 40—45 яшьләрендә, Алексейның хатыны.
ИЛГИЗӘР — 17 яшьтә, Хәлиулланың улы.
ВЕРА — 17 яшьтә, Алексейның кызы.
ТУЙ АГАСЫ.
НИНА.
ИСЛАМ.
I — ИР.
II — ИР.
I — ХАТЫН.
II — ХАТЫН.

Авыл кешеләре: кияүләр, кәләшләр, туйлардагы кунаклар.

### БЕРЕНЧЕ ПӘРДӘ

**Иделдән ерак түгел генә җәелеп утырган Җикән авылы. Авылның яртысында татарлар яши, яртысында — руслар. Бүген бу авылда туй. Татар туе. Туйның кызган чагы. Кунаклар өйгә сыешмыйча ишегалдына чыгалар. Гармунчыга дигән урындыкны баш очына утыртып бии-бии Туй агасы чыга. Урындыкны ишегалды уртасына куя. Гармунчы үз дәрәҗәсен үзе белеп шул урындыкка урнаша, бию көен уйнавын дәвам итә. Өйдән чыккан кунакларның берише биюгә кушыла, кайсылары биючеләргә куәт биреп кул чабып тора. Туй агасы үзенең көр тавышы белән шундый әмер бирә.**

ТУЙ АГАСЫ. Шым кал!.. Үррә кат!... Селкенмә!... Берәү дә бер сүз дәшми, беркем дә бернини хәрәкәт ясамый. Үррә кат! Кияү белән кәләш, түгәрәк уртасына рәхим итегез. *(Кияү белән кәләш уртага чыгып баскач, гармунчыга әмер бирә.)* Башла! *(Гармунчы яңа бию көен уйный, кияү белән кәләш татарчалап бииләр. Калганнар, әлбәттә, җырлап биючеләргә дәрт өстәп торалар.)*

Әй, биегез, биегез,
Уйнагыз да көлегез.
Бүген сезнең тыпыр-тыпыр
Бии торган көнегез.

Әй, кияве, кияве —
Егетнең бер дигәне.
Йөрешләренә килешле —
Асыл заттыр сөяге.

Әй, биегез, биегез,
Матур икән көегез.

Матур көйгә матур итеп
Биеп туймас көнегез.

Әй, каләше, каләше —
Кызларның бер генәсе.
Эшкә уңган, төскә булган
Гүзәл затлар иясе.

Әй, биегез, биегез,
Күккә йолдыз чөегез.
Киләчәктә шатлык белән
Балкып торсын өегез.

НАТАЛЬЯ *(уртага атылып чыгып)*. Иптәшләр! Дуслар!..

ТУЙ АГАСЫ: Наташа апа! Минем рөхсәттән башка беркем дә бер сүз әйтми.

НАТАЛЬЯ. Туктале, энекәем!

ТУЙ АГАСЫ. Мин сиңа энекәем түгел — туй агасы. Туйга мин хужа. Әйтәсе сүзеңне өстәл янында әйтергә иде. Монда бию һәм жыр гына.

НАТАЛЬЯ. Әйтим инде бер сүз, энекәем. Күңелемнен ташкан чагы.

ТУЙ АГАСЫ. Күңелеңнең ташкан чагы булса, әйт инде алайса. (Кунакларга мөрәҗәгать итеп.) Әйтсенме, иптәшләр? Рөхсәт итәбезме?

ТАВЫШЛАР. Әйтсен, әйтсен!..

НАТАЛЬЯ. Авылдашларым! Бәгырькәйләрем! Нәрсә генә әйтим икән. Әйтәсе сүзләрем шул чаклы күп. Күз генә тимәсен иде. *(Каләшне кочаклап.)* Карагыз инде моңа. Сокланып туймаслык бит. Бәхеткәйләр телим үзеңә, сеңелкәем! Әтиең, әниең дөнья бәясе кешеләр — бәхетле булырсыз. *(Кияүне кочагына алып.)* Монысын карагыз инде — сөеп туймаслык лабаса. Әйтсәм әйтим инде, әтиеңә гашыйк идем мин синең. Әтиең миннән дә матурракны алды шул. Миңа менә шушы Алексей эләкте инде. *(Ире Алексейны уртага тартып чыгарып.)* Яле, Алеша, бәгырь кисәгем, әйтик әле кияү белән каләшкә иң матур сүз. Бүген бит аларның иң бәхетле һәм иң җаваплы көннәре. Алар бүген озын-озак юлга чыгалар. Бәхет ясын алар барасы юлга. Синең белән минем кебек матур яшәсеннәр. Әйдәле, алар хөрмәтенә сузыйк әле үзебезнең иң яраткан җырыбызны. *(Гармунчыга)* Габдрахман энекәем, безнең җырны беләсеңме син? *(Гармунчы шунда ук рус халкының «Зачем тебя, милый мой, узнала» җырын уйный башлый. Наталья җырлый, аңа Алексей кушыла.)*

Зачем тебя я, милый мой, узнала,
Зачем ты мне ответил на любовь?
Ах, лучше бы я горюшка не знала,
Не билось бы сердечко мое вновь.
Терзаешь ты сердечко молодое,
Тебя твоя зазнобушка зовет...
Проходит только время золотое,
Зачем же ты, желанный, не идешь?
Я жду, и вот приходит долгожданный,
Целует, нежно за руку берет.
Ах, милый друг,
мой нежный друг желанный!
И сердце песню радости поет.

*(Җыр туктагач, Наталья русча итеп кунакларга башын ия.)* Рәхмәт сезгә, авылдашлар, җырымны күтәреп алдыгыз. *(Шулчак Ислам тавышы ишетелә. Тавышы матур, килешле, авылча. Ул үзенең һәрвакыттта да җырлый торган җырын җырлый — татар халкының «Кыр казы» дигән җыры.)*

ИСЛАМ.

Кыр казлары очты, күрдегезме
Һаваларга менеп киткәнен?
Кыр казы
Иделләр читендә,
Ялгыз башым миңа читен лә.
Беләсеңме, дустым, сизәсеңме
Аерылулар килеп җиткәнен?
Кыр казы
Суларда уйный шул,
Ялгыз башым гел сине уйлый.

ТУЙ АГАСЫ. Булдымы? Җырлап бетердеңме?

ИСЛАМ. Икенче куплеты бар, беләдеңме?

ТУЙ АГАСЫ. Анысы икенче туйда, ярыймы?

ИСЛАМ. Син нигә гел, мин җырлаганда, килеп кысыласын, ә?

ТУЙ АГАСЫ. Туй бит бу. Туйда бер син генә түгел.

ИСЛАМ. Бер син генәме?

ТУЙ АГАСЫ. Ярый, ярый, булды. Җәмәгать, күңел ачуны дәвам итәбез. Яле, Дания апа, әйттер әле берне.

ДАНИЯ. Нигә? Әйттерәм. Бер яшьлектә, бер картлыкта. Әйдә, Наташа. *(Такмак әйтә башлый. Аңа Наташа кушыла.)*

Әйдә бас, бас әйдә,
Биеп калыйк бу җөйдә.
Ике матурның туенда
Тагын берне бас әйдә.

Бас әйдә, бас әйдә,
Биеп күңел ач әйдә.
Биемибез дигәннәргә
Ялынмыйбыз, бигайбә.

**Икәүләп кодаларны биергә чакыралар.**

Кодалар, кодалар —
Уңганнар һәм булганнар.
Кодагыйларга карагыз
Дөнья бизи торганнар.
Балдызлар да кайнешләр,
Барыгыз да беришләр.
Атна саен туй ясарбыз
Гел болай барса эшләр.

**Ишегалдында аягына басып тора алган һәр адәм баласы бии башлый. Бии-бии кайберәүләре арып туктый. Бара-тора уртада Илгизәр белән Вера гына калалар. Алар дөньяда үзләреннән башка беркемне дә күрми бииләр. Бераздан гына аңнарына килеп туктыйлар да арттырып җибәргәннәреннән оялып чыгып йөгерәләр. Туй дәвам итә. Андагы көлеш шау-шу карт өянке астындагы эскәмиядә утырган Нурхәмәт белән Мариягә дә килеп житә.**

НУРХӘМӘТ. Мифтахетдиннәрдә инде бу галәмәт, Маруся күрше.

МАРИЯ. Алар нәселе бәйрәм ясый белә инде ул. Карале, Нурхәмәт күрше, кайсы елны ул без синең белән кара-каршы төшеп биегән идек?

НУРХӘМӘТ. Безнең биегәннәрне санасаң...

МАРИЯ. Юк, анысы үзенә бер төсле бию булды ул. Әле дә хәтеремдә...

НУРХӘМӘТ. Сезнеңчә биегән идекме, безнеңчәме?

МАРИЯ. Сезнеңчә дә, безнеңчә дә. Кайсыбыз алдан арып туктар дип биергә тотынган идек, мин арый башлаганны син сизеп алдың да арыган булып егылдың.

НУРХӘМӘТ. Юктыр, мин үзем арыганмындыр. Сине биетеп арытып булмый иде. Маржа биеп арый димени ул, Маруся күрше. Сез бит биергә бик маһир халык.

МАРИЯ. Сез дә кимен куймыйсыз.

НУРХӘМӘТ. Анысы шулай, кәнишне... Тыңлале, бу синең килен тавышы бит. Уңдын киленнән, молодец синең Әләкчәй.

МАРИЯ. Күз тимәсен, синең килен дә бик уңган.

НУРХӘМӘТ. Уңуын уңдым да, малай бик юаш булып чыкты минем, Маруся күрше... Кара ничек сиптерәләр, ә?.. Шулай инде, безне хәзер туйга да чакырмыйлар.

МАРИЯ. Нишлисең инде. Оныкларыбызның туенда утырсак кына.

НУРХӘМӘТ. Күзле бүкән булып дисеңме?

МАРИЯ. Нишләп, биербез дә әле, биетсәләр. Сездә туй булса, әйтерсең, Марияне чакырыгыз диярсең, бездә булса, мин сине үзем кереп чакырырмын. Шунда яшь чакларны искә төшереп бер биербез дә әле. Синең хәтер начарлана бара шул, Нурхәмәт күрше, икәү каракаршы төшеп биегәнне дә оныткансың.

НУРХӘМӘТ. Онытмадым ла инде... Булды инде, ходай хәерле кылсын.

МАРИЯ. Хәзер ходай дип утырасың. Ул чакта...

НУРХӘМӘТ. Йә инде, искә төшермә инде.

МАРИЯ. Ояласыңмыни, карт төлке.

НУРХӘМӘТ. Үзең бит...

МАРИЯ. Нәрсә үзең? Мин нишләгән?

НУРХӘМӘТ. Чибәр идең бит.

МАРИЯ. Чибәр дигәч тә, юлда тотып үбәләр димени?

НУРХӘМӘТ. Үзең дә качмадың бит.

МАРИЯ. Кая качыйм? Инеш юлы — тар сукмак. Ике ягы шомыртлык.

НУРХӘМӘТ. Шомыртлык шул, шомыртлык, мать честная. Шулай инде. Шулай шул...

> Ап-ак, ап-ак каз итләрен
> Ах, ты, Маруся,
> Мин турадым, син аша.
> Ах, ты, не бойся!
> Пущай безне рассуждают,
> Ах, ты, милая,
> Кил утырыйк янәшә,
> Кому какое дело?!

Ә, Маруся?.. Шулай бит?..

МАРИЯ. Шулай иде, Нурхәмәт, шулай иде.

НУРХӘМӘТ. Ярый, Маруся күрше, керим инде мин. Әллә нәрсә, билләр дә сызлап тора.

МАРИЯ. Сау бул, Нурхәмәт күрше. Исән-сау очрашырга язсын.

НУРХӘМӘТ. Шулай булсын, күрше, шулай булсын.

**Икесе ике якка китәләр. Туй шау-шуы дәвам итә. Йөгереп Илгизәр белән Вера керәләр. Карт өянке янында туктыйлар. Кочаклашып үбешәләр. Ут сүнә. Ут янганда, инде икенче туй бара. Рус туе. Әлегә аның тавышы гына ишетелә. Аны Нурхәмәт белән Мария тыңлый.**

НУРХӘМӘТ. Менә китте дөнья, ә? Бер атна гына элек Мифтахетдиннәрдә туй булды, бүген Микулайлар гуләйт итә.

МАРИЯ. Кай арада үсеп житәләр диген син малайлары.

НУРХӘМӘТ. Кызлар өлгергәч, малайлар үсә инде ул. Кем кызына өйләнгән соң Микулайның малае?

МАРИЯ. Иваннар белән кода булдылар инде.

НУРХӘМӘТ. Кайсы Иван? Чтапан Иванымы?

МАРИЯ. Юк ла инде. Степан Иванының кызы юк ич. Теге Аграфена малае Иванның кызы. Беләсеңдер лә. Правлениедә утыра ич инде. Ак чәчле.

НУРХӘМӘТ. Сез барыгыз да ак чәчле, кем белеп бетергән.

МАРИЯ. Син үзең бик кара инде.

НУРХӘМӘТ. Бар иде чәчләрнең чем-кара чаклары, Маруся. Бар иде. Хәтерлисеңме, без синең белән кара-каршы төшеп биегән идек?

МАРИЯ. Безнең биегәннәрне санасаң...

НУРХӘМӘТ. Юк, анысы үзенә бертөсле бию булды ул.

МАРИЯ. Син арып егылдың. Шуны әйтәсеңме?

НУРХӘМӘТ. Арып түгел лә инде, арыган булып кына, синең алда...

МАРИЯ. Докажи.

НУРХӘМӘТ. Соңрак шул инде доказать итәргә, Маруся. Картайдык, күрше, картайдык.

МАРИЯ. Әй, шыгырдап утырма әле, карт әянке кебек. Тоже мне старик.

НУРХӘМӘТ. Ты не старуха што ли?

МАРИЯ. Старуха не старуха, синең кебек зарланып утырмыйм. *(Урыныннан тора.)*

НУРХӘМӘТ. Кая киттең әле?

МАРИЯ. Туйларын карап кайтам әле Николайларның.

НУРХӘМӘТ. Мине калдырып китәсеңме?

МАРИЯ. Нәрсә, парлап барыйк дисеңмени кеше туена. Чакырылмаган килеш. Әйдә, ишегалдында биииләр бугай. Читтән генә карап кайтыйк.

НУРХӘМӘТ. Килешер микән?

МАРИЯ. Килешмәсә, кал... Без бит анда ашарга-эчәргә сорап бармыйбыз.

НУРХӘМӘТ. Әйдәле, бер кызык булсын әле. Килен күрсә, яхшы түгел инде түгелен.

МАРИЯ. Ир башыннан килененнән куркып торасыңмы? Татар булган килеш.

НУРХӘМӘТ. Әй, Маруся. Татар киленнәре хәзер... Беләсең инде үзең... Киттекме?

МАРИЯ. Подручком барабызмы?

НУРХӘМӘТ. Әллә куркыр дисеңме?! *(Маричне култыклый.)*

МАРИЯ *(кулын тартып алып).* Кит, юньсез. Син тилегә әйткән мин җүләр. *(Чыгып китәләр. Ә Николайларның ишегалдында туй гөр килә. Монда да Наталья уртада. Нина исемле бер хатын белән бергәләп частушкалар әйтә-әйтә бииләр.)*

НАТАЛЬЯ.

Ой, «подгорная», «подгорная»
Веселая игра.
Все бы пела, все бы пела
Все бы пела до утра.

НИНА.

Я «подгорную» плясала
Меня мама уняла.
«Рано, дочка, гулять стала,
Рано волюшку взяла.

НАТАЛЬЯ.

Не хотела я плясать,
Не хотела выходить.
Гармонист такой хороший —
Ему надо угодить.

НИНА.

Поиграй повеселее,
Раньше ты мне играл.
Неужели не сознаешься
Что ты со мной не гулял?

ГАРМУНЧЫ.

Сам играю, сам пою
Подпевать-то некому.
Дайте мне подпевочку
Лет семнадцать девочку.

НАТАЛЬЯ.

Гармонист, гармонист,
Не гляди глазами вниз.
Гляди прямо на меня,
Завлекать буду тебя.

НИНА.

Сыграй, сыграй, припою,
Чтобы раздавалося.
Про измену про твою
Давно я догадалася.

ГАРМУНЧЫ.

Ты не лай, не лай собачка —
У крылечка дамочка.
Ты послушай-ка, милашка.
Как ревет тальяночка.

НАТАЛЬЯ, НИНА *(икәүләп).*

Ой, спасибо, гармонист,
За игру отличную.
Мы еще тебе желаем
Милку симпатичную.

НАТАЛЬЯ. Ой, спасибо, мои дорогие! Спасибо милые! *(Баш ия.)*

ТУЙ АГАСЫ. Прошу внимания. Жених и невеста. Прошу, жених. Прошу, невеста. *(Кияү белән кәләшне кулларыннан тотып уртага чыгара.)*

ИСЛАМ *(уртага чыга).* Мин инде, җәмәгать, сүз әйтә белмим.

ТУЙ АГАСЫ. Әйтә белмәсәң, әйтмә.

ИСЛАМ. Син тик тор, агай-эне, белдеңме!

ТУЙ АГАСЫ. Минем тик торырга хакым юк. Мин — туй агасы, бу туйның хуҗасы.

ИСЛАМ. Бу туйның хуҗасы — Микулай белән Татьяна. Мәнә мин алар хөрмәтенә бер җыр җырлыйм. Син читкә китеп тор, ямe.

ТУЙ АГАСЫ. Һаман шул җырыңнымы?

ИСЛАМ. Анда синең эшең юк, белдеңме. *(«Кыр казы»н җырлый.)*

Кыр казлары очты, күрдегезме,
Һаваларга менеп киткәнен?
Кыр казы
Иделләр читендә,
Ялгыз башым мина читен лә.

ДАНИЯ. Бетмәде шул җырың. Туйда җырлый торган җырмы инде?!

ИСЛАМ. Синең ни эшең бар минем җырда?

ДАНИЯ. Туйда күңелле җыр җырларга кирәк.

ИСЛАМ. Бик күпне беләсең. Хәлләңне өйрәт, белдеңме?

ДАНИЯ. Хәлиулланы өйрәтәсе юк, ул син түгел.

ИСЛАМ. Миңа ни булган, ни булган?

ДАНИЯ. Бернәрсә дә булмаган. Кит, болганма.

ИСЛАМ. Китәрмен мин сиңа.

ДАНИЯ *(Исламга игътибар итмичә гармунчы каршына бара).* «Барыйна»ны уйна! *(Гармунчының уйный башлаганын да көтмичә такмак әйтә-әйтә бии.)*

Әй, барыйна, барыйна,
Күзләреңә карыйм ла,
Күзләреңә карый-карый
Керфекләрең саныйм ла.
Әй, барыйна, барыйна,
Сударыйна-барыйна.
Әй, барыйна, барыйна,
Бер озата барыйм ла.
Кеше кара күрмәгәндә
Бер кочаклап алыйм ла.
Әй, барыйна, барыйна,
Сударыйна-барыйна.

Әйдәгез! Әйдәгез! *(Бүтәннәрне дә биергә чакыра.)*

Әй, барыйна, барыйна,
Булыйм сөйгән ярың ла.
Җаның сөйгән ярың булып
Яннарыңда калыйм ла.
Әй, барыйна, барыйна,
Сударыйна-барыйна.

**Кунаклар барысы да ду килеп бии. Алгы планда Илгизәр белән Вера сиптерә. Аларның биегәнен Нурхәмәт белән Мария карап торалар. Менә Илгизәр белән Вера йөгереп чыгып китәләр. Туй биеп кала. Илгизәр белән Вера карт өянке янына чабышып киләләр. Сулулары капкан, икесе дә көлешәләр. Үбешеп алырга да оныкмыйлар.**

ВЕРА. Шундый рәхәт миңа, Илгизәр.

ИЛГИЗӘР. Миңа да.

ВЕРА. Нигә рәхәт икән ул, Илгизәр?

ИЛГИЗӘР. Ә мин каян белим.

ВЕРА. Ничек инде белмисең?

ИЛГИЗӘР. Беләсем дә килми. Рәхәт булгач рәхәт инде.

ВЕРА. Мине яратасыңмы син, Илгизәр?

ИЛГИЗӘР. Яратам, билгеле.

ВЕРА. Өзелеп яратасыңмы?

ИЛГИЗӘР. Өзелеп яратам, билгеле.

ВЕРА. Ничек итеп яратасың?

ИЛГИЗӘР *(Вераны үбеп ала).* Менә шулай итеп.

ВЕРА. Ни өчен яратасың, Илгизәр?

ИЛГИЗӘР. Каян белим.

ВЕРА. Ничек инде белмәгән килеш яратасың?

ИЛГИЗӘР. Син мине ни өчен яратасың соң?

ВЕРА. Мин сине яратам дип әйтмәдем ич.

ИЛГИЗӘР. Яратмагач, нигә үбешәсең соң?

ВЕРА. Рәхәт булганга. *(Көлешәләр һәм, әлбәттә, үбешеп алалар.)*

ИЛГИЗӘР. Әйдә без дә туй ясыйбыз.

ВЕРА. Нинди туй, Илгизәр?

ИЛГИЗӘР. Өйләнешәбез дә туй ясыйбыз.

ВЕРА. Туйны бит аны өйләнешкәннәр ясамый, әти-әниләре ясый.

ИЛГИЗӘР. Безнекеләр дә ясарлар. Әллә ясамаслармы?

ВЕРА. Ә ни өчен өйләнешәбез, Илгизәр?

ИЛГИЗӘР. Менә кызык. Бергә яшәргә.

ВЕРА. Ә ни өчен бергә яшәргә?

ИЛГИЗӘР. Кара... Син нәрсә, миннән көлеп утырасың?

ВЕРА. Мин көлмим, Илгизәр.

ИЛГИЗӘР. Алайса, нигә гел сорау биреп утырасың?

ВЕРА. Ә син җавабын тап.

ИЛГИЗӘР. Бик кирәге бар.

ВЕРА. Алайса, син сорау бир, мин җавабын эзлим.

ИЛГИЗӘР. Минем соравым юк.

ВЕРА. Бер генә, бер генә дә соравың юкмы?

ИЛГИЗӘР. Юк.

ВЕРА. Илгизәр. Тагын бер генә сорау бирим инде. Син нигә миңа исемем белән эндәшмисең? Мин сиңа Илгизәр дип кенә торам. Ә син бер генә тапкыр да миңа Вера дип эндәшкәнең юк.

ИЛГИЗӘР. Бер дәме?

ВЕРА. Бер тапкыр да юк.

ИЛГИЗӘР. Белмим. Миңа барыбер.

ВЕРА. Миңа барыбер түгел.

ИЛГИЗӘР. Ишет инде алайса. Вера́, Вера́, Вера́, Вера́, Вера́!

ВЕРА. Вера́ түгел, Илгизәр, Ве́ра.

ИЛГИЗӘР. Барыбер инде ул.

ВЕРА. Барыбер түгел, Илгизәр.

ИЛГИЗӘР. Кара, нигә бәйләнәсең әле миңа?

ВЕРА. Хатын-кызлар бәйләнә инде ул, Илгизәр. Төзәсең инде. Төзәсеңме?

ИЛГИЗӘР. Бик исем китте. Рәхәтләнеп бәйләән. Безнең әни әтигә гел бәйләнә, әтинең исе дә китми. Башын иеп тик йөри.

ВЕРА. Син дә, өйләнгәч, башың иеп тик йөрерсеңме?

ИЛГИЗӘР. Әни әйтә, син мина охшагансың, ди.

ВЕРА. Маменькин сынок инде алайса.

ИЛГИЗӘР. Үртәмә диләр сина...

ВЕРА. Үртәсәм, нишләтәсең?

ИЛГИЗӘР. Нишләтәмме? *(Вераны үбәргә үрелә, Вера тайпылып өлгергәч.)* Нишлисең, ә?

ВЕРА. Үптерәсем килми.

ИЛГИЗӘР. Менә кызык. Кызык икәнсең син. Әле яңа гына үбештең ич.

ВЕРА. Яңа гына үбештек, хәзер үбешәсем килми.

ИЛГИЗӘР. Ни өчен?

ВЕРА *(кычкырып көлеп)*. Соравым юк дигән идең, ике сорау бирдең. *(Илгизәрне үбеп ала.)* Әйдә, Илгизәр, жырлыйбыз.

ИЛГИЗӘР. Мин жырлый белмим.

ВЕРА. Мин жырлыйммы?

ИЛГИЗӘР. Җырла.

ВЕРА. Синең өчен жырлыйм, ярыймы? Кайсы жырны жырлыйм?

ИЛГИЗӘР. Мина барыбер.

ВЕРА. Сиңа бөтенесе дә барыбер икән.

ИЛГИЗӘР. Мина, син булгач, житкән.

ВЕРА. Ярый, тыңла алайса. *(Әкрен генә җырлый.)*

Вот и встретились!.. Вот и прощаемся...
Как натянуто мы улыбаемся.
Что ж друг к другу с тобою мы тянемся,
Если будучи вместе маемся.

Вот и встретились!.. Вот и прощаемся...
Может быть, навсегда разлучаемся.
Вот и встретились! Вот и прощаемся.
И с тоскою запоздалою каемся.

Что ж мы каемся, что ж мы маемся,
Вряд ли когда-нибудь догадаемся.
Вот и встретились!.. Вот и прощаемся.
Может быть навсегда разлучаемся.

**Ут сүнә. Сәхнә яктыргачда Хәлиуллаларның өй эчен күрәбез. Сәхнәдә берәү дә юк. Ишек шакыйлар. Чаршауны ачып, чаршау артындагы караваттан торып, Хәлиулла чыга. Утны яндыра. Чолангә чыгып ишекне ача. Аннан Алексей белән керә.**

АЛЕКСЕЙ. Ачуланма инде, Хәллә.

ХӘЛИУЛЛА. Нишләп ачуланыйм, уз әйдә.

ДАНИЯ *(Чаршау артыннан)*. Алексей, синме сон ул?

АЛЕКСЕЙ. Мин әле, Дания. Төнлә йөргәнгә ачуланмагыз инде.

ДАНИЯ. Берәр нәрсә булмагандыр ич?

АЛЕКСЕЙ. Булуын булмады да. Киллем әле. Наташа йөрмә төнлә кеше борчып дигән иде дә, киллем әле. Хәллә белән сөйләшәсе сүз бар иде. Хәллә, капка төбенә чыгып утырыйк.

ДАНИЯ. Килешмәгәнне. Өйгә кергәч. *(Чаршау артыннан халатын киеп чыга.)* Уз әйдә, утыр. Хәлиулла, нәрсә катып калдың? Ки чалбарыңны. Сәгать ничә соң әле?

АЛЕКСЕЙ. Соң инде, Дания. Ачуланма инде.

ДАНИЯ. Юк сүз сөйләп торма әле. *(Өстәл янына урындык куеп.)* Утыр. Мин — хәзер.

АЛЕКСЕЙ. Мина берни дә кирәкми.

ДАНИЯ. Тик кенә утыр. Хәлиулла, кая югалдың инде? Уяна алмыйсың мәллә?

ХӘЛИУЛЛА *(чалбарын киеп чыгып)*. Хәзер, хәзер. Бармы соң безнең?

ДАНИЯ *(өстәл әзерли-әзерли)*. Нишләп булмасын инде.

АЛЕКСЕЙ. Зинһар, борчылмагыз! *(Хәлиулла өстәлгә шешә куйгач.)* Кирәкми.

ДАНИЯ. Йә, йә. Күрше булсагыз да көн саен кереп тормыйсыз. Наташаны да алып керергә иде. Бәрәңгеләр алынып бетте, кешеләр туй ясый. Безгә дә бер утырып алырга ярыйдыр инде. Бар, Хәлиулла, алып чык Наташаны. Кермим дисә, сөйрәп алып кер.

АЛЕКСЕЙ. Юк, юк, Дания, кирәкми. Зинһар. Мин Хәллә белән генә...

ДАНИЯ. Син Хәллән белән сөйләшерсең, сезнең сүзегез мина кирәкми. Без Наташа белән сөйләшергә сүз табарбыз.

АЛЕКСЕЙ. Юк дидем, Дания. Ачуланма. Наташаның кәефе дә юк.

ДАНИЯ. Ни булды?

АЛЕКСЕЙ. Булды инде. Зинһар, бернәрсә кирәкми. Алайса, чыгып китәм. *(Хәлиуллага.)* Утыр әле, Хәллә. Дания, ачуланма, без Хәллә белән икәү генә...

ДАНИЯ *(аптырап калган җиреннән)*. Ярый инде, алайса. Чыгып торам, сөйләшегез. *(Бүлмәләрнең берсенә кереп китә.)*

АЛЕКСЕЙ. Капка төбендә генә утырасы иде.

ХӘЛИУЛЛА *(стаканнарга аракы салып)*. Йә, тотыйк әле.

АЛЕКСЕЙ. Монсыз гына сөйләшик.
ХӘЛИУЛЛА. Тот әйдә, тот. Әйбәт булды әле керүең, баш та авыртып торае. *(Чәкешеп эчеп куялар.)*
АЛЕКСЕЙ. Фу, чиргә әйләнде бу. Кешегә керер хәл юк.
ХӘЛИУЛЛА. Нишлисең инде... Шулай инде... Капкала... Даниянең булган әле ярый. Кичә малайлар белән җыелышып эштән соң бераз ниткән идек. Нәрсә, сез дә ниткән идегез мәллә?
АЛЕКСЕЙ. Юк ла... Нихәлләрдә соң, Хәлиулла?
ХӘЛИУЛЛА. Нихәлләрдә, дип, үзең беләсең инде. Алга барган җир юк.
АЛЕКСЕЙ. Юк шул. Очы-кырые күренми.
ХӘЛИУЛЛА. Хәерле булсын инде. Шунысына шөкер, яшьтәш, ашарга-эчәргә бар.
АЛЕКСЕЙ. Син сизәсеңме, Хәллә, дөньяның рәте-чираты булмагач, булган ризыкны рәхәтләнеп, тәмләп ашап булмый икән.
ХӘЛИУЛЛА. Валлаһи шулай бит әй, Алексей. Телевизор карыйсың да әппитит бетә.
АЛЕКСЕЙ. Да-а-а... Төн уртасында нишләп йөри инде бу, дип уйлыйсың инде син, әйеме? Нигә сүзен әйтми, дип уйлыйсың инде.
ХӘЛИУЛЛА. Уйламыйм да...
АЛЕКСЕЙ. Болай әллә ни юк югын. Наташа белән сөйләшеп яттык әле. Син минем бабайны хәтерлисең микән, яшьтәш?
ХӘЛИУЛЛА. Ничек хәтерләмәскә.
АЛЕКСЕЙ. Аның сөйләгәннәрен искә алып яттык әле Наташа белән. Безнең менә монда сезнең авылга килеп төпләнүебез турында. Безнең халыкны монда Петр беренче заманында көчләп күчереп утыртканнар. Бабайның әйтеп калдырганынча, Воронеж якларыннан булырга тиеш без. Кайсыбер татар авылларыннан татарларны бөтенләй куып җибәреп безнең кебекләрне урнаштырганнар. Авыл исемнәре татарча калган. Беләсең инде аларын. Тәмте әнә, Каратун, Бортас... Күп инде алар.
ХӘЛИУЛЛА. Татарлар булганмыни анда?
АЛЕКСЕЙ. Татарлар, конечно. Сезнең авылга ни өчендер тимәгәннәр. Сезнең яннан безгә җир бүлеп биргәннәр. Татарлар турында куркыныч әкиятләрне күп ишеткән бабайлар. Башта сакланыбрак яшәгәннәр. Сезнекеләр үзләренчә, безнекеләр үзләренчә. Бара-тора инде, үзең беләсең. Үзең беләсең инде бүген ничек. Күз тимәсен, бер авыл, бер ил булып яшибез. Өч йөз елга якын бергә яшәп бер генә тапкыр да сугышып урамга чыкмаганбыз. Сез безнең телне беләсез, без сезнең телне өйрәндек. Безнең бабайлар сезнең бәйрәмнәргә, сезнең бабайлар безнең бәйрәмнәргә йөргән. Безнең туйларда сез — табын уртасында, сезнең туйларда без — кадерле кунак.
ХӘЛИУЛЛА. Ничек инде шулай булмасын, бер авылда яшәп.
АЛЕКСЕЙ. Хәтерлисеңме, Хәллә, өченче ел сабан туенда Бакырчы авылының бер егете минем энекәшкә бәйләнгән иде. Ике арада сугыш чыккач, бөтәннәр дә кушылып, ике авыл бәргәләшергә тотынды. Без — татарыурысы бергәләп, Бакырчыларга каршы сугыштык. Син үзең дә катнаштың бугай.
ХӘЛИУЛЛА. Андый чакта карап тормыйсың инде. Бер җүләр аркасында ямьсезләштек, шунысы гына.
АЛЕКСЕЙ. Урыс егетен яклап сугыштың бит, Хәллә. Бакырчы татарлары белән.
ХӘЛИУЛЛА. Урысның, татарның ни катнашы бар монда? Син әллә нинди әле бүген, Алексей. Тот әле, әйдә, исәнлеккә-саулыкка... *(Күтәреп куялар.)*

**Пауза.**

АЛЕКСЕЙ. Бер сорау биримме сиңа, Хәлиулла яшьтәш? Беләсеңме, ни өчен без ничәмә-ничә ел бергә яшәп сугышу түгел, телгә дә килгәнебез юк?
ХӘЛИУЛЛА. Ә нигә сугышасың ди?
АЛЕКСЕЙ. Кешеләр нигә сугыша соң?
ХӘЛИУЛЛА. Нигә дип, бүлешә алмыйлар.
АЛЕКСЕЙ. Безнең бабайларның бүлешәсе нәрсәләре булмаган дисеңме? Сугышмаганнар. Акыллы итеп бүлешкәннәр. Безнең бабайлар безнең патшалардан акыллырак булганнар. Сез үз җирегездә рәнҗетелгән, без үз җиребездән куылган — нигә сугышырга?! Язмышлар бер.
ХӘЛИУЛЛА. Кызык син бүген, Алексей. Укытучылар кебек сөйлисең.
АЛЕКСЕЙ. Юк, син көлмә, Хәллә. Безнең бабайлар бер-берсен хөрмәт итә белгәннәр. Сугыш чыгарырлык эш эшләмәгәннәр. Безнең тел бөек тел, сезнең тел бәләкәй дип ахмак сүз сөйләмәгәннәр.
ХӘЛИУЛЛА. Син татарча миннән остарак сиптерәсең әле.

АЛЕКСЕЙ. Йәле, сал әле, Хәллә, чүт кенә итеп. *(Тотып куйгач.)* Даа-а... Шулай шул, Хәллә, шулай. Аннан соң, Хәллә, син беләсеңме, безнең бабайлар ничаклы бергә яшәп бер тапкыр да уртак туй ясамаганнар. Әтиләр дә андый эшне эшләмәгәннәр. Ни өчен?

ХӘЛИУЛЛА. Әллә чыннан да?

АЛЕКСЕЙ. Шулай, Хәллә. Руслар белән татарлар безнең авылда бераү дә бер-берсенә өйләнмәгән дә, кияүгә дә чыкмаган.

ХӘЛИУЛЛА. Кара, чыннан да, әйеме? Минем дә ишеткәнем юк.

АЛЕКСЕЙ. Арада яратышучылары да булгандыр инде юкса. Сезнең кызлар нинди чибәрләр, егетләрегез нинди! Без дә ямьсез халык түгел, күреп торасыз. Бер-берсенә күзләре төшкәндер инде. Ни өчен өйләнешмәгәннәр икән?

ХӘЛИУЛЛА. Әкәмәт. Казанда өйләнешәләр инде анысы.

АЛЕКСЕЙ. Син Казанны алма! Казан — шәһәр ул. Шәһәрдә анда эт — баш, сыер — аяк. Берсен-берсе белми дә, күрми дә. Кемгә өйләнгәнен дә, нәрсә сөйләгәнен дә чамаламый. Йорьләр өерелеп урам этләре шикелле. Бүген өйләнә, иртәгә аерыла. Авыл ул бүтән, монда бер-береннән башка яшәү читен. Монда мин сине көн саен күрәм. Монда өерелеп йөреп булмый.

ХӘЛИУЛЛА. Шулай шул. Чыннан да өйләнешүчеләр нигә булмады икән?

АЛЕКСЕЙ. Нурхәмәт абый өйдәме соң?

ХӘЛИУЛЛА. Өйдә, йоклый.

АЛЕКСЕЙ. Чакырыйк әле!

ХӘЛИУЛЛА. Минем әткәнне яратмый ул. Өйдә шешә күрсә, тавыш куптара.

АЛЕКСЕЙ. Алып куй әле. *(Шешә, стаканнар яшерелгәч)* Чакыр әле. Алексей дәшә, диген. *(Хәлиулла Нурхәмәт йоклый торган бүлмәгә кереп чыккач)*. Чыгамы?

ХӘЛИУЛЛА. Хәзер. Сөйләшеп утырырга дисән, ул...

НУРХӘМӘТ *(чыгып җитеп)*. Нихәл, Әләкчәй күрше.

АЛЕКСЕЙ. Йокыннан уяттым инде, Нурхәмәт абый.

НУРХӘМӘТ. Йоклыйсы көннәр алда әле безнең, Әләкчәй күрше. Нихәлләрдә?

АЛЕКСЕЙ. Менә сөйләшеп утырабыз әле Хәлиулла белән.

НУРХӘМӘТ. Ярый, ярый, яхшы. Күрше белән күрше сөйләшеп утырса, әйбәт ул, дөнья тыныч диген сүз.

АЛЕКСЕЙ. Менә бер сорауга җавап таба алмыйбыз әле, Нурхәмәт абый.

НУРХӘМӘТ. Бик четерекле мени? Нәрсә, аракының да файдасы тимәдемени?

ХӘЛИУЛЛА. Без әз генә.

АЛЕКСЕЙ. Нурхәмәт абый... Менә безнең авылда руслар белән татарлар күпме яшәп бер тапкыр да берберсе белән өйләнешмәгәннәр. Болай гынамы ул, берәр хикмәте бармы?

НУРХӘМӘТ. Хикмәте бар, Әләкчәй күрше, хикмәте бар. Болай гына бер нәрсә дә булмый бу дөньяда. Болай гына тавык тирәсендә әтәч тә йөрми.

АЛЕКСЕЙ. Нәрсәдә инде аның хикмәте?

НУРХӘМӘТ. Нәрсәдәме? Синен мәрхүм әтиең белән сөйләшкән бар иде ул турыда. Аның хикмәте шунда, Әләкчәй күрше, тату яшәргә кирәк бит, талашып бергә яшәп булмый бит. Талашмас өчен шулай эшләгән безгә кадәргеләр. Без дә шулай эшләдек. Шулай тиеш.

АЛЕКСЕЙ. Тиеш үкмени?

НУРХӘМӘТ. Тиеш. Ир белән хатын кем ул? Сез әйтәсез дә муш и жена — адна сатана дип, адна сатанага өйләнгәнче алар башта аерым-аерым сатана бит әле. Башта һәрберсе үз ягын каера. Кайвакыт каера-каера каерып ук чыгаралар. Башта юктан гына тавыш чыга да ызгышка да әйләнә. Кызып китеп бер-берсенең начар яклары санап бетергәч, нәсел-нәсәпләргә барып җитәләр. Кайчак ахмак ир белән юньсез хатынның җүләрлеге аркасында чыккан ызгыш туган-тумачаларына күчә. Китә талаш, китә сугыш.

АЛЕКСЕЙ. Гел алай булмый инде.

НУРХӘМӘТ. Гел булмый билгеле. Сезнең белән безгә берсе дә житә, Әләкчәй күрше. Безгә кадәргеләр ара бозылудан курыкканнар. Ике җүләр арасында чыккан гауга зурга китсә, ни белән бетәсен чамалаганнар.

АЛЕКСЕЙ. Язылмаган закон булган инде алайса?

НУРХӘМӘТ. Булган, Әләкчәй күрше, булган. Беләсегез килсә, кешеләрне язылган законнар түгел, язылмаган законнар кеше итеп тота. Язылмаган законнарны бозсалар, кешеләр звиргә әйләнәләр. Хикмәте бар, Әләкчәй күрше, хикмәте бар.

АЛЕКСЕЙ *(паузадан соң)*. Менә шуның өчен дә кердем бит әле, Нурхәмәт абый. Сез берни дә белмисезме?

НУРХӘМӘТ. Нәрсәне?

АЛЕКСЕЙ. Илгизәр бернәрсә дә әйтмәдеме?

НУРХӘМӘТ. Миңа ул нәрсә әйтсен. Мине түгел әтисен дә санга сукмый ул.

ХӘЛИУЛЛА. Нәрсә булган Илгизәргә?

АЛЕКСЕЙ. Алар бит Вера белән өйләнешергә җыеналар.

ХӘЛИУЛЛА. Ничек өйләнешергә?

АЛЕКСЕЙ. Вера бүген кич белән әйтте, озакламый туебыз була, ди.

НУРХӘМӘТ. Ничек инде ул «туебыз була?»

ХӘЛИУЛЛА. *(Данияне чакырып).* Дания, беләсеңме, Илгизәр белән...

ДАНИЯ. Ишетеп торам. Өйләнешсәләр, ни булган?

ХӘЛИУЛЛА. Сиңа әйттеме Илгизәр?

ДАНИЯ. Әйтсә, әйткәндер инде...

НУРХӘМӘТ. Әтисе белми.

ДАНИЯ. Әткәй, син безнең семья эшенә кысылма. Урының — җылыда. Син дә, Алексей, төн уртасында ах-ух килеп... Нәрсә булган ул хәтле. Яшьләр өйләнешә инде ул. Нәрсә, безнең белән кода буласыгыз килми мәллә?

АЛЕКСЕЙ. Кодаларын кодалар да...

ДАНИЯ. Син безнең әткәйне тыңлама. Ул инде яшисен яшәгән. Хәзер инде бүтән замана. Яшьләр нишләргә кирәген үзләре беләләр.

НУРХӘМӘТ. Нәрсә беләләр, нәрсә беләләр? Аракы эчә беләләр.

ДАНИЯ.Син дә әүлия булмаган, әткәй, дәшми генә утыр. Тапканнар тавыш чыгарырлык нәрсә.

АЛЕКСЕЙ. Без бит тавыш чыгармыйбыз, Дания күрше, уйлашабыз.

ДАНИЯ. Күп уйласагыз, тиз картаерсыз. Язылмаган закон дигән булып. Юк-барны уйлап чыгарып утырасыз. Әнә безнең Рашат язылган закон буенча өйләнде. Татар кызына. Аның кебек иблисне дөньядан эзләп таба алмассың. Төкерәм мин аның татарлыгына.

АЛЕКСЕЙ. Татарның татарлыгына син төкерсәң бер хәл, Дания. Менә мин төкерсәм, бик яман. Русның руслыгына син төкерсәң дә начар.

ДАНИЯ. Нәрсә, син каршымыни, Алексей? Татарга кызыңны бирәсең килмимени? Кимсенәсеңмени? Шулай дип өзеп әйт, нәрсә аны. Наташа да шулай диме? Шуны әйтергә сине кертеп җибәрдеме?

АЛЕКСЕЙ. Туктале син, Дания күрше. Кинәт кенә бит.

ДАНИЯ. Малайларның, кызларның үсеп житүе кинәт була инде ул. Кинәт беләсең инде ул. Безнекеләр ярый әле әйтеп торалар өйләнешәселәрен, кайсыларыныкы балалары тугач кына беләләр. Шунысына рәхмәт әйт. Миңа әйтте Илгизәр. Рөхсәт сорады. Уйлашырбыз, дидем. Нигә аңа күтәрелеп бәрелергә?

ХӘЛИУЛЛА. Миңа да әйтергә була иде инде.

ДАНИЯ. Эштә идең. Эчеп кайткан идең. Укаң коелмас, әйткән булыр идем.

ХӘЛИУЛЛА. Үзе кайда соң Илгизәр?

ДАНИЯ. Кайда булсын — егет кешенең кайда булганы билгеле инде.

НУРХӘМӘТ. Егет. Авызыннан балавыз сарысы китмәгән. Бала-чагалар. Өйләнешкәч, кем ашатыр дип уйлыйлар икән соң?

ДАНИЯ. Анысы синең кайгы түгел, әткәй.

АЛЕКСЕЙ *(Нурхәмәтнең үз бүлмәсенә кереп баруын күреп).* Нурхәмәт абый, тукта әле.

ДАНИЯ. Йокласын. Аның эше беткән инде, үзенекен өйләндергән. Менә нинди әйбәт килене бар. Дөньяда бер дигән. *(Көлә.)*

НУРХӘМӘТ. Бер дигән инде...

ДАНИЯ. Нәрсә, әллә ошамыйммы? Татар кызы бит. Таптылар сөйләр сүз. Радиосын ачсаң — татар, телевизорын карасаң — татар. Сөйләргә сүзләре беткән диярсең. Аптырама, Алексей. Яшьләр әйткән белән генә бүген-иртәгә туй үткәрмәбез. Әйбәт итеп ясарбыз. Кешеләрнекеннән ким булмас! Үзләре табышканнар икән, бер-берсенә ярашканнар икән, өйләнешсеннәр! Яраткан — елан ите ашаган, ди. Менә мин дә яраттым — чыктым. Карап торырлык кыяфәте дә юк иде. Нишлисең син, җүләр, диделәр. Мин чыктым. Аллага шөкер менә дигән итеп егерме биш ел торабыз. Менә шул. Берсе үзсүзләнеп Чаллыга китте, ята хатынының колы булып. Монысын үз яныбыздан җибәрде юк. Үзебезнең авыл кызын сайлаган — бик әйбәт. Бергә-бергә менә дигән итеп яшәрбез.

АЛЕКСЕЙ. Безгә хәтле бит...

ДАНИЯ. Безгә хәтлесе безгә кирәкми, Алексей кода. Безгә үзебезнеке дә бик җиткән.

НУРХӘМӘТ *(ишекне ачып).* Сез генә түгел дөньяда, бүтәннәр дә бар. Өч йөз елга чаклы сакланып килгән тәртипне нигә синең малаең гына

бозарга тиеш. Башында миең бармы синең бераз?

АЛЕКСЕЙ. Сезнең жирегездә сезнең белән талашып яшисем килми минем, күршеләр.

ДАНИЯ. Ә кем куша сиңа талашырга?!

**Ут сүнә. Сәхнә яктыргааида Илгизәр белән Вера өянке астындагы утыргычта утыралар. Сөйләшер сүзләре беткән, күрәсең, үбешеп алалар да тагын үзалларына карап утыра бирәләр.**

ВЕРА *(тынлыкны бозып)*. Гел үбешәбез дә үбешәбез...

ИЛГИЗӘР. Нишлисең инде тагын.

ВЕРА. Минем әти белән әни аптырап калдылар.

ИЛГИЗӘР *(көлеп)*. Минем дә әни күзләрен акайтып миңа карап тора. Ул карап калды, мин чыгып киттем. *(Көлешәләр дә үбешеп алалар.)*

ВЕРА. Әйткәч, кызыгы да бетте. Әйтмәгән чакта кызыклырак иде. Әллә кияүгә чыкмаска инде. Чыгасы да килми башлады. Синең һаман да өйләнәсең киләме әле, Илгизәр?

ИЛГИЗӘР. Килә.

ВЕРА *(көйләп)*.
Әй, илә-лә, илә-лә,
Өйләнәсем килә лә.
Өйләнәсе килгән егет
Кәҗә сатып өйләнә.

Әйдә, болай эшлибез, Илгизәр. Әнә син тегендә бас, әйеме. Мин — монда. Шуннан күзләрне йомышып, кулларны сузып кара-каршы киләбез. Әгәр дә кулларыбыз очрашса, өйләнешәбез, очрашмаса — өйләнешмибез.

ИЛГИЗӘР. Өйләнешмичә, нишлибез соң?

ВЕРА. Анысын аннан соң уйлашырбыз. Әйдә. *(Икесе сәхнәнең ике ягына басалар да кулларын сузып кара-каршы киләләр. Куллары очрашкач, кочаклашып үбешәләр.)*

ИЛГИЗӘР. Әйттем бит.

ВЕРА. Нәрсә әйттең?

ИЛГИЗӘР. Өйләнешәбез, дидем.

ВЕРА. Ә син күзләреңне йомган идеңме?

ИЛГИЗӘР. Әллә ышанмыйсыңмы?

ВЕРА. Әйдә тагын бер тапкыр *(Янә баягы уеннарын кабатлыйлар, янә куллары очраша, янә үбешәләр.)*

ИЛГИЗӘР. Әйттем бит... Кара, Алексей абый бездән чыгып бара. *(Өянке артына посалар.)* Ну, эш булды аларга. Туй, диләр инде, чабыша башлыйлар инде. Әтинең кергән бирәчәк кенә инде әни, чаптырачак кына! Бабай гына утырачак, кем өйләнгән — шул чапсын, дип. Гел акыл өйрәтә ул, туйдырып бетерә.

ВЕРА. Минем авылда да каласым килми инде.

ИЛГИЗӘР. Ә кем кала авылда?! Китәбез. Чаллыга, абый янына китәбез.

ВЕРА. Әниең әйтә, дисең ич. Авылда калдырам дип әйтә, дисең.

ИЛГИЗӘР. Аның сүзенә карасаң. Китәбез дә барабыз. Бер тузыныр да бетәр.

ВЕРА. Синең армиягә дә барасың бар.

ИЛГИЗӘР. Әй, бер ел бар әле аңа.

ВЕРА. Әгәр дә армиядән кайткач өйләнешсәк?

ИЛГИЗӘР. Әй, аңынчы. Бәлки әле алмаслар да.

ВЕРА. Ничек инде алмаслар?

ИЛГИЗӘР. Радиодан әйттеләр. Армия бетә, диделәр.

ВЕРА. Радио әйткәнгә ышансаң... Син мине яратасыңмы, Илгизәр?

ИЛГИЗӘР. Ну, бәйләнәсең син, әйеме. *(Вераны кочаклап үбә.)*

**Ут сүнә. Ут яңгаида Хәлиуллалар өендә туй. Өстәлләрдә ризык, шешәләр. Өстәл янында кунаклар. Алгы планда Нурхәмәт белән Мария янәшә утыралар. Түрдә кияү белән кәләш, ягъни Мәсәлән, Илгизәр белән Вера урыны буш. Анда әлегә дә баягы — Туй агасы басып тора.**

ТУЙ АГАСЫ. Внимание! Тынлык! Карагыз аны, барыгыз да мине тыңлагыз. Бу туй, иптәшләр-товарищлар, башка туйлар төсле булмаячак. По-новому будем проводить свадьбу.

ДАНИЯ. Ашыкма, сабыр ит, кунаклар килеп бетмәде әле.

ТУЙ АГАСЫ. Күпме көтәргә була. Ике сәгать көттек — житте. Нишлибез, җәмәгать, көтәбезме-юкмы? Будем ждать или нет?

ДАНИЯ *(туй агасын җитәкләп алга килә)*. Син нәрсә кыландырасың? Монда барысы да татарча белә.

ТУЙ АГАСЫ. Барысы да русча да беләләр. Интернациональ туй булгач, интернациональ булсын. Ике якка да тигез булсын. Үзең бит миннән Туй агасы булырга сорадың, Дания апа. Теләмәсәгез, көчләп килмәдем.

ДАНИЯ. Ярар, үпкәләргә торма.

ТУЙ АГАСЫ. Башлыйк инде. Киләсе кеше килгәндер инде. Килсәләр, урын күп, матур итеп утыртырмын.

ДАНИЯ. Ярар, әйдә. Килмәсәләр, чукынып китсеннәр. *(Натальяны чакырып алып.)* Башлыйбызмы, Наташа? Килмәгәнне көтеп утырып булмас.

НАТАЛЬЯ. Башлыйк.

ДАНИЯ *(туй агасына)*. Әйдә. *(Үзләре утырышалар.)*

ТУЙ АГАСЫ *(түр башына барып)*. Внимание. Тынлык. Без монда хуҗалар белән киңәшмә-совещание үткәрдек тә туйны башлап җибәрергә булдык. Внимание! Начали!

**Гармунчы туш уйный. Шаһитлар кияү белән кәләшнең кулларыннан тотып тантаналы рәвештә алып керәләр, өстәл башына утырталар. Кул чабучылар да бар. Туй агасы сүзен дәвам итә.**

Кияү белән кәләш! Жених и невеста. Поздравляю вас с вашим самым великим днем. Сезнең икегезгә дә ак бәхетләр телим һәм беренче сүзне кияүнең әтисенә бирәм.

ХӘЛИУЛЛА *(торып)*. Мин нәрсә әйтим инде. Мин сүз әйтә белмим бит.

ДАНИЯ. Әйт инде, нәрсә, әйбәт яшәгез, диген. Котлыйм, диген.

ХӘЛИУЛЛА. Әйбәт яшәгез, балалар. Котлыйм. Әйдәгез, кунаклар, җитешегез әле! Өстәлдә бары белән.

ТУЙ АГАСЫ. Стоп! Ашауга иртәрәк. Сүз кәләшнең әтисенә. Прошу.

АЛЕКСЕЙ *(тора да өстәл янында утыручыларны карашы белән барлап чыга)*. Авылдашлар! Рәхмәт килгәнегезгә. Безне санга сугып килгәнегезгә рәхмәт. Менә безнең балаларның туе инде бу. Туйга килгәнегезгә тагын бер рәхмәт. *(Илгизәр белән Верага озак итеп карап торганнан соң.)* Менә безнең балалар инде болар. Илгизәр кияү белән Вера кызым. Нәрсә әйтим инде сезгә. Котлыйм инде, билгеле... Нинди теләк телим? Теләгәнем шул гына инде, әйбәт яшәгез, безнең йөзгә оят китерә күрмәгез, менә шул инде безнең теләкләр. *(Кулындагы чәркәсен тоткан килеш уйланып басып тора.)*

ТУЙ АГАСЫ. Тост. Тост әйт, Алексей Степаныч.

АЛЕКСЕЙ. Тост? Менә шул теләкләр кабул булсын өчен күтәрик инде.

ТУЙ АГАСЫ. Урра! Кем дә кем шул теләкләр кабул булсын ди, шул иптәшләр кулларын, гафу итегез, рюмкаларын күтәрәләр. Молодцы! Туй бара, туй дәвам итә. Өченче тост өчен сүзне ике свидетельнең берсенә бирәбез. Рәхим итегез, Свидетельләр, прошу, кайсыгыз әйтә? *(Шаһитлар икесе дә торып басалар.)*

ШАҺИТ КЫЗ. Без икебез дә әйтәбез.

ТУЙ АГАСЫ. Пажалысты. Баш өсте! Бүтән булса, каршы килер иде, мин — юк.

ШАҺИТЛАР *(алдан әзерләп куйган кәгазьне алып, икәүләп шуны укыйлар)*. Дорогие Вера и Илгизәр! Кадерле Вера һәм Илгизәр!

Мы вас крепко поздравляем,
Семейной дружбы желаем.
Живите вместе долго-долго,
Растите детей много-много.
Друг друга уважайте,
Радостных дней умножайте,
Если печаль придет,
Пусть она обратно уйдет.
Вы теперь муж и жена,
Пусть мужа любит она,
Пусть и он любит жену
Пусть любит только одну.

*(Җырга күчеп)*.

Сокланып карап туймаслык
Зифа буегызга да;
Онытмагыз чакырырга
Бәби туегызга да.
Алсу йөзле, зәңгәр күзле
Балалар үстерегез,
Туган илгә матур кызлар,
Батыр уллар бирегез.

**Җырлап туктыйлар да утыралар.**

ТУЙ АГАСЫ. Кем дә кем шаһитларның сүзләренә кушылса, шул иптәшләр кулларына рюмка тотып төшереп куя. (Үзе дә чәркәсен эчеп куйгач.) Ә хәзер ашап алырга рөхсәт.

**Үзе дә утыра. Бер ара тавыш-тынсыз гына ашыйлар. Кашык-чәнечкенең тәлинкәгә бәрелгәне, тәмле итеп чәйнәгән, йөткергән, борын тартып алган тавышлар гына ишетелә. Ләкин рәхәтләнеп ашаганда гына туй агасы тагын сикереп тора.**

Иптәшләр! Внимание! Туйга килсәң, туеп кил, дигән мәкальне ишеткәнегез бармы? Ишетсәгез шул, рюмкаларны, ягъни мәсәлән чәркәләрне, тутырыгыз. Сүзне кемгә бирәбез? Сүзне кияүнең әнисенә, Дания апага бирәбез.

ДАНИЯ. *(Кияү белән кәләш янына ук килеп)*. Минем кадерле улым Илгизәр, минем кадерле кызым Вера!.. Мин сезгә бүген шуны телим — бәхетле булыгыз! Кызым Вера, мин сиңа кызым дип кенә дәшәрмен. Без һәрвакытта да күршеләр булдык, бик тату яшә-

дек. Киләчәктә дә шулай яшәрбез. Без хәзер туганлаштык. Кадерле кода Алексей, кадерле кодагый Наташа, мин сезгә телим озын гомер, шатлык, куаныч. Әйдәгез, кадерле кунаклар, безнең улыбыз белән кызыбызның бәхете өчен күтәреп куйыйк әле. *(Чәркәләр күтәрелгәндә Нинаның әче тавышы ишетелә).*

Н И Н А. Горько!.. Горько!..

**Ана тагын кемнәрдер кушыла. Илгизәр белән Вера урыннарыннан торып гадәттәгечә үбешәләр. Нурхәмәт урыныннан торып чыгып китә. Сәхнәдәге яктылык аның белән бергә карт өянке астындагы утыргычка күчә. Нурхәмәт бераз утыргач, аның янына Мария чыгып урнаша.**

М А Р И Я *(паузадан соң).* Шулай инде, Нурхәмәт күрше.

Н У Р Х Ә М Ә Т. Кода, диген.

М А Р И Я. Кода. Хәерле булсын инде, Нурхәмәт кода.

Н У Р Х Ә М Ә Т. Хәерле булмый нишләсен. Бабалары алдында лачкылдатып үбешкәч, хәерле була инде. Аннары этләр кебек синең белән минем каршыда өегешә үк башларлар. Шуннан, хәерле була инде.

М А Р И Я. Син нигә әле мине гаепләгән кебек сөйлисең.

Н У Р Х Ә М Ә Т. Нишләп сине гаеплим?! Мин үземне гаеплим. Бездән туганнан туганнар бит алар. Безнең дә синең белән үбешкән булды. Безнең үбешкәнне кеше түгел ай да күрмәде. Инеш юлындагы шомыртлар гына күрделәр.

М А Р И Я. Без бит синең белән ир белән хатын түгел идек.

Н У Р Х Ә М Ә Т. Нәрсә, ир белән хатын булгач, кеше алдында чишенеп, өстәл өстенә менеп ятыргамыни?

М А Р И Я. Туйда үбешү электән калган йола инде.

Н У Р Х Ә М Ә Т. Сездә калган ул, бездә түгел. Сезнең туегызда үбешкәнне мин үзем дә рәхәтләнеп карап утырам. Сездә аны килешле итеп эшлиләр. «Горько» дигән сүзе дә бар. Бездә бит аның сүзе дә юк.

М А Р И Я. Монда сезнең туй гына түгел бит инде.

Н У Р Х Ә М Ә Т. *(Паузадан соң)* Түгел шул, Маруся, түгел шул.

М А Р И Я. Нишлисең инде хәзер. Яши генә күрсеннәр инде. Бигрәк яшьләр шул әле.

Н У Р Х Ә М Ә Т. Эш яшьлектә түгел монда, Маруся, башсызлыкта.

М А Р И Я. Дөньясы буталды шул.

Н У Р Х Ә М Ә Т. Буталмады. Буталдылар.

М А Р И Я. Да-а-а. Боже мой, боже мой...

Н У Р Х Ә М Ә Т. Гуспади пумилуй диярсен әле, Маруся кодагый.

М А Р И Я. Ярый, әйдә кереп утырыйк, йә әллә ни уйларлар.

Н У Р Х Ә М Ә Т. Кем уйлый? Синең белән мине оныттылар инде алар. Шайтан туена синең белән мин кирәкме? Менә әлегә үзебезне үзебез йортәбез, Маруся. Алар кулына калырга язмасын. Картлар йортына илтеп ыргытачаклар. Вәт шунда булыр бужымуй, бужы муй.

М А Р И Я. Йә инде. Нәрсә инде син? Нишлик, үликмени? Яшәргә кирәк ләбаса!

Н У Р Х Ә М Ә Т. Ачуланма инде, Маруся күрше.

М А Р И Я. Ачуланмыйм да. Туй көнендә болай әллә ничек. Бер алар гына түгел...

Н У Р Х Ә М Ә Т *(Туйдан китеп барган бер ир белән хатынны күреп)* Нишләп бик тизләдегез, Сәлихҗан? Туй яңа башланды гына.

1 И Р. Красноярскидан кунаклар кайтканые да, үзләре генә. Тиз кайтабыз дип киткән идек.

Н У Р Х Ә М Ә Т. Бераз котәрләр иде әле.

1 И Р. Кунак көттерү әллә ничек шул, Нурхәмәт абый. Табын ташлап килгән идек.

Н У Р Х Ә М Ә Т. Шулаен шулай да...

1 Х А Т Ы Н. Ике сәгать буш урындык саклап утырганга без гаепле түгел инде. *(Иренә)* Әйдә.

1 И Р. Сау булыгыз, Нурхәмәт абый. Сау булыгыз, Маруся апа.

Н У Р Х Ә М Ә Т. Сау булыгыз, сау булыгыз... Хатын-кыз азды, Маруся. Кара, ире адәм рәтле сөйләшә, хатыны пуләмит кебек тырылдый. Шулай, Маруся.

Мәскәүски Маручкалар
Кияләр саручкалар.
Көндә шулай гуләйт итсәк,
Җитмәс шул палучкалар,

— диген ә, Маруся кодагый. Әйдә, Маруся күрше, мать якасын. Керик, гуләйт итик.

**Әйдә туй дәвам итә. Яшь җилкенчәк магнитофоннан заман ритмына «танцавайт» итә. Олкәнрәкләр бер-берсенә тотынышып селкеналәр. Шунда Ислам магнитофонны кинәт сүндерә.**

Т У Й А Г А С Ы *(Ислам янына килеп).* Нигә туктаттың магнитофонны? Син хуҗамы монда, минме?

ИСЛАМ. Син тик тор, агай-эне, яме? Нәрсә һаман урыс җыры җырлатасың? Бу бит сиңа урыс туе түгел, белдеңме?

ТУЙ АГАСЫ. Син белмәсәң, тик кенә тор, ярыймы? Урыс җыры түгел бу, беләсең килсә.

ИСЛАМ. Кем җыры соң? Әллә татар җырымы?

ТУЙ АГАСЫ. Бу Америка ансамбле, беләсең килсә.

ИСЛАМ. Миңа барыбер, белдеңме? Нигә син татарча җырлатмыйсың, ә, нигә җырлатмыйсың? Урыс булдыңмыни?

ДАНИЯ *(Исламга килеп ябышып)*. Син эчсәң, буеңа сеңдер, Ислам.

ИСЛАМ. Эчермәгәч тә ник чакырдың соң?

ДАНИЯ. Чакыргач, дуңгыз булганчы эчеп тавыш чыгарырга мыни?

ИСЛАМ. Кем дуңгыз булган, кем? Җырлыйсым килә минем, белдеңме?

ДАНИЯ. Бик ишетәселәре килә ди синең үкергәнеңне.

ИСЛАМ. Нигә син минем җырымнан көләсең, ә?

НАТАЛЬЯ *(Килеп)*. Нәрсә, Ислам, әллә җырлатмыйлармы? *(Исламны кочаклап алып)* Әйдә, җырлыйбыз.

ИСЛАМ. Мин кеше белән җырлый белмим, мин үзем генә җырлыйм.

НАТАЛЬЯ. Әйдә, җырла.

ИСЛАМ. Хәзер инде әпитетны бетерделәр.

НАТАЛЬЯ. Үзем җырлыйммы синең җырыңны?

ИСЛАМ. Әллә беләсең?

НАТАЛЬЯ. Беләм, билгеле. Ничек инде ул синең җырыңны белмәскә.

ИСЛАМ. Яле, яле. Тыңлап карыйм әле.

НАТАЛЬЯ *(Җырлый)*

Кыр казлары очты, күрдегезме
Һаваларга менеп киткәнен?
Кыр казы
Иделләр читендә,
Ялгыз башым миңа читен лә.

ИСЛАМ *(Наталья алдына тезләнеп)*. Их, Наташа!.. Җанкисәгем!..

НАТАЛЬЯ. Бүлдермә, Ислам.

Беләсеңме, дустым, сизәсеңме
Аерылулар килеп җиткәнен?
Кыр казы
Суларда уйный шул,
Ялгыз башым гел сине уйлый.

Булдымы, Ислам?

ИСЛАМ. Мәңге онытмам, Наташа!.. Наташа!.. Бәгырькәем! Менә бу, ичмасам, җыр дисәң җыр. *(Туй агасына)* Ә син завклуб дигәч тә командовать итмә, белдеңме?

ТУЙ АГАСЫ. Белдем, белдем. Ярый, бар, утыр. Внимание! Барыгызга да утырырга. По коням! Тутырдыгызмы чәркәләрне? Сүзне Наталья Васильевнага бирәбез. Рәхим итегез, Наталья Васильевна. Пажалысты.

НАТАЛЬЯ. Әйтеләсе сүзләр әйтелде бугай инде. Авылдашларыма гына әйтәсе сүзем бар барын. Әйтим микән? Әйтимме, Алеша? Әй, әйтим әле. Гаепләмәгез инде сез безне, авылдашлар. Не обессудьте нас, дорогие мои.

ТАВЫШЛАР. Нигә гаепләргә?.. Син нәрсә?.. Рәхмәт чакырганыгызга...

НАТАЛЬЯ. Так уж получилось, дорогие мои. *(Эченнән генә җылап алганнан соң)* Давайте выпьем за все хорошее, что было в нашей жизни.

НИНА. Горько!.. Горько!..

ИСЛАМ *(Сикереп торып)* Горько булса, тышка чык та үбешеп кер, белдеңме? Нәрсә кеше үбешкәнгә кызыгып утырасың.

НИНА. Әйдә, минем белән чыгасыңмы соң?

ИСЛАМ. Чыкты диярләр.

НИНА. Их ты, трус. Куркак. Үзең кычкырып утырган буласың. Чего ты хорохоришься-то? «Урыс туе түгел», «урыс туе түгел». Какая тебе разница? Вот я выйду да попляшу, что ты скажешь? Запретишь что ли? *(Частушкалар әйтә-әйтә биергә тотына)*.

Я девчонка боевая
В себе уверена;
Глазки вниз не опускаю,—
Совесть не потеряна.
Говорят, что я горда —
По-гордому ответила:
Любить тебя, гулять с тобой
Я плана не наметила.
У стола четыре ножки,
У лоханки только три.
Всем ты миленький, хороший,
Только носик свой утри.
Ой с характером миленок,
Не могу его понять:
То заржет, как жеребенок,
То захнычет — не унять.

**Биеп Ислам янына бара. Аны сөйрәп чыгара, муенын каерып үбә дә, аяк чалып, ега.**

Менә, җанкисәгем, маржалар шулай эшли ул, белдеңме? Я, тагын ни әйтәсең?

ИСЛАМ *(Аптырап калган)*. Мин сиңа күрсәтермен әле, белдеңме?

НИНА. Күрсәт, я күрсәт. Күрик әле, хатының ни өчен аерылып китте икән. Менә мин синең кебек дуракны куып чыгардым.

ТУЙ АГАСЫ. Тихо! Туй дәвам итә. Тагын сүз әйтергә теләгән иптәшләр бармы? Әгәр дә сүз әйтергә теләүчеләр булса, миңа заявка бирсеннәр. Ә хәзер танца.

**Магнитофонны кабыза. Селкенеш башлана. Ут өянкене яктырта. Анда Алексей белән Хәлиулла тәмәке тартып утыралар.**

АЛЕКСЕЙ. Син берне дә тотып куймадың ахры?

ХӘЛИУЛЛА. Малай туенда килешми. Әти дә шунда...

АЛЕКСЕЙ. Да-а-а... Шәп кешеләр сез, Хәллә.

ХӘЛИУЛЛА. Кеше кеше инде, Алексей. Сезнең дә начар чагыгызны күргәнем юк.

АЛЕКСЕЙ. Менә бу өянкегә ничә яшь, беләсеңме? Йөз яшьтән дә ким түгел. Аны синең прадед белән минем прадед утыртканнар. Ике арага. Бергә карап үстергәннәр. Элек бит сезнең йорт урыны белән безнең йорт урыны бушлык булган. Авылны икегә аерып торган ул бушлык. Аннан безнең бабайларның әтиләре сөйләшеп йорт житкергәннәр, ике арага шушы өянкене утыртканнар. Аның мәгънәсе бар, бәйләп тора. Ике йортка бер өянке, өянке астында ике йортка бер утыргыч. Хәзер инде менә кодалар булдык.

ХӘЛИУЛЛА. Ислам гына әллә нишли әле.

АЛЕКСЕЙ. Ислам гел шундый инде ул.

ХӘЛИУЛЛА. Чакырмыйк, дигән иде Дания. Чакырмасаң, үзе килеп керә.

АЛЕКСЕЙ. Ислам гел шундый, Хәллә. Элек аның әйткәннәрен ишетми дә идек, бүген ишетелә. Хәзер шаярып әйткәне дә усал булып ишетелә. Безгә иләшергә кирәк инде янадан. Янабаштан иләшергә кирәк. *(Ир белән хатынның китеп барганнарын күреп)* Чего вы, Степа?

II ИР. Чего? Пора, Алеша. Пусть молодые-то танцуют. Нам-то чего. Спасибо за приглашение. Рәхмәт, Хәллә.

ХӘЛИУЛЛА. Иртә бит әле, Степан.

II ХАТЫН. Иртәгә иртүк торасы бар. Пошли, Степан, пошли. *(Китәләр).*

АЛЕКСЕЙ. Таралып бетәләр.

**Болганып Ислам чыкканы күренә. Алексей белән Хәлиулла каршына басып карап торя.**

ИСЛАМ. Утырабыз дисез инде, әйеме? Утырыгыз, утыр. Ә мин китәм.

АЛЕКСЕЙ. Утырырга иде әле бераз.

ИСЛАМ. Юк. Туй түгел бу. Как хош, Алексей, туй түгел. Туй түгел бу, Хәллә.

ХӘЛИУЛЛА. Нәрсә, аракы житмәдеме әллә, Ислам?

ИСЛАМ. Төкерәм мин синең аракыңа, белдеңме. Туйга аракы эчәр өчен йөриммени мин? Мин кешеләрнең ничек итеп бер-берсен яратышканнарын күрер өчен йөрим. Үзем алардан көнләшәм, үземә рәхәт.

ХӘЛИУЛЛА. Ярый, сау бул инде, алайса. Килүеңә рәхмәт.

ИСЛАМ. Алдашма, Хәллә. Минем килгәнемә сөенмәдең, киткәнемә сөенәсең син. Вот так, Хәллә. Вот так, Алексей. Жырлыйммы?

ХӘЛИУЛЛА. Ишеткән бар инде жырлаганыңны?

ИСЛАМ. Юк, аны жырламыйм мин. Ул жырны мин кадерләп кенә саклыйм, белдеңме. Мин сезгә бүтән жыр жырлыйм, белдеңме.

> Ай жаный, вай жаный,
> Татар үпкән маржаный.
> Нигә үпмәсен маржаный,
> Маржаның да бар жаный.
>
> Ак мунчага як мунча,
> Тимә, сызылып тик ясын.
> Ак мунчала үп маржаны,
> Спачибы дип калсын.

Вот так, Хәллә.

**Хәлиулла тора да Исламның йөзенә суга**

АЛЕКСЕЙ. Нишләдең син, Хәллә? Нишләдең, күрше? *(Ә әйдә туй дәвам итә. Магнитофон үкерә дә үкерә).*

## ИКЕНЧЕ ПӘРДӘ

**Хәлиуллалар өе. Туй узган. Табын жыештырылган. Өстәлләр генә үз урыннарында. Өстәл башында кара-каршы Нурхәмәт белән Хәлиулла утыралар.**

НУРХӘМӘТ. Дәшмә!.. Синең урыныңда мин булсам... Син беләсеңме шуны, безнең нәселдә кешегә кул күтәреп сугучы булмаган. Син башладың.

ХӘЛИУЛЛА. Йә, нәрсә инде... Түзмәдем. Каршыда ыржаеп тора. Сизми дә калдым.

НУРХӘМӘТ. Бүтән вакытта каршыңда гел көлеп кенә тордылармыни?

ХӘЛИУЛЛА. Монда бит... Алексей да шунда.

НУРХӘМӘТ. Алексей сукмаган бит.

ХӘЛИУЛЛА. Ничек инде Алексей суксын, аңа килешми дә.

НУРХӘМӘТ. Сиңа килешә.

ХӘЛИУЛЛА. Ярый булды инде, булды. Каныма тоз салма. Болай да... Ничаклы акча түгеп туй ясап... Чакырган кунакның яртысы килмәде. Килгәннәре дә туй беткәнче таралды. Туй булмады инде бу, әллә нәрсә булды.

НУРХӘМӘТ. Хатын сүзе белән йөрсәң, шулай була инде ул.

ДАНИЯ *(Бер бүлмәдән атылып чыгып)* Нәрсә хатын сүзе белән? Нәрсә булган ул хәтле? Аптырагансыз икән. Суккан-суккан, нәрсә ахылдап утырасыз. Телен тыя белсен. Килмәгәннәр икән чакырып, килмәсеннәр, мәтәлеп китсеннәр. Татар тәресенең шул булыр инде анын, үзен үзе әллә кемгә куеп...

НУРХӘМӘТ. Татар тәреләре генә түгел, урыс тәреләренең дә бик күбесе килмәде.

ДАНИЯ. Килмәгәйләре. Чукынып китсеннәр *(Хәлиуллага)*. Кодаларның өстәлләрен кертергә кирәк. Нәрсә тәресен югалткан урыс кебек утырасын?

ХӘЛИУЛЛА. Сүзеңне үлчәп сөйлә инде, ичмасам.

ДАНИЯ. Минем барысы да үлчәнгән. *(Хәлиуллага)* Тот әйдә.

**Бер өстәлне икесе ике башыннан тотып алып чыгып китәләр. Үз бүлмәләреннән эчке күлмәктән генә Вера чыгып тышкы ишеккә үтеп китә. Аның артыннан трусиктан гына Илгизәр чыга.**

ИЛГИЗӘР. Әниләр кайда ул?

НУРХӘМӘТ. Синең, нәрсә, кияргә ыштаның юк мәллә?

ИЛГИЗӘР. Бәйләнмәле. *(Кереп чалбарын алып чыга. Чалбарын киякия)* Әниләр кайда китте ул?

НУРХӘМӘТ. Хатының урамга ялангач чыгып китте. Бар, күлмәк чыгарып бир. Әйт үзенә, минем алда ялангач йөрмәсен?

ИЛГИЗӘР. Ялангач түгел ич ул. Әллә күзең күрмиме?

НУРХӘМӘТ. Бик әйбәт күрә минем күзем. Минем күзем күрмәсә, син бүген бу дөньяда булмас идең. Хәзер син олы кеше булдың инде. Симия башы. Малай булып йөрү килешмәс.

ИЛГИЗӘР. Әниләр кайда ул?

НУРХӘМӘТ. Синең туеңнан соң өй җыештыралар. Син йоклап ятасың.

ИЛГИЗӘР. Бәйләнмә инде. Әни әйтеп тора бит сиңа, урыныңда гына утыр дип.

АЛЕКСЕЙ *(Кереп)*. Мөмкинме? Нихәл, Нурхәмәт абый. Илгизәр нихәл?

ИЛГИЗӘР. Яхшы.

НУРХӘМӘТ. Шөкер, Әләкчәй. Әйдә, уз.

АЛЕКСЕЙ. Узып тормыйм. Мена булышырга кирәк. Бүген бездә җыелабыздыр инде.

НУРХӘМӘТ. Көн дә бәйрәм, көн дә туй, диген.

АЛЕКСЕЙ. Шулай инде, нишлисең. *(Тыштан кереп килгән Вераны күреп)*. Син нишләп болай йөрисең?

ВЕРА. А чё?

АЛЕКСЕЙ. Чё, чё... Голая... Голову что ли потеряла!

ВЕРА. Ну уж... *(Бүлмәләренә кереп китә, аңа Илгизәр ияре)*.

АЛЕКСЕЙ. Син ачуланма инде, Нурхәмәт абый.

НУРХӘМӘТ. Ачуланып нишлисең инде, Әләкчәй. Бер синең кызың гына түгел. Оят югалды бит ул хәзер. Телевизорларда анадан тума йөрергә өйрәткәч, болар нишләсен инде.

АЛЕКСЕЙ *(Нурхәмәт янына утырып)*. Нурхәмәт абый, үзенә генә әйтеп куйыйм, ул-бу булса, тәмсезләнешмик, ярыймы.

НУРХӘМӘТ. Нәрсә булсын?

АЛЕКСЕЙ. Дөресен әйтәм, бергә яшәүләренә ышанмыйм мин.

НУРХӘМӘТ. Кызың турында андый сүз сөйләмә. Син ата кеше.

АЛЕКСЕЙ. Шулай инде... Ата инде. Башсыз бер курчак үстер дә, нинди ата. Иткә тапшырасы үгезне печкән шикелле безне печәргә кирәк булган, Нурхәмәт абый.

НУРХӘМӘТ. Әниең ни хәлдә?

АЛЕКСЕЙ. Аның да кәефе юк, Наташаның да... Вообщем, юк инде, Нурхәмәт абый.

**Өстәл күтәреп чыгып китә. Дания белән Хәлиулла кайталар.**

ДАНИЯ *(Хәлиуллага)*. Бирәнең булгандыр. Шунда кергәч тә эчмәсәң!

ХӘЛИУЛЛА. Эчмәдем ич мин, тотып кына куйдым.

ДАНИЯ. Куйдың. Беләм мин синең куйганыңны. Миңа гына дигәнмени җыештырырга, чабарга.

ХӘЛИУЛЛА. Туй, туй, дип үзең кычкырдың, җыештырасың инде.

ДАНИЯ. Эчмәдем дигән була, теле ачылды.

ИЛГИЗӘР *(Чыгып)*. Әни, ашыйсы килә. Кая йөрисең инде?

ДАНИЯ. Тордыгызмы?

ИЛГИЗӘР. Әллә кайчан инде. Ашыйсы килә.

ДАНИЯ. Килен кайда? Нигә күренми?

ИЛГИЗӘР. Нинди килен?

ДАНИЯ. Аңгыра. Вераны әйтәм.

ИЛГИЗӘР. Ул киенә.

ДАНИЯ. Әйт хатыныңа, чәй куйсын. Әнә теге бүлмәдә өстәл тулы ризык *(Хәлиуллага)*. Әйдә, ал урындыкларны, нәрсә терәлеп каттың?

ИСЛАМ *(Керeп)*. Ярыймы керергә?

ДАНИЯ *(Аның каршысына килеп куныл)*. Бар, бар, үзең булмасын. Күземә күренмә.

ИСЛАМ *(Данияне читкә этеп)*. Туктале. Синең янга килмәдем, белдеңме.

ДАНИЯ. Чыгып кит диләр сиңа.

ИСЛАМ. Хәллә, әйт әле аждаһага берәр сүз.

ДАНИЯ *(Исламга ябышып)*. Бирермен мин сиңа аждаһа, зимагур.

ИСЛАМ. Хәллә, кичә миңа суккан кебек тамыз әле шуңа берне.

ХӘЛИУЛЛА. Дания!.. Дания, кемгә әйтәләр.

ДАНИЯ *(Исламны җибәреп)*. Күрсәтермен әле мин сиңа. *(Урындыкларны алып пырлап чыгып китә)*.

ИСЛАМ. Ай-яй. Ничек яшисең син моның белән шул гомер? Мин аны әллә кайчан кыйнап үтергән булыр идем. Нурхәмәт абый, нихәл?

НУРХӘМӘТ. Саумы.

ИСЛАМ. Савын сау да. Кичә Хәллә бик каты сылады бит әле, белдеңме. Борынның карарлыгы юк бүген. *(Хәлләгә)* Йодрык саллы икән үзеңнең.

НУРХӘМӘТ. Син ямьсезләнеп йөрмә инде, Ислам туган. Үзең гаепле.

ИСЛАМ. Ә мин гаепле булганга килдем дә, Нурхәмәт абый. Мин гаебемне Хәллә суккач та аңладым. Гаепсез булсам, Хәлиулланың сөяген генә җыеп алган булыр идегез. *(Хәлиуллага)* Кенә кума, ярыймы, Хәллә. Мин әйттем — син суктың. Квит. Бир кулыңны.

**Хәлиулла кулын суза — килешәләр. Ислам Нурхәмәт янына барып утыра.**

Әмма да ләкин шунысы бар, Нурхәмәт абый, җырны бит мин чыгармаган. Мин чыгарган җыр түгел бит ул, белдеңме?

НУРХӘМӘТ. Бөтен җырны да җырлап йөрергә димәгән.

ИСЛАМ. Җырланмый торган җырны кеше чыгармый.

ХӘЛИУЛЛА. Бар әле, Ислам, безнең эш күп.

ИСЛАМ. Ә мин мишәйт итмим. Мин Нурхәмәт абый белән. Син эшлә. Син, Хәллә — эшләр өчен генә яратылган җан иясе. Синең кебек дураклар булмаса, болай бөлми идек без, белдеңме? Эшлә син эшлә, Хәллә. Нурхәмәт абый инде эшлисен эшләгән, минем дә стаж нормальный.

НУРХӘМӘТ. Пенсия ала диләр, дөресмени?

ИСЛАМ. Дөрес бит, Нурхәмәт абый. Синең киленең зимагур дигәч тә. Шундый эшләр бар, Нурхәмәт абый, илледән пенсиягә чыгасын да үлем көтеп йөрисең. Менә мин дә үләргә авылга кайттым. *(Хәлиулла урындыклар алып чыгып киткәч)* Чәй куеп эчәр димим инде, Нурхәмәт абый. Берәр буш стакан бир әле.

НУРХӘМӘТ. Өегездә стакан булмадымыни?

ИСЛАМ. Күп сөйләмә инде *(Кесәсеннән шешә чыгара да Нурхәмәт алып килгән стаканга салып эчә)*. Берәр ипи катысы да бир инде *(Нурхәмәт теләр-теләмәс кенә ипи телеме алып килеп бирә. Ислам көлеп куя)* Теләнчегә биргән кебек, ә?

НУРХӘМӘТ. Чакырылган кунагым түгел, гаеп итмә, Ислам туган.

ИСЛАМ. Да-а... Менә син миңа әйт әле, Нурхәмәт абый. Утыз өч яшенә чаклы мич башында яткан Илья Муромецны кем ашаткан?

НУРХӘМӘТ. Кем соң ул Илия Муромис?

ИСЛАМ. Авылга лектор-фәлән килсә, кем ул Илья Муромец диген. Утыз өч яшенә хәтле эшләмичә мич башында яткан Илья Муромецны кем эшләп ашаткан диген. Шула-а-ай. Үзең акыллы да кеше син, Нурхәмәт абый. Нәселегез тәртипле. Безнең ише зимагур нәсел түгел. Ләкин бөтенесен уйлап бетермисең. Әгәр дә дөньясын бер урап кайтсаң, Әбугалисина булыр идең.

НУРХӘМӘТ. Без урыйсын урадык. Герман җирләреннән урап кайттык.

ИСЛАМ. Анысы шулай, шулай. Гафу ит, Нурхәмәт абый. *(Үз бүлмәләреннән киенеп-ясанып чыккан Илгизәр белән Верага)* Сез нихәлләрдә, тутый кошлар? Йокы туйдымы? *(Илгизәр белән Вера исәнләшмичә дә чыгып кит-*

*кәч)* Шулай. Дөнья бервакыт шундый өйрәтә, Нурхәмәт абый, дуңгызга иелеп сәлам бирә башлыйсың. Ярый, ачуланма, киттем мин. Хәлләдән гафу үтенергә дип кенә килгән идем. Ну барыбер дөрес эшләмәдегез сез. Нурхәмәт абый. Безнең авылда иң беренче булып сезнең нәсел чикне бозды. Урыс белән туганлаштыгыз. Минем урыска бер дошманлыгым юк, белдеңме? Мин күп йөрдем, күпне күрдем, татарны яратмый урыс, белдеңме? Наданнар сез. Без урыс белән кушыла алмыйбыз. Урыс белән янәшә генә яши алабыз. Син марҗага өйләнгән бер татарның баласына татар исемен кушканын ишеткәнең бармы? Урыска кияүгә чыккан татар хатынының баласы әнисенә әни дип әйтәме? Урыс татар белән татарны йотар өчен генә туганлаша, белдеңме? Наданнар сез. Нигә бүгенге көнгә хәтле безнең авылда бер татар да бер марҗага өйләнмәгән, нигә бер урыс та бер татар кызын алмаган? Нәрсә, алар сездән дуаграк булганнар мәллә? Юк, бер-берсен бик яхшы белгәннәр алар. Кушылырга ярамаганны белгәннәр.

НУРХӘМӘТ. Бар әле, энем, бар, өеңә кайт.

ИСЛАМ. Кайтам. Ләкин шуны белегез, марҗасын алып авылдан киткән бу ангыра бәрәнегез. Көн күрсәтмәячәкмен мин аңа. *(Ишеккә бара. Анда ишектән килеп керүче Хәлиулла һәм Алексей белән очраша)* Нихәл, Алексей.

АЛЕКСЕЙ. Яхшы.

ИСЛАМ. Син миңа ачуланма, яме.

АЛЕКСЕЙ. Нигә ачуланыйм.

ИСЛАМ. Минем сиңа дошманлыгым юк.

АЛЕКСЕЙ. Минем дә.

**Ут сүнә. Яктырганда өянке төбендәге утыргычта Мария утыра. Уйларына чумган. Нина үтеп барышлый аның янына туктый.**

НИНА. Здравствуй, бабка Мария.

МАРИЯ. Да вот сижу, Нинуленька, сижу и думаю.

НИНА. О чем это думаешь-то, если не секрет?

МАРИЯ. Че уж тут секретничать-то. В мои-то года...

НИНА. Твои года — твое богатство инде. Сездә туй дип ишеткән идем дә, бер дә тавыш-фәлән ишетелми. Туйны сездә уздырмаска булдыгызмыни?

МАРИЯ. Мин ул эшләргә катышмыйм.

НИНА. Наталья өйдәме соң?

МАРИЯ. Өйдәләр. Туган-тумачалар, кодалар гына җыйналып...

НИНА. Алайса туй инде. Шыпырт кына диген. Наталья мине чакырмады да.

МАРИЯ. Анысын мин белмим инде. Бар соң, кер.

НИНА. Чакырылмаган килеш... Незваный гость хуже татарина дигәнне ишеткәнең юкмы әллә?

МАРИЯ. Юк. Ишеткәнем юк.

НИНА. Киявегез татар булгач, колагыгыз ишетми башлагандыр шул. Качып-посып кына туй үткәрәсез. Кичәге туегызны да әйтер идем инде. Татарлар теләсә нәрсә кылана. Без ят кешеләр кебек утырдык.

МАРИЯ. Боларны син нигә миңа әйтәсең?

НИНА. Авылдагы үзебезнең егетләрне санга сукмыйча.

МАРИЯ. Син санга суктың да бит, үзебезнекеләр сине санга сукмады. Аерып җибәрделәр. Ничәвенә чыгып карадың, хәзер менә ялгыз яшисең.

НИНА. Ну и пусть. Мин гомеремдә ир күрмәсәм дә татарга кияүгә чыкмыйм. Пачкать себя не стану.

МАРИЯ. Балаболка ты, Нина.

НИНА. Ну и балаболка. Вот ты на старости лет своих правнуков-татарчат будешь нянчить *(Кулында бала тибрәткәндәй итеп)* Әхмәт, Җәмилә, Абдулла... Әхмәт, Җәмилә, Абдулла. Бәү-бәү, бисмилла, бәү-бәү, бисмилла.

МАРИЯ. Нигә шул чаклы яратмыйсың татарларны, алар сиңа ни начарлык эшләде?

НИНА. Яратмыйм и все. Че они зашумели. Сувиринитет, сувиринитет. Туган тел, туган тел. Недорезанные. Чуть что, они начнут тут хозяйничать. Им только дай волю. Триста лет нас мучали, опять хотят.

МАРИЯ. Кто тебя мучил-то? Беспутная ты, бестыжая. От злости это у тебя все. Люди как люди. По людски-то надо жить.

НИНА. Продались вы все. Душу дьяволу продали. Вот пошло все кувырком. Свадьбу справляют — от людей прячутся. Тьфу!.. Креста на вас нету. Прости, господи, за наши грехи-то... *(Урыныннан торып)* Прощевайте, бабка Мария, пейте, ешьте, гуляйте. *(Алексейлар өендә ишетсеннәр дип кычкырып частушкалар әйтә-әйтә чыгып китә).*

Я хотела выйти замуж,
Хотела за барина.
Хотела за барина
Вышла за татарина.

Мой миленок-татаренок,
Сама не татарочка.

Я сикушка, он чаплашка —
Мировая парочка.

Милого обрезали —
Обезобразили;
Не обезобразили —
Разнообразили.

НАТАЛЬЯ *(Атылып керен)*. Это кто? Нинка, что ли?

МАРИЯ. Она.

НАТАЛЬЯ. Че это она? *(Нина артыннан куып чыгып китә. Анда талашкан, сугышкан тавышлар)*.

МАРИЯ. Господи!.. Господи!.. *(дип кенә утыра)*.

НАТАЛЬЯ *(Әйләнеп керә. Чәчләре тузган)*. Я покажу тебе, вертихвостка. Я тебе покажу, потаскуха чертова. А ты что здесь сидишь? Места что ли дома нет? *(Мариянең йөзенә игътибар белән рәк карап)* Ты че, плачешь что ли? Че ты? Мама... Мам... *(Мария эндәшмәгәч, аның каршына тизләнә)* Ну, перестань. Мама... *(Шуннан Мариянең алдына башын салып үзе кычкырып елап җибәрә)* Да что же это такое!?. Господи!.. Что я тебе плохого сделала. Единственная дочь... На свадьбе-то как на похоронах. Что же это такое? За что, за что так?!. Мама!.. Милая!.. За что же такое наказание?!.

МАРИЯ. Наталья!.. Не надо, Наталья... Успокойся, че ж теперь убиваться-то.

НАТАЛЬЯ. *(Тынычлана төшеп)* Живут же люди... Зачем же так? Живут же... Ничего ж такого не случилось. Ну вышла замуж... Ну не послушалась. Разве мы слушали родителей? Так уж ведется, живут же... Зачем же людей срамить-то. Ну вышла, что я могу делать-то?.. Дура она, Нинка, дура...

ДАНИЯ *(Күренә. Ул шат күңелле)*. Наташа, кая югалдың син? Анда күрсәң... Синеке белән минеке кочаклашканнар да җырлыйлар. Нәрсә җырлаганнарын да белеп булмый. Әйдә, әйдә, утырма, кер. Әйдә, бер кара-каршы басып биик әле, чукынып китсен дөньясы, әйеме. *(Такмак әйтә-әйтә бии)*.

Пич башыннан егылып төшкән
Сәхипҗамал тәтәгез.
Безгә гармун-нар кирәкми —
Гармунсыз да әйтәбез.
Әй, барыйна, барыйна,
Мин дә суга барыйм ла.
Мине суга аппармасаң,
Күтең тибеп ярыйм ла.
Әй, барыйна, барыйна.
Сударыйна-барыйна.
Әй, барыйна, барыйна,
Сударыйна-барыйна.

**Туктаусыз кабатлап бии. Ут сүнә. Ут янганда Хәлиуллаларның өе. Нурхәмәт идәнгә яулык җәйгән дә шуның өстендә намаз укый. Дания кайтып керә, чишенә. Гомерендә намаз укымаган кайнатасының «кыланышына» аптырап карап тора да көлеп җибәрә. Нурхәмәт аңа игътибар итми.**

ДАНИЯ *(Көлүеннән туктап)*. Нишлисең син? *(Нурхәмәт эндәшмәгәч)* Сиңа әйтәләр, әткәй.

НУРХӘМӘТ *(Амин тотып, яулыкны җыеп алгач)*. Күрмисеңмени?

ДАНИЯ. Күргәнгә сорыйм да шул менә. Гомердә кыланмаганны.

НУРХӘМӘТ. Мин кыланмыйм. Колагыңа киртләп куй.

ДАНИЯ. Киртләвен киртләрмен дә. Беренче тапкыр күрәм *(Көлеп)*. Шундый килештерәсең. Әллә мулла булырга җыенасыңмы? Эт чаба, дип, бет чаба. Тотындылар. Дин дә дин. Татар да мөселман. Мәчет салалар да искечә китаплар саталар. Син дә шуларга иярдеңмени?

НУРХӘМӘТ. Гөнаһ җыеп күп йөрдек. Җитәр. Бер ходайдан гафу сорарга вакыт.

ДАНИЯ. Укый беләсеңме хет, ичмасам. Бисмилла да әйтмәгән кеше...

НУРХӘМӘТ. Белмәсәк, өйрәнербез.

ДАНИЯ. Өйрән инде алайса, өйрән. Кәләпүш алып җибәрербез үзеңә. *(Яулыкны кулына алып)* Әнкәй мәрхүмәнең яулыгы түгелме соң бу?

НУРХӘМӘТ. Булса ни.

ДАНИЯ. Нигә әле син минем белән сырт куеп сөйләшәсең? Сиңа сүз әйткән кеше юк лабаса. Рәхәтләнеп укы. Миңа димәгәе. Хәлиуллага әйт, Казан мәчетеннән әйбәт намазлык алып кайтсын. Анда саталардыр... Илгизәрләр кайтмадымыни?

НУРХӘМӘТ. Кайттылар.

ДАНИЯ. Нәрсә, кайтып керүгә тагын шунда кереп киттеләрме?

НУРХӘМӘТ. Әйтмәделәр.

ДАНИЯ. Кызык тапты. Иртә дә алып кереп китә, иртә дә алып кереп китә.

НУРХӘМӘТ. Керсә... Атасының йорты. Сагынгандыр.

ДАНИЯ. Монда йорт түгелмени? Дәшми-дәшми торгач та... Миңа әйткәндә өздереп әйтәсең. Шунда берәр сүз әйтергә ярыйдыр сиңа да.

НУРХӘМӘТ. Ни әйтим мин аларга?

ДАНИЯ. Бу тәп йорт, диген. Килен булып төшкәнсең икән, онытма, диген. Менә мин алай эшләмәдем бит.

НУРХӘМӘТ. Эшләмәдең инде, эшләмәдең...

ДАНИЯ. Нәрсә, нәрсә, нәрсә?.. Нәрсә эшләгән ул кадәрле? Малаең юаш булганга әллә мин гаепләме? *(Өстенә киенә башлый).*

НУРХӘМӘТ. Йөрмә. Кеше белән сөйләшә белмисең. Тавыш чыгаргамы? Кайтырлар.

ДАНИЯ. Өйрәтмә.

НУРХӘМӘТ *(Тәрәзәдән күреп).* Әнә, кайтып киләләр. Сүзеңне үлчәп сөйлә.

ДАНИЯ. Өйрәтмә, диләр *(Илгизәр белән Вера көлешә-көлешә кайтып керәләр).*

ВЕРА. Исәнмесез.

ДАНИЯ. Исәнен исән дә бит менә. Кайтып кергәнсез дә чыгып чапкансыз. Өйләнешкәнегезгә өч ай, өйдә торганыгыз юк. Кунактан кунакка, кунактан кунакка. Ярый, барыгыз, чишенегез. *(Илгизәр белән Вера үз бүлмәләренә кереп китәләр).* Әни, дип тә әйтә белмиләр.

НУРХӘМӘТ. Өйрәтмәгәч, ничек әйтсеннәр...

ДАНИЯ. Җитте инде сиңа. Болай да ачуым чыгарга тора.

**Нурхәмәт үз бүлмәсенә кереп китә. Илгизәр белән Вера чыгалар.**

ВЕРА *(Даниягә бер төргәк сузып).* Менә, әниненең апалары сезгә җибәрделәр. Бүләк.

ДАНИЯ *(Төргәкне сүтеп, аннан кофта ала)* Ай, рәхмәт. Озак тордыгыз.

ИЛГИЗӘР. Җибәрмиләр.

ВЕРА. Мәскәүдә безнең туганнар бик күп бит. Әле берсенә, әле берсенә.

ДАНИЯ. Яхшы булган. Мәскәү ошадымы соң?

ВЕРА. Юк. Кибетләрдә бернәрсә дә юк. Мин теге барганда бөтен нәрсә бар иде.

ДАНИЯ *(Илгизәргә).* Син нигә бер сүз дә дәшмисең?

ИЛГИЗӘР. Нәрсә дәшим. Әйбәт... Яхшы...

ДАНИЯ. Яхшы икән, яхшы. Инде болай. Сиңа ир, сиңа хатын (Верага) булырга вакыт. Гел кунакка гына йөрмиләр. Бу өйдә сез кунак түгел.

ВЕРА. Ә нишләргә? Чәй куярга, что ли?

ДАНИЯ. Чәй дә куярсың, башкасын да эшләрсең. Мин биреп җибәргән акчагызны нишләттегез?

ИЛГИЗӘР. Анда киемнәр юк. Спекулянтларда гына. Кыйбат. Ә без, беләсеңме, нәрсә алдык. Японский магнитофон. Беләсеңме, арзанга туры килде. Болай биш меңгә саталар. Бу өч меңгә.

ДАНИЯ. Күпмегә?

ИЛГИЗӘР. Өч мең *(Бүлмәсенә кереп магнитофон күтәреп чыга).* Менә. Дүрт кассетасы бар.

ДАНИЯ. Акылың бармы синең?

ИЛГИЗӘР. Ә нәрсә? Моны әле көчкә таптык. Оляның танышлары табып бирде.

ДАНИЯ. Кем инде ул Оля?

ВЕРА. Моя двоюродная.

ДАНИЯ. Ике мең генә алып киткән идең бит акча.

ВЕРА. Тетя дала. Взаймы.

ДАНИЯ. Син нигә әле урысча сөйләшеп утырасың? Монда бит урыслар юк. Кем түли инде ул бурычыгызны?

ИЛГИЗӘР. Туйдан калды бит әле акча.

ДАНИЯ. Әй, алла... *(Өстәлдән самавырны җилтерәтеп алып китә).*

ВЕРА. Я тебе сказала.

ИЛГИЗӘР. Әй... Аның ни эше бар туй акчасында. Бүген клубка алып чыгабыз. Көнләшеп үләчәкләр. *(Магнитофонны кабыза. Аннан пәри туена охшаган ритм бәреп чыга).*

*НУРХӘМӘТ (Ишектән башын тыгып).* Ни булды?

ИЛГИЗӘР. *(Рәхәтләнеп көлеп магнитофонны туктата).* Ишеттеңме, бабай? Менә шундый була ул магнитофон. Японский. Японский. Сони. *(Нурхәмәт ишекне ябып куйгач)* Мин сиңа әйттем бит, Вера. Миңа бер сүз дә әйтә алмыйлар алар *(Магнитофонны кабыза).*

ДАНИЯ *(Кереп, бар тавышына кычкыра).* Тукта-а-ат!..

ИЛГИЗӘР *(Магнитофонны туктатып).* Нишлисең син, ә?

ДАНИЯ. Кертеп куй тизрәк, күземә күрсәтмә.

ИЛГИЗӘР. Нишлисең син, ә?

ДАНИЯ. Кертеп куй, аяк астына салып таптаганчы... *(Илгизәр магнитофонны алып кереп киткәч, Верага)* Син әйтер идең шул аңгырага. Син бит — хатын, семья тотасы кеше. Син дә санамагач акчаны, кем санасын. Ирләргә аларга нәрсә: гөмбә — шалкан, бук — талкан. Гомер итәсегез бар.

ВЕРА. Ә миңа нәрсә...

ДАНИЯ. Миңа нәрсә, миңа нәрсә... Кияүгә чыкканда белмәденмени нәрсә икәнен? Кияүгә чыгуны әллә кунакка йөрү дип белдеңме?

ВЕРА. А чего вы на меня кричите?

ДАНИЯ. Мин ни кричу, мин ничек яшәргә әйтәм.

ВЕРА. Ну и яшәгез. Какое ваше дело в нашей жизни.

ДАНИЯ. Ничек инде эшем булмасын?! Мин сезгә әниме, юкмы? Синең миңа, әни, дип тә әйткәнең юк.

ВЕРА. У меня есть своя мама. Только на меня не кричите. Моя мама на меня не кричит.

ИЛГИЗӘР *(Бүлмәдән чыгып)*. Вера, әйдә. *(Вераның кулыннан тотып бүлмәсенә тарта)*.

ВЕРА. Перестань. Скажи своей маме, чтоб она на меня не кричала. Накричалась.

**Илгизәр белән бүлмәгә кереп китәләр. Бик әйбәт кенә сабак алган Дания ни эшләргә дә белми басып кала. Хәтта ул бераз курыккан да бугай әле. Хәлиулла кайтып керә. Сүзсез генә чишенә.**

ХӘЛИУЛЛА. Салкынайтты кичкә таба.

ДАНИЯ. Нәрсә?..

ХӘЛИУЛЛА. Салкынайтты дим. Чәй куйдыңмы?

ДАНИЯ. Ни дидең?

ХӘЛИУЛЛА. Чәй куйдыңмы дим? Балалар кайда соң әле? Кайттылар, дигәннәр ие.

ДАНИЯ *(Әкрен генә исенә килеп)*. Бүлмәләрендә.

ХӘЛИУЛЛА *(Даниянең йөзенә карап)*. Берәр нәрсә булды мәллә? Кыяфәтең киткән?

ДАНИЯ. Нәрсә булсын миңа *(Үзе борынын мышкылдатып елый башлый)*.

ХӘЛИУЛЛА. Ни булды?

ДАНИЯ. Сорама. Сорама, Хәлиулла.

ХӘЛИУЛЛА. Әти белән әйткәләштегезме?

ДАНИЯ. Кайчан минем әткәй белән әйткәләшкәнем бар? Әй, дурак булдым, дурак булдым. Үз кулларым белән тотып бирдем бит улымны. Күршедә генә яшәп, кем икәнен белмәгәнмен. Дурак булдым, дурак булдым.

ХӘЛИУЛЛА. Инде бу киленең белән дә чәкәшеп өлгердеңмени? Нәрсә житми сиңа, ә? Нигә яшьләр арасына керәсең? Тимә, яшәсеннәр үзләренчә. Аларның үз тормышы, безнең — үзебезнеке.

ДАНИЯ. Саруым кайнатып утырмале син дә... Сиңа бөтенесе дә әйбәт. Мин изаланам алар белән. Ходаем, бер сыер алырлык акчага моның хәтле тартма күтәреп кайтканнар бит. Ни кричи, дигән була бит әле, маржа тәресе.

ХӘЛИУЛЛА. Әкрен инде... Нәрсә алып кайтканнар дисең?

ДАНИЯ. Нәрсә булсын — магнитофон, ди. Өч мең тәңкә, ди.

ХӘЛИУЛЛА. Чит илнекедер. Бик кыйммәт, дип, сөйләп торалар иде мастерскойда малайлар. Йә, ярый, алган — булган. Югалтмаганнар бит. Яшьләргә анысы да кирәктер. Үзләре эшли башлагач, акчаның ни икәнен аңларлар әле. Мин механик белән сөйләштем, Илгизәрне үз яныма урнаштырырбыз. Эшкә үзем өйрәтеп, үз урыныма калдырырмын. Вера фермага барыр. Син инде, Дания, давай канатларыңны бик җилпемә. Бераз гына алар җаена да тор. Дөнья бит син дигәнчә генә булмый. Ярый ла мин түзәм.

ДАНИЯ. Түзеп, нишләттем соң әле мин сиңе? Ашарыңа әзер, өс-башың чиста.

ХӘЛИУЛЛА. Анысы шулай инде. Яшьләр беләмени аны.

**Илгизәр белән Вера чыгалар.**

ВЕРА. Исәнмесез... Хәлиулла... Абый...

ХӘЛИУЛЛА *(Вераның уңайсызланганын күреп)*. Ярый, ярый, ничава... Өйрәнерсең. *(Илгизәргә)* Син нихәл?

ИЛГИЗӘР. Әйбәт.

ХӘЛИУЛЛА. Әйбәт булгач, бик әйбәт.

ВЕРА *(Даниягә)*. Сез мине гафу итегез. Я не хотела...

ДАНИЯ. Ярар. Булган — беткән. Утырыгыз. Чәй чыгарам.

**Өстәл әзерли. Вера бик матур итеп кенә утырып тора, ярдәм итәргә уйламый да. Дания аңа карап-карап ала, Вера аның карапын, кызганычка карпы, аңламый.**

ХӘЛИУЛЛА *(Нурхәмәт бүлмәсенең ишеген ачып)*. Әти, чык чәй эчәргә. *(Нурхәмәт чыгып утыргач)* Эшләр ничек, әти?

НУРХӘМӘТ. Тәгәри.

ДАНИЯ *(Эш арасында)* Син аңа кәләпүш алып кайт, намаз укый башлаган.

НУРХӘМӘТ. Булды инде сиңа, житте.

ХӘЛИУЛЛА. *(Илгизәргә)* Мин механик Хәерҗан абыең белән сөйләштем. Мастерскойга урнашырсың эшкә. Жылыда. Эшкә өйрәнерсең.

ИЛГИЗӘР. Без бит китәбез.

ДАНИЯ *(Самавар күтәреп чыгып килгән җиреннән ишетеп калып)* Ничек китәсез? Кая китәсез?

ИЛГИЗӘР. Абыйлар янына, Чаллыга.

ДАНИЯ *(Самаварны өстәлгә куеп)* Нәрсә калган анда сезгә?

ИЛГИЗӘР. ЕлАЗга эшкә керәбез.

ДАНИЯ. Нинди елаз?

ИЛГИЗӘР. Машина заводы. Автомашиналар чыгарачак ул. Шунда китәбез.

ДАНИЯ *(Хәлиуллага)* Син аның нәрсә сөйләгәнен ишетәсеңме? *(Илгизәргә)* Кем котыртты?

ИЛГИЗӘР. Беркем котыртмады. Авылда калмыйбыз.

ДАНИЯ. Безнең ни әйткәннәрне оныттыңмыни? Әтиең белән гел әйтеп килдек, авылда, үзебезнең янда, төп йортта каласың, дидек. Бер кая да китмисез. Менә ындыр табагы хәтле өй. Кем өчен дип тырышып-тырышып салдык без аны? Анда упшыйжитиедә йөрергә. Абыеңнар ничә ел упшыйжитиедә интектеләр?

ВЕРА. Мин авылда калмыйм.

ДАНИЯ. Нигә?

ВЕРА. Фермада эшләргә теләмим.

ДАНИЯ. Анда эшләмәсәң, бүтән җирдә эш табылыр.

ВЕРА. Мин барыбер авылда калмыйм.

ДАНИЯ. Ничек инде мин калмыйм, ирең бар бит синең.

ВЕРА. Ул теләсә нишләсен.

ДАНИЯ. Ничек инде?..

ХӘЛИУЛЛА. Туктагыз әле, туктагыз. Алексей, Наташа, бергәләп сөйләшербез. Болай гына булмый ул. Уйлашырбыз. Син, кызым, алай кистереп сөйләшмә. Әнә, әнкәң Дания, сүзен өзеп сөйли дә соңыннан үкенеп бетә алмый. Һәрнәрсәнең дә тәртибе бар бит. Әйдәгез әле, табын янында әйбәтләп кенә чәй эчик. Карагыз ничек, нинди түгәрәк табын — әти, без, сез... *(Нурхәмәткә)* Шулаймы, әти?

НУРХӘМӘТ. Матур итеп сөйләргә өйрәнеп кайткансың әле, тыңлыйм да аптырап утырам.

ДАНИЯ *(Вераның муенына асылган тәрене күреп алып)*. Нәрсә ул?

ХӘЛИУЛЛА. Тагын ни булды инде?

ДАНИЯ. Тәре бит. Чын тәре. Муенына аскан. *(Верага)*. Яле, күрсәт әле...

ВЕРА. А че? Крестик есть крестик. Оля бүләк итте, үзенә алган булган, миңа бүләк итте. В Москве их полно.

ДАНИЯ. Син тактыңмы?

ВЕРА. А че?

ДАНИЯ. Тәре бит ул.

ВЕРА. Я знаю, что тәре.

ДАНИЯ *(Нурхәмәткә)* Әткәй... Тәре таккан бит.

НУРХӘМӘТ. Утыр әле урыныңа. Әллә тәре күргәнең юкмы?

ДАНИЯ *(Илгизәрнең изүен ычкындырып карап)* Син нигә такмадың? Нәрсә инде бу, я, нәрсә инде бу? *(Илгизәргә)* Син күрдеңме аның тakkанын?

ИЛГИЗӘР. Күрсә, ни булган?

ДАНИЯ. Тәре бит ул, беләсеңме син шуны, тәре!..

ВЕРА. Нәрсә инде сез тагын кычкырасыз?! Он же подарок сестры моей. Я же не верующая. Вы же знаете, я не верующая.

ДАНИЯ. Хәлиулла, син нигә бер сүз дә дәшмисең?

ХӘЛИУЛЛА *(Кычкырып)* Җитте диләр сиңа. Дәшми-дәшми торгач та. Башта үзең йөрдең. Белмәдеңмени малаеңның кемгә өйләнгәнен.

ДАНИЯ. Белмәдем, белмәдем. Мин тәре тага торган марҗага өйләндерергә үстермәдем улымны. Миңа тәреле марҗа кирәкми.

ХӘЛИУЛЛА. Әйтеп торалар бит сиңа, «бүләк», диләр. Киеп йөрер дә салып куяр.

ДАНИЯ *(Верага)* Сал, хәзер үк сал! Күземә күрсәтмә!

ВЕРА. А вот и не сниму. Назло буду носить.

ХӘЛИУЛЛА. Вера, кызым, туктале, утыр әле.

ВЕРА. Ә нигә ул миңа кычкыра. Не кричите на меня *(Кычкырып елап, өстенә дә кимичә, чыгып йөгерә)*.

ХӘЛИУЛЛА *(Аның артыннан ашыгып)* Вера, туктале, Вера...

**Дания башын учлап уфылдап утырып кала.**

НУРХӘМӘТ *(Башын аска иеп утырган Илгизәргә)*. Син нишләп утырасың, бүкән? Хатының чыгып китте. Хатының чыгып китте, диләр сиңа. *(Илгизәр урыныннан торып, әнисенә карый-карый ишеккә таба бара)*.

ДАНИЯ. Тукта!.. Аягыңны атлыйсы булма!..

НУРХӘМӘТ. Син нишләгәнеңне беләсеңме, тиле баш?! *(Туктап калган Илгизәргә)* Бар!

ДАНИЯ. Тәре ич, әткәй! Мин аны шушы яшемә җитеп авылда карт марҗалар белән карт урысларда гына күрә идем. Ялтырап тора торган тәре тагып кайткан бит.

ИЛГИЗӘР. Әни!..

ДАНИЯ. Тәресен өйләрендә калдырмаса, бусагамны атлап кермәгез.

**Ут сүнә. Ут карт өянкене яктырта. Утыргыч буш. Сәхнәнең ике ягыннан Мария белән Нурхәмәт керәләр. Берсен-берсе күреп туктап калалар. Ике күрше йорт арасыннан узып киткән шомның шаукымы боларга да кагылган — икесе дә гөнаһ эшләгән кешеләр сыман уңайсызланалар.**

МАРИЯ *(ниһаять, телгә килеп)* Нихәл, Нурхәмәт. Берәр җиргә баруыңмы?

НУРХӘМӘТ. Кибеткә дип чыкканыем да, ачыкмыдыр.

МАРИЯ. Ачыгын ачык та, бернәрсә дә юк анда. Сания бер үзе туңып утыра.

НУРХӘМӘТ. Көн суыткан, ахрысы.

МАРИЯ. Ни дисең?

НУРХӘМӘТ. Көнне суыткан ахры, дим.

МАРИЯ. Минем колак шаулый башлады әле, Нурхәмәт күрше. Кычкырыбрак сөйлә. Унбиш градус дигәннәрие иртән радиодан.

НУРХӘМӘТ. Булыр. Раштуа житеп килә бит. Нихәлләрдә соң, күргәнем дә юк. Өйдән дә бик чыгасы килми хәзер. Мичкә сыртны терәп утырам шунда. Эш кушучы да юк. Сыерлар астын карарга дип чыкканыем кичә, килеп куып кертте. Йөрмә, ди, авырып егылсаң, мина интегергә кала, ди.

МАРИЯ. Шулай инде, нинди эш инде ул бездән.

НУРХӘМӘТ. Гомер буе эшләгәч, йөрәк чыдамый шул. Кирәксез кеше булудан да начар нәрсә юк икән, Маруся күрше. *(Икесе дә әкрен-әкрен селкенеп үзләре сизмәстән утыргыч янына килеп җиткәннәр. Нурхәмәт урындыкны бияләе белән сыпырып)* Утыр әле, Маруся күрше.

МАРИЯ. Кирәкми, Нурхәмәт, кузгатма, искә төшерәсем килми.

НУРХӘМӘТ. Юк, мин аны әйтмим. Теләсәләр нишләсеннәр. Безнең ни катышыбыз бар, әйе бит. *(Шулчак һәрвакыттагыча салып алган Ислам пәйда була).*

ИСЛАМ. Һәйт!.. *(Куркып киткән Мария белән Нурхәмәттән көлеп)* Кода белән кодагый нишли монда, бу салкында? Өегездә утырыгыз. Эшләр ничек соң, ә? Как дела, тетя Маруся? Картаеп буламы?

МАРИЯ. Син үзең дә инде яшь түгел.

ИСЛАМ. Сезнең арттан куам.

НУРХӘМӘТ. Бик әлләни куалмассың ла...

ИСЛАМ. Нигә, Нурхәмәт абый?

НУРХӘМӘТ. Аек көнең юк.

ИСЛАМ. Син минем өчен кайгырма, Нурхәмәт абый. Ходай биргәнен ашәрбез. Салкын бит. Үтеп барышлый Ниналарга кердем дә, яле мин әйтәм, раштуа бәйрәмене куган самогонынпан авыз иттер әле, дим. Юк, дигән була. Белмиләр ди самогоны барлыгын. Тәки бер стакан салып бирде, мә, проклятый татарин, ди. Үзе проклятый, ди, үзе бирә. Шулай ул дөнья, тетя Маруся. Җырлыйммы, Нурхәмәт абый?

НУРХӘМӘТ. Бугазына суык тияр.

ИСЛАМ. Ничава. Безнең бугазлар каешланып беткән инде ул.

> Кыр казы
> Иделләр читендә.
> Ялгыз башым миңа читен лә...

**Ут Хәлиуллаларның өе эчендә күчә. Анда Хәлиулла, Дания һәм Илгизәр.**

ХӘЛИУЛЛА. *(Даниягә)* Чәенне куй.

ДАНИЯ. Анарга әнисе куйган чәй ошамады бит. Кипәтүк эчәргә китте, пумала башка иярәп.

ХӘЛИУЛЛА. Бергә яшәгәч, иярәсен инде ул. Мин дә бит утыз ел сина ияреп йөрим.

ДАНИЯ. Иярт ерсең сине. Дәшми-дәшми торасың да тешләп аласың *(Илгизәргә)* Рәхәттер инде упшыйжитийдә яшәүләре. Сүз әйтергә әни юк. Хат язып салу юк. Балаларының туганын да кешеләрдән генә ишетәбез.

ИЛГИЗӘР. Үзең ич. Кайтып күренәсе булмагыз, диден.

ДАНИЯ. Кайткансың бит әле. Хатынының әнисе килдеме соң?

ХӘЛИУЛЛА. Барсак, бергә генә барабыз, диде ич Наташа.

ДАНИЯ. Ышан ул астыртын еланга.

ХӘЛИУЛЛА. Булды. Чәенне куй *(Илгизәргә)* Бар, бабаң белән исәнләшеп чык, чирләбрәк тора. *(Илгизәр керерп киткәч)* Бик каты бәрелмә, болай да башы әйләнгән чагыдыр.

ДАНИЯ. Әйләнчек бәрән булып туган инде туганда ук. Сора әле, балаларына нинди исәм куштыралар икән? Әйт, Айдар кушсыннар.

ХӘЛИУЛЛА. Үзләре табарлар әле. Баласын тапканнар бит.

ДАНИЯ. Табарлар, бик әйбәт итеп табарлар. Иван куштырып куяр маржасы.

ХӘЛИУЛЛА. Иван булса, Иван инде, бер нишләп тә булмый.

ДАНИЯ. Утырмасана үртәп... Болай да җыларга гына торам. Бөтен нервыларымны бетерде. Хәлиулла, сөйләш яме матур итеп. Мин әйткәнне колагына алмый ул. Зинһар өчен дип сорыйм, урыс исеме куштыра күрмәсен баласына.

ХӘЛИУЛЛА. Әйтте ич инде Наташа, Илгизәр үзе нинди исем таба, шуны кушарлар, диде. Алексей да шулай ди.

ДАНИЯ. Кайчан сөйләшеп өлгерден соң әле?

ХӘЛИУЛЛА. Кичә сүз чыкты да...

ДАНИЯ. Үзең тагын мыштым

гына йөрсәң дә... *(Илгизәр чыкканы күреп)* Ярый, сөйләшеп утыра торыгыз, мин хәзер чәй куеп җибәрәм *(Самоварны күтәреп алып чыгып китә)*.

*ХӘЛИУЛЛА. Нәрсә, Вера кайтмаска итте мени?*

*ИЛГИЗӘР. Кайтты ул. (Шул сүз әйтелүгә Дания ялт итеп килеп чыга, тыңлап тора).*

ХӘЛИУЛЛА. Кайда соң алайса?

ИЛГИЗӘР. Өйләренә кереп китте.

ХӘЛИУЛЛА. Бергә кайттыгызмы соң?

ИЛГИЗӘР. Бергә.

ХӘЛИУЛЛА. Сүзгә килмәгәнсездер ич?

ИЛГИЗӘР. Юк.

ХӘЛИУЛЛА. Ничек инде ул алай?

ИЛГИЗӘР. Мин сезгә кермим, диде. Әниең күзенә күренмәскә кушты, диде.

ДАНИЯ. *(Түземичә)*. Нигә соң алайса үзең кердең? Ияреп киткәнне ияреп керергә иде.

ХӘЛИУЛЛА. *(Чыгырыннан чыгып)* Җитте сиңа канса кансов! Сугып торып җибәрермен. Нәрсә сез мине!.. Кем башына ашкынасыз? Әллә сез мине уенчык дип белдегезме? *(Даниягә)* Бар урыныңа, күренәсе булма!

ДАНИЯ. *(Куркуга төшеп)* Нишлисең син, ә? Нишлисең син, ә? *(дип чигенә-чигенә чыгып югала)*.

ХӘЛИУЛЛА. *(Илгизәрнең изүеннән тотып күтәрә)*. Ә син!.. *(Ни әйтергә белми улына карап тора да)* Их, сез!.. *(Илгизәрнең изүен җибәреп)* Ишәк. Хәер, атасы ишәк булгач, малае кем булсын? *(Бала күтәргән Вераны җитәкләп Наталья керә)*...

НАТАЛЬЯ. Исәнме, Хәллә? Менә киленегезне алып кердем.

ХӘЛИУЛЛА. Нихәл соң, Вера?

ВЕРА. Исәнмесез *(Баласын кочаклап утыра бирә)*.

ХӘЛИУЛЛА. Безнең онык ничек соң? Яле, күрик әле.

**Вера янына килгәндә тышта карт өянкенең шатырдап ауганы ишетелә. Хәлиулла тәрәзәгә барып каплана. Ни булды? дип Дания белән Наталья чыгалар.**

ХӘЛИУЛЛА. Өянке ауды.

ДАНИЯ. Күпме әйттем кисеп ташлыйк дип. Черегән иде инде.

ХӘЛИУЛЛА. *(Тәрәзә яныннан китеп)* Йә, ярар. Хәерлегә булсын! Ярый әле үтеп баручы булмаган. *(Илгизәргә)* Әйдә, урамга аркылы ауган, юлны ачыйк *(Чыгып китәләр)*.

НАТАЛЬЯ. Син миңа ачу саклама, Дания. Икесе дә тиле бит әле, нишләтәсең. Утыра бит әнә авызын турсайтып *(Верага)*. Исәнләшергә дә оныттыңмы әллә? Кара, мине яклар, дип уйлама.

ВЕРА. Ну и не надо. Я и не хотела приезжать... Сама писала-плакалась.

НАТАЛЬЯ. Замолчи! *(Даниягә)* Нурхәмәт абый ничек?

ДАНИЯ. Ята.

НАТАЛЬЯ. Сөенечен алырмын дигән идем. Оныгыбыз койган да куйган ул. Сакал-мыек та ябыштырсаң. *(Верага)* Күрсәт әле, кызым. *(Баланы үз кулына алып Даниягә күрсәтә)* Күр әле, койган да куйган, әйеме?

ДАНИЯ. Исемен Айдар дип кушабыз.

НАТАЛЬЯ. Айдар? Айдар Илгизәрович. Нигә? Матур *(Верага)*. Шулай бит, кызым?

ВЕРА. У него уж есть имя.

НАТАЛЬЯ. Куштырдыгызмыни? Нигә соң аны әйтмәдең?

ВЕРА. Не спрашивала — не сказала.

НАТАЛЬЯ. Ничек соң?

ВЕРА. Иван.

ДАНИЯ. Иван?!

ВЕРА. Да!.. Иван!.. Есть свидетельство о рождении... Иван!..

ДАНИЯ. Ходаем!.. Хәлиулла-а!.. *(дип үкереп чыгып йөгерә, аңа Наталья ияреп. Ул Данияне ауган өянке янына озата чыга. Дания кычкырып өянке янында балта тотып торган Хәлиулла янына чаба)* Хәлиулла-а!.. Иван... Хәлиулла-а...

НАТАЛЬЯ. *(Йөгереп килеп Данияне тота)*. Дания!.. Туктале, Дания!

ДАНИЯ. Кит! Китегез! Барыгыз да бер... *(Натальяны этеп җибәреп)* Иван... Иван...

**Чыгып китә. Аңа Хәлиулла белән Наталья ияреп. Илгизәр берүзе басып кала. Бала күтәреп Вера чыга. Илгизәргә күз дә салмый, үзләре ягына юнәлә.**

ИЛГИЗӘР. Вера...

ВЕРА. *(Өянке өстенә баскан килеш)* Отстань! *(Китеп бара. Илгизәр ялгызы өянке янына утырып кала. Мария керә.)*

МАРИЯ. Ни булган бу өянкегә? Әллә кискәннәр инде. Ауган түгелме соң бу? Ауган ич бу. Кара, бер дә авар кебек түгел иде ич. Ауган шул. Нурхәмәт белә микән. Кара син, ә, бер дә авар төсле түгел иде.

ПӘРДӘ

# КОТЛАУЛАР

Татарстан Республикасы Югары Советы Президиумы мөхтәрәм «Казан утлары» журнал коллективын олы юбилейлары белән чын күңелдән котлый.

Татарстанда һәм аннан бик еракларда яратып укылучы һәм хөрмәткә ия бу журналга — 70 ел. Үзенең беренче номерларыннан ук ул республика тормышының мөһим мәсьәләләренә, татар халкының мәдәниятенә янача мөнәсәбәте белән киң җәмәгатьчелекнең игътибарын җәлеп итте. Заманыбызның бик күп күренекле язучыларына һәм шагыйрьләренә иҗат мәктәбе булды. Бүгенге татар мәдәниятенең үсешенә журналның керткән өлешен бәяләп бетерү мөмкин түгел.

Сезнең талантлы коллективыгыз киләчәктә дә туган телебезне, әдәбиятыбызны һәм сәнгатебезне үстерү кебек изге эшкә турылыклы булып калыр дип ышанабыз.

Рухиятнең бөек әләмен югарырак күтәрегез!

Изге эшегездә Сезгә иҗади уңышлар һәм бетмәс-төкәнмәс оптимизм телибез.

**Татарстан Республикасы**
**Югары Советы Президиумы**

## «Казан утлары» журналына

*(70 ЕЛЛЫК ЮБИЛЕЕ УҢАЕННАН)*

Яндың ярып син төннәрне,
караңгы болытларны...
Бәйрәмең белән котлыйбыз
сине, «Казан утлары»!

Инде көннәр туды кебек,
шулай булсын, йә хода!
Синдә безнең иҗатларның
башы да, ахыры да...

Син барында без булырбыз,
яшә син бездән соң да;
мәңгелек яшәү уты бул
күзебез карасында.

**Татарстан язучылары.**




# ГӨРЛӘП ҮТТЕ

ТАНТАНАЛЫ КИЧӘДӘН РЕПОРТАЖ


Кадерле укучылар!

«Казан утлары» журналының 70 еллык юбилеена багышлап чыгарылган бишенче санын (№ 5, 1992) май аенда алып укыдыгыз, журнал узган катлаулы тарихи юл, әдәбиятыбыз үсешендә ул уйнаган роль, татар әдипләренең иң күркәм әсәрләрен дөньяга танытуда керткән өлеше хакында мәгълүмат алдыгыз, юбилеебызны зурлап Татарстан Республикасының газета-журналлары дистәләгән мәкаләләр бирде, радио һәм телевидение махсус тапшырулар оештырды. Журналыбызда төрле-төрле истәлекләр басылды. Шулай ук журналда бик күп күренекле мөхтәрәм шәхесләрнең истәлекләре, котлаутеләкләре басылды. Шул исәптән чит илләрдән (Америка, Алмания, Төркия, Финляндия һ. б.), Бәйсез Дәүләтләр Берләшмәсе илләреннән, күрше тугандаш республикалардан да котлаулар күп иде. Мең-мең рәхмәт аларга!

Бу сәхифәләрдә без журналның 70 еллыгына багышланган тантаналы кичәнең ничегрәк узуы турында язарга булдык. Безнең бәйрәм, мәгълүм булганча, Казанда беренче тапкыр уздырылган Бөтендөнья татар конгрессы көннәренә туры килде. Алай гына да түгел, журналның житмеш еллык тантанасы Конгресның эш программасына кертелде һәм бу олуг вакыйга менә шушы безнең әдәби-музыкаль кичә белән башланып та китте. Шунлыктан бәйрәмебезгә дөньяның һәр тарафында яшәүче иң могътәбәр милләттәшләребез кунак булып килде. 18 июньдә үткән ул кичәдә Г. Камал исемендәге мәшһүр театрыбыз бинасында басып торырга да урын юк иде. Әмма тарсынучылар булмады. Һәр кайттадан жыелган канкардәшләрнең йөзендә елмаю балкый, һәр тарафта — чәчәкләр, чәчәкләр, телләрдә исә — бер-берен котлау, тәбрикләү сүзләре. Җаннарда шатлык, тантана, горурлык хисләре тулган!

Кичәне Татарстан Республикасының премьер-министры урынбасары, Татарстан фәннәр академиясенең президенты, академик **Мансур Хәсәнов** ачып җибәрде.

— Хөрмәтле иптәшләр! Ханымнар һәм әфәнделәр! — дип мөрәҗәгать итте академик залдагы кунакларга. — Иң элек, сүземне башлаганда ук, суверен Та-



# БЕЗНЕҢ БӘЙРӘМНӘР

тарстан Республикасы хөкүмәте исеменнән сезнең барчагызны да әдәбиятыбызның йөзек кашы булган зур журналыбыз — «Казан утлары»ның 70 еллык юбилее белән кайнар котларга рөхсәт итегез!

Язгы эшләрдән бушагач, татар халкының иркенләп, матур итеп бер бәйрәм үткәрүе — Сабан туйларын шаулатуы — якын һәм ерак күршеләребезгә дә, бүтән милләт кешеләренә дә яхшы мәгълүм. Татар җаны бу көннәрдә ил күгендә гүя салават күпере булып балкый!

Татар кешесе Сабан туен салкын кыштан һәм авыр язгы кыр эшләреннән соң бәйрәм итсә, тулаем татар милләте исә, гаять тә «салкын» чорларны һәм җепшек елларны исән-имин уздырганнан соң, үз язмышындагы Олы Сабан Туен бәйрәм итә түгелме соң бу көннәрдә?!!

Әйе, безнең бу бәйрәмнәребез бик тә символик мәгънәгә ия.

Ә инде «Казан утлары» юбилееның әнә шул бәйрәмнәр чорына туры килүе, шулар белән тоташып, ялганып китүе — тагын да мәгънәлерәк, тагын да күркәмрәк күренеш! Чөнки ул үзенең 70 еллык гомерен тулысынча ил белән, халык белән бергә үтте. Авыр еллар газабын да бүлеште, имин еллар бәхетен дә милләт белән бергә татыды.

Ә менә Бөек Ватан сугышы чорында, илнең байтак басмалары ябылып беткән вакытта, безнең «Казан утлары»ның чыгудан тукталмавы — бусы бүген аеруча горурланып әйтерлек күренеш. Инде журналның эчтәлегенә килсәк, аны чын мәгънәсендә татар тормышының энциклопедиясе дип әйтергә була. Моңарчы халыктан яшерелеп килгән Болгар һәм Казан ханлыкларының тарихы да шушы журнал аша укучыларга ирешә. Әдәбиятның зурлыгын, димәк, халыкның да зурлыгын билгеләгән һәм моннан 800 ел элек язылган «Йосыф — Зөләйха» кыйссасы да шушында басылды.

Кара көчләр тарафыннан тыелган данлыклы «Идегәй»не дә халыкка «Казан утлары» кайтарып бирде.

Журнал үзенең төп вазыйфасын — татар әдипләренең әле табадан гына төшкән өр-яңа әсәрләрен заман укучысына җиткерүне бигрәк тә уңышлы башкара. Журналның 70 ел эчендә дөнья күргән 835 санында үлемсез әсәрләрне — вакыт узган саен идея-эстетик эчтәлегенең зурлыгы һәм тирәнлеге тагын да ачыграк аңлашыла барган чын әдәбият әсәрләрен без бик күп күрәбез.

Җыйнап кына әйткәндә, әгәр дә бүген дөнья буйлап сибелгән, чәчелгән татар халкы үзенең Мәккәсе булган Казанга тартылып яши икән — аларда бу хисне, бу омтылышны булдыруда, тәрбияләүдә «Казан утлары»ның өлеше бик тә зур! Бигредә безнең «Казан утлары» көчле балкымаса, читтәге миллионлаган милләттәшләребезнең йөрәге, бәлки, алай ук җирсемәс һәм туган якны алай ук сагынмас та иде.
Бәйрәм уңае белән журналга, аның күп санлы авторларына һәм редакция хезмәткәрләренә, шулай ук меңләгән укучыларына зур уңышлар телим. Үзегезнең олы, изге юлыгыздан баруны дәвам итегез! Авыр һәм буталчык еллар сезне куркытмасын! Халык иманы сезгә гомерлек юлдаш булсын!
Әй Татарстан хөкүмәте милләтнең тарихи журналын ярдәменнән ташламас!

* * *

Шушы кереш сүзеннән соң Мансур Хәсәнов, тантананы дәвам иттереп, сүзне журналның баш мөхәррире, Татарстанның халык депутаты, шагыйрь Равил Фәйзуллинга бирде. Баш мөхәррир кунакларны журналның тарихы, бүгенгесе һәм киләчәккә планнары белән таныштырды. Шушы кыскача докладтан соң кичәне **Равил Фәйзуллин** алып барды. Ул түбәндәге иптәшләргә сүз бирде.

**Зилә Вәлиева,** Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисенең беренче урынбасары.

— Кадерле милләттәшләр! Мин татар халкындагы ин күркәм гадәтләренең берсен искә төшерер идем: бездә, кунаклар килер алдыннан, өйләрне бик матурлап бизиләр, иң тансык ризыкларны пешерәләр, иң матур киемнәрне киялар. Бу кичәдә әлеге сыйфатны искә төшерүем тикмәгә түгел. «Казан утлары»ның юбилей тантанасын бик-бик ерактан килгән кадерле кунакларыбызга тәкъдим итәбез икән, димәк, бу нииндидер датаны чираттагыча билгеләп үтү генә булып калмый инде. Бу — татар халкының республикакүләм көтеп алынган тансык бәйрәме, дигән сүз. Журнал 70 ел буена республикада рухи тәрбия, эстетик тәрбия ролен үтәп килде, язучыларыбыз өчен исә ул — әдәби көч сынашу мәйданы һәм сәяси чыгышлар трибунасы. Дөрес, хәзерге вакытта янадан-яңа газета-журналлар ачылып тора, әмма моңа карап кына «Казан утлары» журналының кыйммәте һич тә кимеми, киресенчә, яңа басмаларга үрнәк булып, аңа тартылу көче арта бара.
Мин журналның киләчәктә дә шушы әйдәп баручанлыгын саклавын, янадан-яңа уңышларга ирешүен телим. Укучыларына, авторларына һәм хезмәткәрләренә иҗади ачышлар, сәламәтлек, зур бәхетләр юлдаш булсын! Беләм: барлык басмалар кебек үк «Казан утлары» бу дәвердә матди кытлык кичерә. Татарстан хөкүмәте белән бергә Республика Югары Советы аларга һәръяклап ярдәм итәргә тырыша. Мин ышанам: кыенлыклар үтәр, без бергәләп аларны җиңәрбез. «Казан утлары» мәңге сүнмәс, тагын да яктырак балкып, республикабызның алга, тулы мөстәкыйльлеккә бару юлын яктыртыр. Бу талантлы колектив исән-имин эшләгәндә, башкача булуы мөмкин дә түгел.
Шул кыска гына чыгышымда мин әлеге теләкләрне җиткереп, чәчәкләр тапшырасым килде. Рәхим итеп кабул кылсагыз иде!
Инде рәсми төстә тапшырылырга тиешле бүләкләргә күчәм. Республикабыз Президенты «Казан утлары» журналы редакциясе коллективын «Мактау грамотасы» белән бүләкли. Моннан тыш журналның бүлек мөхәррире Шамил Маннапов һәм баш мөхәррир урынбасары Рашат Низамиевка Татарстан Җөмһүриятенең атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем бирелде. Мин бөтен коллективны бу бүләкләр белән ихлас күңелдән котлыйм!

**Әхмәт Галиев,** Казан компрессорлар заводы директоры.

— Хөрмәтле кардәшләр! Бүген бирегә татар халкының милләткә тугры, иманлы вәкилләре җыелды. «Казан утлары» редакциясенә безнең Хезмәт Кызыл Байрагы орденлы заводыбызның меңнәрчә милләттәшләре махсус котлау язып җибәрделәр. Анда язылганча, журнал җир шарының барлык континентларына барып житә. Димәк, ул барлык илләрдәге милләттәшләребезгә зур рухи-тәрбияви хезмәт күрсәтә. Без озак еллар буе милли рухыбызның хәлен шул журнал битләреннән белеп килдек. Халкыбыз хәле дә, республикабыз хәле дә анда чагылыш тапты. Илдә золым һәм ялган хөкем сөргәндә дә, бу журнал кешеләре-

бездә иман саклануга ярдәм итте. Шуларның барысы өчен дә журнал хезмәткәрләренә зур рәхмәт! Бүген һәм алдагы көннәрдә дә журнал милли бердәмлегебезне ныгытуга ярдәм итәр дип ышанабыз.

Без гаиләдә дә бу тантананы көтеп алдык. Хәтта журналга багышлап шигырь дә чыгардык. Аның соңгы юллары: «... Сүнә күрмә, «Казан утлары», Мәңге яшә, «Казан утлары»!» — дип тәмамлана.

Завод колективы исә, матди хәлен бераз җиңеләйтү теләге белән журналның банктагы исәп-хисап кассасына 20 мең сум акча күчерергә булды. Котлау сүзләрем белән бергә шул чекны да кабул итсәгез иде!

**Ринат Мөхәммәдиев,** Татарстан Язучылар берлеге рәисе.

— Хөрмәтле туганнар! Кунаклар! Әдәбият сөюче дуслар! Казанлылар, татарстанлылар һәм бик омтылып та монда килә алмый калган кардәшләр! Татар халкының иң булдыклы вәкилләре, туган туфракка җыелып, зур бәйрәмгә — Бөтендөнья татар конгрессын уздырырга әзерләнде. Шул тантананың «Казан утлары»на 70 ел тулуны билгеләүдән башланып китүе символик бәягә ия. «Казан утлары» — гади генә журнал түгел, ул, дистәләгән яңа газета-журналлар чыга башлаган бүгенге көннәрдә дә һич тоныклана алмый, чөнки аның олуг тарихы һәм якты киләчәге бар.

«Казан утлары» — әүвәл-әүвәлдән әдәби журнал, ул озак еллар буенча Татарстан Язучылар берлегенең органы булып килде. Язучыларның иң күркәм әсәрләре шушы журнал сәхифәләрендә дөнья күрә. Әлеге традиция һич бозылмыйча дәвам итә, шуңа күрә дә миңа журналның тарихы гына түгел, бүгенге чынбарлыгы тагын да әһәмиятлерәк кебек тоела. Журналның чыга башлавы 70 ел дип билгеләнә икән, бу — хакыйкатькә туры килеп бетми, бу хәл совет чынбарлыгына бәйле рәвештә генә шулай исәпләнә, чөнки татар халкы бервакытта да матур әдәбиятсыз, язма әдәбиятсыз яшәмәде. Революциядән соң да, рөхсәт бирелү белән үк, әдәби журнал дөнья күргән икән инде, бу факт үзе үк татар әдәбиятының күптәнге рухи байлыкка ия булганлыгы хакында сөйли. Менә шуңа күрә дә безнең бу журнал халыктагы милли аң үсешенә карата дошмани фикерле кешеләрнең эчен пошырып торды. Әле дә хәтердә: сиксәненче еллар башында, журналның тиражы йөз дә ун меңнән артып киткәч, КПСС Үзәк Комитетында зур тавыш чыкты, журналны пропагандалаган өчен Язучылар берлеге идарәсе рәисе Гариф Ахунов белән журналның ул чактагы баш мөхәррире Зәки Нуриңа партия тарафыннан шелтә белдерелде. Халык язмышы белән әнә ничек тыгыз бәйләнгән аның тарихы. Шуңа да без бу бәйрәмне Бөтендөнья татарлары бәйрәме, милли академиябез бәйрәме итеп үткәрәбез.

Мин ихлас күңелдән журнал коллективын Татарстан Язучылар берлеге исеменнән тәбрик итәм.

**Ренат Галиев,** «Татнефть» берләшмәсе җитәкчесе.

— Хөрмәтле иптәшләр! Хөрмәтле кунаклар!

Бүген минем дулкынлануым бик көчле, сүзләрем бик үк тигез чыкмаса, гаеп итмәссез. Безнең коллектив кадерле журналыбызга багышлап менә мондый фикерләр җиткерергә үтенде.

Хөрмәтле «Казан утлары»! Татарстан нефтьчеләре журналның чыга башлавына 70 ел тулу уңаеннан чын күңелдән сезне тәбриклиләр! Бүген дөньяның төрле якларында сибелеп яшәүче татарларның зур бәйрәме. Бу уңайдан шуны да әйтик: исеме берничә тапкыр үзгәрсә дә, журнал җитмеш ел буена үз йөзен саклап кала алды. Бу елларда дөнья күргән 835 санның һәммәсе халкыбызның шатлыгын һәм кайгысын чагылдыра, милли телнең сакчысы булганлыгын, әдәбиятыбыз үсешен тәэмин итүче икәнлеген күрсәтеп тора. Юбиляр журнал — безнең кара алтын чыгаручы меңләгән кешеләрнең көтеп ала торган кадерле кунагы, дусты һәм адашкан күңелләргә иман нуры сибүче якты йолдыз да ул.

Нефтьчеләр тормышын чагылдыручы иң яхшы әсәрләр, кагыйдә буларак, иң әүвәл «Казан утлары» битләрендә басылды һәм басыла килә. Безнең белән иңгә-иң торып иҗат итүче Әлмәт оешмасы язучыларының әсәрләрен журналда күрү — безгә икеләтә куаныч. Инде җөмһүриятебез тулы мөстәкыйльлек өчен көрәшкән бу соңгы елларда журналның тагын да активрак булачагына, үз яктысы тирәсенә барлык милләттәшләрне тагын да тыгызрак туплаячагына тулысынча ышанабыз.

Бүгенге олуг юбилее белән котлап редакция коллективына зур-зур уңышлар телибез!

*«Казан утлары» алда да һич тә киметмәс көчен!*
*Сезнең белән дуслар булу — горурлык безнең өчен!*

Кадерле дуслар! Безнең бу зур бәйрәмгә коры кул белән киләсебез килмәде, менә бу папкада 200 мең сум акчага чек та бар. Тормышта төрле чаклар була, кыен көннәрдә азрак ярдәмебез тисен, дидек. Аннары — менә ике кассеталы магнитофон бүләк итәбез, күңелегез теләгән музыканы яздырып, кирәк чакта тыңлагыз! Әсәрләрнең тагын да әйбәтрәген иҗат итәргә этәргеч булсын!

**Мостафа Өнәр,** Төркиянең Измир университеты доценты, язучы һәм тәрҗемәче.

Мөхтәрәм кардәшләрем! Төркиядә яшәүче 60 миллионлы туганнарыгыздан татарның изге бу бәйрәме көннәрендә сәлам бирәмен, котлы булсын! Татарның бу мөкатдәс көннәрендә, рөхсәт бирсәгез, мин сүзләремне татарча сөйләр идем.

Мөхтәрәм кардәшләр! Мине татарчага өйрәтә торган ике зур хәлфә булды. Берсе — «кечкенә Апуштан» татарның зуп-зур улы булып чыккан Габдулла Тукай иде. Ул егерме җиде яшьтән үлмәсләр дөньясына күчте. Зур иҗаты бу көн дә сау-сәламәт. Икенче хәлфәмнең җитмешенче туган көне бу кич уздырыла. Ул хәлфәм — «Казан утлары». Бу журнал хакында күп сүз сөйләргә мөмкин булса да, беренче итеп болай дияргә тиешмен: «Казан утлары» — бер мәктәптер, татарчаның һәм татарлыкның мәктәбе. Бу мәктәп иң авыр елларда да Америкага, Алманиягә, Япониягә, Австралиягә, Финляндиягә, Төркиягә, Себергә һәм Питерга, димәк, әйтергә кирәк — бөтен дөньяга ишек ачты, татарның, татарчаның уты җитмәгән урыннарга Казанның утларын җибәрде. Татар күңелләрен яктыртып, ялтыратып торды. Анда нәрсә язылды исә дә, ул татарчаны яшәтте. Без, төркиялеләр, шул өметтә торабыз: татарлар бу зур байлыклары рәхәтендә мәңгегә яшәсеннәр! Шул рәвештә «Казан утлары»н дөньяга күбрәк тарату мөмкинлеге артсын! Таралган һәм таратылган һәр татарга Казанның уты сибелсен! Бу журнал бәйрәм көннәрендә балкыган бүгенге утлар кебек үзенең «утларын» һаман ераккарак чәчсен! Бу эштә көчен куйган һәм киләчәктә дә тырышачак кешеләргә Төркия исеменнән рәхмәтләребезне кабул итегез!

**Мөнир Әһлиуллин,** «Ватаным Татарстан» газетасының баш мөхәррире, Татарстанның халык депутаты.

— Хөрмәтле иптәшләр! Милләттәшләр! Туганнар! Бүгенге олы бәйрәм, әлбәттә — әдипләр, язучылар, журналистлар бәйрәме генә түгел, ә бөтен халкыбызның олы бәйрәме. Моннан 75 ел элек чыга башлаган безнең газета редакциясе өчен исә ул аеруча кадерле тантана, чөнки бу олы журнал һәм безнең олы газета инде менә җитмеш елдан артык кулга-кул тотынышып, бик дустанә мөнәсәбәттә иҗат итәләр. «Казан утлары» журналы никадәр генә зур булса да безнең халыкның әдәбияты һәм сәнгате, тарихына, көнкүрешенә кагылышлы мәсьәләләр аңа гына сыеп бетә алмый, шунлыктан күп авторлар, әдипләр, язучылар үз әсәрләрен, публицистик мәкаләләрен безгә дә тәкъдим итәләр. Аларның безнең газетада басылып чыккан әсәрләрен генә аерым китаплар итеп чыгарсак, ул йөзләрчә том тәшкил итәр иде.

Икенче яктан, безнең редакциядә эшләүчеләр арасында да күп кенә язучылар, шагыйрьләр бар. Бүгенге кичәгә мин шул әдипләребез тарафыннан язылган шигырьне дә алып килдем. Шуның азагындагы:

*«... Каләмдәшләр, уртак язмыш,*
*Юллар авыр, болгавыр.*
*Илһам салсын күңелләргә*
*Җырлап ошбу самавыр!»*

— дигән юлларга өстәп, бүләк самоварыбызны кабул итегез!

**Фәрит Иделле,** «Азатлык» радиосының татар-башкорт редакциясе җитәкчесе (Алмания).

— Хөрмәтле милләттәшләрем! Өч-дүрт ел элек күз алдына да китерүе мөмкин булмаган хәлләр — мөстәкыйль Татарстан башкаласы Казанда «Азат-

лык» радиосының Мюнхеннан килгән бер хезмәткәре милләттәшләре алдында чыгыш ясый. Мондый мөмкинлек биргәнегез өчен күп рәхмәт сезгә! Без зур Конгресс алдыннан «Казан утлары»ның 70 еллыгын котлыйбыз. 70 ел — кеше өчен тулы бер гомер. Кеше гомеренең озынлыгы төрле булганы кебек матбугат органнарының да гомерләре төрлечә була. Кайберәүләр тугач ук, кайберәүләр тәпи йөри башлагач, бу дөньядан китәләр. Бу журнал исә, исеме берничә кат үзгәрсә дә, озын гомерле булып чыкты. Күз тимәсен! — дип әйтик инде. Әлбәттә, кеше гомерендәге кебек үк, журналның да гомерендә төрле дәверләр була. Тормыш ыгы-зыгылары, дөнья хәлләре кешегә ничек тәэсир итсә, аларның журналларга да тәэсире булмый калмый. Шулай, «Казан утлары» да төрле чорларда төрле давыл-бураннарда чайкалды. Анын тарихын, узган юлын сез яхшырак беләсез.

Монда мин, чит илдә яшәгән бер татар буларак, журналның минем тормышта уйнаган роленә туктап китәргә телим. Моннан берничә ел гына элек чит илдәге татарлар, автономияле республика булганнары сәбәпле, Татарстан белән Башкортстаннан газеталар алдырта алмый иде, тик журналлар алдырту мөмкинлеге генә бар иде. Менә шушы шартларда Ватанда ниләр барганлыгын, сәяси хәлләрне азмы-күпме белү «Казан утлары» аша гына мөмкин иде. Дөрес, бу да барысын да ачыктан-ачык укып белерлек барометр түгел иде. Вакыт үтү белән кеше язылганны укып кына түгел, ә язылмаганнарны аңларга өйрәнә. 60 еллар башындагы «җепшү» дәверендә журнал битләрендә кыйммәтле әсәрләр басылып чыгып калды. Әмма бу чор кыска гомерле булды. «Җепшү» дәвереннән беткәнлеге журналның эчтәлегендә сизелде. Бу да үзенә күрә бер ишарә, иҗат ирегенең чикләнгән булуын күрсәткән бер ишарә иде. Сигез-ун битлек мәкаләдә кыстырылган бер-ике җөмләне табып алу, журналның тиражы мәсьәләсе — болар алып барылган сәясәтне аңлатучы алымнар иде.

Үзгәртеп кору җилләре дә «Казан утлары» журналына бераз соңга калып килеп житте. Үткән эшкә салават. «Казан утлары» журналы хәзер күтәрергә тиешле вазифасын башкару юлына басты. Ул татар милләтенең үзанын уяту, тарихыбызны дөрес яктырту, милли рухны җанландыру, җөмһүриятебезнең мөстәкыйльлегенә ирешүгә өлеш кертү өчен тырыша.

Менә шулай, «Казан утлары» журналы бик катмарлы, борылышлар белән тулы 70 еллык юл узды. Минем шәхси теләгем шул: аның баскан юлыннан баруы, тагын да камилләшеп, чәчәк атуы, татар мәдәниятенә зур өлеш кертүе.

«Казан утлары»! 70 еллыгың котлы булсын! Иркле, мөстәкыйль Татарстанда гомерең озын булсын!

**Р и м  Г ы й н н я т у л л и н,** Үзбәкстанның мелиорация эшләре министры.

— Әссәламегаләйкем, мөхтәрәм, газиз кардәшләр! Мин башта һич тә сөйләрмен дип уйламаган идем, ләкин бәйрәмнең олуглыгын күреп, чыдый алмадым, залдан кычкырып, рөхсәт сорап алдым. Исәнмесез, туганнар! Исәнмесез, татарлар! Исәнмесез, «Казан утлары»!

Үзбәкстанда ярты миллионнан артык татарлар тора. Олуг, өлкән үзбәк халкының бәгърендә урын тапкан, җир тапкан, су тапкан ул сезнең кардәшләрегез. Без дә анда «Казан утлары»н укып торабыз. Журнал безнең өчен — Ватаныбыздан килгән нурдай. Без, татарлар, бөтен дөнья битенә йолдызлардай сибелгәнбез. Үзебезнең телебезне, үзебезнең денебезне югалтмый яшибез. Бу юлда «Казан утлары» безгә бер ярдәм бирә.

Инде ни диим?! Кеше үзенең әтисен, әнисен танымаса, аның тамыры юк, аның киләчәге юк. Без, татарлар — төрки халыклары вәкиле. Үзбәкләр дә, балкарлар да, кумыклар да тагы бик күп төркиләр — канкардәшләрбез. Әгәр дә без үзебезнең милләтне, телебезне, денебезне сакларга теләсәк, үзебезнең төркилекне онытмаска тиешбез! Безнең бу саклануга омтылыш башка һичбер халыкның иминлегенә каршы килмәс, аларның теленә, мәдәниятенә каршы килмәс. Болыннарда нинди күп төрле чәчәкләр үсә — берсе-берсенә комачауламый бит! Урманнарда ничек күп төрле агачлар үсә — бер-берсенә комачауламый бит! Әмма бер агачны киссәң, ямьсез төп башы кала. Шуның өчен, әгәр киләчәгебезне сакламакчы булсак, татарларның гына түгел, бөтен инсаниятнең имин киләчәген сакламакчы булсак, һәрбер чәчәкне, ягъни һәр халыкның мәдәниятен сакларга кирәк! Күпсанлы чәчәкләр арасында татар чәчәге дә әле мең еллар буенча күкрәп торыр. Моның өчен башка милләт белән көрәшү кирәк түгел, башка дин белән дә көрәшү кирәк түгел, тату яшәү кирәк! Һәрбер гөлгә ярдәмләшү кирәк! Бәлки, без, татарлар, бүген нәкъ менә шул ярдәмгә мохтаҗбыздыр?!

Биш йөз елдан артык, нинди кыенлыклар булуга карамастан, телебезне сакладык, мәдәниятебезне, күркәм гадәтләребезне, динебезне сакладык. Димәк, мескен халык түгелбез.

Үзбәк халкының сөекле Алишер Нәваие бар. Ул да милләтләрне аермаган, барлык кешеләрне зурлап язган. Кешеләрне татулыкка, дуслыкка бәрадәрлыкка чакырган. Мин «Казан утлары»на үзбәк халкының шул олуг улы сурәте төшерелгән келәмне бүләк кылам. Мин шулай уйлыйм: бу шәхес үзбәк халкының гына түгел, бөтен дөнья кешеләренең бөек улы, чөнки ул кешеләрне бердәмлеккә, дуслыкка чакырган.

Алкышларыгыз өчен рәхмәт! Сау булыгыз!

**Ренат Харис,** «Татарстан хәбәрләре» газетасының баш мөхәррире, шагыйрь, Татарстанның халык депутаты.

— Хөрмәтле дуслар! «Казан утлары»н инде 70 ел журнал итеп тотып торучы иң зур көч — «Казан утлары»ның укучылары. Менә мин монда ике Галиевнең күршесе булып утырам: берсе — Әхмәт абый Галиев, берсе минем адаш Ренат Галиев. Алар да, әле генә чыгыш ясаган Үзбәкстан министры да матди ярдәм вәгъдә итте. Мин, «Казан утлары»ның элеккеге баш редакторы буларак, хәзер Югары Совет газетасының баш редакторы буларак, «Казан утлары»на биш йөз мең вәгъдә итәм, әлбәттә акча түгел — у к у ч ы! Сан! Тираж! Һәрхәлдә журналның 500 мең укучысы булсын өчен тырышачакмын.

Хөрмәтле дуслар! Бүген «Казан утлары» журналының юбилее белән тагын бик зур бәйрәмнәр сериясе башланып китә. 1922 елда (әлбәттә, бу үлчәү — шартлы үлчәү) элеккеге СССРда иң беренче булып, калын журналлардан «Казан утлары» журналы чыга башлый. Аннан соң «Сибирские огни», «Полымя» һәм башкалар... Утызынчы елда — «Агыйдел», ә «Казан утлары»ннан да алдарак чыга башлаган журнал безнең элеккеге дәүләтебез территориясендә юк. Димәк, «Казан утлары» бәйрәменең дулкыны бер-бер артлы СНГда чыга торган башка калын журналларның 70 еллык бәйрәмен кузгатып җибәрәчәк.

Ни өчен калын бу журнал? Чөнки аңа җанлы романнар да сыйган, аңа бер юл белән генә аңлатып бирерлек, Әфләтун хәзрәт фәлсәфәсенә тиң халык мәкальләре дә сыйган, аңа елап, моңланып укый торган шигырьләр дә сыйган, аңа киләчәккә фараз да сыйган, аңа үткәнгә карап гыйбрәтләнү дә, киләчәккә карап өметләнү дә сыйган. Шуңа да «Казан утлары» — эчтәлеккә калын, рухка калын, дәрткә калын безнең остазыбыз.

Без «Казан утлары»н котлавыбызны үз газетабызда бастырып чыгардык. Анда мондый сүзләр дә бар иде: «Татар халкының күңелен һәрчак пакъ тоткан, йөрәген һәрчак дәртле тоткан, беләген һәрчак көчле тотарга ярдәм иткән «Казан утлары»на аның 70 еллык юбилей көнендә бер генә теләк — яшә, сөекле мәгърифәтчебез!»

**Наҗар Нәҗми,** Башкортстан республикасы шагыйре.

— Әссәләмегаләйкем, канкардәшләр! Башкортстан татарлары исеменнән һәм Бөтендөнья татар мәҗлесенә килгән делегатлар исеменнән һәм Башкортстандагы меңәрләгән «Казан утлары»н укучылар исеменнән журналның житмеш еллык яшьлеге белән котларга рөхсәт итегез!

Мин журналның юбилей санында басылып чыккан үз мәкаләмдә «Казан утлары» журналын, Татарстаннан читтә яшәүче татарлар өчен әдәбият илчесе, дип атаган идем. Аның башка әһәмиятләрен дә санап күрсәткән идем. Бүген аның тагын бер сыйфатын әйтмәкче булам. Бу — аның көрәшчәнлеге, кыюлыгы. Ни өчен шулай бәялим? Чөнки кайбер шигырь һәм поэмаларымны, Башкортстанда басыла алмаса, беренче мәртәбә «Казан утлары» дөньяга чыгарды. Шуларның берсе — «Татар теле» шигыре. Инде, журналга рәхмәт йөзеннән, мин сезгә шушы шигырьне (кеше алдында беренче мәртәбә) укып күрсәтмәкче булам. Ул шигырь 1966 елны, дөньяларның бик катмарлы чагында язылган иде. Аның шундый эпиграфы бар, анда рус шагыйре Ярослав Смеляков юллары китерелә:

*«Вы, прадеды наши,...*
*Мукою запудривши лик,*
*На мельнице русской смололи*
*Заезжий татарский язык...»*

Туган жирең — Идел буе,
Һәр телнең бар туган иле.
Туган жирең кебек назлы,
Жырдай моңлы татар теле.

Альяпкычлар бәйләсәләр,
Өзелеп тора кызлар биле.
Кызлар кебек шат чырайлы,
Ачык йөзле татар теле.

Халкың кебек уңган да син,
Хезмәттә син көне-төне,
Ир егетләреңдәй кыю,
Гайрәтле син, татар теле.

Фәннән сине аерса да
Гасырларның афәт жиле,
Аксакалларыңдай олпат,
Акыллы син, татар теле.

Яндың да син, туңдың да син,
Нишләтмәде язмыш сине?!

Дөньяда күп нәрсә күрдең,
Әй мөкатдәс Тукай теле!

Ассалар да, киссәләр дә,
Үлмәдең син, калдың тере.
Чукындырган чагында да
Чукынмадың, татар теле.

Төрмәләргә дә яптылар
Жәлил белән бергә сине.
Төрмәләрдә дә килмешәк
Булмадың син, татар теле.

Зинданнарны ярып чыктың,
Ялкынланып чыктың кире.
Хәтта фашист тегермәне
Тарталмады шунда сине.
Әй син, батыр татар теле!

Кабатланмас үткәннәрең,
Гасырларның ямән чире.
Кабатлар сине гасырлар —
Татар теле, дуслык теле!

**Роза Туфитуллова,** «Сөембикә» журналының баш мөхәррире.

— Хөерле кич, кадерле милләттәшләр!

Татар матбугаты бүген, гасыр башындагыча, янә бер күтәрелеш кичерә. Бүген без барыбыз да хак сүз әйтергә омтылабыз. Бүген андый сүзне әйтү күпкә жиңелрәк. Әмма ул сүзне ничек итеп, ни рәвешле әйтәсең бит. Жаннарга рәхәт салыпмы, әллә халкыбызга хас аерым бер итәгатьлелек беләнме? Татар халкы борын-борыннан китап сүзен изге дип кабул иткән. Бүген дә ул бездән жаннарны дәвалардай сүз көтә.

Әйе, бүген безгә кемлегебезне, бу фани дөньяга ни өчен килүебезне аңлау өчен аксакал сүзе кирәк. Һәм ул сүзне нәкъ аксакалларча иттереп «Казан утлары» әйтә.

Бүген безгә, бердәм бер көч булып туплану өчен, иҗтиһад кылу өчен, рухыбызны яңартырдай мәгърур сүз кирәк. Һәм ул сүзне аерым бер горурлык хисе белән «Казан утлары» әйтә.

Бүген безгә күңелләребезгә матурлык, яктылык иңдерердәй шигъриятле сүз кирәк. Һәм ул сүзне шигърият телендә, жаннарны кузгатырлык итеп, «Казан утлары» әйтә.

Без, «Сөембикә» журналының барлык ханым-туташлары, ир-егетләре, мөхтәрәм «Казан утлары»н, хөрмәтле каләмдәшләребезне ихлас күңелдән котларга килдек. Бәйрәмегез мөбарәк булсын, дуслар!

Бәйрәмегезгә дип алып килгән бүләгебез дә күңелегезгә хуш килер дип өметләнәбез. Ул — татарның данлыклы кызыл башлы сөлгесе. Аны «Сөембикә»нең «Казан сөлгесе» дигән конкурсына Ижау якларыннан жибәргәннәр иде. Бу сөлге белән, бәлки, татарның бер сылуы килен булып төшкәндер, бәлки, бу сөлге Сабан туе батырының биленә дә салынгандыр, шуңа да без аны, бөтен сагышмоңнары белән, сезгә бүләк итәбез. Истәлеккә генә түгел, зур мәгънә салып. Татар бүген үзенең билен турайтырга азаплана. Бирмәскә иде бит билне, егетләр! Бирмәскә!

**Миркасыйм Госманов,** язучы, академик, Казан университетының кафедра мөдире.

— Хөрмәтле рәис, кадерле, гыйззәтле кунаклар!

«Казан утлары»ның бәйрәме — бөтен татар халкының бөек бәйрәмнәренең берсе, чөнки иң авыр елларда да «тегермәнгә тартылмаган» татар теле кебек үк, татар әдәбиятын, татар сәнгатен, мәдәниятен иң авыр шартларда да саклап килде «Казан утлары». Бер-ике генә мисал китерәсем килә. Университетта эшләгәндә, кульязмалар жыю буенча, миңа элекке СССРның һәрбер почмагында диярлек булырга туры килде. Әйтик, Рязань ягыннан — Иркутскига, Кировтан — Әстерхан-Баку якларына кадәр. Шунда очраткан күпсанлы гаиләләрнең мәдәниятен, әдәбиятка мөнәсәбәтен, татарлык ничек икәнен белергә безгә берничә галәмәт ярдәм итә иде: берсе — «Казан утлары», икенчесе — «Азат хатын» (бүген-

ге — «Сөембикә») журналы. Әгәр шул журналлар алдырыла торган төбәккә туры килсәк, безнең экспедициянең юлы уңа торган иде.

Менә шуның өчен мин, төрле төбәккә сибелгән безнең халыкны берләштереп торучы «Казан утлары»на укучылар исеменнән рәхмәт әйтергә телим.

Икенчесе — менә бүгенге утырышыбыз, мәҗлесебез. Мин сәхнәдән залга карап утырып соклandым: монда Урта Азиядән килгән иптәшләр дә, Казахстан вәкилләре дә, Казан да, монда Татарстанның төрле төбәкләре, Идел буеның төрле төбәкләре, алай гына да түгел, монда — Америка да, Австралия дә, Финляндия дә, Алмания дә... Димәк, «Казан утлары» элекке СССРдагы туганнарны түгел, бөтен дөньядагы милләттәшләрне бергә туплау сәләтенә ия икән. Моның өчен тагын бер мәртәбә рәхмәт!

Өченчесе — «Казан утлары»ның баш мөхәррире дә, кичәне ачып җибәргән Мансур Хәсәнов та, бүләкләнгән кешеләр дә, алар барысы да — университетның элекке татар бүлеге, бүгенге татар филологиясе, тарихы, Көнчыгыш телләре факультетының элекке шәкертләре. Мин ышанам: «Казан утлары»нда киләчәктә дә шул безнең факультетта укып чыккан кешеләр эшләячәк. Бу исә, узганы һәм бүгенгесе генә түгел, татар халкының киләчәге белән дә безне «Казан утлары» бәйләр, дигән сүз.

Гасырыбыз башында бик күп журналлар чыккан. Бу хакта Равил әфәнде әйтеп тә кйтте. «Шура», «Аң», «Ялт-йолт»... Шуларны искә алганда, без журналның 70 еллыгын гына түгел, бик күпкә зуррак булган журналистикабыз тарихын бәйрәм итәргә хакыбыз бар. Гасыр башында чыккан журналлардан берсенең исеме бигрәк тә ошый иде. Бу — балалар журналы «Ак юл». Бу исемне мин шуңа күрә искә төшерәм: «Казан утлары»ның киләчәгенә дә ак юл теләп каласым килә!

Бүләкләр турында чыны-шаяруы белән сүзләр булды. Без дә буш куллы түгел, безнең факультет, Казан университетының татар факультеты, авторлар куячак, мәкаләләр бирәчәк. Болар инде, иптәшләр, акча белән бәһаләп бетерерлек бүләкләр түгел.

**Ф ә н д ә с  С а ф и у л л и н,** Татарстанның халык депутаты.

— Мөхтәрәм җәмәгать, кадерле кунаклар!

Мин, Югары Советыбыздагы Шәфкатьлелек комитетының рәисе буларак, шәфкатьлелек йөзеннән сүземне кыскартырга булдым. Ахырын гына әйтәм, чөнки без арыттык бугай халыкны, аннары кунакларга да сүз бирергә кирәк. Котлавымны һәм вәгъдәләремне генә әйтәм. Депутат — бай кеше түгел, журнал исәп-хисабына күчерерлек маллар юк, ләкин шуны беләм — күпме миллионнар җыйсак та, үзебезнең газета-журналларыбызны саклый торган гадел законнар кабул итеп өлгермәсәк, аларны саклау авыр булачак. Шуның өчен мин редакциягә, гадел законнарны үткәргән чакта, тикшергән чакта, армый-талмый тартышырга вәгъдә бирәм. Иншалла, нәтиҗәсе яхшы булыр, дим.

Тагын бер сүз. Журнал ул — баш мөхәррир генә түгел, мөхәррирләр, сәркатипләр, язучылар гына түгел, журналда байтак кешеләр эшли: корректорлар да, машинисткалар да бар. Алар сугыш елларында хәтта сукыр лампа яктысында эшли иде. Шуларны да искә алыйк әле! Журнал 70 ел буена алар ярдәменнән башка чыга алмас иде. Аларга да рәхмәт!

Кәрим Тинчуриннын: «... без кабызган утлар сүнмәс алар, сүнмәс алар хәтәр җилләрдә...» — дигән сүзләренә кушылып, ышанып калам. Без, өлкән буыннар кабызган утлар сүнмәс алар, шуларның бер учагы булган «Казан утлары» дөрләп янып торсын!

**А я з  Г ы й л а ж е в,** язучы.

— Туганнар! Мин, шушы форсаттан файдаланып, татар халкына мәдхия укырга җыенам. Дөрес, журналның язмышы авыр булды, татар әдәбиятының язмышы авыр булды. Әгәр ул хөр фикерләрне чыгара башласа, йә Мәскәүдән, йә Казаннан чукмар белән анын башын төеп кенә тордылар. Хәтерен жимерделәр, әдипләребезне утызынчы елларда бер кырсалар, сугыш елларында алар икенче мәртәбә, чалгы астында калып, харап булды. Ләкин журнал чыга килде. Журнал яшәде. Журнал ул — хәтәр җилләрнең уртасыннан барган очкыч кебек, әмма давылларга-җилләргә бирешмәде. Болар хак. Булды, әллә ниләр күрде безнең башлар. Әмма без монда үзебезнең татарны зур хөрмәт белән искә алыйк! Журналны әдипләр генә түгел, сәяси белгечләр генә түгел, шагыйрьләр генә дә

түгел, журналны татар(!) ясады. Татар юксынды журналны, татар яшәтте! Сугыш елларында ике, өч, дүрт мең тираж белән чыккан ул. Уйга калам кайвакыт: кемнәр язылды икән аңа? Кемнәр язылды икән шул авыр чакта журналга?! Нинди хисләр, нинди өметләр белән кулларына тоттылар икән алар безнең журналны? Ничә буын татар «Казан утлары»н үзенең канаты итеп яшәтеп килде. Шуның белән алар татарлыкларын расладылар, журналны яшәттеләр һәм үзләре дә яшәделәр.

Шул уңайдан бер хәвефле уем белән уртаклашасым килә. Бүген журналга 70 ел. Әйдәгез әле, тагын бер житмеш елга сикереп, уйлап карыйк! Алтмыш ел, илле ел... ун ел. Ун елда буыннар үзгәрә. Әйтәләр: егерме елдан соң әдәбиятта ике процентлап кына әсәрләр кала. Бүгенге татар кем ул? Нинди ул? Без бик матур, тынычландыручан сүзләрне күбрәк яратабыз. «Татар уяна», «татар йоклаган иде, хәзер уянды», дибез. Ә нинди татар уяна соң? Карт татар уянамы, әллә яшь татар да уянамы? Нигездә, канында татарлыгы калган өлкән татар уяна. Чөнки дин аның җанында азрак җылылык калдырган. Әле ул элекке замандагы шәфкатьле, игътибарлы, мәрхәмәтле, изге татарларны күреп үскән. Ә хәзерге татар ни күрә? Ул татар ун елдан соң ничек булачак? Димәк, «Казан утлары» үз өстенә әр-яна бурыч алырга тиеш: тагын ун елдан, егерме елдан соң татар нинди булыр? Бу хакта кайгырту — журнал өстендә. Ваемсыз булмыйк, гамьсез булмыйк инде! Дөнья нык өйрәтте бит. Без бер-беребезне юатырга яратабыз. Ләкин милләт язмышы юату-шомартуларга мохтаҗ түгел. Безгә еракка китеп карарга кирәк! Шундагы, ерак киләчәктәге татарны күреп эш итсәк кенә, без халыкны яшәтәчәкбез һәм милләтебезнең эзе тарихта суынмаячак!

**Хәнәфи Нәфыйков,** рәссам.

— Иптәшләр! Әле күптән түгел генә Татарстанның рәссамнар тәшкиләте төзелде. Ул Татарстан рәссамнарыныкы гына түгел, ә Бөтендөнья татар рәссамнары тәшкиләте булыр.

«Казан утлары» — безнең иң яраткан журналыбыз, шуңлыктан без, барлык татар рәссамнары исеменнән аңа менә шушы мәчет рәсемен бүләк итәргә булдык. Рәсемгә төшерелгән мәчет 70 еллык давылны кичкән. Исән калган. Ул — Карабиккол авылы мәчете. Тик аның аен төшергән булганнар. Ясап куярбыз аны! Моның белән шуны әйтәсе килә: дин безне гел изгелеккә өндәгән. «Казан утлары» өчен мин аның шул ягын истә тотарга кирәк дим. Журнал да татар халкына үзенең изге нурын чәчеп торсын!

**Хатыйп Газизов,** Татарстанның Балык Бистәсе районы администрация башлыгы, Татарстанның халык депутаты.

— Хөрмәтле иптәшләр!

Әдәбиятыбызның якты көзгесенә әверелгән «Казан утлары» халкыбызның рухи ныклыгын, батырлыгын сурәтләп, аның язмышын уртаклашып бик тә игелекле эш башкара. Яңа талантлар тәрбияләүдә дә ул үзеннән зур өлеш кертә. Журнал киләчәктә дә тормышыбызның һәрьягын тулы чагылдырган яңадан-яңа әсәрләр тудырырга ярдәм итәр дип ышанып калабыз.

Хөрмәтле Равил әфәнде!

Сезнең аша без журналның барлык мөхәррирләрен һәм башка хезмәткәрләрен 70 еллык юбилеегыз белән тәбриклибез һәм яңа уңышлар телибез. Бәйрәмнәр мөбарәк булсын, ә безнең аралар тагын да ныгыр, дуслыгыбыз көчәер, дип ышанабыз. Якташларыгыз исеменнән сезне чын күңелдән тәбриклибез!

**Сәгыйть Садри,** Австралиядәге Татар җәмгыяте рәисе.

— Әссәламегаләйкем вә рәхмәтулла вә бәрәкәт!

Кадерле туганнарым! Сезгә ерак Австралиядә яшәүче туганнарыгыздан самими сәламнәр житкерергә рөхсәт итегез! Милләтебезнең бу тантаналы көннәренә туры килгән «Казан утлары»ның туе безне тагын да илһамландыра, шатландыра. Милләтебезнең каймагы, кызыл гөлләре булган язучыларыбыз байрагыбызны 70 еллар буе үз сыйфатында саклап килде. Инде соңгы елларда, Советлар Союзында бөтен кешелекне хәйран калдырган үзгәрешләр аркасында, гайрәтле татар халкы үз Татарстанына суверенлык алды. Без ул көннәрдә, үзебез моннан еракта булсак та, бу эштә уңышлар теләп, Аллаһы тәгаләдән ярдәм

сорап гомер кичердек. Аллаһы тәгалә безне бу шатлыклы көннәргә китерде. Инде безнең алда янә дә бик зур вазифалар тора. Шулардан берсе мондый. Беләсез ки, халкыбыз ана телен югалта язды. Дин белән яшәп килгән милләтебез динсез калды. Менә бу алтын каләмле язучыларыбыз, ялкынлы сүзгә ия язучыларбыз милләтебезнең бу югалтуларын кайтарсын иде. Бу олуг вазифаларны үтәүдә без аларга батырлыклар теләп калабыз! Сталинның золымлыгы аркасында юкка чыгарылган латин хәрефләребез Татарстанның бер карары белән яңадан кайтарылсын иде һәм без Корылтайда да бу мәсьәләне күтәрәчәкбез.
Илтифатыгыз өчен рәхмәт!

**Билал Мамбет,** Симферопольдә яшәүчә кырымтатар шагыйре.

— Хөрмәтле иптәшләр! Мин бу ахшамга — кичәгә махсус әзерләнмәгән идем. Мөмкин булса, кырымтатар телендә бер-ике сүз әйтмәкчемен. Әдәби дуслык та әдәби дуслык, диләр. Казан татарлары белән Кырым татарлары арасындагы дуслык, бу ике халык күпме яшәгән булса, шулчаклы яшәгән, дәвам итә һәм дәвам итәр дә. Мисалга Исмәгыйль Гаспринский дигән безнең мәгърифәтчебезне алыйк. «Тәржеман» газетасын чыгарганда ул Казан татары Акчурингә таяна. Алар арасындагы дуслык ерак еллар буена килде.
Безнең бу ике халык бер тәкъдир белән яши. Авырлыкларда булса да, яхшылыкларда булса да. Безнең халыклар арасында килен алмакка, кияүгә чыкмакка каршылык булмады. 1944 елда безнең халык башына төшкән авыр тәкъдир һичкем башына төшмәсен! Бу елларда безнең кырымтатар әдәбияты гомумән яшәмәде. 60-70 елларда исә безнең беренче шигырьләрне басып чыгарган журнал «Казан утлары» журналы булды. Безнең классикларыбызның, шагыйрьләребезнең әсәрләре басылды ул изге сәхифәләрдә. Димәк, барлык төрки әдипләре арасында да Казан татар әдипләре безнең тәкъдирне тирәннән аңлаган.
Бүгенге бәйрәмнәрендә мин бу журнал коллективына кырымтатар язучылары һәм туган халкым исеменнән тәшәккер белдермәкчемен. Шуннан зуррак бүләгем юк. Күнелемдәге хисләрне чишәргә мөмкинлек биргәнегез өчен һәммәгезгә тәшәккеремне белдерәм!

**Зиннур Хөснияр,** «Салават күпере» журналының баш мөхәррире, язучы.

— Вакыт аз, җәмәгать, мин кыска гына әйтәм.

*Татарның җанын томалап,*
*Караңгы төшкән чакта*
*Синең нурың юл күрсәтте*
*Туп-туры кыйбла якка.*
*И мәгърур «Казан утлары»!*
*Ян тагын да яктырак!*
*Юлны упкыннар сагалый,*
*Барасы юллар ерак.*
*Күңелләр кебек җилпенә,*
*Дөрли ут. Исән, тере!*
*Бүген бер балан синең*
*Без — «Салават күпере».*

Безнең «Салават күпере» журналының юбилярга багышланган бүләген исә иң актив авторыбыз Муса Маликов тапшыра. Ул — Казан консерваториясенең махсус мәктәбе укучысы, сезгә, үзе гармунда уйнап, «Туган тел»не җырлаячак...

Күптән инде халык мәхәббәтен яулап өлгергән моңлы бала Муса Маликов җырлаганнан соң, сәхнәгә чәчәкләр яуды.
Кичәдә, әлеге чыгыш ясаучылардан тыш, сәхнәгә бик кыска тәбрик сүзе һәм истәлек бүләге тапшыру өчен каләмдәшләребездән Нур Әхмәдиев, Клара Булатова, «Шәһри Казан» газетасы баш мөхәррире урынбасары Илдус Илдарханов, «Мәгариф» журналы баш мөхәррире Фәрит Шәрифуллин да күтәрелде.
Тантаналы бүлектән соң Татар дәүләт җыр һәм бию ансамбле зур концерт күрсәтте.

Язма журнал өчен **Кояш ТИМБИКОВА** тарафыннан әзерләнде.



● Кичәбезне академик Мансур Хәсәнов ачып җибәрде.



● «Татнефть» берләшмәсе генераль директоры Ренат Галиев.



● Язучы һәм тәрҗемәче Мостафа Өнәр (Төркия.)



● Үзбәкстанның мелиорация эшләре министры Рим Гыйниятуллин Алишер Нәваи сурәте тукылган келәм бүләк итә.



● Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисенең беренче урынбасары Зилә Вәлиева журналның баш мөхәррире урынбасары Рашат Низамиевка Татарстан Җөмһүриятенең атказанган сәнгать эшлеклесе дигән мактаулы исем таныклыгы тапшыра.



● Күренекле шагыйрь Нәҗәр Нәҗми:
«Аксакалларыңдай олпат,
Акыллы син, татар теле».



● «Сөембикә» журналының баш мөхәррире Роза ханым Туфитуллова.



● «Азатлык» радиосының татар-башкорт редакциясе җитәкчесе Фәрит Иделле (Алмания).



● Татарстанның халык депутаты Фәндәс Сафиуллин: «Казан утлары» мәңге сүнмәсен, янып торсын!»



● Австралиядәге Татар җәмгыяте рәисе Сәгыйть Садри: «Сез — милләтебезнең каймагы...»



● Кичәбезне нәни җырчы Муса Маликов «Туган тел» җырын җырлап тәмамлый.

В. ЗОТОВ фотосурәтләре.

«Казан утлары» журналының 70 еллык бәйрәмен ихластан уртаклашкан милләттәшләребезгә, дус-кардәшләребезгә ихтирам вә хөрмәт белән кабатлап әйтәбез:

— Зур рәхмәт сезгә!

## ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ

# ЗАМАН СУЛЫШЫН ТОЙМАСАҢ...

ЯЗУЧЫ ҺӘМ ГАЛИМ АЛЬБЕРТ ЯХИН БЕЛӘН ӘҢГӘМӘ



*Альберт абый, Сезнең элегрәк «Чаян» журналында баш редактор булып эшләвегез әле хәзер дә күпләрнең хәтерендә. Торгынлык еллары булуга карамастан, Сез җитәкләгән басма үзенең кыюлыгы һәм кызыклы әсәрләр күплеге белән аерылып тора иде. Сезнең яңалыктан курыкмый торган тәвәккәл редактор булуыгыз турындагы сүзләр ул чакта безгә, университетта укучы яшь журналистларга да, килеп ирешә иде.*

*Университетта укыта башлагач та Сезнең яшьләргә белем бирүне заман рухына яраштыру буенча зур эксперименталь эшкә тотынуыгыз мәгълүм. Татар әдәбиятын укытуда Сез кертә башлаган яңалык әдәби җәмәгатьчелектә зур кызыксыну уятты.*

*Әңгәмәбезне шушындый сораудан башлыйк әле: бу яңалык нинди ихтыяҗдан килеп чыкты соң?*

— Заманында мин дә укучы бала идем. Иң яратмаган дәресем әдәбият булды. Һәр язучы турында бер үк нәрсә сөйләүне аңламадым да, яратмадым да. Бер заман үзем укыта башладым. Гамәлдәге дәреслекләрдән укытуның шактый ук күңелсез эш икәнлеген белдем. Шуңа күрә, яхшымы, яманмы, үземчә укыттым. Моның өчен мине һаман яманлап, орышып килделәр. «Чаян»да эшләгәндә дә ул дәреслекләр эчне пошырып торды. 70 елларны дәреслекләр турында «Кәҗә сакалын селкетә» исемле фельетон яздым. Анда бер әсәргә карата әйтелгәннәрне юри башка әсәргә каратып, бутап бирдем. Берни үзгәрмәде. Бу сүзләр, ике тамчы су кебек, бер-берсенә охшаганнар иде. Фельетон чыккач, министрлыкта зур сүз булды. «Дәреслекләрне башка авторлардан яздырырга» дигән карар кабул итепдә. Һәм аларны башка авторлар язды да. Ләкин дәреслекләрнең сыйфаты бик аз үзгәрде. Күрәсең, заманы шундый булгандыр. Мине ул вакытта да берәр дәреслек язарга кыстап йөрделәр. Баш тарттым, чөнки дәреслек язарга әзер түгел идем әле... Мин университетта әдәбият укытам. Шулай килеп чыкты инде, татар әдәбиятының бөтен чорын да укытырга туры килде. Әдәбиятның яңа теориясен өйрәнми торып, нинди дә булса яңалык кертү мөмкин түгеллеге аңлашыла иде. Шуңа күрә яңа теория өйрәндем. Ә студентлар белән мәктәпкә практикага баргач, әдәбият укытуның аяныч хәлдә булуына тагын бер мәртәбә төшендем һәм мене үзем яңа программа язарга булдым. Дәрес, башта Шәлдә һәм Казанның 10 мәктәбендә үзем укытып карадым. Балаларның белем, аны үзләштерү дәрәҗәләрен һәм психологиясен өйрәндем. Яңа программаларга конкурс игълан итепдә. Мин дә язып җибәрдем һәм беренче урынны алдым. Шуннан соң дәреслекләрнең үзен дә язарга тотындым.

*— Әдәбият укытудагы бу яңалыкның төп принциплары, ягъни нигезе нәрсәдән гыйбарәт?*

— Әдәбият укытуның ике ягы бар. Иске дәреслекләрдән укытканда укытучылар нинди генә яңа методикалардан файдалансалар да, нинди генә әсбапларны күтәреп керсәләр дә, барыбер, сыйнфый көрәш, дошманнарга нәфрәт, элеккеге тормышның яманлыгы, диннең әшәкелеге, совет тормышының матурлыгы турында сөйләргә тиеш булалар. Шуңа күрә башлап дәреслекләрнең эчтәлеген үзгәртергә кирәк иде. Мин шулай эшләдем дә. Программаны да, димәк, дәреслекләрне дә системага кордым. Система теориясе дигән фән бар. Заманында мине шуны өйрәнгән өчен генә дә гаепләп, «ул буржуаз фән өйрәнә» дип, хәтта университетның кайбер профессорлары югары оешмаларга хәтле хатлар да яздылар. Ә ул фән нибары катлаулы күренешләрне ничек өйрәнү турындагы фән иде...Әдәбият — үзе бик катлаулы күренеш. Ә аны укытуда, өстәвенә, укучы белән укытучы да катнаша. Әйтик, бер үк вакытта, бер үк дәрестә балаларны логик фикерләргә дә (югыйсә анализ ясый алмый), сәнгатьчә уйларга да, әсәрнең матурлыгын тоярга да, хиске биреләргә дә өйрәтергә кирәк. Шул катлаулы эшне ничек башкарып чыгарга? Шундый чакта система теориясе ярдәмгә килә. Минем дәреслекләр бәйләнеш табуга корылган. Әгәр дә әсәрнең эчтәлеге әсәр төзелешендә катнашкан өлешләрнең бәйләнешендә генә ачыла икән, димәк, эчтәлек табу өчен әсәрнең өлешләрен һәм алар арасындагы бәйләнешләрне табарга кирәк, дигән сүз. Ләкин әсәрне ничек итеп өлешләргә бүлергә? Бу бүленешнең иң күп кабатлана торган биш нигезе барлыгы беленде. Укучы бала шуларны өйрәнгәннән соң, теләсә нинди әсәр өстендә үзе баш ватып утыра ала. Әлеге нигезләрнең әле берсен куеп карый, әле икенчесен. Тапкач, шатлыгыннан кычкырып җибәрүен үзе дә сизми кала. Баланың шундый шатлыгына укытучы шатлана. Аннары балалар бәйләнеш төрләрен өйрәнәләр һәм шулай ук әле берсен, әле икенчесен куеп карыйлар. Шул рәвешле башта аерым әсәргә анализ ясыйлар, аннан соң әдәби төрләргә анализ ясау үзенчәлекләрен өйрәнәләр. Шундый ук юл белән аерым язучылар иҗатына бәя бирәләр. Тик хәзер өлешләр булып әсәрләр хезмәт итә. Өйрәнү объекты тагын да катлаулана төшә: әдәби чорларга да шул ук алым белән бәя бирелә. Ә өлешләрне хәзер аерым язучылар иҗаты тәшкил итә. Укучылар башта әсәр эчендәге бәйләнешләр аша эчтәлек табалар, аннан соң әсәрләр бәйләнеше аша язучы иҗатына хас эчтәлекне һәм стильне табалар. Соңыннан язучылар иҗаты арасындагы бәйләнешне табып, андагы уртак проблемаларны, темаларны чорның үзенчәлеге дип бәялиләр. Ләкин әдәбият тарихи үсештә өйрәнелә бит әле. Моның өчен өлеш итеп чорларның үзен алырга кирәк була һәм чорлар бәйләнеше табыла. Чорлар арасындагы уртак сыйфатларны мирас, дибез. Аерманы яңалык дип бәялибез. Кыскасы, яңалык — әдәбиятны катлаулы бер система итеп өйрәнүдә һәм аның системасын табуда. Күрәсез, шулай иткәндә дәрес белән дәрес һәм дәреслек белән дәреслек тыгыз бәйләнештә торалар. Һәр дәреслек алдагы ел дәреслегенең дәвамына әйләнә. Һәр дәрес алдагы дәреснең дәвамы була. Ләкин, шул ук вакытта, тәмамланган, нәтиҗәләре чыгарылган бөтенлек тә тәшкил итәләр.

Әдәбият укытуның икенче ягы — укыту методикасында. Дәреслекләрнең эчтәлеге методика төрен үзе әйтеп бирә. Класста укучы хәзер күбрәк уйларга һәм сөйләргә тиеш була. Әйтергә кирәк, бу методика укытучының эшен катлауландыра, ләкин бик кызыклы итә. Хәзер аңа кочак-кочак әсбаплар күтәреп керү хаҗәте калмый. Кеше абстракт төшенчәләр белән генә уйлый ала. Ә теләсә нинди күргәзмә предметы төшенчәне алыштырып килә һәм уйларга комачаулый башлый.

*— Шулай ук бу яңалыкның максаты турында да берничә сүз әйтеп китсәгез иде.*

— Педагогика фәнендә дәреслекләргә куелган шартларны санап тормыйм. Мин аларның барысын да үтим. Дәреслекләрдәге яңа эчтәлек, андагы система тудырган максатлар турында гына сөйлим. Берсен программада яздым. Бер балыкчы хәерчегә балык биреп китә: «Мә, тамагыңны туйдыр»,— ди. Ул көнне балыкчы ашап йоклый. Икенче көнне балыкчы берни дә бирми, ләкин хәерчегә иртән диңгез буена килергә куша һәм үзе белән алып, балык тотарга өйрәтә. Хәерче шулай итеп хәерче булуыннан туктый — көн дә тук була. Максат — үз-

баш уйларга өйрәтү. Дөрес нәтиҗәне тапкач, укучы шатлана, дидем. Үз хезмәтеңнән шатлану кешене үзен кеше итеп тоярга өйрәтә. Горур итә. Мин моны бик мөһим тәрбия юнәлеше дип исәплим. Әсәргә анализ ясаганда да укучы логик фикерләргә тиеш була. Анализ ясый — әсәрне өлешләргә тарката, охшаш өлешләрне җыя — синтез башкара, аннары гомумиләштерә. Логик фикерләү аша ул әсәрнең эчтәлеген һәм андагы матурлыкны таба. Хәтта башкалар күрмәгән эчтәлекләргә һәм матурлыкларга да тап була. Әсәргә бәяне укып чыгып та, анализсыз да биреп була, диләр. Әсәрнең исеменә карап, китапның тышына карап та бәя биреп була, билгеле. Ләкин әсәр байлыгы фәкать анализда гына ачыла. Шулай булмаса, тәнкыйтьчеләрнең кирәге дә булмас иде. Матурлыкны күрергә һәм аңа карап сокланырга өйрәтү — максатларның берсе. Әсәрнең эчтәлегендә кешеләр язмышы, кичерешләре ята. Укучы персонажлар кичерешләрен үз кичерешләре итеп кабул итәргә тиеш. Шуңа күрә дәреслекләрдә күбрәк кешеләрнең күңел дөньясы турында сөйләнә. Бала кеше игелеккә, шәфкатьлеккә, әдәпкә башкаларга теләктәш булып, персонажлар кайгысын кичереп өйрәнә. Әдәбият эчтәлегендәге әхлаккә өйрәтү — төп максатларның берсе. Аннары дәреслекләрдә иҗат дәресләре дә, гомумән иҗат эшләре дә күп. Сәнгатьчә фикерләргә әсәр төзелешен анализлап һәм үзе язып өйрәнә бала. Шулар өстенә, тагын бер бик мөһим максат — укытучыларның абруен күтәрү максаты да бар. Моңа кадәр укытучы дәреслекләрдә язганны сөйләп, укучылардан шуны кабатлатып сөйләтүче вазыйфасын гына үти иде. Хәзер ул укучыларны уйлатып кына калмый, үзе дә уйларга тиеш була. Ул балаларга китапларында юк нәрсәне эзләтә, юнәлеш бирә, өстәмә сораулар куя. Чынлап торып укытучыга әйләнә.

*— Элеккеге, ягъни традицион алымнар белән бәйләнеш ни дәрәҗәдә саклана? Без күнеккән юл бөтенләй үк алышынамы, әллә өлешчә генә үзгәрәме? Кискен үзгәреш булса, аңа психологик әзерлек соралмыймы икән?*

— Элеккеге дәреслекләрнең эчтәлеге белән яңа дәреслекләр эчтәлеге арасында бәйләнеш юк. Соравыгызны ачыклыйм, сез мәктәптә күнеккән юл бөтенләй алышына. Ләкин укыту процессы да бар бит әле. Укыту процессында бик күп кызыклы укыту алымнары туган. Аларның барсы да диярлек бик файдалылар. Аларның берсеннән дә баш тартырга кирәкми. Әйтик, дәрес буена диярлек укучыларны уйлату һәм сөйләтү алымын без уйлап чыгармадык. Мин аны уңышлы үткәрү өчен шартлар гына тудырам, ягъни уйлау өчен балага нигез бирәм. Аннары һәр укытучы яңа дәреслек материалын үзенә кулай алым белән бирә ала.

Яңа программаның концепциясе бөтенләй башка. Шуңа күрә, сез әйткәнчә, үзгәреш кискен. Укытучыларны югары уку йортларында, кызганычка каршы, үзбаш уйларга өйрәтмиләр. Кемдер, билгеле, аптырап та калачак. Ләкин заманалар үзгәрү белән әдәбият эчтәлеге дә үзгәрүен укытучылар яхшы аңлый. Хәзер аларның хәле бик авыр. Алар һаман иске дәреслекләрдән укытырга мәҗбүрләр. Шуңа күрә укытучыларга яңача укытуны үзләштерүдә ярдәмгә килергә тырышабыз да инде. Һәр дәреслек-хрестоматия өчен укытучыларга кулланма язам. Укытучы үзе шул кулланмадан өйрәнә. Анда биремнәргә соралган җавап вариантларыннан алып, өстәмә аңлатмаларга, инша темаларына, нәтиҗәләргә, хәтта дәрес планнарына кадәр язылган. Андый кулланманың булганы юк иде әле.

*— Сез үзегез дә мәктәпләрдә укытып, тәҗрибәләр үткәреп йөрисез. Ул тәҗрибәләр ниндирәк нәтиҗә бирә?*

— Мин язасы дәреслеген автор башта үзе укытып, сынап карарга тиеш, дигән фикердә торам. Югыйсә балаларның ни язганны үзләштерү дәрәҗәсен, сорауларга җавап бирә алу-алмавын ничек беләсең. Мин башта булачак дәреслек темаларын үзем укыттым, хәзер дә дәресләр бирәм. Ике мәктәптә экспериментальь классларбар. Ул классларда яңача укыту кирәклегенә тәмам ышанган, тәҗрибәле, бик яхшы укытучылар укыта. Шәле (Питрәч районы) һәм Казандагы элеккеге 10 мәктәп экспериментларны берьюлы башлап җибәрделәр. Шәле укытучысы Язилә Харисовна алдагы уку елында унынчыларны яңача укытачак. Казанда Тихния Миргалимовна, кызганычка каршы, башка гимназиягә күчте, класс алышынды. Ләкин ул башка урында да яңача укыта. Яңача укытучы башка педагоглар белән дә элемтә зур. Шулай итеп, дәреслекка

кергәнче һәр тема башта мәктәптә сынала. Эксперимент үткәрүчеләргә рәхмәтем зур. Алар миңа киңәшләре белән бик нык ярдәм итәләр. Тиешле шартлар тудырып, даими рәвештә ярдәм итеп торучы Шәле мәктәбе директоры Наил Газизовка да, җае чыкканда рәхмәт әйтеп китим әле.

Ә укыту нәтиҗәсе турында миңа әйтүе кыен. Шуны гына раслый алам, эксперимент үтүче класслар башка фәннәрдән дә әйбәт укыйлар. Шәле укучылары шигырьләр, хикәяләр язалар. Аларның иншаларын һәм әсәрләрен район газетасы даими рәвештә басып бара.

*— Яңа алымны раслаганда очраган иң зур каршылык нәрсәдә? Укучыларда? Укытучыларда? Галимнәрдә?*

— Каршылык зур дип зарланмас идем. Киресенчә, бар да ярдәм итәргә генә тора. Халык мәгариф министрлыгы хезмәткәрләре кыстый-кыстый, куалый-куалый яздыралар. Һәр яңа дәреслек белән шунда ук танышып, хуплап баралар.

Укучыларны искечә укытуга хәзер кочләп тә күчереп булмый. Мин укытучылар белән бик күп очрашуларда булдым. Араларында, бәлки, каршылар да бардыр, ләкин шушы көнгә кадәр андыйларны очраткан юк. Бар да бик кызыксыналар. Әйткәнне тизрәк язып алырга тырышалар. Бик күп һәм бик әйбәт сораулар бирәләр. Мин белгән галимнәр бар да хуплыйлар. Кызыксынып, сорашып, ярдәм итеп торалар.

*— Сезнең программа кайсы уку елыннан тормышка ашырыла башлар дип уйлыйсыз?*

— Китап булып басылып чыкканчы, бишенче, алтынчы класс дәресләре «Мәгариф» журналында басылган иде. Бик күп укытучылар шул дәресләргә нигезләнеп өч ел укыта инде. Быел бишенче класс дәреслеге һәм аңа кулланма дөнья күрде. Димәк, сентябрьдән яңача укытучылар бермә-бер артачак.

*— Сезнең яңа алым турында башка белгечләрнең фикерләре ничегрәк? Новаторлар белән консерваторлар арасында мәңге бара торган көрәш бу мәсьәләдә ни рәвешле чагыла?*

— Укытучылар әйтүенә караганда, укытучыларның белемен күтәрү институтында әдәбият укыту белән шөгыльләнүчеләр программага һәм дәреслекләргә (дәресләргә «Мәгариф» журналында чыккан дәресләргә) каршы нидер сөйләп, яңача укытмаска өндәп йөриләр. Яңага каршы кешеләрне «консерваторлар» диләр. Күрәсең, сез әйткән консерваторлар шунда оялагандыр инде.

Тагын, Сез әйткән әлеге «башка белгечләр»гә мин бер генә киңәш бирер идем. Яңа программа һәм дәреслек ошамый икән, язысыз соң! Утырыгыз да үзегез языгыз. Альтернатив дәреслек булыр. Үзләренә кирәкне укытучылар сайлап алырлар, дияр идем. Ләкин, нинди сәбәбе бардыр, каршы мәкаләләр язалар (Г. Саттаров, мәсәлән, «Социалистик Татарстан» газетасында чыккан мәкаләсендә бишенче, алтынчы класларда халык авыз иҗаты укытырга ярамый, аларга борынгы әдәбият укытырга кирәк дип яза), ләкин берсе дә дәреслек язарга утырмый. Җитмеш дәрес язуга караганда җитмеш мәкалә язу җиңелрәк, күрәсең.

*— Дәреслекләр төзү белән эш ничегрәк тора? Ул кулланмалар мәктәпкә кайчан барып җитәчәк?*

— Әйткәнемчә, бишенче класс дәреслеге һәм кулланмасы басылып чыкты. Алтынчы һәм җиденче класс дәреслекләрен, тизрәк дөнья күрсен дип, Министрлык бер китап итеп чыгарырга булды. Алары (кулланмалары белән, әлбәттә) киләсе уку елына әзер була. Хәзергә типографиядә җыелып ята. Сигезенче класс дәреслеге нәшриятта. Тугызынчы класс дәреслеген һәм кулланмасын быел җәй язып бетерәм. Ул 1994 елда чыгачак. Шулай итеп, ун белән унберенче класслар гына кала. Аларына тагын ел ярым вакыт кирәк булачак. Шулай итеп, быел бишенче класс дәреслегеннән башлап, укытучылар ел саен алдагы класс дәреслеген алып торачаклар.

*— Язучыларны яңа алым белән таныштыру, аларның фикерләрен белешү булмадымы?*

— Элегрәк яңа алым турында язучыларга берничә мәртәбә сөйләргә туры килгән иде. Программа һәм дәреслекләр эчтәлеген таныш язучылар бар да беләләр. Ә мин язучыларның шактые белән якыннан таныш.

*— Сүз уңаеннан шуны да сорап китик әле: Сезнең имла алмаштыруга карашыгыз ничек? Татар мәгарифе һәм теле авыр чор кичергәндә бу эш бик зур зыян китермәсме? Авыру кешене ялан тәпи бозга бастыру түгелме соң бу?*

— Татар имласына хәрефлар өстәргә кирәк, сүз дә юк. Ләкин, мин сезнең белән килешәм, без бу эшне эшләргә соңгарак калмадык микән. Китаплар бастыру елдан ел кими. Имла алышынганнан соң чыккан китаплар бармак белән генә санарлык булачак. Халык хәзерге хәрефләр белән басылган китапларны укуны дәвам итәчәк. Кагыйдәләр яңа, китаплар, дәреслекләр иске — тәмам буталып бетәчәкбез дип уйлыйм. Хәрефләр өстәр өчен гамәлдәге язу машинкаларының клавиатурасы җитми. Минем белүемчә, хәзер гамәлдә кырыклап машинка төре бар. Аларга махсус сегментлар ясау мөмкин түгел. Яңалары юк һәм бик кыйммәт. Димәк, күп еллар дәвамында машинкалар иске имла белән басачаклар, ә мәктәпләрдә балалар яңа кагыйдәләр өйрәнәчәкләр. Берничә хәреф өстәү — күп миллионлы акча түгү дигән сүз. Ә бит бүген безнең акча хәтта программаларга, дәреслекләргә түләү өчен дә юк. Сез беләсезме, мәктәп программасын язган авторга күпме түлиләр? 300 сум. Дәреслекләр турында әйтеп тә тормыйм. Дәреслек язып чыгару өчен әлегә автор үзе акча түләргә тиеш була. Ә без имла дибез!

*— Яңа алымга әйләнеп кайтсак, университетның үзендә ул ни дәрәҗәдә яклау таба? Ни дәрәҗәдә кулланыла?*

— Университетта яңача мин үзем укытам. Баштарак татар әдәбияты кафедрасында эшләдем. Әйткәнемчә, бер-ике укытучыны санамаганда, бу кафедра әгъзалары минем система белән шөгыльләнүгә каршы чыктылар. Төрле оешмаларга шикаятьләр яздылар. Бу методны мин аларның берсенә дә мәҗбүри такмадым. Берәүгә дә комачауламадым.

Яза бирәләр. Буржуаз фән, диләр. Шикаятьләрнең берсе үземдә дә бар... Хәзер мин методика кафедрасында эшлим. Монда эш башка. Методны бар да яклыйлар. Аеруча зур теләктәшлек күрсәтүчеләр — студентлар. Мин моңа бик шат. Яңа программа һәм дәреслекләр белән күбрәк рус әдәбият кафедрасы әгъзалары һәм тарихчы галимнәр кызыксына. Профессор Йолдыз Нигъмәтуллина, академик тарихчылар Илдус Таһиров, Рафик Нафигов, Миркасыйм Госмановлар, мәсәлән, даими рәвештә сорашып, ярдәм итеп торалар.

*— Без, ягъни әдәби журнал редакциясе, әдәбият укытудагы яңалыкны тормышка ашыруда нәрсәләр эшли алабыз икән? Үзегезнең теләкләр, тәкъдимнәрегез юкмы?*

— Бүгенге көндә укытучыларның хәле бик авыр. Яңа дәреслекләр юк, искеләрендә әлегә дә баягы партияле әдәбият, социалистик реализм да коллективлаштыру тантанасы, индустрияләштерү тантанасы, сыйнфый көрәш тә боек юлбашчылар. Алар хәтта иске программадагы «муллаларның татар хатын-кызларын изү эстетикасы» темасын да үтәргә мәҗбүрләр. Галимҗан Ибраһимовның «Тирән тамырлар»ын, Шәриф Камалның «Матур туганда»сын, Гадел Кутуйның «Тапшырылмаган хатлар»ын, Һади Такташ иҗатын, мәсәлән, укучыларга ничек аңлатырга? Журналыгызда дөрес үрнәкләре бирсәгез иде, димим. Анысы «Мәгариф» журналы эше. Ләкин язучылар иҗатын өйрәнүдә яңача караш мәсьәләсе журнал укучыларын кызыксындырырга тиеш дип уйлыйм. Әлеге әсәрләргә бирелгән бүгенге анализны укытучылар дәресләрендә бик теләп файдаланырлар иде.

**Әңгәмәне Мансур ВӘЛИЕВ алып барды.**

# ГАЯЗ ИСХАКЫЙНЫҢ ШИҺАП МӘРҖАНИ ТУРЫНДАГЫ МӘКАЛӘСЕ УҢАЕННАН

1935 елны Кытайда, Манчжуриянең Мукден шәһәрендә дөньяга сибелеп, чит илләрдә яшәүче татарларның Гомуми корылтае үткәрелә. Корылтайның төп максаты — Кытай, Япония, Корея, Финляндия, Германия, Төркия һәм башка илләргә таралган татарларның язмышы, аларны чит милли мохиттә милләт буларак эреп югалудан саклау, үзара ярдәмләшү турында сөйләшү һәм конкрет эшләр оештыру. Шушы уңай белән кабул ителгән карарларда мәктәп-мәгърифәт, матбага эшләре буенча да планнар кабул ителә. Бу Корылтайны үткәрүдә иң актив катнашучыларның берсе булган Гаяз Исхакый дөньяга таралган татарлар өчен махсус бер үзәк газета оештыруны яклап чыга. Корылтай бу газетаны ачу, аны оештыру эшләрен Г. Исхакыйга йөкли. Аның тырышлыгы белән татар сәүдәгәрләре, байлары ярдәмендә, шундый газета чыгару өчен тиз арада зур эшләр башкарыла. Һәм шул ук елны Мукденда «Милли байрак» исемле зур форматлы газета чыга да башлый. Газетаның беренче мөхәррире дә Гаяз Исхакый була. Ул 1935 елдан 1939 елның уртасына хәтле шушы эшне башкара, аның хәбәрчеләр коллективын төзи, чит илләрдә яшәүче татарлар белән элемтә урнаштыра, газетаның рухи җитәкчесе һәм аның иң актив авторы да була.

Г. Исхакый Кытайдан киткәч, газета чыгару, аның мөхәррирлек һәм башка вазифалары Ибраһим һәм Рокыя Дәүләткильдиләргә кала. Газетаның беренче көннәреннән Г. Исхакый белән эшләгән бу фидакарь җаннар — нибары ике кеше! Газетаның мөхәррире дә, әдәби хезмәткәре дә, корректорлары да... Хуҗалык эшләре — газетаны бастыру, тарату эшләре дә алар өстендә була. «Милли байрак» дигән бу газета (үземнең бер мәкаләмдә мин аны «Милли юл» газетасы белән бутаганмын. Анысын да Г. Исхакый чыгарган, ләкин ул Берлинда чыккан татарча газета) Кытайга совет гаскәрләре кергәнче, 1945 елның августына хәтле чыгып килә. 1935 елдан алып газетаның 440 саны дөнья күргән. Совет гаскәрләре Кытайга кергәч, Ибраһим белән Рокыя Дәүләткильдиләрне кулга алалар, алар совет концлагерена озатыла. Ун ел төрмә-лагерьларда газап чиккән бу фидакарь җаннар ул җәһәннәмнән исән чыгалар, хәтта күрешәләр дә. Ләкин саулыгы какшаган Ибраһим әфәнде озак яши алмый, тиздән дөнья куя. Ә Рокыя ханым, ире вафат булгач, үзенең туган ягына, Казанга кайта. Ул 1939 елга хәтле Казанда мәктәптә инглиз теле укытучысы булып эшләде һәм шул елны вафат булды. Мин Рокыя ханым белән берничә тапкыр очраштым, аның аркылы Кытай татарлары тормышы турында, шулай ук «Милли байрак» газетасы турында күп мәгълүматлар алдым. Рокыя ханым ул газетаның күп кенә илләргә таратылуы, аның сакланып калуын тәэмин итү өчен һәр чыккан санын Мисырның дәүләт китапханәсенә, Англиядәге Британ музеена, Вашингтондагы Конгресс китапханәсенә җибәреп торуларын да әйтте.

«Милли байрак» газетасы — ул чит илләрдәге татарларның язмышы, аларның тарихы, мәдәнияте, әдәбияты, икътисади хәле турында энциклопедия дияргә була. Аның битләрендә чит илләрдәге татар әдипләре, галимнәре, сәүдәгәр-эшмәкәрләре, җәмәгать эшлеклеләре, дин әһелләре милли азатлык өчен көрәш турында гаять кызыклы материаллар теркәп калдырганнар. Газета татар халкына аның милли аңын, милли телен, рухын, гореф-гадәтләрен сакларга ярдәм итүдә зур рухи көч булган.Шунысын әйтеп үтү кирәктер: татарлар XIX гасыр дәвамында чит илләргә барып урнаша башлаганнар, XIX гасырның соңгы чирегендә АКШка күчеп китеп, аның университетларында белем алган, анда сәүдә белән шөгыльләнүче милләттәшләребез аз булмаган. Ләкин алар шул ил халыклары арасында эреп беткәннәр, аларның милли эзләре юкка чыккан. Ерак Көнчыгышка барып чыккан татарлар исә югалмадылар, алай гына да түгел, алар башка чит илләрдәге татарларны саклап калуга да күп көч куйдылар. Моңа Гаяз Исхакый оештырган, чит илләргә

барып чыгып та үз милләте турында кайгырткан зыялылар, алар чыгарган газета-журналлар, китаплар, алар ачкан мәктәп-мәдрәсәләр зур ярдәм иткән. Гаяз Исхакый тәрбияләгән һәм хәзер АКШ, Финляндия, Япония, Германия кебек илләрдә яшәүче милләттәшләребез шул изге эшне үзләре дәвам итәләр, нәселләрен милләт буларак тәрбиялиләр, милли, мәдәни өлкәдә дә эшләп киләләр, безнең милли азатлыгыбыз өчен дә көрәшәләр. Әнә шул изге җаннар тырышлыгы белән безгә иң авыр елларда да хак сүз сөйләп килгән «Азатлык» радиосы ачылган иде.

Күптән түгел миңа дустым, япон профессоры Хисао Комацудан бандероль килеп төште. Анда ул үзе һәм хатыны Каурый белән бергә татар теленнән япон теленә тәрҗемә иткән Риза казый Ибраһимовның әле генә Токиода басылып чыккан «Япония сәяхәте» китабын һәм «Милли байрак» газетасының бер санын җибәргән. Дөресрәге, бу газетаның 1936 елда чыккан (15 гыйнварда) унберенче санының ксерокүчермәсе. Аның беренче битендә «Ерак Көнчыгыштагы Идел-Урал төрек-татарының атналык газетасы вә беренче Корылтайның тәрҗеман әфкаре» диелгән. Бу санда Разия Дәүләткильдинең «Шиһап хәзрәтнең тәрҗемәи хәле», Рокыя Мөхәмәдишнең (өстә искә алынган Рокыя Дәүләткильди) «Милли матбугат», Хәсән Агиның «Хайларда (шәһәрендә) рамазан бәйрәме», Г. Тукайның «Шиһап хәзрәт» исемле шигыре, татар халкы тарихы сериясеннән «Без кем?» исемле тарихи очерк (авторы күрсәтелмәгән, безнеңчә Г. Исхакый булырга тиеш), Г. Ильясның «Шанхайда (татар) балалар кичәсе» дигән һәм башка мәкаләләр бар. Шушы ук санда Гаяз Исхакыйның исеме күрсәтелгән ике мәкаләсе бар. Берсе «Урынсыз таләп» исемле, Манчжурия татарларының тормышыннан, ә икенчесе — Шиһап Мәрҗанинең тууына 120 ел тулу уңае белән язылган күләмле мәкаләсе, үзенең әйтүе буенча, Шиһап хәзрәттән ишетеп белгәннәре турында истәлек сыман язылган. Без сезгә әнә шул мәкаләне тәкъдим итәбез. (Аның текстын басуга әзерләүдә Раиф Мәрданов та катнашты, аңа рәхмәтебезне белдерәбез).

Әхмәт Таһир «Милли байрак» битләрендә Гаяз Исхакыйның зур күләмле 21 мәкаләсе басылуын яза (Мөхәммәд Аяз: һайәте вә фалате. Анкара, 1979, 117—119 бб.). Ул аларны санап та үткән. Без аларны биредә тулысынча китереп тормыйбыз, шулай да кайберләренең исемнәрен күрсәтүне кирәк саныйбыз, чөнки аларның исеменнән үк Гаяз Исхакыйның бу газетада нинди проблемалар күтәрүен яхшы күзалларга мөмкин. Менә ул мәкаләләрнең берничәсенең исемнәре: «Ерак Шәрыктәге милли агымның төп максаты вә аның юллары», «Советларның руслаштыру сәясәте», «Ерак Шәрыктә милли матбугат», «Финляндия татарлары», «Милли мәҗлеснең 20 еллыгы», «Милли мәдәни мөхтәриятның мәгънәсе нәрсә?», «Киләчәгебезнең нигезе», «Өченче юл юк», «Большевикларның динемезгә каршы золымнары», «Европаның язмышы»... Гаяз Исхакыйның мәкаләләре авторы күрсәтелмичә дә басылган, аларны барлау үзе зур тикшеренүләр сорый.

Без Гаяз Исхакыйны, нигездә, әдип буларак кына беләбез. Аның дистәләрчә газета-журналларда актив язышып килүе, дистәләрчә еллар матбугат битләрендә мәкаләләре басылуы күп укучыларга билгеле түгел. Гаяз Исхакый, классик язучы булу белән беррәттән, татар милли азатлыгы хәрәкәтенең юлбашчысы да, идеологы да, философ һәм публицист та, тарихчы һәм әдәбият белгече дә, журналист һәм мөхәррир дә... Ул шулай ук дәүләт һәм хокук буенча, икътисад һәм сәясәт буенча да яңа сүз әйткән зур фикер иясе дә... Милләтебезнең язмышы өчен янган, аның азатлыгы өчен көрәшүгә бөтен сәләтен, иҗатын, гомерен биргән баһадир ул! Безгә аны аңлап белү, аның гаять күп кырлы эшчәнлеген ачу, халыкка җиткерү өчен әле эшлисе дә эшлисе...

Биредә Гаяз Исхакыйның «Милли юл» газетасында басылган кайбер мәкаләләренең исемнәрен дә күрсәтеп үтмәкче булам. (Бу газета 1928—39 елларда Берлинда чыккан.) Менә алар: «Русиянең киләчәге», «Милләтләр хокукы һәм рус шовинизмы», «Татарстан тоташтан колхозлаштырыла», «Татарстан совет җөмһүриятенең 10 еллыгы», «Яшь буыныбызның милли тәрбиясе», «Руслар һәм казачийлар», «Совет иленең икътисади хәле», «Большевикларның соңгы уены», «Икътисади торгынлык», «Большевиклык-русчалык», «Советлар төрек халыклары өчен рус әлифбасы», Риза Фәхретдин, Г. Кариев, Г. Тукай, К. Насыйри, И. Гаспралы, Фуат Туктар, Әхмәт бай, Йосыф Акчура, Садри Максуди һәм башкалар турындагы мәкаләләр...

Безгә Гаяз Исхакыйның рухи мирасын тулысы белән күз алдына китерүе дә авыр. Чит илләрдә Гаяз Исхакый хезмәтләре басылган газета-журналлар безнең илебездә юк. Без андый чыганакларның, шул исәптән ул үзе чыгарган вакытлы матбугатның кайсы илләрдә саклануын да (әгәр сакланса) белмибез.

Аларны барларга, һич булмаса ул басмаларның ксерокүчермәләрен алдыру турында кайгыртырга бик вакыт. Еллар үтү белән алар югала баралар, онытылалар, бу — иң куркыныч нәрсә, безне хәтерсезлеккә, ярым-йорты хәтерле халыкка әй-

ләнүгә китерә. Татарстан фәннәр академиясе ачылгач, милли рухи мирасыбызны барлау-туплау, өйрәнү, басып чыгару, халыкка җиткерү — иң зарури эш. Шуңа ышанасы килә. Шундый чыганаклардан башка татар халкының тарихын да, аның әдәбияты, иҗтимагый фикерен дә дөрес, объектив язуны күз алдына китереп булмый. Җиң сызганып эшкә керешергә вакыт. Шуны аңлыйк, югыйсә соңга калуыбыз бар.

**Әбрар КӘРИМУЛЛИН,**
академик.

*19 март 1992.*

**Гаяз Исхакый**

# ШИҺАБЕТДИН ӘЛ-МӘРҖАНИ ХӘЗРӘТЛӘРЕ

**19.I.1815—18.IV.1889**


ملی بایراق
THE NATIONAL ORGAN OF IDEL-OURAL TURKO-TATARS IN THE FAR EAST
شهاب الدین المرجانی حضرتلری

Бу ел Шиһабетдин әл-Мәрҗани хәзрәтнең тууына 120 ел тулды. (Сүз 1935 ел турында бара — ред.) Шул мөнәсәбәт белә милли матбугатымыз Шиһаб хәзрәт Мәрҗанига багышлап шактый мәкаләләр язды. Аның Идел-Урал төрек-татарларның уянуында уйнаган ролен күрсәтергә теләде. Үзенең бердәнбер калган бик мәһабәтле чалмалы рәсеме белә алдыбызда басып торучы Шиһап хәзрәт Мәрҗани соң кем ул? Илебездә 10—15 меңгә саннары җиткән шундый ук муллалардан аның аермасы кайда? Аның тууын бәйрәм, үлүен матәм көне итәрлек ул нинди эшләр кылган? Нинди мирас калдырды?

Бу сөальләргә тулы җавап бирерлек Шиһап хәзрәт Мәрҗанинын йөз ел мөнәсәбәте белә Казанда анын шәкертләре тарафыннан җиде йөз битлек зур бер китап нәшер ителгән иде[1]. Вә шул китапта мәрхүмнең милли эшләребездәге вә дини сахәдәге[2] хезмәтләре белә бергә тулы тәрҗемәи хәле дә язылган. Вә анын хакында хатирәләр дә кертелгән иде. Бу китап мөһаҗирәткә[3] чыга алдымы, юкмы — мәгълүм түгел. Мәрхүм Шиһап хәзрәтнең тәрҗемәи хәле хакында тулы мәгълүмат алырга теләүчеләрне шул китапка мөрәҗәгать итәргә үтенеп, Шиһап хәзрәтнең дәвере хакында гына үземнең хәтеремдә калганнар белә генә бүлешмәкче булам.

Шиһап хәзрәт Мәрҗани Бохараның мөтәгассыйб[4] дәверендә анда тәхәссыл[5] итә. Шиһабетдин хәзрәт Мәрҗанидә уйлау, мәхкәмә[6] итү коты бик зур булганга, ул Бохарада укыган чагында ук һәрбер мәсьәлә хакында «китап шулай әйткән»,— дип кенә канәгатьләнми. Ул ник шулай әйткән? Моның сәбәбе нәрсә? Бу китапның әйткәне исламиятнең рухы белә оеша аламы? — кебек бик күп үзенә сөальдәр биреп, шуларга җавап эзләгән вә һәр бер дини мәсьәләне бик зур тикшерүләр ашасында үткәрергә тырышкан. Үзенең остазлары, сабакташлары белә шул нигездә бик күп моназарәләр[7] ясаган. Аннан шулай һәр дини мәсьәләнең төбенә төшеп житеп белергә теләве бер тарафдан үзен бик тиз шәрикләрендән[8] югары күтәргән булса, икенче яктан, һәр нәрсәгә «китап әйтә» дип ышанучы тәнкыйтьчеләрнең кәсфен бик бозган. Ул дәвердә Бохараның уку-укыту эшләрендә остазымыз мәрхүм шулай әйтә иде. Фәлән галим фәлән китабында шулай дип әйткән, монасыйф рәхмәтулла галия[9] шулай дип әйтде, төсендә фикере тәкълидчелек[10] ысулы хаким булганга, күпчелек Шиһабетдин әл-Мәрҗанинең бу җентекләнүчәнлегенә каршы булган. Мәрхүмнең шул инә белә кое казуында мөҗтәһидләр[11] остазлар олуг галимнәргә хөрмәтсезлек ясау төсен бирергә теләү вә Шиһап хәзрәтне төрле бәдмәзһәблек[12] белә гаепләүләргә кадәр барып житә.

Шиһабетдин әл-Мәрҗанинең бу тикшеренүчәнлеге иске заманның мөтәгассыйб муллаларында бик зур корал булган, иҗтиһад[13] коесы ябылган (Ягъни Коръән хәдисдән үз башыңа уйлап, төшенеп хәкемләү, фәтвалар чыгару), дигән сүзләренә барып бәрелеп, иҗтиһад ябылганмы, юкмы дигән ысуле фикъһенең[14] бер мәсьәләсе яңадан җанлана. Шиһап хәзрәт Мәрҗани иҗтиһад ябылмаган дигән фикердә булып, шул дәгъвасене бик каты исбат итәргә тырыша. Бохарада ул вакытта ук яңа могътәзилә шигый мәзһәбле[15] дигән кушаматлар тагыла. Берәүнең могътәзилә (ягъни тугры юлдан тайпылучы) шигый дип әйтү, хәзерге көндә большевикны «милләтче», «тайпылучы» дигән кебек бер зур гаеп саналганга вә бу гөнаһлар (өчен) төрмәләргә ябылганга түгел, дар агачына асылуларга да юл ачканга Шиһабетдин әл Мәрҗанинең мондагы вәзгыяте авырлашкандан авырлаша. Шуның өстенә тагы яңа бер уңайсызлык килеп чыга. Ул вакытның төрек солтаны Солтан Габделмәҗид русларның бөтен Төркестанны алып бетерергә кистереп куюларын күреп, Бохара әмиренә мәсьәләне аңлатырга бер һәйәт[16] күндерә. Ул вакытта бик котлы булган Төркиянең Төркестан химаясенә[17] рәсми юл ачар өчен бу һәйәт Бохара әмирлегенең төрек солтаннарын хәлифә итеп танып, мәсҗедләрдә солтанлар исеменә хөтбә укулары вә Бохар әмирлегенең сүздә генә булса да Төркиянең мохтар[18] бер өлкәсе икәнен игълан итүләрен мәслихәт бирәләр.

---

[1] «Мәрҗани» исемле бу җыентык 1915 елда Казанда басыла.
[2] Сахә — мәйдан.
[3] Мөһаҗирәт — эмиграция.
[4] Мөтәгассыйб — фанатик.
[5] Тәхәссыл — яшәү, белем алу.
[6] Мәхкәмә — хөкем, хөкем йорты.
[7] Моназарә — бәхәс.
[8] Шәрик — иптәш, сабакташ.
[9] Монасыйф рәхмәтулла галия — бөек гадел зат.
[10] Тәкълид — иярүче.
[11] Мөҗтәһидләр — тырышучылар.
[12] Бәдмәзһәблек — ялганлау.
[13] Иҗтиһад — тырышу.
[14] Фикъһе — ислам диненең мәсьәләләре турындагы белем.
[15] Могътәзилә шигый мәзһәбле — ислам диненән аерылып чыгу мәгънәсендә.
[16] Һәйәт — бирелә «хәбәр» мәгънәсендә.
[17] Химая — яклау.
[18] Мохтар — ирекле, азат.

Бу план бәлки ул вакытларда русларның Төркестанга җирләшүләренә бик зур шөбһә белә карауч инглиз дәүләтенең киңәше белә дә эшләнгәндер. Ләкин Бохараның сарае, хосусан, аның эшләренә хаким, диннен барышында җаһил голәмә сыйныфы Төркия хөкемәтенең шул кардәшлек хәрәкәтен Бохараны мөстәкыйль итү, әмирне тәхкыйрь[1] итү тәсен бирәләр. Шиһабетдин әл, Мәрҗани Төркестанның чыгарлык вазгыятен, гаскәри хәлне күреп Русиянең планнарына вакыйф[2] булганга Төркия һәйәтенең бу эшен зур бер дустлык, төреклек эше, мөселманлык сәясәте дип карый вә Төркия белә аңлашуның кирәклеген сөйли, аңлата. Ләкин Мәрҗани хәзрәтләрнең дошманлары бу эшне Бохараның да, әмирнең дә дәрәҗәсен төшерү, Бохара голәмәсенең дә хөрмәтен бетерү өчен эшләнгән вак мәсьәлә төсен бирәләр вә бу «килмешәк нугай»ның «Бохараи шәриф»не мыскыл итәргә теләвенә катгый чаралар алырга хөкүмәтне дәгъвәт итәләр. Шиһабетдин әл-Мәрҗанинең вә төрек һәйәтенең русның гаскәренең куәте зурлыгы хакында китергән дәлилләрене бердән җимерү өчен «Бохара мәхфүзәтин билмәлаикиһи» дигән бер җөмләне (ягъни Бохараны фәрештәләр саклыйдыр), пәйгамбәр галиәссаләмнең хәдисе кебек йөртәләр. Мең бәла белә Төркиянең һәйәте[3] башын коткарып кайтып китәләр. Шиһабетдин әл-Мәрҗани Бохарадан качарга мәҗбүр була. Ул Сәмәрканд көтепханәләрендә, Сәмәркандның иң парлак вакыты — Шаһрух-Олугбәк дәверлегендәге голәмәләрнең китапларын укып, гыйлемен күбәйтеп, күз карашын киңәйтеп туган иле Казанга кайта (1849 ел). Ул дәвердә Казанның сәүдәгәрләр сыйныфы шактый котлы була. Голәмә сыйныфы Бохараның тәкълидчелегенең шәкердләре булалар. Казанда иң сүзе үтә торган бай ул вакыт үзен Озын Ибрай кушаматы белә таныткан Ибраһим бай Юнысов була. Ул вакытдагы гадәт буенча Бохарадан яңа кайткан дамелланы сынар өчен, аның гыйлемен белү өчен Казан байлары берсе артлы берсе голәмәләр мәҗлесе ясыйлар вә шунда яңа дамелладан, Шиһабетдин әл-Мәрҗанидән сүз соратып моназарәләр кыйлдыралар. Шул моназарәләрдә өстен чыгуын күреп йорты башкаларныкындан зур булсын, аты башка байларныкындан юртак булсын, сүз башкаларныкындан өстен йөрсен, дигән табигатьтә булган Озын Ибрай, муллам да башка муллалардан галим булсын, дип Шиһап хәзрәтне үз мәхәлләләренә имам, мөдәррис итеп ала. Вә аңарга мәдрәсә салдырып бирә. Шиһап хәзрәт имам булып дәрес әйтергә тотыну дәресләрен үзе дөрест дип тапкан тәнкыйть ысулыннан җентекләү юлында алып бара. Бик тиз аның шөһрәте таралып, мәдрәсәсенә йөзләп шәкерд тула. Вә шул нисбәттә аның дошманнары күбәя. Озын Ибрай, бай булгач ни кыйланса да ярый, дигән бер байгура булганга, Шиһап хәзрәткә сәдакага кызыгып йөри торган бар муллага кыйла торган бөтен ваклыкларын кыйлдырмакчы була. Вә аны минем мәдрәсәдә торасың, минем мәхәлләмдә имам буласың, минем акчамны ашыйсың, дип үзенә сәҗдә[4] кылдырырга маташа. Шиһап хәзрәт Казан муллаларының байлар алдында хезмәтие кеби кыйлануларындан хурланып әһел голәмәнең хөрмәте, дәрәҗәсене күтәрү вакыты җиткәнлеге фикерендә була. Ул вакытларда бик күп була торган мәҗлесләрдә голамәләр табынын көрпәләр җәеп идәнгә ясау, байлар табынын, аяк бөкләп утыру уңайсыз, дип өстәл тирәсенә корулар гадәт була. Голамәләрнең мәҗлескә алдан килеп байларның килүен көтеп тору да гомуми бер хакәм[5] халенә кергән була. Кайсы бай ни кадәр озак көттерсә, шул бай иң шәбе саналган. Голамәләр берничәшәр сәгать шул байгураларны көтеп торырга мәҗбүр булалар. Һәр эштә беренче булырга теләгән Озын Ибрай да иң көттерүче була. Шиһап хәзрәт беренче мәҗлестә үк байларга корылган өстәл табынына барып утыра. Хуҗаның: «Хәзрәт, голамәи табыны идәндә», диюенә «байларның аяк астына тезләнеп утырырга голамә байларның хезмәтчесеме?» — дип җавап бирә дә шул өйнең иң түр мәҗлесенә утыруны гадәткә кертә. Байларны көтүгә дә разый булмый. Минем дәресем бар, минем мәхәллә хезмәтем бар, эшегез булса бирегез, дип кысрыклый, вакытында килмәгәннәрне көтмәүне гадәт итдерә. Дәрес вакытында һичбер мәҗлескә бармый. Боларның барысы Казанның иске байларына, Озын Ибрайга бер дә ошамый. Ул Шиһап хәзрәтне үзенең кәефенә баглы тотмакчы була. Вакытлы-вакытсыз аны ашка чакыра. Мәдрәсәгә керә, дәресенә катнаша, моны укытма, фәлӘнне укыт, диеп, үзе белмәгән эшләр белән Шиһап хәзрәтнең башын

---

[1] Тәхкыйрь — хур итү, мыскыллау.
[2] Вакыйф — үзгәрешсез.
[3] Һәйәт — биредә «комиссия», «бер төркем» мәгънәсендә.
[4] Сәҗдә — баш ию.
[5] Хакәм — кагыйдә, норма.

катыра. Табигый, төрле тарафдан муллалар да бик күп коткы тараталар. Шиһап хәзрәт белә Озын Ибрай арасы ачыла.

Шиһап хәзрәт Озын Ибрай салган мәдрәсәне бөтен шәкердләре белә бергә ташлап чыга. Озын Ибрайның мәдрәсәсе буш кала. Мәрҗани үзенә хәзерге «Шиһап хәзрәт мәдрәсәсе» дигән мәдрәсә салып, дәресен дәвам итә. Ләкин Озын Ибрай вә аның янындагы коткычылар бу эшкә көфранә нигъмәт[1] төсен бирел Озын Ибрайга үч алырга юл ачалар. Шиһап хәзрәтне гаепмиләр. Губернатор фәлән белә дуслыгыдан файдаланып, Озын Ибрай Шиһап хәзрәтнең указын алдырта. Ләкин боларның берсе дә Шиһап хәзрәтнең дәрәҗәсен төшерми, эшендән дә туктата алмый. Ул һаман голамә хезмәтендә дәвам итә. Ләкин аның тирә-юнендә дәрте-куәте дә өзелми. Берсе Шиһап хәзрәт шигый, ди, берсе бәдмәзһәп, ди. Шиһап хәзрәт: «Эт өрә, караван йөри», дип мәдрәсәдән башка, тарих белә дә мәшгуль була.

Ул илебезнең тарихын язарга материал җыя. Тарихи җирләребез: Болгар, Биләр харәбәләренә сәяхәтләр ясый, иске китаплар, кульъязмалар җыя. Вә шул эштә Казан дәрелфөнүне янындагы тарих җәмгыяте әгъзалары — мөстәшәрыйклар[2] белән таныша вә аларның мәҗмугаларына Болгар тарихыннан мәкаләләр бирә башлый. Шәл дәвердә төрек теленә, соңындан бик зур хезмәт иткән нимес мөстәшәрыйге Радлов Казанга мәгариф мәэмүре[3] булып җирләшә. Ул Шиһап хәзрәт белә бик тиз танышып китә вә анлардан Казан шивәсене өйрәнергә бик күп ярдәм күрә. Үз тарафыннан Шиһап хәзрәткә гарепнең тарих тикшерү хакындагы ысулларын анлата вә төрек-татарның киләчәге хакында бик күп фикер алышалар.

Казан төрек-татар уянуында шактый роль уйнаган, Казан учительски школасын ачуында (Радлов шул мәктәпне коручы һәм беренче мөдире) Шиһап хәзрәтнең киңәше, фикере бик зур роль уйный. Шиһап хәзрәт безнең голамә тормышыбызны үзгәртү рәвешен, мәдрәсәләребез, мәктәпләребезне ислах итәргә вә Европаның фәннәрен укытырга кирәк дип ышанганга, татар балаларына учительски школа ачуны сөенеч белә каршы ала вә шул мәктәптә милли, дини тәрбиясе житешкән яшьләрне укытыр өчен үзенең мәдрәсәсенең дәртле шәкердләрен школага кертә, үзе дә шул школага дин мөгаллиме булырга риза була. Идел буендагы мәгълүм мөгаллимнәрдән Шакирҗан Таһири, Шиһабетдин Газиз (календарьчы), Фасих Мөхетдин, Мөхәмәдов Шиһап хәзрәтнең шәкердләредер.

Тормышының соңгы елларында, мәдрәсәсен тәмам юлга куеп бетергәч, Шиһап хәзрәт вакытының зур өлешене китаплар язарга сарыф итә. Аның төрле шәригать мәсьәләләре хакында язган бик күп китапларыннан башка «Вафият әл-әслаф» исемендә гарәпчә алты җилдлек һәм дә «Мөстәфадел әхбәр фи әхвәле Казан вә Болгар» исемендә төрекчә тарих китаплары зур әсәрләрендәндер. «Вафиятел әслаф»нең «Мөкаддимә»се генә басылгандыр. Зур өлеше революциягә кадәр басыла алмаганы хәлдә иде. Китапның асыл нөсхәсе революциягә кадәр ышанычлы җирләрдә саклана иде, хәзере ни хәлендәдер, мәгълүм түгел. Шиһабетдин әл-Мәрҗани үзенең озын гыйльми тормышында безнең Идел буена ачык күзле, дингә тугры карый торган бик күп шәкердләр житешдерде. Үзенең рисаләләре, дәресләре, вәгазьләре белә безнең илебездә хаким булган дини тәгассыйбне[4] җимерергә зур сәбәпче булды. Фәннәрен мәктәп, мәдрәсәләребезгә кертүдә дә юлбашчы булды. Дөньяга карашыбызның үзгәрүендә, Идел буе төрек-татарның мәдәниләшүендә вә төрек-татарны мәдәни мөселман ясауда беренче баскычны атлаучы булды. Һәм тарихыбызга бик зур хезмәт куеп мәрхүм Исмәгыйль Гаспралының мәктәпләребезне ислах, тормышыбызны җәмгыятьләштерү хәрәкәтенә киң зәмин[5] хәзерләде.

Исламиятнең һәр төрле мадди, мәгънәви алга китәргә һич бер каршы түгеллеген киң катлауга анлатып, безнең иң дәверебезне башлаучысы эшне эшләде. Шиһап хәзрәт Мәрҗани исламиятне тормышка вә дөньяга уйгын бер тәгълим[6] икәнне өйрәтеп тәрәккъыйпәрвәр[7] голәмәләрнең беренче остазы булды. Үзедән соң килә торган Галимҗан хәзрәт Баруди, Риза хәзрәт Фәхретдин,

---

[1] Көфранә нигъмәт — көферлек эше.
[2] Мөстәшәрыйк — ориенталист, шәрыкче галим.
[3] Мәэмүр — чиновник.
[4] Тәгассыйб — фанатиклык.
[5] Зәмин — җирлек.
[6] Тәгълим — өйрәтү.
[7] Тәрәккъыйпәрвәр — прогресс тарафдары.

Бубилар кебек олут голамәләребезгә шул юлда хезмәт итәргә мәйдан ачты. Безнең Идел-Урал төрек-татарның милли тормышының корылуы, дин белә милләтнең бергәлеге берләшеп кулга-кул тотынып баручы милләтнең нигезендә булганга, Шиһап хәзрәт безнең милли тормышыбызның дини нигезен дә ныгытты. Милли тормышыбызның бер диварын, өстенә үскән мүкләрдән, төрле җирдә ябышкан черек-чүрәкәдән тазартды вә шулай итеп бүгенге көндә милләтебезне саклыйбыз дигән авыр эшебезнең зур бер өлешене эшләшде, җиңеләйтде. Шунарга Шиһап хәзрәт безнең милләтчелек ноктасыннан карганда ул бер адым гына, бер мөдәррис кенә, бер дин галиме генә түгелдер. Ул милләтебезне яңа нигезгә корышучы, милләтебезнең киләчәк җил-давылдан саклануы өчен, аның тамырын тазартучы — бер милли хезмәтчебездер, бер ил төзүчебездер. Шуның өчен без аның бу туган көнен бәйрәм итәбез. Шуның өчен без Шиһап хәзрәткә милләтебезне төзүчеләр, коручылар арасында зур хөрмәтле урын бирәбез.

Бүгенге көндә илебездә хаким сөргән милли, дини сәфәребездәге авыр көннәрдә вә Ерак Шәрыкда иң кирәкле милли, дини эшләребезне эшләргә, сарыф итәр өчен кыйммәтле вакытларыбызны, ахмак байгураларыбызны көйләргә сарыф итәргә мәҗбүр булуларыбыз белә аның башына килгән шул мәгънәсез байгуралар белә тартышып чагыштырып, аның бу ахмакларны җиңеп чыгуында көч алабыз вә бу көнге көнне бөтен аңлы милләтчеләребез белә бергәләп мәрхүмнең туган көнен бәйрәм иткәндә, аның милли эшенә комачаулаучы ахмаклар, җүләрләр, сатлыкларның һәрбер аңлы милләтче тарафыннан чиркәнү, рәнҗү белә хәтерләнүен күреп, безнең Ерак Шәрыкдә милли эшебезне эшләргә комачаулык эшләүче хаиннарның да, милли кәрванның көпчәгенә таяк тыгарга маташучы вак, түбән байгурачыкларның да, киләчәктә шул ук хис белә зекер итәчәкләренә ышанып мәрхүм Шиһап хәзрәтнең рухына вә ярдәмчеләрнең рухына дога кыйлабыз вә аларны милләт белә торган хәер белә зекер итәбез.

«Милли байрак» газетасы. 17.I.1936. № 11. Кытай. Мукден шәһәре.

*Мәкаләне журнал өчен академик* **Әбрар КӘРИМУЛЛИН** *әзерләде.*

## ӨЧ РЕСПУБЛИКА КИҢӘШӘ

1992 елның 19 августында Уральск шәһәрендә Казагыстан Республикасы Президенты Н. Назарбаев, Башкортстан Республикасы Югары Советы Рәисе М. Рәхимов һәм Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиевнең очрашуы булды.

Очрашу уңаеннан кабул ителгән коммюникеда, аерым алганда, түбәндәгеләр әйтелә:

«Бу республикаларның халыкларын борынгыдан ук традицион туганлык мөнәсәбәтләре, тарихи үсешләренең, мәдәниятләренең, телләренең һәм традицияләренең уртаклыгы бәйләп тора.

...Яклар мөнәсәбәтләрне суверенлыкны, рухи кыйммәтләрне һәм халыкларның милли горурлыгын үзара хөрмәт итү һәм шулай ук кеше хокукларын саклау нигезендә үстерергә теләүләре хакында белдерделәр.

...Яклар икътисади хезмәттәшлектә катнашучылар арасында турыдан-туры хезмәттәшлек итүне яклаячаклар, озак вакытка исәпләнгән нигездә ресурсларны, файдалы казылмаларны, промышленность, авыл хуҗалыгы һәм фән-техника потенциалын бергәләп файдалану өчен туры элемтәләр булдыруны һәм җитештерүдә кумәк эшләүне алга таба да үстерәчәкләр. Шулай ук яклар бер-берсенә нефть продуктлары һәм ашлык сату, урып-җыюны оештыру мәсьәләләрен хәл итүдә өлгерлек күрсәтергә булдылар.

Яклар үзләренең халыклары арасында элемтәләрне киңәйтәчәкләр, мәдәният, сәнгать, мәгариф һәм информация өлкәләрендә алмашуларны үстерәчәкләр, уку йортлары, академик һәм тармак тикшеренүләре институтлары, оешмалары арасында турыдан-туры бәйләнешләр булдырачаклар.

...Яклар ике яклы килешүләр һәм шартнамәләр төзү кирәклеген әйттеләр».

## СӨЙЛӘШҮЛӘР ДӘВАМ ИТӘ

3 һәм 4 августта Мәскәүдә Татарстан Республикасы һәм Россия Федерациясе рәсми делегацияләренең чираттагы очрашуы булды. Татарстан делегациясен җөмһүриятебез вице-президенты В. Лихачев, Россиянекен — дәүләт секретаре Г. Бурбулис җитәкләде.

Сөйләшүләр барышында Россия белән Татарстан арасындагы мөнәсәбәтләрнең принципларына һәм характерына кагылышлы мәсьәләләр каралды. Делегацияләрнең чираттагы очрашу йомгаклары буенча сөйләшүләрне яңа, югарырак дәрәҗәдә алып барырга мөмкинлек бирә торган документ эшләнде.

Яклар әлеге документта вәкаләтләрне бер-береңә бирү турындагы шартнамә булырга тиешлеген билгеләп үттеләр. Аның эчтәлеге якларның гражданнар арасында тынычлыкны, милләтләрнең килешеп яшәвен һәм халыкларның имниләген, шулай ук үзбилгеләнүгә халыкара танылган хокукларын тәэмин итә торган реаль тигез хокуклыгын гәүдәләндерергә тиеш.

Килешүдә шулай ук Татарстан Республикасының субъектлык хокукы, шул исәптән халыкара мөнәсәбәтләр өлкәсендәге субъектлык турындагы тезис анык итеп күрсәтелде.

## ПАРЛАМЕНТ ҖИТӘКЧЕЛӘРЕ ОЧРАШТЫ

13 августта Мәскәүдә Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин Россия Федерациясе Югары Советы Рәисе Р. Хасбулатов белән очрашты. Алар ике республиканың бюджет системаларын закон дәрәҗәсендә килештерү мәсьәләсе буенча сөйләштеләр. Татарстанның тәкъдимнәре аңлап каршыланды. Россия парламенты спикеры хөкүмәткә бу мәсьәлә буенча нәтиҗә әзерләргә кушты.

## ПРЕЗИДЕНТ ИЛЧЕЛӘР БЕЛӘН СӨЙЛӘШӘ

Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев Кремльдә Согуд Гарәбстанының гадәттән тыш вәкаләтле илчесе Габдел Газиз Мөхәммәд Хаҗины кабул итте.

Президент олы кунакны республикадагы иҗтимагый-сәяси һәм икътисади хәл белән таныштырды, Россия Федерациясе белән сөйләшүләрдә Татарстан җитәкчеләренең тоткан юлы турында сөйләде.

Илче Согуд Гарәбстаны короленең сәламен тапшырды һәм кунакчыл кабул итүе өчен Президентка рәхмәтен белдерде.

Татарстан Республикасы Президенты М. Шәймиев шулай ук Мәскәүдә Президент отелендә Төркия илчесе Волкан Вурал әфәнде белән дә (аның үтенече буенча) очрашты.

Бу очрашулар җөмһүриятебезнең халыкара мәйданда турыдан-туры элемтәләре ныгый һәм киңәя бару турында сөйли.

## Ф. МӨХӘММӘТШИННЫҢ ГЕРМАНИЯДӘ БУЛУЫ

Татарстан Республикасы Югары Советы Рәисе Ф. Мөхәммәтшин 20—25 июльдә Бавариянең сәүдә-промышленность палатасы чакыруы буенча Германиядә булды. Шушы визит барышында ул Мюнхенда Бавария ландтагы (парламенты) Президенты Вильгельм Вордан әфәнде белән очрашты. Әңгәмә вакытында Татарстан Республикасы белән Бавария арасында сәясәт һәм икъти-

сад өлкәсендә, парламент эшчәнлегендә үзара бәйләнеш мәсьәләләре каралды.

Очрашуда Бәйсез Дәүләтләр Берләмлегенең Мюнхендәге генераль консулы А. Петров та катнашты. Ф. Мөхәммәтшин шулай ук Бавария ландтагы утырышында да катнашты.

## ТӨРКИ ӘДӘБИЯТЛАР ФОРУМЫ

Төркиядә 20—25 майда төрки телләрендә иҗат итүче шагыйрьләрнең халыкара форумы булып узды. Аңа төрки халыклар яшәгән барлык илләрдән күренекле шагыйрьләр җыелган иде. Төркия Язучылар берлеге тарафыннан оештырылган беренче җыенда татар шагыйрьләре Равил Фәйзуллин һәм Ренат Харис катнашты. Алар Әнкара, Бурса, Конья, Истанбул шәһәрләрендә үткән шигъри кичәләрдә, митингларда, төрки телләр һәм әдәбиятларның актуаль проблемаларына багышланган конференцияләрдә чыгыш ясадылар. Төркия, Иран, Ирак, Греция, Румыния, Югославия, Болгария, Әзербәйҗан, Казагыстан, Кыргызстан, Төрекмәнстан, Молдова, Башкортостан, Кырым язучыларын татар әдәбиятының бүгенге хәле белән таныштырдылар. Аларның интервьюлары, шигырьләре Төркия матбугаты битләрендә басылып чыкты, радиодан яңгырады.

Форумда Төркия Язучылар берлеге тарафыннан Әмрә, Нәваи, Физули исемендәге халыкара премияләр булдырылды.

Икенче форумны 1994 елда Казагыстанда үткәрергә дигән карар кабул ителде.

## ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕНДӘ

Татарстан Фәннәр Академиясенең БДБ илләре һәм ерак чит илләрнең фәнни оешмалары белән элемтәләре киңәя. Күптән түгел бездә Шаньдун провинциясенең Ижтимагый фәннәр академиясе социологик тикшеренүләр институты директоры Ша-Цзин-Цюнь житәкчелегендәге Кытай галимнәре булып китте.

Татарстан Фәннәр Академиясе президенты академик М. Хәсәнов кытай коллегаларын яңа төзелгән академиянең эш планнары, җөмһүриятебездә үткәрелә торган фәнни тикшеренүләрнең төп юнәлешләре белән таныштырды. Ике академиянең үзара бәйләнештә эшләве һәм хезмәттәшлеге юллары һәм формалары турында фикер алышынды. Икътисад, философия, тарих, социология, юриспруденция, Көнчыгышны өйрәнү, этнография, милләтара мөнәсәбәтләр һәм башка гуманитар проблемалар өлкәсендә даими нигездә тикшеренүләр үткәрүне күздә тоткан беркетмәгә кул куелды. Фәнни информация алмашу, уртак фәнни хезмәтләр бастырып чыгару һ. б. мәсьәләләр дә күздә тотыла. Хезмәттәшлек турында килешү төзү максатында фәнни делегацияләр алмашу турында да килешүгә ирешелде.

## ҮЗ ФЛОТЫБЫЗ БУЛАЧАК

Билгеле булганча, Татарстан республикасы зур нефть запасларына һәм нефть химиясе продуктларына ия. Хәзер ул әлеге байлыкларның күбрәк өлешен тышкы базарда мөстәкыйль рәвештә сату мөмкинлеге ала. Шулай итеп, Республиканың үз валюта средстволары булачак. Ләкин нефтьне һәм башка продукцияне чит илләргә сату буенча тышкы сәүдә операцияләрен башкарганда, транспорт мөмкинлекләре чикләнгән булу сәбәпле, зур кыенлыклар килеп чыга.

Хәлбуки, республика нефтьне су юлы буйлап ташу мөмкинлекләрен әлегә һич тә тулы файдаланмый. Нефтьне якындагы һәм ерактагы чит илләргә үзенең нефть судолары белән ташу исә республикага бәйлелектән котылырга һәм валюта акчасының шактый өлешен янга калдырырга мөмкинлек бирәчәк.

Татарстанның нефть һәм башка продуктлар ташый торган судолар флотын булдыру идеясе әнә шулай туды. 15 августта Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетында шушы эшкә мөнәсәбәте булган җитәкчеләр һәм белгечләрнең киңәшмәсе булды. Бу киңәшмә Татарстанның үз танкер флотилиясен булдыру идеясен тормышка ашыру юлында мөһим адым булып тора.

## ҖӘЛИЛЧЕЛӘРГӘ ЧӘЧӘК

Моннан 48 ел элек фашистлар Муса Җәлил һәм аның көрәштәшләренең башларын кистеләр. Шул көнне, 25 августта, Казандагы Муса Җәлил һәйкәленә чәчәкләр салу булды. Митингны җәлилчеләрнең көрәш юлын өйрәнүче язучы Рафаэль Мостафин ачты. Чыгыш ясаучылар арасында каһарман шагыйрь хатыны Әминә Җәлил һәм фашизмга каршы көрәшкән татар легионеры Әмир Үтәшев, җәлилче легионер Ибраһим Айтанулов, француз почетлы легионеры Зыя Камалов, фашист тоткынлыгын кичергән язучы Әнәс Галиев, тоткынлыкта юк ителгән шагыйрь Рәхим Саттарның улы Ил Саттаров, Татарстан мәдәният министры урынбасары М. Низамиев, язучы Ш. Мостафин, шагыйрь Ә. Гадел, М. Җәлил музее директоры И. Минһаҗева һәм башкалар бар иде.

Соңыннан митингта катнашучылар М. Җәлил музеенда булдылар.

## МАРИ ЭЛДӘ

## ТАТАР ӘДӘБИЯТЫ АТНАЛЫГЫ

24—28 август көннәрендә Мари Эл Республикасының татарлар күп яшәгән Бәрәңге районында Татар әдәбияты атналыгы булып узды. Анда шагыйрьләр: Мөдәррис Әгъләмов, «Казан утлары» журналыннан бүлек мөхәррире Шамил Маннапов һәм прозаик Рәфкать Кәрами катнашты. Алар Портянур, Ирнур, Мазар Башы, Куян авылларының культура йортларында әдәби кичәләр уздырдылар. Бу очрашу һәм кичәләрдә Татарстан кунаклары татар әдәбиятының бүгенге торышы, республикабызның сәяси һәм мәдәни тормышы турында сөйләделәр, үз әсәрләре белән таныштырдылар, тамашачыларның күпләгән сорауларына җаваплар бирделәр.

## ХӨРМӘТЛЕ УКУЧЫЛАРЫБЫЗ!

1993 елның беренче ярты еллыгына журналыбызга язылу быелның август аеннан башланды. Искәртәбез: «Россвязьинформ» оешмасы язылуны әлегә бары тик ярты елга гына эшли. Бу хәл базар бәяләренең тотрыксызлыгыннан килеп чыга.

Бу санда без сезгә 1993 елның беренче яртысына язылу өчен әзер квитанция тәкъдим итәбез. Квитанциягә үзегездән тулы адресыгызны язып, исем-фамилиягезне күрсәтеп, өзек-өзек сызыклар буенча кисеп алыгыз һәм тиз арада элемтә бүлегенә тапшырыгыз. Бу — киләсе елда журналны өегезгә алдыруда ныклы гарантия булачак.

---

Ф. СП-1

Министерство связи СССР
„Союзпечать"

АБОНЕМЕНТ на газету/журнал 73210 (индекс издания)

"Казан утлары" (наименование издания)

Количество комплектов: I

на 1993 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| X | X | X | X | X | X | | | | | | |

Куда ________ (почтовый индекс) ________ (адрес)

Кому ________ (фамилия, инициалы)

---

ДОСТАВОЧНАЯ КАРТОЧКА

ПВ | место | литер

на газету/журнал 73210 (индекс издания)

"Казан утлары" (наименование издания)

| Стоимость | подписки | 120 руб. 00 коп. | Количество комплектов: | I |
|---|---|---|---|---|
| | переадресовки | ___ руб. ___ коп. | | |

на 1993 год по месяцам:

| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 | 10 | 11 | 12 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| X | X | X | X | X | X | | | | | | |

Куда ________ (почтовый индекс) ________ (адрес)

Кому ________ (фамилия, инициалы)

## «Казан утлары»: дуслык дәвам итсен!

Аңлашыла ки, башка газета-журналлар кебек үк, «Казан утлары» да ярым-йорты оешып килгән базар мөнәсәбәтләренең четерекле, чуалчык ятьмәсенә килеп эләкте. Басмабыз матди яктан авыр көннәр кичерә, шуңа күрә язылу бәясен шактый күтәрергә мәҗбүрбез. Бер санның хакы язылучыларга — 20 сум, ирекле сатуда килешенгәнчә булачак.

«Казан утлары» журналыннан аерылмас өчен, сезне август-сентябрь-октябрь айларыннан да калмыйча язылырга чакырабыз. Ярты еллык бәябез — 120 сум. Индексыбыз — 73210.

Дуслык дәвам итсен, милләттәшләр!

**ПРОВЕРЬТЕ ПРАВИЛЬНОСТЬ ОФОРМЛЕНИЯ АБОНЕМЕНТА!**

**На абонементе должен быть проставлен оттиск кассовой машины.**

**При оформлении подписки (переадресовки) без кассовой машины на абонементе проставляется оттиск календарного штемпеля отделения связи. В этом случае абонемент выдается подписчику с квитанцией об оплате стоимости подписки (переадресовки).**

Для оформления подписки на газету или журнал, а также для переадресования издания бланк абонемента с доставочной карточкой заполняется подписчиком чернилами, разборчиво, без сокращений, в соответствии с условиями, изложенными в каталогах Союзпечати.

Заполнение месячных клеток при переадресовании издания, а также клетки «ПВ—МЕСТО» производится работниками предприятий связи и Союзпечати.

1988 г. Обл. тип., г. Кострома, зак. 983, тир. 141.150.000

# ИЯЛӘР, АЛБАСТЫЛАР, УБЫРЛАР...

Рәссам Әхсән Фәтхетдиновның яңа әсәрләрен бергә туплаган иҗади күргәзмәсе Казанның мәдәният үзәгендә булып, тамашачылар алдында зур уңыш казанган иде.

Күргәзмә залына килеп керүгә, бер мәлгә имәнеп китәсең: сине сихри бер дөнья — ияләр, албастылар, убырлар — кыскасы, халкыбызның мәҗүсилек чорына хас сынландырылган затлар-җаннар уратып алган кебек була. Рәссам Әхсән Фәтхетдинов үз әсәрләре аша табигатьнең мәңге тере, җанлы икәнен әнә шулай сурәтләп бирә, шуны раслый һәм халык аңына кайтара. Без барыбыз да сабый чактан ук ишетеп-белеп үскән, әмма әле күз алдына китерә алмаган, дөресрәге, күзгә күренмәс рухлар, өрәкләр, җаннар чынлыкта безнең яшәешебезне чолгап алган, алар безнең арада, дип ышандыра рәссам безне.

«Ияләр», «Җаннар», «Кабер ташлары» дигән циклларга берләштерелгән әсәрләре белән Әхсән Фәтхетдинов, һичшиксез, үз иҗатында тагын да бер баскыч югары үрләде. Без инде тәмам өлгереп җиткән, зур талантка ия булган рәссамны күрәбез.

«Кабер ташлары» циклы күренекле шагыйрь Равил Фәйзуллинның шигъри юлларын шәрехләп эшләнгән.

Әхсән Фәтхетдиновның төп материалы — агач. Ул агачның «һәр күзәнәген» тоеп иҗат итә, безнең алда гади генә такта кисәге дә сынланып-җанланып, әллә нинди явыз яки изге рухларга, өрәкләргә, ияләргә әвереләләр. Шулар аша рәссам халкыбыз тормышын чагылдыра, гади җир кешесенең шатлыгын да, кайгысын да ачып сала. Адәм затының җаны теләсә кайчан теләсә кайсы әнә шул сынландырылган җаннарга күчәргә мөмкин бит. Кайсы ягы белән ачыла кеше әнә шул мизгелләрдә — аңарда изге, ак-пакь көчләр җиңәме, әллә булмаса, явыз кара көчләр өстенлек аламы? Кешенең бар асылы әнә шунда. Үзең нинди — сине озата йөрүче, бер генә мизгел дә ычкындырмаучы рухың, ияләрең дә шундый. Яхшылыкта булсын күңелең, кеше! Абзар иясеме, йорт иясеме, капка иясеме, юл иясеме — синнән гел изгелекләр генә көтә алар һәм үзләре дә игелек белән җавап кайтарачаклар.

Рәссамның әсәрләре гаҗәеп нечкә тоемланалар: алар күбесенчә безнең күзгә дә эңгер-меңгердә яки төнлә генә күренәләр, имеш. Шуңа күрә дә вакыт төшенчәсе бик шартлы биредә — әллә теге яки бу әсәрдәге сурәт кичә генә булган хәлләрне сөйли, әллә ул безгә мәңгелектән аваз сала... Белмәссең...

Без сезгә бүген Әхсән Фәтхетдиновның дистәләгән әсәрләреннән бары берсен тәкъдим итәбез. Сез аны журнал тышлыгының беренче битендә күрәсез. Ул әсәр «Тыкрык иясе» дип атала. Игътибар белән рәк карагыз әле: ул явыз да кебек, игелекле җан да шикелле. Әгәр дә кем дә кем кыек эшләр белән кыек тыкрыкларга сугылса, миннән игелек көтмәсен, мин аны адаштырачакмын, ди кебек ул. Ә инде игелекле изге җаннарны, кирәксенә, туры юлга алып чыгачагына да һич шик юк.

Менә шундый бай, гаҗәеп матур-ихлас, халкыбызның иң борынгы йола-ышанулары дөньясына алып керде безне рәссам Әхсән Фәтхетдинов. Әйтергә кирәк: бик талантлы, зур рәссам.

**Тышлыкның дүртенче битендә:** Татарстан комсомолының Муса Җәлил бүләге лауреаты, шагыйрь Ркаил Зәйдулла.

М. КОЗЛОВСКИЙ фотосурәтләре

Бәясе 1 сум 80 тиен
Индекс 73210



КАЗАН УТЛАРЫ
QAZAN UTLARI
ОГНИ КАЗАНИ

Ежемесячный литературно-художественный
и общественно-политический журнал
(на татарском языке)

Журнал включен во Всесоюзный каталог